8(057)

# казан утлары

8
АВГУСТ-1973

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**8**

АВГУСТ
1973


## Бу санда


Ш. МАННУР. Агымсуларга карап. Повесть . . . 3
И. ЮЗЕЕВ. Таш диварлар авазы. Поэма . . . . 26
Ә. ХӘКИМОВ. Очар кошлар. Повесть . . . . 45

Л. ИХСАНОВАГА 50 ЯШЬ

Л. ИХСАНОВА. Гамбәр кызы Зөлфия. Хикәя . . 116

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 122
М. МАЛИКОВА. Чәчәкләргә бай тормыш . . . . 126

Е. И. ПУГАЧЕВ ВОССТАНИЕСЕНЕҢ 200 ЕЛЛЫГЫНА

С. АЛИШЕВ. Князь Йосыф Енгалычев һәм башкалар . . . . . . . . . . . . . . . . 135

ИСТӘЛЕКЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Г. ИДЕЛЛЕ. Беренче зур сәяхәт . . . . . . . 142

М. ГАЙНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ

Н. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН. Галим, җәмәгать эшлеклесе . 156
М. ГАЙНУЛЛИН. Дөньяви әсәрләр эзеннән . . 159

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Н. ЮЗИЕВ. «Хәрәкәттәге эстетика» — хәрәкәттә . 166
Ф. МИҢНУЛЛИН. Хикәягә бер караш . . . 178

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. НӘФИКОВ. Тарихыбызның мөһим мәсьәләләре. 183
Р. АБДУЛЛИНА. Җәйләр җитсә. . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәм
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 3/V-1973 ел. Басарга кул куелды 3/VII-1973 ел. ПФ 07085. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83246 экз. Заказ Я-238. Бәясе 50 тиен.

---

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, йорт 19.

Шәйхи Маннур

# АГЫМСУЛАРГА КАРАП

ПОВЕСТЬ

## Ай югары, без түбән...

Узган саен гомер юлкаем һаман
Каерылып карыйм артыма:
Иң кадерле чаклар шунда калган
Һәм манылган бар да алтынга...
Кайгы да юк анда, хәсрәтләр дә,
Сагышлар да үзәк өзмәгән,
Күрелмәгән газап-михнәтләр дә...
Гел гизелгән зәңгәр эзләрдән.
Нигә шулар һаман сагындыра,
Ник күңелем шунда тартыла?..
Гомернең шул газиз чагын гына
Бер күрәсем килеп,
Әйләнәм дә карыйм артыма...



Карыйм да...

Төймә генә борынлы бер бәләкәй малай күрәм. Өйалды баскычыннан менеп килә ул. Күзләре дә аның орчык белән төртеп тишкәндәй генә. Шул ике ноктадан ике тамчы май шикелле күз карасы җемелдәп тора. Сабыйларча түгәрәк йөзенә бер генә чалым да сызылмаган әле ул малайның. Ник дисәң, кайгы-хәсрәт, куаныч-шатлык, бәхетле-бәхетсез дигән сүзләрнең нәрсә икәнен дә белми әле ул. Аңар әле дингез тубыктан. Ике дөнья — бер морҗа, төтене өйгә керми, күзләрен әчеттерми (Әнәе шулай ди). Тамагы тук, өсте бөтен. Рәхәт аңа! Тик шуны гына тоя ул.

Чынлап та, кемдә бар аныкы шикелле кызыл дебет белән чигелгән бик әйбәт кара-чуар итек? Атасы әллә кайдагы Ерак күмердән җибәргән бит аны! Ә кемдә бар аныкы төсле олы сәдәпле, кайтарма якалы, шулай ук читтән килгән яшел бишмәт? Алар гынамы соң әле! Ә кемдә бар аныкы шикелле әйбәт әнәй? Инде бишенче яшь белән барса да, ул аны һаман кочагында йоклата, йомшак җылы куллары белән иркәли-

иркәли, Аксак Куян белән Китек колак Йомран турында хикиятләр сөйли...

Үзе кая барса, шунда аны да житәкләп чаба торган, тырнак белән дә чиертми торган Хөршит түтәе дә бар бит әле аның! Аннары, көн озын диярлек аркаларына кочтырып, үз өйләренә алып чыга һәм, ни белән булса да сыйлап, шулай ук кочтырып кертеп куя торган күрше кызлары Нәфисәттәй белән Шәмсурыйттәйләре дә бар әле. Алар инде житкән кызлар. Кыш буе, кич саен дигәндәй, куна керәләр — әнәенә иптәшкә. Иөзлек буена тезелеп утыралар да жырлый-жырлый жеп жегерлиләр. Орчыкларын зыр-бөтереп жибәрәләр дә, идәнгә барып тигәнче сузып, кетер-кетер тәрәшле кыркалар. Күйләре дә аларның шул жеп сапламнарыдай озын була, моңлы була. Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, аның Хөршит түтәе дә каба төбенә утырган, аларга кушылып жеп сузып, жыр сузып маташа.... Ә бу малай берүзе бөтен кешегә комачау итеп чытлыклана: әнәен кочаклый, түтәенең зырлап әйләнгән орчыгын тотып ала, арттан килеп, ике кулы белән Нәфисәттәенең күзләрен томалаган була. Аннары идәнгә сикереп төшә дә, мич казнасы буенда рәхәт кенә күшәп яткан ике бәрәнне кузгатып, «төк-төк-төк!» дип, уч төбен сөздерергә маташа башлый. Аның учын сөзәм дигәндә генә тәкә бәрәннең маңгае «дөк!» итеп йөзлеккә килеп сугыла, ә шук малай кычкырып көләргә тотына.

Кызлар кич утырган көнне һич йокы керми аңа. Әнәе төрлечә жайлаган-көйләгән булып, хәтта бер шакмак шикәр дә тоттырып, тизрәк аны «нәвем базары»на озатмакчы була, ә моның күзләре, шырпы белән терәткәндәй, шар-ачык. Шәмсурыйттәе аны яклап сүз кыстыра:

— Борчымагыз инде кешене-е! Жегетме ул, түгелме? — ди.— Кызлар кич утырганда ниткән жегет йоклап ятыр, әгәр дә мәгәр эчендә жаны булса!— дип куя аннары.

Шулай утыра торгач, әтәч тавышы ишетелә.

— И-и, беренче әтәс тә житкән, карагыз әле, гүпчи жегерләп булмады бүген!— дип көяләнәләр дә тагын да кабаланыбрак тотыналар. Икенче әтәч ничектер сизелми дә кала, өченче тапкыр кычкыргач кына:

— Әтекәйләрем, беттек! Өченче әтәс түгелме соң бу?— дип каба төбеннән куба Нәфисәттәе. Шуннан барысы да дәррәү күтәрелеп, идәнсәкегә коелган талкыш-чүбекне тиз-тиз себерәләр дә олы якка түшәкястык жәяләр. Бары да шунда тезелеп ята. Кызлар аны уртага сала, ике яктан да шап-шоп сөйгән булалар. Ә ул әле, күзләре йомыла башлаган булса да, шаярудан һаман туктамый...

Кем соң бу иркә малай, бу ут борчасы, бу кыланчык, бу елак малай? Кем икән соң бу әнәе кочагында гына һәм кызлар уртасында гына ята торган бишенче яшендәге егет малай, борын асты желек малай? Ул ак жилкәнле көймә белән татлы йокы дәрьясына кереп киткәнче, белеп калырга иде бит аны, кем икән ул?..

Карыйм да... танып алам шикелле мин ул юеш борынлы егетне! Бөтен төс-бите, бөтен кыланышы минекенә охшаган сыман аның. Шул үзедер, ахры, мин дигән малайдыр инде бу!..

...Шулай рәхәт шаянлык белән кызлар уртасында йоклап китүемне сизми дә калам, иртәгесен мин уянганчы алар әллә кайчан чыгып киткән була инде. Көн бер дә әйбәт башланмый: мин әле үзе дүрт аяклы, үзе ат хәтле кыр казына атланып Каф таулары артына патша кызын эзләп очкан чакта гына түтәй килә дә борчырга тотына:

— Тор инде, тор, төш житте, самавар сүнеп бетте. Ятма сөрхәнтәй булып, үсмәссең тәтәй булып,— дип такмаклый-такмаклый мине урыннан кубарып, битне, юдыра, табынга утырта. Алдыма куелган шикәр кисәген ярты чынаякка да житкермичә, шатыр-шотыр чәйнәп бетерәм дә, тагын сорап әнәйнең желегенә тия башлыйм. Бер бирә, ике бирә дә, «бетте»,

ди. Бетмәгәнен беләм: шикәр әллә нихәтле! Әтәй читтән җибәрде, сандыкта гына ята. Ә сандык, түтәй белән икебез сыярлык олы сандык, сәке өстендә тора. Өстенә түшәк-ястык өйгәч, ул безнең өйне икегә бүлә: олы як, кече як. Шикәр шулай якында гына булсын да, түзеп тор, имеш! Һаман тыкырдатам.

— Корты бар аның,— ди әнәй аптырагач.— Тешеңне корт ашап бетерер дә әби авыз булып калырсың!..

Белеп торам: юрамалый әйтә. Бер корты да юк аның, бик тәмле! Әнәй күпме каты торса да, барыбер елап җиңәм мин аны:

— Ши-кә-әр, ши-кә-әр!..

Бу көн саен шулай була, әнәйнең үзәгенә үтеп, ачуын китереп бетерәм.

— Туктале мин сине!— диде ул бер көнне.— Ник сораганына үкенерсең!

Шуннан соң сандыкны бик матур шыңгыратып ачты да, олы бер шакмак шикәр алып, мич буеннан әйләнеп килде һәм минем кулга тоттырды. Аны-моны уйламастан, шакмакны комсызланып кабуым булды, авыз эчен яндырып та алды, ут капты мәллә дип торам. Әнәй аны калай савыттагы кап-кара борычка манып биргән икән. Тагын да әшәкерәк тавыш белән елый-елый, шикәрне идәнгә атып бәрдем, ишек катына ук тәгәрәп китте. Бер күз белән елыйм, бер күз белән шикәргә карыйм: бик җәл булып күренә, каһәр. Иәзлектән шуып төшеп, шикәрне барып алдым, күлмәк итәге белән кат-кат сөрткәләдем дә шатыр-шотыр кимерә башладым. Авызны борыч өтәли, ә шикәр барыбер тәмле.

Әнәй белән түтәй миңа карап торалар. Төсләрендә бер дә ярату күренми.

— Һай, улым,— ди әнәй зарлы тавыш белән,— аздың син, бик әшәке малайга әйләндең. Атаң өйдә булса, өйрәтерие сиңа акылны!..

Әйе шул. Мин әле дә онытмадым, былтыр җәй көне иде бугай, каяндыр түтәй белән кайтып кергән генә идек, кыздыра да башлады бу безне тал чыбыгы белән. Чыр-чыр елый-елый ишекле-түрле чабабыз, безнең арттан идән буйлап юеш эзләр генә кала. Әнәй, алъяпкыч итәген күтәреп, кече якта тора, аның да коты очкан:

— Җитәр инде, Фәрхулла, җитәр,— дип ялвара ул.

Нинди гаебебез булгандыр, анысын хәтерли алмасам да, әтәйнең «акыл өйрәтүен» искә төшерү мине мышкылдаудан туктатты. Шикәр белән эшне бетереп, урамга чыкмакчы булдым. Хөршит түтәй аякка кара-чуар итекне кигезде. Ул бик матур, бик калын, бик нык, күн итек шикелле! Аннары өскә бишмәт кидереп, башка кызыл француз яулык урады, аның өстеннән бүрек киертте. Чыгып киттем туптай тәгәрәп (әнәй шулай ди). Безнең өйалды балчык идәнле, баскычлары да балчыктан, астан өскә менмәле. Бер, ике, өч, дүрт. Көн саен шулай санап өскә менәм. Өйалды ишегенә житкәч, тагын бер баскыч үнга борылып китә, анысы ап-ак такта. Мин шунда борылып, анысын да саный-саный, өскә күтәреләм. Анда безнең «югары өй». Аның әле ишеге дә, тәрәзәләре дә юк, стенада бер бәләкәй тишек кенә бар, ярым караңгы. Ул әле эшләнмәгән, ди әнәй. Мин шул тишектән «югары өй»гә кереп балчык таптап йөрим дә, тагын аска төшеп китәм, ишегалдына чыгам. Анда ап-ак кар, түтәй көрәгән тап-тар гына сукмаклар. Ул инде ун яшьтә. Ун күпме була торгандыр, мин әле белеп бетермим, ә буйга миннән бермә-бер озын. Кар көри ала, утын кертә, табак-савыт юа, идән-сәке юганда әнәйгә булыша, чиләк-көянтә асып суга да барган була.

Көн кояшлы икән бүген, жылы, шыбыр-шыбыр тамчы тама. Җепшек карга шыгырт-шыгырт басып, урамга таба атлыйм.

— Әй, туктале, энекәш, кая киттең болай, сәлам дә бирмиче!— дигән таныш тавыш ишетелде. Артка борылам. Амбар янында Мактый бабай

белән малае Габдулла абый утын ярып яталар. Куанып алар янына йөгерәм.

Габдулла абый балта сабы тотып тора, ә Мактый бабай олы имән тукмагын күтәреп, төйтәгә китереп суга.

— Гггы-ы-ы-х!— дип куя ул суккан саен. Бөтен ишегалды яңгырап китә, җир селкенгәндәй була. Мин бик яратам аның шул тавышын, шулай көчле булуын. Ул суккан саен мин дә кулларны күтәреп суккан булам, гых дип куям, тик минем бер дә алай шәп чыкмый.

— Һай бу чайры төбен!— ди Мактый бабай.— Әдәм яра торган гына түгел, карамадан да кирерәк бу шайтан мөгезе!

Ә үзе яра. Инде әллә нихәтле ярган, юри генә зарлана бугай. Ул утынны безгә Дәүабай белән Тәтәбай китергән иде көз көне, Югары Тәкәнештән. Түтәй әйтә, анда гел шундый утын гына үсә икән, ди.

Утын ярганны карап туйгач, ишегалдындагы тавыкларны пыркыта-пыркыта, капка төбенә киләм. Безнең капка — җил капка. Ни өчен алай дип әйтәләрдер — мин белмим. Әллә җиңелгә микән? Мин дә аны яртылаш ача алам: җырлап ачыла, җырлап ябыла.

Урамга чыгам. Берәү дә юк, Гыйльметтин дә күренми, өйдә утыра микәнни соң? Ул безнең орынып кына торган күрше малае, буйга миннән озынрак, көче дә хәтәр — көрәшә башласак, әйләндерә дә сала. Шулай да без гел бергә. Сугышмый ул, көче белән дә мактанмый,— әйбәт малай.

Капка келәләрен үренеп ачам да ишегалларына узам. Тәбәнәк кенә баскычларыннан күтәрелеп өйләренә керәм. Гыйльми әллә нәрсә ясап маташа, анасы Ләүхия җиңги бәрәңге әрчи.

— Нихәл, ылан. Әйдә түргә уз,— ди ул.

— Җакшы әле.— дип, борынны тартып кына Гыйльметтин янына килеп утырам.— Нәстә җасыйсың, малай? — дим.

— Күтәрмә ясыйм, яз җитте бит,— ди ул.

— Миңа да җаса әле, малай, итеккә бәйләрлек итеп.

— Итеккә күтәрмә бәйлиләрмени?— дип көлә Гыйльми.

— Атаңнан хәбәр-хәтер юкмы, кайтам дип әйтмәгәнме?— дип сорый җиңги.

— Бар, хаты килде. Җаз кайтмасам, көз кайтырым, көтеп тор, җаныкаем, дигән.

Гыйльметтин анасы көлеп җибәрә.

— И-и, бигрәкләр дә матур итеп язган икән,— ди. Ул миннән тагын әллә нәрсәләр сораштыра да:— Җәле, ылан, эчең катып бер көл әле,— ди.

Башны артка ташлап, күзләрне четердәтеп йомып, авызны зур итеп ачам да, «гы-гы-гы-ыггы» дип, «эч катып» көләргә тотынам.

— И-и, шәп тә көләсең инде син!— дип шакката җиңги. Шундук яңа сорау бирә:— Ылан, Әсма тутаң нишләгән?

— Ник, нишләсен, «кәрәкә күле» чыгарган.

— И-и,— ди җиңги,— ничек алай булган соң у-ул?

— Әй лә, әйтмим, әнәй ачулана: «Өйдә булган бөтен җук-барны кешегә такылтап йөрисең, урамавыз син!»— ди...

— Җә инде, ылан, әйт инде,— дип ялынган була җиңги.— Миннән генә яшермә инде, берәүгә дә сөйләмәм, икебезнең сер генә булыр, әйт инде...

Француз яулыкны ияк астына кыстыргалап, борынны шырык-шырык тартып торам да чишелеп китәм:

— Ник, шул инде, Хөршит түтәйнең дус кызы Әсма түтәй безгә куна килгәч, астын чылаткан дагын, иртүк торып өенә сызган үзе. Урын

жыйган чакта әнәй күреп алды да: «И-и, бала, кәрәкә күлләре чыгарган икән бу...» дип шаклар да катты. Менә шул инде...

Ә Ләүхия җиңги һаман туктамый, тавыклар күкәй саламы, сарыклар бәрәнлиме икәнен сорый да:

— Ә син, Шәйхелислам ылан, «сөйдергеч догасын» беләсеңме?— ди.

— Ник белмәскә?— дип, мин тагын тотынам:

И ходаем, и сәнә,
Бер матур кыз бирсәнә.
И матур кыз, и сәнә,
Атлас күлмәк кисәнә,
Алларыма килсәнә,
Җаным-бәгърем дисәнә,
Үбеп-кочып сөйсәнә...

Шунда туктап калам.

— Бетмәде бит әле, — ди җиңги. — Калган ягын белмисеңмени?.. — Шуннан үзе очлап куя:

— Үбеп-кочып сөймәсәң,
Бер кундырым инсәңә!

Ул андый такмазаларны, жыруларны бик күп белә, безгә дә өйрәтә. Моннан элек кергәнемдә ул миңа «Аллаһыма инни»не өйрәтте. Шуннан озак та үтмәстән, безгә Гыйльмевафа әби килгән иде. Бик өметләнеп торсам да, ул миңа бер нәрсә дә бирмәде. Бер тустыган гына чәй эчеп чынаягымны капладым да:

Аллаһыма инни,
Безгә кунак килми,
Килсә, китә белми!
Күчтәнәчен бирми,
Кыртыш белән кыйный,
Илләһан амин, аллаһәппәр, —

дип дога кылдым. Чак кына колак төбемә эләкмәде, йөзлектән сөреп кенә төшерделәр. Әнәй өч көн эрләде шуның өчен.

Моңарчы бер сүзгә дә катышмыйча, һаман юнышып маташкан Гыйльми ахырда күтәрмәләрен ясап бетерә, каты юкә белән чабаталарына беркетә дә без урамга чыгабыз. Аның тизрәк яңа күтәрмәләрдә йөреп карыйсы килә.

— Бер аяк озын, бер аяк кыска, — ди ул.

— Нишләп? — дип сорыйм.

— Күтәрмәләр тигез булмаган бугай ла, — дип атлап китә Гыйльми. Капка төбендәге казларны куып, урам уртасында утырган мәчет янына киләбез. Анда казлар күп җыелган, бик шәп итеп гаңгылдашалар. Мәчет түбәсеннән тамчы тама, бәләкәй чокырга әз генә су да җыелган. Ин элек Гыйльметтин кереп карый, күтәрмәсе дә күмелми, аннары чуар итекләр белән мин дә керәм, бик сай икән шул, итекнең борынына да җитми.

Әллә кайдан балтачылар тавышы ишетелә. Монасыйп абзыйлар чатыннан борылган идек, Мөфти Ибрайлары капка төбендә бура бурыйлар икән. Шунда киләбез. Балта чапкан саен бүрәнәләр шыңгырап ала, әллә нихәтле ак, кызыл, сары йомычкалар чәчри, струк астыннан чыкканнары тәгәрәп китә. Аларның иң матурларын гына җыеп, өйгә алып кайтасы килә. Ничек аласың? Кешенең йомычкасына да тиярgә ярамый, ди әнәй.

— Нихәл, дуслар! — ди Ибрай абзый безгә. — Ата казларыгыз күкәй саламы?

— Безнең ата каз жук бит, — дим мин, аны-моны белештермичә.

— Ата казыгыз да юкмыни-й? — дип суза Ибрай абзый бик гаҗәпләнгән төс белән. — Алай булгач, син инде шәп кенә итеп җырлый да белмисеңдер, агай-эне, ә?..

Әллә ничек сөйләшә бу Ибрай абзый. Ата каз юкка карап кына җырлый белмимме инде кеше?

— Ник авызыңа су каптың? Әллә чыннан бер җыру да белмисеңме?— дип кабат сорый ул.— Әнә Гыйльметтин күршең бәрәңге мылтыгы белән чыпчык атып ала дажы!

Мин Гыйльмигә карыйм. Ничек инде бу? Миңа күрсәткәне дә юк, әйткәне дә юк. Тырбайчык! Аңа ачу итеп, муенны кукрайтам да:

— Белмәс, бар! — дип куям бик эре генә.

— Соң, белсәң, җырлап күрсәт, — ди Ибрай абзый,— жуктыр, белмисеңдер...

Тагын Гыйльмигә карап борынны бер тартам да җырлап җибәрәм:

Ай югары, без түбән,
Безнең көнеләр сүрән.
Безнең көнел нигә сүрән? —
Җырак китте җан сөйгән!

— Әттә-тә-тә! — ди Ибрай абзый. — Менә, ичмаса, җегет! Тагын берне әйтеп бирмисеңме, агай-эне?

— Ник әйтмәскә!

Әтәй миңа ат бирде шул,
Иярлә дә чап, диде.
Кайда матур кызны күрсәң,
Кочакла да жат, диде-е.

— Ах, җегетләр! — ди балтачылар. — Барып та чыккан маладис икән бу! — Ә үзләре шаркылдап көләләр.

— Инде сиңа нәрсә бирергә бу әйбәт җыруларың өчен, — ди Ибрай абзый, аптыраган булып.

— Йомычка! — дим мин, тәмам кыюланып.

— Йомычка? Ал теләгәнең хәтле, рәхәтлән, әйдә!

Без Гыйльметтин белән ап-ак струк йомычкаларының олы кыршаудай түп-түгәрәк булып килгәннәрен генә сайлап алабыз да юлга ташлабыз, җил уңаена берәм-берәм тәгәрәтеп җибәрәбез. Артларыннан үзебез йөгерәбез. Җил аларны төрле якка уйнатып алып китә, карга батып бетәбез. Тез башлары, бишмәт итәкләре җепшек карда манма су була, аннары бозланып ката. Казлар янына килеп җиткәндә актык йомычкам, тәгәрәп барган уңайга, әлеге күлдәвек эченә барып төшә. Андагы су хәзер шактый күбәйгән, итек йөзенә җитә, шулай да аякка су үтми. Менә, ичмаса, итек!

Кичке якта гына өйгә кайтып кергәч, Хөршит түтәй мине чишендерә башлый, әнәй аптырап кулларын җәя:

— И, улым, — ди, — гел җуләр Җәхмәриш инде син, бер тиеннек акылың юк, — ди. — Атаң җибәргән итекне шулай су ерып бетерәләрмени?

Мин эндәшмим. Җәхмәришне генә сорыйсы килә — кем малае икән ул? Мин аны күргәнем дә юк бит. Аның да шундый чуар итеге бар микәнни соң?

Хөршит түтәй мине, этеп-төртеп дигәндәйрәк итеп, мич башына менгереп җибәрә. Ул да ачулана. Янәсе, ул да олы кеше. Ә мич башы әй рәхәт, әй җылы. Андагы тараканнар, мине күргәч, кыштыр-мыштыр ярыкларга качалар, минем аларны куасым килми, яратмыйм үзләрен. Түтәйнең иске бишмәтенә башны куеп, түшәмгә карап ятам да, андагы ярыкларны саный торгач, әллә кая югалам.

## Олы бер кашык май, торна ташлаган малай

Кичкә унай. Мичтә салам яна. Иөзлек буенда утырган әнәй кузгала да кисәү агачы белән аны болгатып җибәрә. Мич көймәсенә тулган ут толымнары тагын да шәбрәк ялкынлана башлый, аның җылысы хәтта минем битләргә килеп бәрелә. Мин кече як сәкесендә, бүтән чакта бик җылы була торган иске толып астында калтыранып ятам. Әнәй әйтә, суык тигән сиңа, ди. Нигә ул миңа тиде икән? Минем аңа тигәнем юк бит. Әнәй көлә:

— Син тимәсәң дә тия ул, ялан аяк күбрәк йөрсәң,— ди.— Әнә бит, аякларың гел чеби белән тулган...

— Чеби белән? Ничек инде ул? Бер чеби дә юк минем аякта! — Мин дә көлә башлыйм: аякка чеби чыккач, ник чыелдамый соң берсе дә? Чеби күкәй эченнән генә чыга бит ул? Бәхәсләшергә маташкан булам. Әнәй, күзләрен тутырып, һаман елмая, миңа таба үренеп, толып аркылы гына булса да шап-шоп сөеп куя.

— И-и, җүләрем! — ди ул. Аның тавышында ниндидер бик рәхәт, бик иркәләүчән җылылык бар, ниндидер бик татлы моңсулык яңгырый. Шул сүзне гел әйтеп торса да һич үпкәләмәс идем. Өйдә без икәү генә, Хөршит түтәй каядыр чыгып киткән — тышта мал асты карап, салам келтәләп йөри микән, әллә мине ташлап уенга тайды микән? Без икәү генә. Җиргә казып салган таш өй эче тып-тын, олы якка караңгы төшеп килә. Мичтә шаян ялкыннар дөрли. Толып астыннан сикереп чыгып, әнәйнең муенына сарыласы килә, кочагына чумасы килә, анда тагы да җылы, тагы да рәхәт икәнен мин беләм, шул рәхәттә майдай эрисе килә...

Карлыккан тавыш белән кинәт корык-корык йөткереп куям. Әнәй тагын кызгана мине:

— И гөлкәем, суык тигән сиңа, бик каты тигән. — ди. — Менә мәтрүшкә кайнатып эчерермен, аякларыңа күкәй сөртербез...

Дөрес әйтә, тисә дә тигәндер шул. Кар астына су төште бит, капка төбендә гөрләвек ачып йөргән булдым. Ишегалды да гел су булгач, чуар итек күрде күрәселәрен. Ә Мактый бабайларның урамга караган келәте алдында уч төбе хәтле генә җир чыкты. Көндез кояш җылысына кунаклап, малайлар шунда ташыяклы уйный, мин дә ялан тәпи генә шулар катына йөгерәм. Чүгәләп, бишмәт итәкләрен аякларга каплаштырабыз да ташыяк чөябез. Ә ул, бер кесә булса да, уйный торгач бетә дә китә. Аны эзләр өчен бәрәңге бакчасына чыгып китәбез. Кар астыннан яңа чыгып килә торган саз балчыкны балтырдан ерып, кышын түгелгән чүп өемнәрен актарабыз. Чынаяк-тәлинкә ватыклары шунда була. Шаккатарлык матур бизәкле ташыяклар килеп чыга алардан!

Уен яңадан кызып китә. Кичке суык төшә, гөрләвекләр чыйрый башлый, ә без һаман келәт артында. Колаклардан сөйрәп алып китә башлагач кына таралышабыз. Мине дә әнәй моннан өч-дүрт көн элек шуннан җилтерәтеп алып кергән иде. Шулай булгач, безгә тими, кемгә тисен инде ул суык! Ә хәзер ничек икән урамда? Әллә ниләр бардыр инде!— кар эреп бетәдер, келәт арты ямь-яшел чирәмдер, сыерчыклар әллә кайчан килгәндер, оя да куеп булмады. Габдулла абый ясап бирермен дигән иде, югыйсә. Инде су да ташый башлагандыр...

Әнәй мичкә актык көлтәсен тыкты, ялкыннар дөрләп кабынып, аны чорнап алды. Шул чакта ишек ачылды. Мин, түтәй кайтты дип торсам, аннан Шәмсеямалттәй килеп керде. Ул безнең каршыдагы күрше, өйләре урам аркылы гына. Минем иптәш малай Һадиулланың анасы. Исәнлек-саулык сорашкач, әнәй аны мич каршына чакырды.

— Озак юана алмыйм, Бибигайшә, — диде ул, — суга төшеп менәсем бар. Шәйхелислам сырхап тора дигәч кенә кергәнием. Әлерәк кенә май жаздым да, тукта, ул бала да авыз итсен дигән булдым. Әз булса да тамагына йомшак булыр бәбкәмнең...

Ул яулык почмагын күтәрде дә әнәйгә олы бер кашык май сузды. Рәхмәт укый-укый әнәй аны озата чыкты. Майны да шул уңайдан өйалдына салкынга куеп керде.

Май күргәч, минем авыздан сулар китте. Ак май. Яңа язган ап-ак май! Ә безнең сыер юк. Сөт эчеп үстем микән мин? Хәер, хәтерлим, шул ук Шәмсеямалттәй таш савыт белән сөт керткәли иде бит... Бәлки шундый тансык булгангадыр, бу майны минем бик ашыйсым килде, шундук ашыйсым килде, әмма әнәй бер генә дә ашыкмый. Мичтәге алтын салам көлләрен тартып, кисәү агачы белән төйгечли-төйгечли учакка тутырды. Мичкә бәрәңге тәгәрәтеп, алдын капкачлап куйды. Аннары мич башына үрелеп моржаны япты, ис чыкмасын дип кече учакны ачты, лампага ут кабызды, самавар куйды.

Боларның барысын да көтеп яту минем өчен әҗәлгә әйләнде. Сабыр канаты гел сынып китте, мин бик кызгандыргыч итеп ыңгыраша, йөткергәли башладым, хәзер үк елап җибәрергә дә күп кирәкми.

Ниһаять, шул вак-төяк эшләреннән арынып, әнәй минем янга килде.

— И балакаем, бик каты чирлисеңмени соң, кичкә каршы тагын кочәеп китте микәнни?— диде ул, нык борчылган тавыш белән. — Менә хәзер мәтрүшкә куярмын, сөт кенә табып керим дә...

— Кирәк түгел миңа мәтрүшкә,— дидем мин бүселеп китәргә торган елак тавыш белән.— Әче ул, төче ул.

— Анысы ничек була тагы? — диде әнәй көлемсерәп.— Нәрсә кирәк соң? Суык тигәннәч иң әйбәт дәва шул инде.

Мин, эндәшмичә, һаман ыгы-мыгы көйсезләнә бирдем.

— Әйт, улым, нәрсә телисең соң? Шикәр бирим мәллә?

— Шикәр дә кирәкмә-әс,— дип баш селкедем әлеге бик чирле тавыш белән.

— Нәрсә бирим соң, балам, нәрсә белән терелтик? — дип өзгәләнә башлады әнәй. Тагын әзрәк көттердем. Аннары елак тавыш белән мышык-мышык килеп әйттем:

— Шул кашыктагы майны ашасам, әллә терелерием ми-и-ин...

Әнәй бот чабып көлеп җибәрде.

— И балакай гынам! — диде ул.— Бигрәкләр дә каты авырыйсың икән! Соң ул майны синнән башка кем генә ашасын инде! Сиңа көчтәнәч итеп кертkән бит Шәмсеямалттәң!

Самавар кайнады. Чәйниктә мәтрүшкә пеште, аның хуш исе минем тыңкыш борынга да килеп керде. Мичтән бәрәңге чыкты. Әлеге олы бер кашык май да табынга килде. Итәкләрен манма су итеп Хөршит түтәй кайтып керде. Без сәке өстендәге бәләкәй генә табында түгәрәкләнешеп утырып, өч бөртек җан иясе бер булып, чәй эчтек. Туйганчы бәрәңге ашадык, мичкә тәгәрәткән тәмле бәрәңге ашадык! Туйганчы май ашадык, олы бер аш кашыгы май!

Сабый чакның бер киче күңелдә мәңгегә уелып алган.

Менә җәй дә җитте. Каршыдагы Пәрхи әбиләрнең шомырты әчкелтем ис чыгарып яфрак ярды. Безнең урамга ямь-яшел чирәм чыкты, чирәм өстендә каз бәбкәләре күренә башлады. Сәке астыннан мине юри генә чукып ала торган безнең ак каз да җиде бәбкә чыгарды. Хәзер мин аларны капка төбендә саклыйм. Бәбкәләре шундый бәләкәй, шундый ямь-яшел, сап-сары, мамыклары шундый йомшак, тәпиләре белән томшыклары шундый кызыл-ак, әйтерсең барын да ясап куйган! Ә үзләре шундый хәлсез,—бер бәләкәй генә чирәм яфрагын нәни борыннары белән тартып өзсәләр, шундук артларына чүгәләр. Аларның бик

матур, бик ягымлы бала тавыш белән «пип-пип-пип» дигән булулары — бик дус итеп сиңа эндәшкән төсле. «Әйдә, син дә безнең белән чирәм аша, бик тәмле бит!» дигән кебек тоела. Яннарында ук яткан килеш мин аларга куя сузам, аркаларыннан сыпырасым килә, уч төбенә басты-рып сөясем килә. Тик кая ул! Ана каз шундук башын күтәрә дә, муенын сузып ыслый-ысылый, миңа ташлана. Яратмыйм шуны! Тияммени инде мин аның бәбкәләренә? Әйтерсең ул гына. Мин дә яратам ич ул бәбкәләрне. Тилгәннән кем саклый? Мин булмасам, бер үзе нишли алырые ул! Мин булмасам, кем аның бәбкәләрен ипи белән туйдырырые. Кем аның үзенә ипи катысы ыргытырые, кем ул бәбкәләргә китек табадан су эчертерие?— шуны да белми ул: каз дисәң каз!

Гыйльметтин белән Һадиулланың каз бәбкәләре дә шушы ук чирәмдә йөри, без аларны бергә саклыйбыз. Һадиларның ата казы да бар әле — аның янына гүпчи барып булмый. Безнең янга вак-төяк кызлар да җыела, башта борыннарына чиертеп елатабыз, аннары бергә уйный башлыйбыз. Без, киртә буйларыннан карманып, чыбык-чабык, йомычка кисәкләре китерәбез, алар өй кага, юл туфрагыннан коймак пешереп, безне кунакка чакыралар. Өйнең бик матур борма тыкрыклары да кызыктырса да, эченә сыярлык булмаганга, янына гына утырып, коймак белән чәй эчәбез. Өй түрендә кызларның чуар чүпрәк курчаклары гына утыра. Ни өчендер ачу килә ул курчакларга — Һади аларны туздырып ташлый. Шуннан чыр-чу китә, елаш-әрләш китә, «көдер», «күркә», «тавык», «кәҗә», «кипкән таракан» дип атаулар китә, үкереп елый-елый әнәйләргә әләкләшү китә, уен тарала. Иртәгесен тагын татуланышабыз, тагын уйныйбыз, тагын сугышабыз. Шулай үтә көннәр.

Ә бәбкәләр һаман калкына бара, чирәм өзгән саен артка чүкмиләр инде хәзер, йоннары да элекке матурлыгын җуеп, алара, каурыйга әйләнә бара, тәпиләре дә яшелгә ката бара. Ана казлар, аларны ияртеп, ераграк китә, әкрен-әкрен чишмә башына юл тота башлыйлар. Алар артыннан без дә күчәбез. Анда инде яңа уен. Уен түгел, «эш»: чишмә ерганагына бөя бөйибез, «кавыз» ясап, шунын турына тегермән корабыз. Бөягә су тулып, кавыздан бик шәп ага башлагач, иң элек тегермән җимерелә, аннары бөя бүселә.

— Ташу китә, ташууу!— дип кычкырабыз.— Әнә тегермәнне алып китте! Әнә күперне ярды!..

Тагын тотынабыз. Тездән һәм терсәктән сазга батып бетсәк тә, күлмәкнең түшләренә хәтле балчык катса да, чишмә суы боз күк суык булса да — туктау юк. Тагын бөйибез, тагын китә! Казлар искә дә керми хәзер. Алар бәләкәй генә дугайда чыршы үләне кимерәләр, аннары инешкә төшеп йөзәләр, ә безнең ак казны «зимагур» дип белми әйтми торгандыр түтәй, ул инде инеш аръягына ук чыгып киткән була. Анда күрше авыл — Шәмәк болыны. Алып китеп япсалар — беттең! Елардай булып өйгә йөгерәм. Хөршит түтәй коткара. Әллә кайдагы тау асты басмасыннан әйләнеп зимагур казны тирги-тирги өйгә алып кайта.

Безнең бик су коенасы килә, тезгә хәтле кереп карыйбыз, ә инеш суп-суык. Берәүнең дә кыюлыгы җитми.

— Күке кычкырмаган бит әле,— ди Гыйльметтин.

Ә кайда кычкыра икән ул күке: бакча талларындамы, болындамы, урмандамы? Ә урманны минем күргәнем дә юк, авылдан әллә ничә чакрым диләр аны. Гыйльметтин сораганга Зиннәт килеп тыгылды.

— Шуны да белмисеңме, ар нәселе?— дип көлдә карлыккан тавышы белән. Ул миннән олы малай, төптән юан чыккан, көчле, усал. Маңгаеңа бер чиертсә, күзеңнән утлар чәчри.— Зиратта кычкыра ул! — дип өстәде аннары.

Тагын аптырап калдым: аны ишетер өчен зиратка барырга кирәк микәнни?

«Ар нәселе» дигәнне дә белмим мин. Ә Зиннәт очраган саен гел мыскыл итә:

Килде-китте, килде-китте,
Бер тиен акча бирми китте.
Мазарасты, Кәчемире,
Киндеркүле — ар нәселе,
— Пике пан-пан-пан
Пике пан-пан-пан! —

дип такмаклый ул тыңкыш борын. Мин еларга да, көләргә дә белмим. Каян тапкан шундый тозсыз сүзләрне? Аңа көч җитми безнең, ату өйрәтер идек. Ә ул шуны бик яхшы белгән кебек, бүтәннәрне дә әшәке сүзләр белән мыскыллый да, берәребезнең касыгына төртеп китеп бара. Бу юлы Һадига эләкте. Ул аның артыннан таш атып калды, «Чәнчәм мин аны үскәч», дип янады.

— Кит аннан!— дип куырылдым мин.— Аны әйтүе дә куркыныч бит!..

Гыйльми башта эндәшмәде. Ул гел шулай тыныч, юк-барга исе китми. Тик бу юлы сүзсез калырга уйламаган икән, бөягә балчык салып яткан җиреннән аягүрә басты да:

— Чыннап тотынганда бөгәрләп булырые аны,— дип куйды. Без аңа карышмадык: чыннан да, булдырырые. Беләкләре — бәләк, йодрыклары тукмак бит аның! Ул үзе генә белеп җиткерми бугай кулларының ничаклы хәтәр икәнен.

Зиннәтнең теге сүзе һаман бәгырьгә кадалып тора. Кичен өйгә кайткач, әнәйдән сорадым: «Ник мине ар нәселе дип үчеклиләр?» Әнәй көлде генә.

— Шундый кушамат тагканнар, улым,— диде аннары ул.— Пазый бабаңның ерак бер бабасы Түбән оча дигән ар авылыннан кыз алган, шуның белән бик тату гомер иткәннәр, күп бала үстергәннәр, дип сөйлиләр. Ә син гарьләнмә, бер гарьлеге дә юк аның, улым...

Ә бер көнне безгә Әхтәмҗан абый килде. Әнәйнең энесе ул. Әнәй аңа, чәй токмачы пешереп, чәй эчертте. Кунак килсә, минем өчен дә бик шәп була: тәмлерәк сыйга корт булып төшәм, шикәрне дә яшерә алмыйлар. Табыннан кузгалгач, Әхтәмҗан абый мине «үчтеки» итеп түшәмгә хәтле сикертте-шаяртты да:

— Әйдә, Шәйхелислам дус, мин сине кунакка алып китәм,— диде.

Кунакка булгач, кем каршы килсен? «Әйдә, әйдә!» дип, абыйга сарылдым. Әнәй минем бит-кулларны юып, чиста күлмәкләр киертеп, арбага чыгарып утыртты. Бу арада ул нишләптер бик авыр йөри башлады, мине күтәреп чыкканда да мыш-мыш килеп бетте. Хөршит түтәй капкага йөгерде. Җил капка шыгырдап ачылуга без чыгып киттек. Атка утырып кунакка киттем мин! Алты чакрымдагы Югары Тәкәнеш авылына!

Андагы сыйларны, анда үткәргән көннәрне, анда уйнаган малайларны каян хәтерлисең инде хәзер. Төш шикелле матур һәм төш шикелле томанлы булып кына калган ул.

Атна-ун көннән соң мине китереп куйдылар. Өйгә кайтып керсәм, сәп-сәер хәл: ишек ачып, тупсаны атлаганда ук бәбәй тавышы ишетелде, яшь бәбәй тавышы! Әнәй кочагында! Ул аны имезеп утыра!

Иөгереп янына килдем:

— Нәрсә бу?— дип сорадым, бәбәйгә бармак белән төртеп. Тавыш та әллә ничегрәк чыкты бугай.

— Нәрсә түгел, бәбәй ул,— диде әнәй гадәтенчә елмаеп.— Синең шикелле үк ир малай! Менә энең дә булды инде хәзер...

— Ник минем энем булсын ул?.. Каян алдыгыз аны?..— дидем төксәреп.

Әнәй тагын елмаеп куйды:

— Менә син кунакта чакта тутан белән басуга чүп утырга чыккаНЫек, баш очыбыздан торналар узып барганын күрдек. Шунда бер ак торна түбәнгәрәк төште дә яшел җәймәле бәләкәй генә бер төенчек ташлады да китте. Тотып алып, ачып карасак, менә шушы малай килде дә чыкты җәймә эченнән...

— Җәймә эченнән? Ак торна?..— дидем мин шаккатып һәм берсенә дә ышанмыйча.— Анда бәбәй каян булсын ди?..

— Ник булмасын,— ди әнәй һаман көлемсерәп.— Күктә кояш бар, ай бар, күпме-күпме йолдызлар бар. Аннан кыр казлары, аккошлар, торналар оча, аларга ияреп әнә шундый бәләкәй бәбәйләр дә оча икән. Күр әле син аның матурлыгын, нәкъ сиңа охшаган бит.

Мин, теләр-теләмәс кенә бәбәй янына килеп, үренеп карый башладым. Әнәй аның йөзенә каплаган юка гына ак пәрдәне ачты. Кып-кызыл битле, йомык күзле, кашсыз бер бала имчәк суырып ята. Шул да булдымы матур? Шул да булдымы минем энем?

...Шулай да, тора-бара мин инде ана иярләнә башлаган идем, энем дә буласы булгач, ничектер тере уенчыгым булыр төсле иде, юри генә бишеген дә тирбәткәләгән була идем, тик һич тә көтмәгәндә әшәке бер ягы килеп чыкты бу малайның: төнлә елый башлады. Бишегендә тып-тыныч кына ятса, ни булган инде. Юк, җиде төн уртасында каравыл кычкырырга тотына. Әнәй белән түтәйне генә түгел, мине дә йокыдан уята! Ул гынамы соң әле: тирбәтеп тә йокламагач, әнәй аны үз янына алып сала. Ә мине түтәй читенә күчерә. Аның аркасында мин гомер буе йоклаган урынымнан колак кагам! Бер төн түздем, ике төн, өч төн түздем, гел кысрыклап чыгарды бит бу мине әнәй кочагыннан! Артык түзәрлегем калмады, бер көнне иртүк уяндым да, бик кызгандыргыч тавышлар чыгарып, үкси-үкси елый башладым. Әнәй дә, түтәй дә борчылуга төште:

— Ни булды, улым, әллә куркып уяндыңмы, әллә берәр җирең авыртамы?— ди әнәй өзгәләнеп.

— Ылан,— ди, Хөршит түтәй,— туктале, тор әле, әйдә битеңне юыйк, бер нәрсәкәй бирәм үзеңә...

Ә мин аның саен ярсыбрак елый бирәм. Ул миңа каяндыр китереп бер канфит суза. Күзнең кырыен гына төшерәм, безнең өйдә күренми торган әйбер булса да, алмыйм. Аннары ул олы бер шакмак шикәр китерә, аны да кагып кына җибәрәм. Үзем һаман елыйм. Әнәй дә төрлечә көйләп, сораштырып карый, бер сүз эндәшмим — илаулыйм гына. Чыбык белән дә куркытып карады — бар дип беләм! Барыбер сукмый ич ул.

Гел аптырауга төште болар. Төрле сүзләр белән юмалау китте. Ә безнең әнәй үзенең татлы сүзләре белән юмалый, сөя башласа, түзеп буламы соң? Барыбер тел ачарга туры килде. Ялындырып елаудан әле һаман туктап җитә алмыйча, әнәйнең муеныннан шытырдатып кочып алдым да:

— Кире илтеп ташлагыз ул малаегызны басуга-а-а!— дип суздым.— Ник ул җылак пәри минем урынны ала-а-а, мин үзем җатам синең җанда-а-а!..

— И-и җуләркәем, менә ничек икән хәлләр!— дип көлә башлады әнәй, мине шап-шоп сөя-сөя.— Көнче күмәч пешергән, ашый алмый көлгә төшергән! Үз энең бит ул, ник көнләшәсең аннан, ничек аны кызганмыйча басуга илтеп ташларсың?..

Шулай итеп, мине җинделәр, шул елак малайны яратырга өйрәттеләр, туганнан бирле яткан урынны да бирергә туры килде. Аннары, карт хәзрәтне ашка чакырып, «Мулла Шамил» дигән ат куштырдылар. Мин аның мулласын әйтеп тормадым, Шамил дип кенә йөри башладым, ә күп чакта «торна малай» дип тә ычкындыра идем...

Бу җәйне тагын әллә ниләр үтте әле баштан. Иң хәтәрләрен генә әйтмичә дә булмый.

Бер төнне безне Мактый бабай кереп уятты. Ишегалдындагы ян тәрәзәгә килгән дә ул пыялата чиертә-чиертә:

— Килен, Гайшә килен, торыгыз әле, тор, ут бар бит. Җунислар яна!— дип эндәшә икән, куркытмаслык итеп кенә. Әнәй шунда ук уянган, тик җавап кына бирә алмый икән. Ник дисәң, тел ящерә олы кешедән! Ул түтәйне уятырга тотынган. Шул арада ничектер мин дә уянып киттем. Күзләрне ачканда безнең түбән өй эче ут шәүләсеннән кып-кызыл якты иде.

— Улым, әйт Мактый бабаңа, уяндык, диген,— дип пышылдады әнәй мина.

— Бабай, уяндык! Тордык!— дип кычкырдым мин кабатлап.

Тиз генә җыенгалап, әнәй аркасына олы бер төенчек асты, аннары Шамилне күтәрде, түтәй белән миңа да берәр төенчек тоттырды да ишегалдына чыктык. Шундук Мактый бабай белән Габдулла абый өйгә кереп, олы-авыр әйберләрне алып чыга башладылар. Капка төбендә аларның җигүле аты тора иде, бөтен әйберне шунда төяделәр. Түтәй белән мине дә Габдулла абый арбага селтәде дә, югары очка менеп киттек. Әнәй безнең арттан менде. Басу капкасы артына чыгып, әйберләрне тиз-тиз бушаттык та, бабай белән Габдулла абый тагын төшеп чапты. Монда хатын-кыз, бала-чага бик күп җыелган иде инде. Барысы да курыккан, елаша, зарланыша. Минем дә кот очкан. Әйберләр өстенә утырган килеш янгын шәүләсенә текәлгәнмен. Юныс абзыйлар безнең урам аркылы күршеләр генә бит, мәчет янында гына. Теге Зиннәт дигән усал малайның атасы инде ул, шулар йорты яна икән.

— Ярый әле, җил юк, тып-тыныч, алла рәхмәте,— ди карчык-әбиләр.— Югыйсә, мәчет тә калмасые, ярты авылын да бетәрие...

Әллә нәрсәләр шарт-шорт килүе ишетелә. Шуннан соң чәйниктән олырак очкыннар атылып күккә менә. Менә дә кыйгачлап түбән томыла.

— Ходаем, үзең сакла,— ди бер җиңги.— Менә шул очкын берәрсенең абзар түбәсенә килеп төшсә, бетте диген инде, гел кругум салам бит!..

Мин тагын да куркарак төшәм, елыйсы килә, әнәйгә сыенам. Аның җылысы ничектер тынычландырып җибәрә. Күзләр күккә текәлә. Анда түшәк-түшәк ак болытлар. Араларындагы бушлыктан җемелдәп йолдызлар да күренә. Бар да тып-тыныч, берсе дә кыймылдамый, бер төрле хәтәр-хәвеф тә сизелми анда. Минем әле җәйге төн күген болай озак итеп беренче тапкыр карап ятуым. Нинди ерак, нинди матур, нинди иксез-чиксез икән ул! Ә куркыныч шәүлә әле һаман сүрелми...

Безне таң атып, яктырып беткәндә генә өйгә алып кайттылар. Шул ук Мактый бабай инде. Капка төбенә җиткәндә гел утлы күмергә әйләнгән баганаларның ыржаеп торганын күрдем. Якын барып карарга куркыныч. Хәер, болай да күренә бит: йорт-җир, каралты-кураларыннан бер нәрсә калмаган. Кап-кара бушлык. Өй почмакларында гына шомыртлары бар иде, бик зур, бик учарлы иде, ул да күренми. Пешеп килә торган күпме шомырты әрәм булган аның! Бүтән кеше берәү дә янмаган. Аларның бакча башына орынып кына торган һадиуллалар да исән калган. Түтәй мине өйгә алып кереп китте. Гәүдә бик авырайган иде, чәй дә эчмәдем, йокыга түндем. Гел саташып яттым, гел шул янгын, күккә томылган бүрек хәтле очкыннар, куркытып торган утлы баганалар йөдәтеп бетерде. Төшмени инде бу?..

Тәмәкедән чыккан, имеш, дип сөйләделәр. Булса да булыр. Тәмәке төпчеге бик хәйләкәр була ди бит ул. Нихәтле төкереп ташласаң да, сүн-

ми ди, керфеген кысып кына ята да кешеләр гел йоклап беткәч кенә күзен ачып, яңадан көйри башлый ди. Дусайда шулай бер урам гел көл булып очкан, имеш...

Тора-тора бу да онытылды. Малайлар җиләккә йөри башлады.

— Әй ире! Чыпчык башы хәтлеләре табыла!— дип мактаналар. Бер көнне мин дә аларга ияреп киттем. Безнең ише юеш борыннар өчен урман — зиратта иде. Ник дисәң, авылдан әллә ничә чакрымдагы чын урманны күрү безгә тәтеми әле. Зират та урман шикелле бит безнең. Басу капкасыннан чыккач әллә нихәтле барасы! Андагы үлән араларыннан, кабер өсләреннән (курка-курка гына булса да) аклы-кызыллы бөреләр чүпләдек. Җыйган нәрсәбез нихәтле булгандыр, кайтырга чыктык. Көн эссе иде, тамак кипте. Басу капкасын кергәч тә, әнәйнең дусы Хәпҗамалттәйләр бар иде, мин аларга су эчәргә кердем, малайлар кайтып китте. Капкаларыннан узуга унда лапас, анда чылбырга бәйләгән соры эт ята оясы янында. Мин аның белән дус, әнәй белән килгән чакларда әллә ничә рәт башыннан сыпырганым бар. Дүрт күз дип атыйлар аны. Ник дисәң, нәкъ күзләре өстендә генә тагын ике кап-кара тимгеле бар, читтән караганда гел дүрт күз булып күренә. Ул миңа өрмәде, дусына нигә өрсен ди! Каршына килеп чүгәләдем дә сулагай кулым белән маңгаеннан сыйпый башладым: «Һай, Дүрткүз, нихәл, исәнме, эсседән әлсерәп ятасыңмы?» дим. Бер дә уйламаганда гына «хап!» итеп беләктән капты да алды бу. Мин чырыйлап кычкыра-кычкыра ишеккә таба йөгердем, эт минем беләкне әләктергән килеш ырлыйырлый сөйрәлеп килә. Өйләреннән Хәпҗамалттәй йөгереп чыкты: «Чу, кем бар анда, нәрсә булды?»— ди. Ул тиз генә эткә ташланды. «Пөзең кара булгыры!» дип, этне аерып алды да, типкәли-типкәли илтеп, оясына япты.

— И балакаем, нишләдең соң син, котырттың мәллә?— ди ул.

— Сөядерием генә...

Ул минем җиңне сызгандырып, беләкнең биш-алты төшеннән чәчрәп чыккан кан тамчыларын сөртеп алды, су эчәргә керүемне белгәч, кар базларыннан әйрән чыгарып бирде, аннары мине җитәкләп өйгә төшереп куйды. Җиң сызганган, беләкнең әллә ничә төшеннән кан тагын бәреп чыккан. Кайтам урам буйлап. Кем очрап сораса, шуңа:

— Эт талады-ы-ы,— дип елап җибәрәм.

Искә төште: кайда калды икән минем җиләк, әнәйгә алып кайтам дип, сабаклап кына җыйган җиләк? Хәер, җиләк кайгысы идемени соң?

— И улым, улым,— дип өзгәләнә башлады әнәй минем хәлне күргәч,— бәйдәге эткә кагылалармы соң! Бәйдәге эт явыз була, хуҗасыннан кансыз була, дигән борынгылар. Онытма шуны.

Аннары ул минем яралы беләкне әллә нилләр белән юып, сөртеп, бәйләп куйды, кече якка мендәр салып, урынга яткырды.

«Эт ярасы» шешеп, үлекләп, озак кына төзәлмичә йөрде. Шуннан соң этләрнең берсен дә яратмый башладым, күңелдә дошманлык калды аларга. Дүрт аяклылары белән генә түгел, хәтта ике аяклылары белән дә дус була алмадым...

Бу җәйнең тагын бер хәтәр көне истә калган әле. Без ул көнне Һадилар ишегалдында уйнадык. Аларның бәләкәй генә ян бакчаларында умарталары бар иде. Бал кортларының тыз-быз кайнашуына шаккатып, рәшәткә аркылы карап тордык. Якын килә башласалар, лапас эченә йөгердек, андагы тавыкларны пыркыттык, келәт түбәсенә менеп күгәрчен оясын карадык. Аннан төшкәч, абзардагы колын янына килдек. И матур шуларның колыны: аклы-кызыллы чуар. Аның төсле колын бүтән беркемдә дә юк безнең авылда. Атлары да шундый, каян табып алган Һадиның атасы.

Мин ул колын тирәсеннән бик озак китә алмадым. «Бах-бах, кил

әле, кил!» дип кычкырып карадым, бик гөрбиян икән — әйләнеп тә карамады. Ишегалдыннан чирәм йолкып суздым,— ашамады.

— Ипи генә ашый ул!— ди Һади масаеп кына.— Анда да мин бирсәм генә әле!

Мактана инде. Аты, колыны бар, янәсе! Шулай да минем бу матур колын яныннан бер дә китәсем килми. Һади мине йолкып алгандай итеп сөйри башлады:

— Җитәр, күп каныкма! Җә күз тиерерсең!— дип, бәрәңге бакчаларына ук алып чыгып китте. Бәрәңгеләре дә нинди шәп үсә икән боларның: юан-юан сабаклары мине кумәрлек булып, учарланып үскән. Ә көнбагышлары нарат хәтле. Табак-табак башлары сап-сары чәчәктә утыра. Ә безнекеләр бөтенләй мондый түгел.

— Әйдә, Әюпләрнең айбагырын алып чыгабыз,— ди Һади миңа пышылдап кына.— Аларның ишшү дә шәп, инде карала да башлаган!

Күзләре ут яна моның. Күп әйдәкли торгач, бу мине бакчаның түбән башына алып төшеп китте. Чытырлы киртә аркылы беләкләрне сыдыра-сыдыра, Әюпләр бакчасына кердек. Өч-дүрт адымда гына үскән озын-озын айбагырга ташландык. Борам да борам бер сары башны. Ник кенә өзелсен, әллә чи каеш тагы! Шулай кабаланып маташканда гына:

— Һайт, разбунниклар! Кайсылар ул анда?!— дигән куркыныч тавыш яңгырады бакчаның теге башыннан. Нәгызь Әюп абзый тавышы иде бу. Бик хәтәр чылгый мыегы да күзгә чалынгандай булды хәтта.

Коелдым да төштем. Өзелмәгән айбагырны ташлап, киртәгә йөгердем. Һади да шунда ук килеп капланды. Киртәне бер генә сикерде дә Юныс абзыйлар бакчасына төште, аның янгыннан соң киртәсез торган кырыеннан урамга чыкты, аннан чишмә юлына таба йөгерде дә тыкрык чатындагы Гайнеттиннәр ишегалдына узды һәм туп-туры балчык абзарларына кереп китте. Мин дә аның артыннан калмый чабып, шул ук абзарга кереп егылдым. Үзем һаман калтырыйм, куркуның чик-чамасы юк, тешләр тешкә шак-шок бәрелә. Әйтерсең биш сәгать буе су кергән! Балчык кирпечтән салынган абзарның аргы почмагына поскан килеш бәләкәй генә ачык ишегеннән күзне алмыйм. Менә хәзер Әюп абзый килеп керер дә колактан эләктереп, арыяктагы каравыл өенә яптырып куяр күк тоела.

Ә Һадиның исендә дә юк: әллә миңа гына сиздерми, әллә ул бик йөрәкле. Өстәвенә әле, ул үзенең айбагырын да өзеп өлгергән икән. Күлмәк эченнән чыгарды да чөмнәрен, чәчәкләрен кырып ташлап, ап-ак көнбагыш чиертә башлады. Тагын бер кат үкенеп куйдым: шул ач тешле көнбагыш өчен йөргәнбез, карала да башламаган, ичмаса!

Шулай ни кыларга белми аптырап утырганда, Гайнеттин килеп керде.

— Нишләп утырасыз монда?— диде ул шаккатып.— Ник кердегез?

Ул бездән берәр яшькә олы, буйга да зуррак, шулай да чишмә башында, дугайда гел бергә уйныйбыз. Әйбәт малай үзе — гел муенны төйгечләп кенә тормый.

Һади аңа хәлне сөйләп бирде, айбагыр сыныгы да сузды. Ул аннан эрерәкләрен генә чемченде дә:.

— Чүп бит бу!— дип, почмакка атып бәрде. Аннары урыныннан кузгалды да: — Арыякка ыстарыстага атлы казаклар килгәнен ишеттегезме? Ырыйстан эзлиләр ди. Әйдә, карарга чыгабыз,— диде.

Мин тагын коелып индем. Бөтенләй почмакка сеңеп, тын да тартмый утыра башладым. Ә күзләр — гел ишектә. Хәзер үк шул атлы казаклар килеп керер төсле. Һади, берни булмаган кук, аңа иярде. Гел башсыз икән! Алар абзардан чыгып киткәч, инде күптән мөлдерәп тулган күз

яшьләрен туктаусыз коя башладым. Гарьләнәм, әрним, үзгәләнәм: ник кердем соң мин ул бакчага? Ник кеше әйберсенә тидем? «Кешенең йомычкасына да тияргә ярамый», дип, әнәйнең йөз кат әйткәне бар бит!.. Бөтен дөнья мине ташлаган, берәүнең дә миңа әйләнеп карыйсы килми, бар да дошман күрәләр сыман тоела. Кайда соң әнием, кайда соң, ичмаса, Хөршит түтәй? Ник килмиләр алар? Ник килсеннәр, синең ише бакча карагы кемгә кирәк?

Шулай күпме тозлы су агызып утырганмындыр, белмим.

— Ә-ә-ә, менә кайда икән ул ырыйста-ан! — дигән тавышка сискәнеп уянып, күзләремне ачсам, каршымда әнәй тора. Чырае караңгы, мәрхәмәт заты булыр сыман күренми.— Нишләп ятасың монда тирес корты булып! Тор!— диде ул, бик ачулы итеп. Аннары җилтерәтеп абзардан алып чыгып китте.— Кеше күзенә ничек күренерсең, оятсыз! Ыштыр бит! Менә кайткач, чыбык белән ярам әле мин сине! Атаңа хат язам: малаең үсте — бакча карагы булды хәзер, дип.

Эндәшү юк инде, елау да онытылган. Кайтам шунда сөйрәлеп, маңгай белән җиргә төртелеп, җир тишегенә керерлек булып. Әле бу хәтле оялганым юк иде әнәйдән дә, кешеләрдән дә. Ә урамда әллә кайчан кич булган, көтү дә кайткан, казлар да чишмә тыкрыгыннан менеп киләләр, кояш та түбән үк төшкән. Шуны аңладым: мин абзар почмагында йоклап ятканмын икән.

Кайткач, аллага шөкер, чыбык булмады, тамакка да ашаттылар. Ә икенче көнне түтәй сер итеп кенә әйтте; әнәй барып алмаска кушты: «Көн буе шунда утырсын, төнәтик әле үзен шул әшәке малайның!» — дип әйтеп әйтте, диде.

Төнәтү дигән сүзнең мәгънәсен шуннан бирле бик яхшы беләм мин...



## Безнең әнәй бай хатын

Түтәй инде әллә кайчаннан бирле сабакка йөри. Әптияк укый, букчасында тагын әллә нинди калын китаплары да бар. Ул йөргәч, минем дә сабакка йөрисем килә, бик тиз генә кыйлемне чумырып алыр сыман кыланам. Әнәй җибәрмичә аптырата, бәләкәй әле син, ди. Быел инде түзмәде, миңа да мендәр тышы төсле шакмаклы киндердән букча тегеп бирде. Эченә «Иман шарты», кәгазь-карандаш салынган яңа букчаны киеп, кыш башыннан ук мин дә укырга йөри башладым. Әнәй иртәнге караңгыдан ук торгыза да битне-күзне юдырып, тамакны туйдырып, өсне-башны киендерә, аннары түтәйгә ияртеп абыстайлар өенә җибәрә. Икебезгә ике ярка утынны бик авырсынып кына тоттыра ул. «Көн саен ике агач... Каян җиткермәк кирәк аны... Усакның да саржины биш тәңкә бит...» ди. Тырышып укырга куша, сабакларыбызны белеп кайтырга.

Тырышмыйбызмы соң? Мин бу кышны иң элек әлеппине ятладым. «Әлиф, би, ти, си, җим, хи...» дип кат-кат чәйни торгач, җиде төн уртасында сорасалар да, төртелми әйтеп бирерлек булдым. Һәм ул хәрефләр әкренләп күңелгә дә сеңеп кала башлады. Аннары «әбҗәткә» күчтем. «Әбҗәд, һәүәз, кәләмән...» Түбән өй сәкесенең йөзлек буена тезелешеп әй такмаклыйбыз шул сүзләрне. Тик бу сәер сүзләр нәрсәне аңлата, анысы безгә караңгы. Төшендереп бирүче дә юк, үзебез дә сорамыйбыз. Ахырына хәтле такмаклыйбыз да «аллаһәкбәр» дип бетерәбез. Шулай булгач, берәр догадыр инде ул. Ә күп еллардан соң бу сүзләрнең чын мәгънәсен белеп алгач, мин шаккаттым: «Әбҗәд» — бер, ике, өч, дүрт; һәүәз — биш, алты, җиде; хөтти — сигез, тугыз, ун; кәләмән — егерме, утыз, кырык, илле» дигән саннарны аңлаткан икән. Менә сиңа дога! Ярый әле, ул чакта аңламаганбыз. Юкса, әбҗәткә әйләнеп тә карамаган булыр идек.

Кыш урталарыннан соң «Иман шарты» китабына төштем. Аны ижекләп укыталар икән: «Кәпсенкәләмасылый, Кәлимимсемә, Кәлимәтенкөтертен, кәлимәтен...» Без, быел кергән вак малайлар, вак кызлар, шушы сүзләрне ниндидер бер көйгә тирбәлә-тирбәлә ятларга тырышабыз. Нәрсәне анлата икән бу? Иман — үзе нәрсә дигән сүз икән? Берсен дә белмибез. Бездән олыраклар да белми. Әнә безнең Хөршит түтәй Әптияк хәтле калын Әптиякне дә ничәдер кыш эчендә шулай ижекләп чыкты бит инде! Ә мәгънәсен ул да белми.

Безнең Тулбай авылында нишләптер мәдрәсә юк, арыяк мулласы да, биреяк мулласы да түбән өйдә генә укыталар. Абыстайның сарык бәрәннәре дә, бозавы да безнең белән бергәләп шунда сабак укый. Шул билгесез сүзләрне бер-ике сәгать чәйнәгәч, хәзрәтләрнең абзарын җыеп, саламын көлтәләп, суын ташып бирәбез дә өйгә кайтабыз. Аннары — тау башына чана шуарга!

Минем бәләкәй чана булмаса да, артык үкенеч юк. Әтәй шахтадан алып кайткан киң тимер көрәк бар. Без аны «соскыч көрәк» дип йөртәбез. Аның сабы юк. Шуны күтәрәм дә тау башына сызам. Чишмә тавы яртылаш бозланып каткан. Тимер көрәккә утырып, шаңгыратып шуннан төшеп киткәндә, бураннар гына уйнап кала, чанаң бер якта торсын! Дөрес, бишмәт итәкләре күрә күрешен, ә кич кайткач әнәйдән эләгә, — хәер, анысына гына түзәсең инде аның. Бик ачулы сыман кизәнсә дә, әкрен генә төшә безнең әнәйнең кулы, авырттырмый. Башка да түгел, колак төбенә дә түгел, йомшак җиргә генә төшә тагы үзе.

Шулай шуа торгач, кыш та узып китте, тамчылар да тама башлады, сабак ташлар чаклар да җитеп килә. Бер уйлаганда бик рәхәт инде бу: безнең авылда сабак башлауның билгеле бер ае-көне булмаган шикелле, ташлау көне дә юк. Инде гел кыш җитеп, урамнарга ап-ак кар чынлап торып яткач, сабак башлана. Береннән-бере күреп килә. Таралганда да шулай: көннәр җылытып, тамчылар шәбрәк тама башлау белән олырак, шаянрак малайлар сабактан туктый, алардан күрмәкче — без, вак-төякләр. Бер атна эчендә мулла абзый өе бушап кала. Моңа беркем бер сүз әйтми.

Минем кыш буе алган гыйлем: әлеппи дә әбҗәт белән «Иман шарты» булды. Анысының да яртысына җитеп кенә калдым. Хәер, аңлашыла торган сабакны да әзрәк өйрәндем өйрәнүен.

«Кәлимәтен тайбатын,
Безнең әнәй — бай хатын,
Арты тулы тәңкә,
Борыны тулы...»

Өйрәнеп кайткан көнне әнәйгә тыңлатып күрсәткән идем, колакны әчеттереп борып алды.

— Җүнсез, каян өйрәнәсең шундый тузга язмаганны, әшәкене! — диде ул, шактый ачуланып. — Син шәкерт буласы кеше бит инде хәзер!

Шәкерт! Шушы кышта алтынчы яшькә генә чыксам да, бу сүз мине шундук үстереп җибәргәндәй булды.

Шулай үсенеп кенә йөргәндә, без сабактан көчкә кайтып егылдык. Без килгәнче иртүк ягып томалаган түбән өй бик эссе иде. Бер-ике сәгать узуга бәләкәйрәкләр коса, елый, йокымсырап бер якка кыйшая башлады. Олыраклар: баш әйләнә, маңгай сызлый дияргә тотынды. Кайсыларыдыр мичтә әллә нихәтле утлы күмер калуын, ә юшкәнең ябык булуын, кече учак моржасының да ачык түгеллеген күреп алдылар.

— Ис чыккан, исереп үләбез! — дигән тавышлар китте. Кемдер югары өйгә, абыстайга йөгерде, олырак кызлар, чиләкләр белән кар алып

керел бала-чаганың мангаен, битен уа башлады. Тар баскычтан көчкә генә кысылып түбән төшкән абыстай:

— Ай алла, хараплар булдык! — дип, өй ишеген шыгырдатып ачып җибәрде. — Барыгыз, урамга чыгыгыз, карда аунагыз, өйләрегезгә кайтыгыз!..

Без, нихәтле бәлҗерәп төшкән булсак та, ишеккә сыеша алмыйча тышка ташландык. Түтәйгә сөйрәлеп, көчкә кайтып кердем. Бер атна буе чирләдек без. Баш авыртып, күңел болганып, косып, тәмам йөдәп беттек. Сабакка бөтенләй йөрисе килми башлады. Әнәй дә кысмады:

— Ярар, улым, сиңа белгә җитеп торыр, — диде.

## Кайтты, китте

Язгы ташулар узгач, җир-су кибеп килгәндә, әтәй кайтты. Кайтты дигәч тә, анысын мин күрмәдем. Иртәгесен йокыдан торуга ул өйдә идс инде. Гел шулай кызык итә ул, төнлә кайтып керә, төнлә чыгып китә. Мин белми дә калам. Ә бүтән кешеләр алай итми: тимерхут җиктереп, дугасына шөлдер тактырып, келлиң-келлиң келтерәтеп кенә көпә-көндез кайтып киләләр. Басу капкасыннан кергәндә, безнең ише капка ачкан малайларга учлап-учлап прәнник чәчеп узалар. Менә, ичмаса, читтән кайту! Ә без юл туфрагына төшеп аунаган шул кызыл прәнникләр өчен әй әүмәкләшәбез, әй сугышабыз, — нәкъ инде бер күз орлык өчен чырчу килеп чукышкан чеби әтәчләр!

Нигә шулай тып-тын гына кайтып керә икән безнең әтәй? Әллә аның прәнник алырга акчасы житенкерәмн микән? Алай дисәң, безгә дигән күчтәнәчләре күп була бит аның. Бу юлы да чит җирендә генә була торган әллә нинди алтын укалы, күбәләк бизәкле канфитлар, авызга капкач эреп кенә китә торган баллы түгәрәк прәнникләр, кетердәп кенә тора торган бер олы бау клиндер, бер олы бөтен ап-ак калач, чәй-шикәр алып кайткан. Аннан килеп: миңа бик матур сай кырпу бүрек (әнәй әйтә, бик тә килешеп тора инде! ди), түтәй белән әнәйгә күлмәклек, бишектәге Шамилгә тагын әллә нәрсәләр шунда: теле юк әле, мактана белми.

Әтәй читтән кайтты... Ике-өч көннән соң өйгә ниндидер басынкы тынлык төште. Үзара шаулашу, миндәге юкка да кәҗәләнү, елап җинәргә маташулар су белән юып ташлагандай булды. Хәтта бишектәге Шамил дә күп кычкыра алмый, хәзер барып тирбәтергә тотынабыз. Алай да булмаса, ипи йомшагы белән шикәр чәйнәп имезлек сала түтәй. Ул эшне миңа гына ышанмыйлар: ипиен дә, шикәрен дә үзең чәйнәп йотасың, диләр. Соң авызда үзләре эреп беткәч, мин нишләтим инде!

Мондый юаш тынлыкның сәбәбе билгеле:без әтәйдән ятсынабыз. Түтәй дә, мин дә ничектер ияләшеп, үз булып китә алмыйбыз. Бернисез әнәй кочагына барып сарылган шикелле, ана барып сарылу — кая инде ул! Әтәй үзе дә бездән ятсына бугай: алдына алып, үз итеп, тәгәрәтеп бер сөйгәнен, уйнатканын, аяк йөзләренә бастырып «деңги-деңги» иткәнен, шуннан түшәмгә хәтле сикертеп, кочагына кысканын да элек-электән үк хәтерләмим. Ә Мактый бабайларга керсәм, ул мине гел шулай матчага хәтле сикертеп җибәрә, аның муеныннан шытырдатып кочаклап алам, аның каты гына йомшак сакаллары минем битләрне кытыклый, и рәхәт тә була соң!

Хәер, әтәйнең эше дә, мәшәкате дә күп бугай. Рәтләп өйдә дә күренми. Пошынып кайтып керә дә тагын чыгып китә. Бөтен кеше сабан чәчә, ә безнең әтәйнең әле сукага барганы да юк. Ник дисәң — ат юк. Үзенекен чәчеп бетермичә, кем сиңа ат бирсен? Шунар күрә бер дә чырае ачылмый торгандыр аның. Шуның өстенә, әнәй дә нишләптер авыртын-

кырап йөри башлады әле. Гел йөткерә, туңа, хәле бетә. «Мартта Мөхлисуллаларга солы сукканда гына суык тидердем», ди ул.

— Үз-үзеңне абайламыйчы, — ди әтәй борчылып. — Март дисәң дә кыш бит ул...

— И Фәрхулла-а, — ди әнәй моңаебрак. — Кеше эшенә чыккач, сынатып буламыни? Алты чабагыш бит ул. Көлтәләр дөңгелтәп, биеп кенә йөри. Үзең дә шыбыр тир, бишмәтең дә, шәлең дә төшә инде җилкәңнән...

Ничек итсә итә — гел шул Мактый бабай коткара инде безне бәладан. Бу юлы да ул үзенең өч иманасын тиз-тиз чәчеп бетерде дә атын безгә бирде. Аның бөкре сыртлы усал алашасы безнең лапаска күчте. Әтәй аңа әйбәтләп җылы су белән генә башак болгата, күп итеп көрпә сибә. Әй ашый теге курт-курт китереп. Мин янынарак килсәм, хәзер койрыгын селти башлый, колакларын шомарта, я булмаса, «пыр-р-р-рх-х» итеп пошкырып куя. «Йөрмә бу тирәдә, яратмыйм мин сине, безнең мондый черки юк!» — ди бугай ул. Әй сәрсән дә инде шул, бер дә Мактый бабайның үзенә охшамаган! Ә мин барыбер яратам аны, усал булса да яратам, ялыннан эләктереп, биленә атланасы килә!

Икенче көнне төштән соң түтәй белән мине ярты капчык орлык белән тубал салган, артына тырма таккан арбага утыртып, Тәкәнеш үрендәге җиргә алып барды әтәй. Алашаны туарып, тырмага җикте дә арбага бәйләде. Аннары, капчыктан арпа бушатып, баулы тубалны муенына киде һәм, бисмилла әйтеп, иртән сөрелгән җир буйлап чәчеп тә китте. Тар гына тасма иде ул. Әтәй кулын киеребрәк селтәп җибәрсә, орлыклар күрше җиренә барып төшә башлый. Менә бер заман аның кулыннан ниндидер ак нәрсә атылып китте. Аннары тагын бер, тагын бердән соң тагын бер... Әллә ничәү!

— Күкәй, күкәй! — дип кычкырды Хөршит түтәй. Без ул күкәйләрне җир башына утырып, тоз сибеп, ипи белән бик тәмләп ашадык та зират юлы буйлап өйгә кайтып киттек. Әтәй шул җирне тырмалый калды.

Минем әле үз җиребезгә баруым да, иген чәчкәнне күрүем дә беренче тапкыр иде. Бар да кызыклы, бар да матур икән, дөнья чиге дә күренми икән. Тик бер генә нәрсә аңлашылмады: ни өчен җир өстенә күкәй чәчәләр?

— Шуны да белмәгәч! — диде түтәй. — Чәчкән орлык шул күкәйләр хәтле ире булып үссен өчен!

— Алай булгач, иртәгә дә әтәй икенче җиргә күкәй чәчәме? Ә без аны җыеп ашарга тагын барабызмы?

— Ай-яй оста, татар икәнсең, — диде түтәй. — Көн саен сиңа күкәй чәчәрләр, көн саен күкәй ашатырлар — эчеңә тияр! Бәйрәм ашы бер генә була ул!..

Җәй урталарында әнәйнең хәле тагын да сәерләнебрәк китте: эссе көндә дә, арка үзәгем туңа дип, иңенә шәл салып, камзул киеп йөри башлады. Төнлә озын-озак йөткерүенә кайчак мин дә уянып китәм. Сүзләре дә әллә ничек боек чыга, йөреш-торышы да сүлпән. Элекке якты чырай белән ялт килеп йөргән уенчак күңелле әнәй кая соң безнең?.. Ә бер көнне әтәй Мөхлисулла абыйларның атын тимерхутларына җигеп кайтты да әнәйгә әйбәт киемнәрен киендереп, кунакка баргандагы шикелле олы күпчек өстенә утыртып, Бигәнәй мулласына алып китте. Безнең тирәдән әллә кая еpактагы Бигәнәй авылында бик зур ишан хәзрәт бар икән. Аңа барып күренгән, ул өшкереп биргән даруларны эчкән кеше терелмичә калмый ди. Безнең әнәй дә терелер, боерган булса! Суык тию хәтәр чир икәнен беләм, үзем дә авырдым бит. Ярый ла миңа Шәмсеямалттәй керткән май килеште, әнәйгә тагын да шифалырак кирәктер шул...

Аннан кайткач, чынлап та әйбәт кенә күренә башлагандай булды әнәй. Күңеле дә көррәк шикелле, гәүдәсе дә җиңелрәк йөрешле. Әтәй

белән икесе иртүк торып уракка китәләр. Түтәй белән без Шамилне карап өйдә калабыз. Ул малай да үсеп килә инде хәзер, имчәктән дә аердылар үзен, арбада да тик кенә утырмый, гел егылып төшү ягын чамалый. Каз карау да безнең өстә бит ул. Ә зимагур ак каз безнең биш кенә бала чыгарды быел. Шул биш бәбкәсен иртә дә дөнья гизә. Без, бәләкәй арба тартып, аны әзләргә дугайга, күпер башына, Галиәрчүенә, хәтта Әчекүлгә тикле чабабыз...

Бер имана җирнең урагын тиз тоттылар. Әнәй хәзер өйдә, гел безнең янда. Әтәй күзге чәчү артыннан йөри. Тагын кеше юк. Өйгә кайтып керсә дә сүзе шул хакта:

— Кемгә барасы инде?.. Гел-гел Гайзулла абзыйдан да өмет итеп булмый бит... Үз эшен кая куйсын?

Шунда белдем: Мактый бабайның чын аты Гайзулла икән. Алай булгач, нигә аны бөтен кеше «Мактый» дип йөртә? Мыскыл итеп әйтүләре микәнни? Алай дисәң, бабай моңа бер дә ачуланмый бит. Ә нәрсә дигән сүз икән ул «Мактый»? Гыйльметтин белән Һадидан сорарга оялам, шуны да белми икән туң баш, дип көләрләр генә...

Бер иртәне әтәй Хисамбый абзыйның җирән аты белән ишегалдына кайтып керде. Моны без арба тавышыннан ук төшенеп алдык. Ник дисәң, аның бу атаклы арбасы бөтен авылга ишетелерлек итеп шыгырдый иде. Аты да атаклы. Аныкы шикелле арык, үшән ат бүтән беркемдә дә юк. Хисамбый абзый арыяк басуыннан иген ташыганда бөя аркылы йөрми, тегермәннең түбән ягыннан су ердырып чыга. Аты инеш уртасында туктап, ярты сәгать буе су эчә.

— Нә-әсәнә, үләт тигере, су күргәнең җук мәллә? Кара, кара, гел йоклады бит баскан җирендә, җык суккан ниямәстәкә-әй, — дип, бик зарлы да, көлке дә итеп сукранулары белән Хисамбый абзый үзе дә атаклы. Дилбегәсен күп тарткалый торгач, йомшак кына сүс чыбыркысы белән юри генә, искәртер өчен генә, берәрне сосып та алгач, аның үшән биясе әкрен генә атлап, су аркылы чыгып китә. Ә гомер буе дегет күрмәгән, исерек кешедәй алпан-тилпән килә торган шинсыз тәгәрмәчләре суга күбенеп, теге як юлга төшкәч илау салып шыгырдамый башлый.

Хисамбый абзый — карт кеше, Фәрбизә исемле буй җиткән кызыннан башка бер кеме дә юк. Бәләкәй генә, иске генә өе, бер-ике торык каралтысы бар. Йортында бүтән ир заты булмагач, ул да бер иманадыр инде! Шундый фәкыйрь генә тормышы белән дә ат асрый. Шул ат белән Хисамбый абзыйныкын да, үзебезнең күзге чәчүне дә төгәлләп куйды әтәй. Бер дә яманларлык булмады әле ул: ат юаш, тешләми, колагын да шомартмый. Бер кичне тезгененнән тотып кына чишмәдә сугарып та мендем әле мин аны. Атланып төшәргә генә йөрәк җитмәде, малайлар атны өркетеп ектырырлар дип курыктым...

Сабан урагы да озакка бармады. Быел аның урырлыгы да юк, чыккан да каткан, ди әнәй. Йолкып алырга дип, кайсы көннәрне түтәйне дә алып китkәләде. Урак беткәч, Яңа күпер башындагы җитенне йолкып, зират буендагы киндерне алдык. Боларына мине дә алып барды әнәй. Озын нечкә киндер көлтәләрен бәпкәгә куярга өйрәтте.

Инде көз кереп килә. Үзе белдермәскә тырышса да, әнәйнең хәле шәптән түгеллеге безгә дә сизелә. Җүтәле туктамый, суык тию шул хәтле озакка барыр икән! Үзе һаман ябыга бара, чырае саргылт-ак, йөзе моңлы, боек; гәүдәсе бөкшәйгән, йөреш-торышы көннән-көн сүлпәнләнә килә. Әтәй дә пошынулы төс белән башын түбән иеп сүзсез йөри. Хөршит түтәй дә гел әнәй тирәсендә, ул кушкан бөтен эшне эшләп кенә тора. Олы чиләкләр белән чишмәдән су алып кайта. Ишектән кергәндә чиләге борыска орына да суы чайпалып түгелә.

— И кызым, — ди әнәй йөзлек буена утырган җиреннән, — ник шул

чиләкләрне тутырып аласың? Авыр бит ул сиңа, бәләкәйдән авыр күтәрсәң, үсми калырсың!

— Җук, авыр түгел, — дигән була түтәй. — Күтәрәләм!

Анын, буй житкән кызлар шикелле, олы чиләкләрне мөлдерәмә итеп су алып кайту белән мактанасы килә: авызы ерыла, күзләре елтырый.

— Үсәсең инде, кызым, бик зур булып киләсең, бөтен эшемә ярый башладың! — дип, әнәй аның күнелен таба.

— Әнәй, әнәй, тагын нәрсә йомышың бар? — ди түтәй, башы күкләргә тиеп.

Безнен өчен бар да шулай ансат кына, матур гына шикелле дөнья. Ә бер кичне, инде чана юлы төшкәч, капка төбенә жигүле ат килеп туктады. Ике кеше өйгә килеп керде. Берсе аның Ибәт Галиме дигән абый, икенчесе «Мөти әтәй» дигән абый — әтәйнең читтә йөргән дуслары. Әтәй кыстаса да, чәйгә утырып тормадылар.

— Әйдә, кузгалыйк,— диде озын буйлы, кыл мыеклы Галим абый.— Юл кешесенең юлда булуы яхшы дигәннәр. Барасы жир ерак бит...

Әтәйнең юл капчыгы әзер иде. Өстен киенде дә безнең белән хушлашты:

— Хода юлларны уң итсә, озак юанмабыз, әнисе, исәнлектә күрешик. Саулыгыңны сакла! — Аннары безгә иелде ул: — Әниегезнең сүзен тыңлагыз, сабакларыгызны тырышып укыгыз, — диде, безнең башлардан сыйпап.

Алар артыннан без озата чыктык. Урамда караңгы булса да, кар яктысы бар, күрше-тирә тәрәзәләрдә ут яна. Әтәйләр чанага төялештеләр дә китеп бардылар. Алар Зариф абзыйлар чатына житкәндә гармун яңгырады. Галим абыйдыр инде. Гармунга кушылган жыру тавышы да ишетелде:

Без урамнан чыгып киттек
Бер чанага төялеп.
Озата чыгып карап калды
Баганага сөялеп...

— Әтәй жырлый, әтәй! — дип кычкырды түтәй. Каян белә ул? Мин әле аның жырлаганын бер дә ишеткәнем юк иде. Шуңар күрә ышанмыйча әнәйдән сорадым итәгенә сарылып.

— Атаң шул, улым, — диде әнәй, шул якка караган килеш.

Ат күләгәсе, чатка борылып, күздән югалды. Гармун белән жыру тавышы да ерагайды...

— Әйдәгез, балалар, керик, — диде әнәй. — Суык тияр...

Кердек. Бишектә йоклаган Шамил көйсезләнә башлаган иде. Әнәй аны рәтләп салды да бишек читенә аскан бауны аягына элеп, утырган килеш кенә тирбәтә башлады. Шамил әтәйнең читкә киткәнен күрмичә калды, элегрәк уянса соң, җүләр, ни булыр иде. Хәер, минем дә беренче күрүем бит әле. Моңарчы гел йокыда кала идем. Әнә ничек була икән ул: жырлап та китәләр икән, гармуннары да бар. Читкә киту кызык сыман күренсә дә, озатып кергәч, күңелсез була икән. Өй эче әллә ничек бушап калган, суынып киткән шикелле. Матча кырыена аскан жиделе лампа да кичәгедәй якты янмый төсле. Кече якка, ишек каты почмакларга карангылык оялаган. Яман да олы пәрәвезнең куркыныч оясыннан аркылы-торкылы киткән җепләр шикелле, лампа чыбыкларыннан юан-юан кара сызыклар сузылган. Әнәй йөзлек буенда бер сүзсез уйга батып утыра. Кашык-аяк юып маташкан түтәй дә эндәшми. Минем дә елыйсы килә. Тик сәбәбен генә белмим әле. Әтәйне юксыныптырмы инде ул... Мин бит аңар нәләнеп килә идем инде. Кайчакта бот буена сыенгалый идем, чәчне дә ак сөяк саплы, су күк үткен пәкесе белән бер дә авырттырмыйча ала иде. Дөрес, матчага бик шәп тал чыбыгы кыстырып куйган иде куюын, әмма бу кайтуында ул чыбык та безнең балтырларда сызгырмыйча калды. Ник тисен, үзебезнең әтәй бит ул!..

# Кычкыра күке баласы

Нишләп болай булды соң әле бу? Көпә-көндез түшәк җәюле. Әтәй әлек читтән җибәргән бишни җон күлмәге өстеннән шәмәхә камзулын кигән, башына зәңгәр шәлъяулык япкан ак чырайлы әнәй шул түшәктә ята... Әйе, әтәй читкә киткәннән соң берәр ай узды микән — ул урын өстенә менде. Хәл белергә кергән күрше җиңгиләрдән ишеткән бу сүзне үземчә генә аңлап, мин дә теләсә кайвакытта урын өстенә менеп ята башладым. Көн буена җыелмый торган түшәк-ястыкта аунап-тәгәрәп алу, әнәй янына сыенып яту баштарак бик рәхәт тоелса да, тора-бара әллә ничек кызыксыз булып китте. Әнәйнең чырае боек, тамак төбенә әллә нәрсә ябышкандай озак итеп, буылып йөткерә, еш-еш тын ала, маңгаена бөрчек-бөрчек тир чыга. Мине дә элекке шикелле шап-шоп итеп сөйми хәзер. Янында күп сырпалана башласам: «Улым, туктале, борчыма әле» дип, яныннан җибәрергә тырыша. Әллә яратмый микән ул мине хәзер? Аның болай булуы минем эчкә пошаман сала, кая барып сугылырга, ни кылырга белми аптырап йөрим.

Түтәй хәзер өйдә «олы кеше» булып китте. Тыштан утын ваклап кертә, чыра телеп мичкә яга, самавар куя, аш пешерә, өч баш сарыкны өйгә кертеп, он сипкән,тоз сипкән җылы су эчерә, бәкәйләре имеп туйгач, абзарга чыгарып яба, асларын тазарта, салам көлтәли. Мин аның артыннан тагылып йөрим, эшләгән булып аңа комачау итәм. Икенче көнне өйгә салам ягабыз, анысы рәхәт була, мин салам өстендә тәгәрәп уйныйм.

Хөршит түтәй он да или, токмач та баса, ипи дә пешерә инде хәзер.

— Кызым, иләгеңне бик сикертмә, онын җилпучтан читкә сибелмәсен,— дип өйрәтә әнәй урын өстендә бөкшәеп утырган килеш. Суның җылылыгын тел? белән үзе татып карый, тозны үз учы белән үлчәп бирә. Онның да күләмен үз күзе белән билгели. Түтәй шуларның барысын да бер-бер артлы күәс чиләгенә сала да озын саплы агач калак белән изә-туглый башлый.

— Кызым, апараңда он төерләре калмасын, кат-кат тугыла, җәме,— ди әнәй.

Түтәй карусыз. Ул бөтен эшне әнәй кушканча эшли. «Рәхмәт, кызым», дип кенә тора әнәй аңа. Минем шикелле кәҗәләнеп йөрмәвенә шаккатъым мин аның. Гел эштә дә гел эштә, уен да әләкми аңа, үзенең дә бик исе китми бугай. Хәер, кайчакта ычкынгалап куя куюын. Әнәй көтә-көтә дә мине чыгарып җибәрә: «Бар, улым, эзләп алып кайт тутаңны», ди. Мин аны күрше кызлары Мәсүррәттәйләрдән, анда булмаса, Мәлүфәттәй яныннан табып алып кайтам. Әнәй аны бер дә орышмый. «Балам, дөньяңны онытып йөрмәсәнә, акыллым, син бит инде унбер яшь тутырып килә торган олы кыз», дип кенә куя.

Әнә шул «олы кыз» кичә изгән күәстән ипи сала бүген... Бу аның өченче пешерүе инде. Безнең сәке биек, күәс чиләге дә тирән. Кулы белән аның эченә сузылырга түтәйнең буе җитми.

— Букәнне китер әле, ылан, — диде ул. Мин букәнне тәгәрәтеп алып килдем дә аяк астына утыртып куйдым. Ул аңа менеп басты. Аннары, иләп куйган онын әнәй кушканча апара өстенә салды да, җиң төбенә хәтле үк сызганган бәләкәй генә ап-ак кулы белән күәс баса башлады.

— Кызым, төптән үк әйләндереп-әйләндереп, кат-кат бас, җәме,— ди әнәй.. — Онын укмашып калмасын.

Бик озак басты ул аны. Битенә бөрчек-бөрчек тирләр чыкты. Бая чымырдап утырган сыек апара тыгыз камырга әйләнде хәзер. Әнәй, көчхәл белән булса да, күәс эчендәге камырны үзе килеп карады:

— Ярар, кызым, — диде, — әйбәт булган бугай. Тәмле булып кына пешсен инде...

Түтәй, кулындагы камырны агач пычак белән кыргач, тиз генә юып килде, күәс чиләген җәймә белән бәйләп, өстенә иске чүпрәк киез капլады, аннары мичкә ягып җибәрде. Күәс кабарып чыгу белән ипине әвәләп, сәкегә җәелгән ашъяулыкка тезде, өстенә күп итеп тоз сибәсибә бәләкәй ипиләр дә ясады. Аннары күәс төбен кырып алды да: «Монысын нишләтик микән, әнәй?» дип сорады.

— Анысыннан шишара яса, кызым, әйбәтләп тоз сип, тәмле булыр,— диде һәм ничек ясарга икәнен өйрәтте.

Мичне тартып, ашъяулыктагы ипиләрне берәм-берәм көрәккә утыртып, мичкә тыгулары да әйбәт узды түтәйнең. Бер камыры да ашъяулыкка ябышып, кулына сыланып калмады, көрәктән дә төшеп китмәде. Өстенә ипи утырткан килеш ничек күтәрә ул шундый озын саплы зур көрәкне? Гел олы кеше дип торырсың!

Байтактан соң ипи пешеп чыкты, өйгә тәмле ис тулды, самавар өлгерде. Өстенә тоз сибеп тыккан теге бәләкәй ипиләре белән шишарасы бигрәк тә матур булып, кызарып пешкән иде түтәйнең. Без табынга утыргач кына күршенең Ләүхия җиңги килеп керде.

— Ылапаска утынга чыкканыем,— дип башлады ул сүзен,— бөтен ишегалдына шундый да тәмле хуш ис таралган — башларың әйләнеп китәрлек! Каян килә соң, дим, борыннарны кытыклый торган мондый да татлы күмәч исе? Иснәп-иснәп тордым да, тукта, дим, Хөршитбану ипи сала түгел микән? Алар морҗасыннан чыккан шикелле бу, дим. Ипи исе әкәмәт тә хикмәт нәстә бит ул: бөтен дөньяга таралыр ди, «Мин пештем! Авыз итегез!» дип әйтеп әйтеп чакырыр ди.

— Әйдүк, җиңги, әйдүк, табынга уз!— диде әнәй чырае ачылып.— Мактап кына йөрисең икән, нәкъ өстенә туры килдең. Чыннап та, Хөршитбану бик тәмле ипи пешергән шул, күз генә тимәсен балакаема.

Без, урталай ярып кискән бәләкәй ипиләрне кетердәтеп чәйни-чәйни, бик озаклап чәй эчтек. Шишараны да бик мактады җиңги. Сүзләре дә күбәйгән икән: этәйдән хат-хәбәр бармыйдан башлап, кышның суык килүен, кемнең ашарына беткәнен, кем сыерын сатып он алганын, язгаҗәйгә ничек барып тоташырбыз дип хафалануларын сөйләшеп утырдылар. Кышкы көн — бер карыш, дигәндәй, өйгә караңгы керде, түтәй ут яндырып, самаварны яңартып китерде. Сүз яңадан безнең өйдәге хәлләргә кайтты.

— Болай каты сырхаулап китүләреңне Пәрхуллага язмадыңмы соң син, Гайшә?— диде җиңги.— Дөрес, бу авыр кышны бер уздырып җибәрсәк, болай да терелерсең терелүен алла теләсә.

— Сабыр итик әле, җиңги,— диде әнәй, бик үк ачылып китәсе килмәгәндәй.— Барып эшкә генә керешкән бит әле ул... Борчымаска исәплидерием хәзергә...

— Анысы шулай шулаен да...— дип куйды җиңги.— Түлке менә кеше сүзе — каһәр суккыры: «Пәрхулла җаратмый икән, шуңар күрә чирле көенчә ташлап чыгып киткән икән», дип лыгырдыйлар бит...

Көн буе мич каршында биегән түтәйнең күзләре йомыла башлады. Ул кече якка урын җәйде дә: «Әйдә, ылан, нәвем базарына китәбез», диде. Мин дә, мондый авыр сүзләрне тыңлап утырасым килмичә, иске толып астына чумдым һәм эреп киткәнне сизми дә калганмын...

Иртәгесен бер агач утын күтәреп сабак өенә киттем. Түтәй хәзер рәтләп йөри алмый, өй эше белән бүленеп кала. Кайсы көннәрне Һади белән, Гыйльметтин белән урамда ук очрашам, бергә барабыз, бергә утырып, «кәпсен кәләм асылый»ны такмаклый башлыйбыз. Сабак уку миңа никтер артык авыр түгел, тиз бикләп алам, китап битендәге билгеләр дә миңа хәзер төрле-төрле булып күренә — хәреф танырга маташам бугай, ахры. Өйдә дә әнәйгә тыңлатып күрсәткәч: «Рәхмәт, улым, сабагыңны белеп кайткансың», дигән сүзне ишетәм. Борын өскә күтәре-

леп китә, ә күнел алай түгел. Өйгә кайткач нигәдер бигрәк тә көйсезләнә башлый ул. Әнәйнен суык тию чиреннән болай озак ятуы да әллә ничек жанны кыерсытып торган кук. Әтәйне дә сагынам бугай, ахры. Аңа үз кулым белән, үз сүзем белән хат язасы килә. Ә абыстай безне язарга өйрәтми әле. Ничек өйрәнергә соң? Әгәр өйрәнсәм: «Кайт, әтәй, кайт! Безгә читен син булмагач», дип язар идем мин аңа. Шуна күрә мин аның хатын сорап алам да, ян тәрәзә төбенә җәеп салып, үз кәгаземә күчереп язам. Тик рәтләп танып кына булмый, нәрсә күчергәнемне генә белмим... Ул минңа быел китәр алдыннан гына чана да ясап биргән иде. Такта чана, бик жинел, бик матур. Тик, астында калае булмагач, бик шәп шумый, чишмә тавыннан выжлап төшкәндә, бүтән малайларныкыннан уздырып жибәреп булмый...

Бүген дә шул чананы калтыр-кылтыр өстерәп, итәкләр катканчы шуып, караңгы төшкәч кенә кайттым. Өсне чишенеп, юеш ыштанны алмаштырып, түр башына менгәч, Шамил белән уйнаган булдым. Ул хәзер бишегеннән чыгып килә инде, сәке буйлап үрмәләгән була, ике кулыннан тотып бастырсаң, «тәтәй тора». Үсә бит торна ташлаган нәмәстәкәй! Шулай да андый вак черки белән уйнавы кызык түгел, әз генә кагылдыңмы, хәзер сытыла башлый...

Түтәй, табак тутырып, бик тәмле бәрәңге пешереп китерде. Без жин сызганып сыпырганда әнәй ике генә бәрәнге ашады... Аннары чәй эчтек. Табынны жыештыргач, түтәй тәрәшле ясарга кереште. Әнәй минем сабак өендә ертып кайткан бишмәт жинен ямый башлады. Безгә кич утырырга керүче кызлар юк инде хәзер. Шәмсурыйттәй дә, Нәфисәттәй дә кияүгә киттеләр. Берсе Тәкәнештә, берсе Чыршы арты дигән авылда. Кияүләре белән кунакка килгәч, түтәйгә исле сабын, миңа чуклы канфит бирделәр. Канфитлары тәмле булса да, Нәфисәттәйләр үзләре кич утырырга кермәгәч, күңелле түгел икән. Мысыр күгәрчене тавышы белән өйне яңгыратып көлүчеләр дә юк, уен-көлке сөйләшү, шаулатып жырлау да юк. Түтәй белән мин жырлый башласам, икебез ике аеры чабабыз. Бүген дә менә шулай: ул башлагач, ян сәкедә мәчет ясап утырган жирдән мин дә кушылып караган идем дә, көйләребез кипкән борчак шикелле төрле якка тәгәрәде дә китте. Башта көлешеп алган булдык та тынышып калдык. Өй эчен шыксыз бушлык баскандай булды. Белмим, шул бушлыктан качар өченме, хәле-уйлары жинел булмаганмы, әллә электән үк жыр яраткан гадәте буенчамы, хәсрәтле генә тавыш белән әнәй үзе жырлап жибәрде. Инде икенче тапкыр ишетәм, һаман шуны жырлый:

Иске зират өсләрендә
Кычкыра күке баласы.
Кычкырма күке баласы,
Без дә шунда барасы...

Ник алай дип жырлый икән ул? Иске зират арыякта, Иске тауда бит ул. Анда күке кычкырырлык бер агач та юк, малайлар аннан жиләк тә тапмый, ул өч-дүрт кенә каберле киртәсез зиратка кеше дә барып йөрми. Ә ник соң әнәй: «Без дә шунда барасы» дип жырлый?..

*Дәвамы бар*

Илдар Юзеев

# ТАШ ДИВАРЛАР АВАЗЫ

ПОЭМА

Мин гүя өнсез-авазсыз,
Җилкәнсез-юлсыз кораб —
Тын тордым еллар, гасырлар,
Сулар агышын карап.
Шомлы, куркыныч зиндан мин.
Миңа нур кергәне юк,
Эчләремдә бераүнең дә
Елмаеп йөргәне юк.
Мин төрмә. Шашкын акылга,
Ирек-хыялга төрмә.
Әй, шагыйрь, йөрмә якында,
Яныма килә күрмә.
Мәңге салкын ташларымда
Уй-хисләр, серләр саклыйм,
Беркем дә укый алмаган
Сүзләр, шигырьләр саклыйм.
Диварларда: Хыял. Каргыш.
Васыятьләр. Сатылу.
Нәфрәт. Сөю. Шашу. Качу.
Хыянәт. Үч. Атылу.
Кер, шагыйрь, шашкын ирләрнең
Җуелган эзен табыйк.
Һәр дивар — көйсез хикәя.
Һәр дивар — моңсу тарих.
Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымданиләр барын.
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.
...Борын-борын заманнарда
Таш идем мин, ком идем.
Су җәелгән яланнарда
Йөгерек дулкын идем.
Уйнадым, көлдем, кагындым,
Ярсыдым ул чагында.
Иркәләндем, назландым мин
Ике яр кочагында.
Торналар да ояларын
Үзәнгә корган иде,
«Бергә торыйк» дигән сыман
Кычкыра торган иде.

Кешеләр — җир балалары
Тигезләр, хөрләр иде.
Ерткычка каршы барганда,
Һәммәсе бердәм иде.
Көттем миннән — ком-ташлардан
Сарай корырлар диеп,
Туфрагыма шатлык чәчеп,
Бәхет урырлар диеп.
Җир белән дә, су белән дә
Ул вакыт тигез булдым...
Нигә соң газап-кайгыга —
Төрмәгә нигез булдым?
Камчы эзләре уелган
Таш булып катып калдым,
Коллар күзеннән коелган
Яшь булып ятып калдым.
Тыңла, шагыйрь, мине төзгән
Колларның хәсрәт җырын,
Адәмнәрнең адәмнәргә
Аталган нәфрәт җырын.

## ҖИР АСТЫННАН КОЛЛАР ҖЫРЫ

**Без — коллар, без төрмә төзибез,**
**һай, авыр,**
**Мөмкинме язмыштан качулар?**
**Диварны гөл белән бизибез,**
**Ә гөлләр кан сыман алсулар,**
**һай, авыр.**
**Без төрмә төзибез, без — коллар,**
**һай, авыр,**
**Мәңгегә үзгәрмәс кануннар,**
**Без — коллар, чыдамнар, сабырлар**
**Дүрт дивар эчендә калырлар,**
**һай, авыр.**
**Камчылар үзәкне өзәләр,**
**һай, авыр,**
**Бергәләп күтәрик, әйдәгез,**
**һай, авыр,**
**Ташларны башларга тезәләр:**
**Нигезгә салыныр гәүдәбез,**
**һай, авыр!..**
Коллар, сизеп, баш күтәрде:
Тик алар соңладылар,
Дүрт диварым эчләрендә
Богаулар чыңладылар.
Белмәдем ни икәнемне...
Мин инде әзер идем...
Мине төзгән коллар өчен...
Зинданга әверелдем.

Ялвардылар коллар:
— **Зинһар, зиндан, ач ишегең, без чыгыйк,**
**Юкса, синдә үләбез бит тончыгып.**
Ә мин әйттем:
— Җаныгызны кая куяр урын юк.
Мин бары таш, ачар идем — кулым юк.

Сорадылар коллар:
— Әйтче, зиндан, нигә безне яптылар,
Хакыйкатьне җинаять дип таптылар?
Ә мин әйттем:
— Үземнең дә тыныч узган төнем юк...
Мин бары таш, аңлатырлык телем юк.
Сорадылар коллар:
— Күрче, зиндан, хаклык җирдә таптала,
Вөҗдансызлык һәм түбәнлек мактала?
Ә мин әйттем:
— Күрәм: сездә башка чыдар түзем юк,
Мин бары таш, нишлим: ике күзем юк.
Сорадылар коллар:
— Бирче, зинһар, киңәш, ничек түзәргә?
Хакыйкатьне кайдан, ничек эзләргә?
Ә мин әйттем:
— Мин бары таш, Кеше, сора үзеңнән:
Йөрәгеңнән, кулың, телең, күзеңнән...
Зар булып кояш нурына
Ал таңнар аткан саен,
Күтәрелдем югарыга
Вәхшилек арткан саен.
Кемнәр генә үтмәделәр
Диварларыма карап!
Үтерүче, сатлык, хаин,
Фахишә, угры-карак...
Җанлылар ничек түзәдер,
Мин бары таш, мин түзәм,
Тоткыннар, бәлки, сизәдер,
Адәмнән өмет өзәм.
Бар икән ич дөреслектән
Өметне өзмәүчеләр,
Кешелектән, җирдән, күктән
Хакыйкать эзләүчеләр.
...Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымда ниләр барын,
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.

*1000 ЕЛ. ШӘҺРИ БОЛГАР.*
*ЗИНДАН. БИЛГЕСЕЗ БОЛГАР ЧӘЧӘНЕ.*

Юллар арасыннан,
Коллар арасыннан
Кузгалдым мин сызып сазымны,
Идел — туган өем,
Кыйссам, сүзем, көем
Каен тузларына язылды.
Ак каеннар яфрак ярдылар,
Сүзләремне көйгә салдылар.
Кызыктырып данга,
Китерделәр ханга,
«Нә боерсам — булыр шул»,— диер.
Сән кол,— диер,
Былбыл чәчән
Бәнем сараемда бул»,— диер.

Читлектәге кошлар алдыйлар.
Гыйбрәт ал да бездә кал, диләр.
«Күкрәгемдә йөрәк
Ирекле кош сымак,
Тәхетеңне мактап сайрамам,
Кулым уйнаганда,
Сазын куймаганда,
Мин хурлыклы юлны сайламам».
Моңлы сазны тартып алдылар,
Кулларыма богау салдылар.
Киттем Идел буйлап,
Ил әхвәлен уйлап,
Күз күрмәгән хәлләр күрдем мин:
Кан-яшь, аh-зарын да,
Коллар базарында
Кулсыз-сазсыз җырлап йөрдем мин.
Олуг ханга алып бардылар,
Күзләремне чокып алдылар.
Урман-кырлар үттем,
Чулман-суга җиттем,
Күңел күзен илгә сөйләдем:
Дәрья-таулар гиздем,
Ишеттем мин, сиздем:
Җил хәбәрен илгә сөйләдем.
Олуг ханга алып бардылар,
Колагыма агу салдылар.
Бар байлыгым минем —
Туган илем, телем,
Юк гаиләм, өем, атым да...
Телне көйләдем мин,
Хаклык сөйләдем мин
Ханның явызлыгы хакында.
Олуг ханга алып бардылар...
Илне, телне тартып алдылар.
Бетте читтә хәлем,
Мәҗрух [1] күңелем-тәнем,
Туфрак-ләхет кирәк җырчыңа.
Кайттым картлыгымда,
Туган туфрагымда
Йөрәгемнән мәхзун [2] җыр чыга.
Олуг ханга алып бардылар...
Тар зинданга илтеп салдылар.
Онытмаслар әле,
Корытмаслар әле
Каеннарны кардәш-болгарлар,
Җырлап үлде диеп,
Каберемне сөеп,
Ташларыма ятып еларлар.
Ак каеннар язып алдылар,
Җырларымны көйләп калдылар.
Идел ага торып,
Дулкын кага торып,
Еллар елга булып агарлар,
Кол чәчәннең атын,

[1] Мәҗрух — яралы.
[2] Мәхзун — кайгылы.

Соңгы әманәтен
Каен тузларыннан табарлар.
    Зиндан-таш кабергә салдылар,
    Каеннарым сыктап калдылар.

*1 600 ЕЛ. РИМ. ТОР-ДИ-НОН ТӨРМӘСЕ.*
*ГАЛИ АКЫЛ ИЯСЕ ДЖОРДАНО БРУНО.*

Хакыйкать таңы
Атмаган Җирдә,
Чиркәү гөмбәзе
Кояшлы күкне
Каплаган Җирдә,—
Күкләргә аштым,
Кояшка бактым,
Галәмнән хаклык
Эзләдем — таптым.
Нурланды күңел,
Яктырды күгем:
Чиксез ул Галәм,
Җир ялгыз түгел!..
Диңгездә кораб
Сыман йөзә ул,
Әйләнеп йөри
Кояш тирәли.
Шушы иманга
Тугры булганга,
Ябып куйдылар
Кысан зинданга.
Чиркәү чаңнары
Шомлы кагалар,
Мәйданда инде
Утлар ягалар.
Хакыйкать өчен
Янармын дөрләп,
Ваз кичкәнемне
Көтмәсен җәллад.
Күрерсең, Кеше,
Яктыргач күгең:
Чиксез ул Галәм,
Җир    ялгыз түгел!
Төтенгә-көлгә
Әйләнермен мин,
Ләкин барыбер
Кояш тирәли
Әйләнермен мин,
    Әйләнермен мин,
    Әйләнермен мин!..

*ИЗГЕ ИОАННЫҢ ҖӘЗАЛАУ ТУГАНЛЫГЫ*
*ХРОНИКАСЫННАН. 19 ФЕВРАЛЬ, 1600 ЕЛ.*

*«Пәнҗешәмбе көнне иртә белән чәчәкләр мәйданында җинаятьче-дәһри Джордано Бруно тере килеш утта яндырылды...»*

Кемнәрне генә күрмәдем,
Ни генә ишетмәдем,

Ачканнар белә төрмәнең
Дәһшәтле ишекләрен...
Берләр миндә югалдылар
Хәбәрсез-гаип булып,
Берләр мәңгегә калдылар
Онытылмас бәет булып.
...Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымда ниләр барын,
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.

*1774 ЕЛ. КАЗАН ТӨРМӘСЕ.*
*ПУГАЧЕВ ПОЛКОВНИГЫ МӘСӘГУТ ГОМӘРОВ.*

**Торна дип йөртәләр,**
**Хурланмыйм һич тә мин,**
**Яратам кошларның**
**Кайтканын, киткәнен.**
**Белмисез әле сез**
**Торналар нәселен.**
**Хыялы — тирәндә,**
**Ачуы — яшерен.**
**Кайдадыр еракта**
**Торналар кычкыра,**
**Кошларның ирегә —**
**Безгә тик төш кенә.**
**Лашманчы[1] нужасын**
**Күтәргән бер малай**
**Йөрим мин урманда**
**Адашкан торнадай.**
**Кем килеп юатыр,**
**Кар-буран — бар кадер,**
**Патшага ил — Сарай,**
**Ә безгә — тар кабер.**
**Ишеттем шул вакыт:**
**Ярлы-кол халыктан**
**Безнең үз патшабыз**
**Рәсәйдә калыккан.**
**Йөз еллык наратлар,**
**Иманнар ектым мин,**
**Карурман эченнән**
**Атылып чыктым мин.**
**Иелгән башымны**
**Күтәрдем югары,**
**Әйдәде еракка**
**Киек кош юллары.**
**Меңләгән кешене**
**Ияртем артымнан.**
**Боярлар өркеде**
**Ярсыган атымнан,**
**Пугачев патшага**
**Олылап баш ордым,**
**Указын, әмерен**
**Ил-йортка тапшырдым:**

---

[1] Лашманчы — кораб агачы хәзерләүче.

«Ярлылар һәм коллар!
Җир бирәм җирсезгә,
Су бирәм, тоз бирәм,
Дин бирәм мин сезгә.
Кем бояр, янарал;
Туптан ут ачыгыз,
Байлыгын алыгыз,
Кисегез, асыгыз!»
Айкадым кылычны,
Атыма сызгырдым,
Алпавыт, морзаның
Оясын туздырдым.
Өздем мин коллыкның
Мәңгелек чылбырын,
Иректә яшәдем
Гомеремнең бер елын.
Гомеремнең бер елы
Тәмле бер төш кебек,
Очты ул бик озак
Кайтмаслык кош кебек.
Бәхил бул, Мамадыш,
Бәхил бул, Минзәлә.
Аяк-кул богауда,
Мин ятам төрмәдә.
Җыенга чакырып
Залимнар чаң кага,
Дарларда асылган
Дусларым чайкала.
Бар халык алдында
Мин ятам йөзтүбән,
Торналар, елашып,
Узалар өстемнән.
Үч ала дошманың,
Түз, чыда, Мәсәгут.
Тимерне кыздырып
Маңгайга баса ут.
Мин инде үкенмәм,
Мин инде еламам,
Бил бөгеп, баш орып
Мәрхәмәт сорамам.
Җанымда ничәдер,
Битемдә — өч тамга,
Тәнемә сугалар,
Сугалар вөҗданга.
Дошманда — тантана,
Җәзалап тәм таба,
Чаж да чож, чаж да чож
Йөз илле мәртәбә,
Йөз илле мәртәбә!
— Идеңме башыңны?!
— Кердеңме тәртәгә?!
Чаж да чож, чаж да чож
Йөз илле мәртәбә,
Йөз илле мәртәбә.
Тән чыдар, җан чыдар,
Чыжылдый камчылар,
Йөз илле мәртәбә,

Йөз илле мәртәбә
Чәчри ал тамчылар.
Җан чыгар, җәлладлар
Гәүдәмне яшерер,
Йөз илле яз булыр,
Йөз илле көз булыр,
Йөз илле эз булыр,
Онытма, нәселем.
Мәңгелек каторга —
Патшаның хөкеме.
Юл тулы богаулы
Дусларым төркеме.
Колодка кидереп,
Тезделәр чылбырга,
Кайтмаска китәбез,
Туганым, кул болга.
Бәхил бул, Иделем,
Чулманым, Ык суы,
Сулкылдый йөрәктә
Торналар үксүе.
Баш бирми болында
Чапкандыр аткаем.
Миндәй бер егетне
Атландыр, аткаем.
Чылбырдай тезелеп,
Торналар кайтырлар,
Каторжан Мәсәгут
Хәлләрен әйтерләр:
«Көтмәгез, ул кайтмас,
Мәсәгут каторжан.
Җан бирде, тик башын
Имәде батыр җан».
Хуҗасын юксынып,
Туратым пошкырыр,
Урманнар өстендә
Торналар кычкырыр.
Мин инде кайтмамын,
Мин инде китмәмен
Яларын, көзләрен
Торналар шикелле.
Канатны каера,
Илемнән аера,
Сөенмә, и палач,
Торнаның нәселе
Илендә кала ич,
Озата бара ич!
Белерсез әле сез
Торналар нәселен,
Хыялы — тирәндә,
Нәфрәте — яшерен.
Иелмә, бунтарь баш,
Йөрәгем, бирешмә.
Күтәрәм башымны,
Югары күтәрәм
Чылбырлы килеш тә!
Еракта-еракта
Торналар чылбыры,

**Бәхил бул, гомеремнең**
**Бәхетле бер елы...**
**Бәхил бул...**

**Күпләр тынды. Тик чыңлады**
**Көннәр-төннәр зынҗыры.**
**Диварларымда тынмады**
**Туу һәм үлем җыры.**
**Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен**
**Ташымданиләр барын.**
**Серле китап битләредәй**
**Ачылыр диварларым.**

*1881 ЕЛ. ПЕТЕРБУРГ.*
*ПЕТРОПАВЕЛ КРЕПОСТЕ.*

*Туу җырын көйләүче гали зат Н. И. Кибальчич иде. Аның җитәкчелегендә ясалган бомба белән Александр I үтерелде.*

*Зинданда галим реактив очу аппаратының сызымын уйлап тапты. Үлемгә киту алдыннан гали ата «төрмәдә туган бала»сын — кәгазь сызымны кочаклап, туу җырын җырлады...*

**Күрмәсәм дә тәрәзәдән**
**Ерак өмет йолдызын,**
**Карт диварлар арасында**
**Йокламыйча төнозын**
**Мин сине уйлап тудырдым,**
**Син әле — кәгазь-сызым.**
**Син тудың, атаң — дар кетә,**
**Сау-бәхил бул, йолдызым.**
**Тар зинданнан киң галәмгә**
**Юнәлергә теләдем,**
**Теләгемне хыялдагы**
**Йолдызларга сөйләдем.**
**Тар зиндан — синең бишегең,**
**Алга, артка — өч адым.**
**Тоеп кал син әтиеңнең**
**Суынчак кочагын.**
**Үтерүче дип аталдым,**
**Ата дип аталмадым.**
**Патшаны юк иттем, ләкин**
**Төрмәне ваталмадым.**
**Куркытмый мине бу үлем:**
**Җир, Кояш, Галәм кала.**
**Күккә очарга омтылып,**
**Зинданда балам кала.**
**Баш очында — син барасы**
**Йолдызлар кабынырмы,**
**Серле йокыңнан уятыр**
**Гали зат табылырмы?**
**Соң мәртәбә чәчләремне**
**Җилдә туздырып үтәм.**
**Залим патшаны үтереп,**
**Сине тудырып китәм...**

*1769 елны Ярославль шәһәр администрациясе, төрмә җәллады картаеп хәлсезләнгәч, урамнарга белдерүләр эльде:*
*«Халык игътибарына!*
*Шәһәр канцеляриясендә казна хисабына баш кисү остасы булып эшләргә теләүче кеше безгә мөрәҗәгать итсен».*

**Кем ул җырлый туу җырын!**
**Күкләргә үрелә кем анда?**
**Мин килдем.**
**Тукта! Тын!**
**Тавыш-өн чыкмасын зинданда!**
**Мин килдем!**
**Тукта! Кем?**
**Кем карый күктәге торнага?**
**Кемнәр ул башларын калкыта?!**
**Белегез:**
**буйсынмас адәмне**
**балта йә дар көтә!**
**Мин килдем!**
**Мин адәм!**
**Үзем дә**
**көчлегә баш орам.**
**Мин казна кешесе:**
**көчлеләр карарын тормышка ашырам.**
**Мин килдем.**
**Кодрәтем алдында**
**төрмәләр, диварлар калтырар!**
**Башың и, бунтарь җан!**
**Имәсәң —**
**айбалта йә кылыч ялтырар!**
**Мин килдем.**
**Җиңемне сызгандым.**
**Мин көтәм:**
**Йә, кемнең чираты?!**
**Төрмәгә сыймаган җаннарга**
**Киң, иркен бу дөнья-зинданның зираты.**
**Мин килдем!**
**Йә, кемнең чираты?!**

Озатып калган туу җыры
Матәмгә әверелде.
Кеше хаклык-иман өчен
Дарга да әзер иде.
Торналар һаман очтылар
Кычкырып-еламсырап,
«Туган илебез-зинданга
Кайтабыз» дигән сымак.
Диварымда күпме эзләр
Юк булып җуелдылар,
Әмма тоткын язган сүзләр
Ут булып уелдылар.
Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымда ниләр барын,
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.

Сүзләр уеп язылганнар
кан белән,
җан белән,
күз-яшь тамчысы белән,
палач камчысы белән,
таш белән,
баш белән,
җыр белән,
чылбыр һәм акбур белән...

1

Туганмын мин дөнья-зиндан бишегендә,
Мәүлә колы булып яши кеше монда,
Ачалмассың тәрәзен дә, ишеген дә,—
Тәкъдиреңне язып куйган ошбу дөнья!
Туганчы ук ак кәфенгә биләгәннәр,
«Уйна, сөен, ирекле бул» димәгәннәр,
Колагыма мәүләм сүзен көйләгәннәр:
Тәкъдиреңне язып куйган ошбу дөнья!
Зинданымның дүрт дивары тарта гүргә,
Кергәндә дә бишегеңнән тар кабергә,
Мәүлә колы икәнеңне күм хәтергә,—
Тәкъдиреңне язып куйган ошбу дөнья!

2

Аңларлар дип уйладым,
Башны орып еладым,
Өлешемне сорадым
Хуҗа,
тәңре,
патшадан.
«Аңладылар, күрделәр»,
Бәгыремне телделәр,
Мәсхәрәләп көлделәр
Патша,
тәңре,
хуҗалар.
Хәзер инде тезләнмим,
Түкмим яшьләр күздән мин,
Ачу белән көләм мин
Хуҗа,
патша,
тәңредән.
Шигыремне яктылар,
Куркыныч дип таптылар,
Өтермәгә яптылар
Патша,
хуҗа,
җәлладлар.
Аягүрә үләм мин,
Юк, еламыйм, көләм мин,
Курыкканын беләм мин
Хуҗа,
патша,
җәлладның.

3

*1821 елны декабрист Булатов үзе азат итәргә тиеш булган Петропавел крепосте казаматында диварга бәреп башын ярды.*

**Иң соңгы көч белән башымны**
**Диварга бәрәм мин: барыбер**
**Башка һич чара юк... Бер өмет:**
**Яки таш, яки баш ярылыр.**

4

*1847 елны Петропавел крепостенда 26 яшьлек рус кызы Мария Ветрова үз-үзен яндырды.*

**Мин дөньяны яндырырга теләдем,—**
**булмады,**
**Мин диварны яндырырга теләдем,—**
**булмады,**
**Ут төртәм дә инде үземне яндырам,—**
**Бәлки, дөрләр дөнья — инсан зинданы.**

**Янды адәм, ярылды баш,**
**Тик ташлар ярылмады,**
**Дивардагы мең сорауның**
**Җавабы табылмады.**
**Буйсын, кеше, җир-тәмугның**
**Утларында яна тор...**
**Коткарса бары коткарыр**
**Алла, патша, йә батыр...**
**Бармы галәмдә гали зат?**
**Күктә? Җирдә? Әллә соң**
**Әзлиме адәм үзенә**
**Яшеренгән алласын?..**
**Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен**
**Ташымда ниләр барын.**
**Серле китап битләредәй**
**Ачылыр диварларым.**
**Ул зат килде... Көннәр-төннәр**
**Уйланып-атлап йөрде.**
**Дивардагы сорауларны**
**Укып-кабатлап йөрде.**
**Икмәк-кара савытына**
**Салынган сөткә манып,**
**Сөттәй ак кәгазь битенә**
**Язды ул төнен янып.**
**Акылының галилеген,**
**Сүзенең гадилеген**
**Кушып язган хакыйкатьне**
**Һәр тоткын аңлый иде.**

***В. И. Ленин үндүрт ай патша төрмәсендә утырды. Сакчылардан яшерү өчен, ул икмәктән кара савыты ясый, аңа сөт сала һәм каләмен манып, китап битенә яза иде.***

## СӨТ БЕЛӘН ЯЗЫЛГАН ХАКЫЙКАТЬ

**Башларны идергән язмышка**
**Иң катгый, иң гадел сүзебез:**
**Алла да, патша да, батыр да**
**Үзебез! Үзебез! Үзебез!**
**Көрәшкә, иң изге көрәшкә!**
**Коллыкның чылбырын өзегез.**
**Юк, безне беркем дә коткармас:**
**Үзебез! Үзебез! Үзебез!**
**Чүкечле-ураклы кул белән**
**Тигезлек дөньясы төзегез,**
**Азатлык бары шул юл белән:**
**Үзебез! Үзебез! Үзебез!**

Күптән көткән җырны барча
Юксыллар кабатлады...
Сукты ич изге көрәшнең
Хәлиткеч набатлары!
Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымда ниләр барын,
Иң гали кеше турында
Җыр саклый диварларым.

## ИҢ ГАДИ ҺӘМ ГАЛИ ЗАТ ТУРЫНДА ТОТКЫННАР ҖЫРЫ

**Зинданда тонык шәм кабынды...**
**Расланды уй, хыял, төшебез.**
**Гасырлар көткән зат табылды:**
**Иң гади, иң гали Кешебез.**
**Ул безнең үзебез шикелле:**
**Киңәшче, дустыбыз, ишебез,**
**Тоткынлык газабын кичерде**
**Иң гади, иң гали Кешебез.**
**Кап-кара икмәккә манылыш,**
**Сөт белән язылган хисебез,**
**Хакыйкать юлына юнәлтте**
**Иң гади, иң гали Кешебез.**
**Коллыктан котылмый суынмас**
**Патшага-залимга үчебез.**
**Золымны җиңәргә өйрәтте**
**Иң гади, иң гали Кешебез.**
**Кирәксә җанны да бирербез**
**Сөттәй ак Хакыйкать өчен без,**
**Алып бар зур авыр көрәшкә,**
**Иң гади, иң гали Кешебез!**

Узды торналар чылбыры
Таралып минем өстән...
Килде ул көн... Атты туплар...
Тетрәндем сөенечтән.
Калдым зилзилә-давыллар,
Атышлар уртасында.

Өзелде коллык чылбыры
Җирнең бер кыйтгасында.
«Яшә, ирек! Бетсен газап!
Ишетмәде кайсыгыз?
Коллар, тоткыннар, сез — азат!»
«Ишекләрне ачыгыз!»
Бу минутны күпме еллар
Сызланып көтте Кеше,
Богауларыннан ычкынып,
Кузгалып китте Кеше.
Көттем: ирек дулкыннары
Килер дә ташкын булып,
Диңгезләрдә югалырмын
Мәңгегә таш-ком булып.
Әллә инде онытгыгыз,
Ташларымны сүтегез,
Нигеземне корытыгыз,
Акланды өметегез...
Һәммәсе китте Сарайга,
Тын гына торам көтеп...
...Ватмадылар, сакладылар
Нигәдер... корал тотып.
Калыкты явыз бәндәләр,
Мине алдарга теләп,
Бер өзелгән чылбырларны
Янә ялгарга теләп,
Азатлыкның йөрәгенә
Хәнҗәр кадарга теләп,
Бер ачылган Хакыйкатьне
Кабат ябарга теләп.
Ни ишетте диварларым:
«Һәрбер ил — зиндан булыр,
Җир-зинданның бүлмәләре,
Кол белән тулган булыр!»
Җир-илләрне төрмә итеп,
Вәхшиләр атладылар;
Торналар очты югары:
Төшәр җир тапмадылар.
Күренерлек түгел инде
Чикләрем-дәвамнарым...
Ишеттем мин төрле илнең
Сүзләрен-авазларын...
Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымда ниләр барын,
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.

## ТОТКЫННАРНЫҢ СОҢГЫ АВАЗЛАРЫ

### *ЗАКСЕНХАУЗЕН КОНЦЛАГЕРЕ.*

*Фамилиясе билгесез рус хәрби әсире:*

Разрушьте заборы, разбейте те стены,
Что так строго, сурово сегодня стоят.
(Дәһшәт салып торган коймаларның,
Диварларның барысын ватыгыз.)

*Фашист каторгасында үз-үзен үтергән унбиш яшьлек белорус кызы Катя Сусанина:*

Калі ты будзеш, тата, чытаць
гэто ліст, мяне не будзе ў жывых.
Ў я прашу цябе, бацька: аупомеці
фашыцкім вылюдкам. Гэта
апошняе слова твоей дачкі,
якая растаецца з жыццём.

**(Әти, син бу хатны укыганда, мин инде булмам. Минем соңгы үтенечем шул, әти, фашист канечкечләрдән үч ал. Бу — кызыңның соңгы васыяте.)**

*ПАНКРАЦ ТӨРМӘСЕ. Чех язучысы Юлиус Фучик:*

...JAK SE MI CHTĚLO BÝT
PTÁKEM, NEBO KEŘEM, OBLAKEM...
VŠIM, KDO MILUJE, JAKO I JÁ,
PROSTOR, SLUNCE A VÍTR...

**(...Минем очар кош яки куак, яки болыт... үзем кебек үк иркенлек, кояш һәм җилне сөйгән теләсә нәрсә буласым килгән иде...)**

*ГОЛЛАНДИЯ*
*Егерме биш ай кысан караңгы чардакта нацистлардан качып яшәгән унөч яшьлек еврей кызы Анна Франк:*

Helfen Sie doch mir führen
Sie mich aus dieser Hölle hinaus!

**(...Зинһар ярдәм итегез, мине бу тәмугтан чыгарыгыз!)**

*ФРАНЦИЯ.*
*Каршылык хәрәкәте группасы җитәкчесе Фелисьен Жоли:*

Je voudrais que toute
l'humanite etait heureuxe.
Je meus d'un jeune homme,
d'un très jeune homme.

**(Мин бөтен кешелекнең бәхетле булуын теләдем. Мин яшь килеш, бик яшь килеш дөньядан китәм...)**

*МОАБИТ ТӨРМӘСЕ*
*Татар шагыйре Муса Җәлил:*

**Килер ул көн, халык хөкем итәр,**
**Карар булыр кискен һәм кыска,**
**Каным белән язган соңгы җырым,**
**Бул гаепләү акты фашистка!**

Килде ул көн: очрашасы
Бар икән шатлык белән,
Иң гали һәм гади Кеше
Язган чын Хаклык белән!..
Исәннәр кайтты иленә,
Мин кинәт бушап калдым,
Ташландык бер хәрабәгә —
Зиратка охшап калдым.
Әй, кешеләр, җимерегез,
Җир белән тигез булыйм,
Бәхетлеләр яшәячәк
Сарайга нигез булыйм...
Әй, кешеләр, карыйм сезгә
Шәфкать-изгелек көтеп,
Ташлагыз таш-комнарымны
Диңгез ярына илтеп.
Таштай каткан күкрәгемне
Назлы дулкынга куеп,
Агыйм үземне кешедәй
Шат, горур, иркен тоеп...
Торналарым, бик биектән
Карыйсыз җирегезгә,
Киң кырларда очрашулар
Насыйптыр инде безгә?..

## ТОРНАЛАР ҖЫРЫ-ЛЕГЕНДАСЫ

Без күктә югартын очабыз,
Канатлар түбәнгә тарталар,
Җиркәйгә бик сирәк төшәбез:
Кешеләр кешене аталар.
Без күктә очабыз югартын:
Кешеләр ау-тозак корганнар,
Әлегә очасы юллар тын:
Юк монда богаулар, зинданнар...
Үзәндә-кырларда тусак та,
Өзелеп-аерылып киткәнбез,
Сугышсыз-зиндансыз Җиркәйгә
Бер заман төшәрбез микән без?

Инде дөнья ызгышлардан
Мәңгелеккә тынгандыр...
Кемне күрәм? Тагын тоткын...
Бәлки, соңгы корбандыр...
Тыңла, шагыйрь, мин сөйләрмен
Ташымданиләр барын.
Серле китап битләредәй
Ачылыр диварларым.

*1963. МАДРИД. КАРАБАНЧЕЛЬ ТӨРМӘСЕ.*

*Язгы бер таңда ирек җәлладлары үлем җәзасына хөкем ителгән Хулиан Гримауны атарга алып чыктылар. Ләйсән тамчылары аның керфекләреннән, соңгы сүзләрен пышылдаган иреннәреннән агып төште. Аның һәрбер сүзе кайнар тамчы булып тамды.*

**Ташкынны буалмас җәлладлар:**
**Мин бары диңгездән бер тамчы,**
**Хакыйкать юлында бу җирнең**
**Иң соңгы төткыны булсамчы...**
**Тамчылар ярамны юсыннар,**
**миннән соң,**
**Богауны музейга куйсыннар,**
**миннән соң,**
**Ал таңнар гел тыныч атсыннар,**
**миннән соң,**
**Диварлар ташкында аксыннар,**
**миннән соң,**
**Тоткыннар өйләргә кайтсыннар,**
**миннән соң,**
**Хөррият ишеген каксыннар,**
**миннән соң,**
**Торналар сәхралар кичсеннәр,**
**миннән соң,**
**Илемә-җиремә төшсеннәр,**
**миннән соң...**
**Ташкынны буалмас җәлладлар,**
**Мин бары аңардан бер тамчы,**
**Хакыйкать юлында бу җирнең**
**Иң соңгы төткыны булсамчы...**

Шул ташкыннар белән аксам,
Хыялый диңгеземә,
Мәңгегә китеп югалсам,
Ни булыр җир йөзенә?

Мин зиндан — катильгә, хаинга...
Җир кайчан вәхшәттән котылыр?
Әгәр мин югалсам, җәлладлар
Яңадан коралга тотыныр.
Мин көтәм...
дөньяны ут иткән,
Миллионлап адәмне юк иткән,
Ирекле халыкны кол иткән,
Гөлләрнең тамырын корыткан,
Янгын-көл, хәрабә калдырган,
Терелэй мичләрдә яндырган,
Сарайдан зинданнар салдырган,
Ташыма канлы яшь тамдырган
Иң түбән, иң явыз бәндәне...
Мин көтәм... Һәм тыңлыйм: кешелек
Дәһшәттән котылыр хәлдәме?
Бер бүлмә буш тора.
Мин көтәм
Гаепсез дип йөргән бәндәне
Котылган хөкемнән, төрмәдән,
Гүяки гаепсез күзләре.
Янәсе, беркем дә күрмәгән...
Ә җирдә җинаять эзләре.
Юк булган кешеләр, шәһәрләр
«Гаепсез солдатка» дәшәрләр,
Тетрәнеп бар дөнья кузгалыр,
Киләчәк исеменнән сүз алыр:

**I — Мин бүген каберемнән кузгалдым,**
**Мин шаһит, мин килдем, мин күрдем,**
**Хак хөкем исеменнән сүз алдым.**
**Син, катил, син мине үтердең!**
**Соңлаган карарны көтәмен...**
**Тереләй күмелгән ана мин.**

(Мин зиндан. Ә катил ни әйтер:
— Мин солдат. Боерык үтәдем,—
Үземне гаепле санамыйм?..)

**II — Ул хөкем залына килмәгән,**
**Ул кача, тизләтә адымын,**
**Һаман да тынгылык бирмәгән**
**Илбасар... Мин аны таныдым!**
**Тапмассыз — джунгли яшерер,**
**Эзләрен килсәң дә син эзләп.**
**Китте ул йөзләгән кешене,**
**Авылны җир белән тигезләп.**
**Син атып үтергән бала мин,**
**Җавап бир, хак хөкем көтәмен.**

(Мин зиндан. Ә катил ни әйтер?
— Үземне гаепле санамыйм,—
Мин солдат. Боерык үтәдем?..)

**III — Мең еллык яшәвен данлаган**
**Музей мин, урам мин, кеше мин.**
**Ә хәзер көлем дә калмаган,—**
**Картадан сызылган исемем.**
**Приборлар йөрәктәй кузгала,—**
**Мин сизмим, тик алар тоялар,**
**Син каберем өстеннән узганда,**
**Дерелдәп-дерелдәп куялар.**
**Син бомба ташлаган кала мин.**
**Җавап бир! Хак хөкем көтәмен.**

(Мин зиндан. Ә катил ни әйтер?
— Үземне гаепле санамыйм,—
Мин солдат. Боерык үтәдем?..)

**IV. — Мин дөнья. Зур дөнья галәмнән**
**Кечкенә шар булып күренә.**
**Мин тоеп, борчылып әйләнәм:**
**Кулларың бомбага үрелә.**
**Ә кинәт кучәрдән ычкынсам,**
**Үзем дә белмичә сәбәбен,**
**Бушлыкта тузандай юк булсам,—**
**Кем сорар, кем бирер җавабын:**
**— Син юкка чыгарган дөнья мин,**
**Нишләдең? Җавап бир... Көтәмен...**

(Мин зиндан. Ә катил ни әйтер?
— Үземне гаепле санамыйм,
Мин солдат. Боерык үтәдем?..)

Мин зиндан...
Матурлыкка кул сузучы
Вәхшилеккә зиндан мин.
Ә бит якты бу дөньяга
Таш-ком булып туганмын.
Күпме еллар газаплаган

Шикләремнән бушанам:
Җирне төзүче Кешенең
Кодрәтенә ышанам.
Күрдем йолдыз юлларында
Кибальчич оныкларын,
Ачылды күк капусыдай
Өметле офыкларым.
...Берчак кеше вәхшилеккә,
Явызлыкка чик куяр,
Тәмам иркен сулыш алып,
«Ул көн килде!» дип куяр.
Хыялыма алып китәр
Бу алтын сүзләр мине,
Синең кебек уйчан шагыйрь
Килер дә эзләр мине.
Тик мин булмам... таш күкрәгем
Назлы дулкынга куеп,
Агып китәрмен үземне
Шат, горур, азат тоеп.
Ул көн килер,— бер-береңә
Ышанмау-шикләр бетәр,
Илләр-телләр арасында
Таш дивар — чикләр бетәр.
Нурга, куакка, болытка,
Үзәнгә... әйләнермен,
Кояш тирәли мәңгегә
Туктамый әйләнермен.
Күңелдәге боз диварлар
Эрер дә агып китәр,
Җирдә гали затлар язган
Хаклык тантана итәр.
Сугыш-золымнар чигенер,
Богаулар өзелә барыр,
Чергән диварлар урнына
Сарайлар төзелә барыр.
Зиндансыз җирнең йөзенә
Кояш нур коя торыр,
Җиһанның һәр кыйтгасында
Торналар оя корыр.
...Мин гүя телле-авазлы,
Җилкәнле-юллы кораб.
Тирән хәсрәт суларында
Йөзәм диңгезгә карап.
Сау бул, шагыйрь, авыр-салмак
Ишекләремне ябыйк,
Һәр дивар — көйсез хикәя,
Һәр дивар — моңсу тарих.
Сөйлә, шагыйрь, көйгә салып
Ташымда нинәр барын.
...Ә хәзергә зиндан булып
Ябыла диварларым.

Июль, 1971 — январь, 1973.
Казан — Мәскәү.

Әхияр Хәкимов

# ОЧАР КОШЛАР

ПОВЕСТЬ

Бөек Ватан сугышында һәлак булган
комсомолецлар истәлегенә.

## Торналар чыңы



Ерак офык читендә таң беленә генә башлаган әле. Табигатьнең татлы йокыда изрәр чагы. Моннан ярты сәгать чамасы элек ул, чынлап та, талгын оеп, киң дәрьядан күтәрелгән һаумалдай [1] йомшак, сыек томан эчендә йөзә, дөньясын онытып йоклый иде. Әйтерсең сугыш та юк, үлем-кырылыш та...

Тик сугыш алласының йокысы сизгер, шәфкатьсез зиһене уяу: самолетларның ерак гөрелтесе эңгер тынлыгын бозуга җирдә гарасат купты, таң алдының илаһи тынлыгын пулеметларның аяусыз тырылдавы, зениткалар гөрселдәве челпәрәмә китерде. Күп тә үтми, кызгылт төскә кергән һавада ак ноктталар пәйда булды. Алар, җиргә якынайган саен зураеп, дистәләгән парашют чатырына әверелде...

Нәкъ энә шул танда № че десант бригадасының уналты яшьлек радисты Кәрим Атнабаев уйламаган-көтмәгән бәлагә тарыды да инде. Бүтән парашютчыларның кайсы тәңгәлгәрәк төшүен күзәтепме, күк йөзен телгәләгән яктырткыч пулялар сызымыннан, колак тондыргыч атыштан куркыпмы — ул җиргә якынлашуын абайламый калды. Аяк астында кинәт яфрак шыштырдавы, ботакларның шартлап сынганы ишетелде. Исен җыеп өлгергәндә, парашютының чатыры агачка эләгеп, Кәрим һавада асылынып тора иде.

Очраклы бу хәлнең акылга сыймас мәгънәсезлеге, үкенече шунда иде — яшь солдат, күзен чекерәйтеп, тирә-ягына күпме каранмасын, ул төшкән җирдә урман юк, анда-санда, берәм-сәрәм генә агач күренә иде. Кәрим эләккән ялгыз имән тирән чокыр читендә тора, урман исә, шушы ярга табан иңкәйгән сөзәк калкулыкның аргы ягында, карауга бер чакрым чамасы ары иде. Үзән өстенә ябырылырга җыенган яу төсле, ул тынып, сагаеп калган да алга шушы имән сымак берничә ялбыр пәһлеванын сакка чыгарып бастырган. Аста, үзәннең уртасында, таң алды эңгерендә ниндидер биналарның чак аерырлык тоныйк шәүләсе

[1] һаумал — яңа сауган бия сөте.

төсмерләнә. Яктырткыч пулялар нәкъ шул тәңгәлдән өерелеп чыга иде.

Өйрәнүләр вакытында берәр иптәшенең урман уртасына төшеп, парашюты агачка эләгүен, я, күлгә чумып, сусар сыман юешләнеп, бузарып чыгуын күргәне бар иде Кәримнең. Анда ни — эшнең азагы билгеле: суга төшкәне бер-ике көн йөткереп-төчкереп йөри дә — син күр дә мин; агачка эләккәне исә, битен-башын ботак сыдыруын исәпкә алмаганда, аннан да җиңелрәк котыла.

Анда бер хәл, монда — икенче шул. Бәхетеңә иптәшләрең килеп чыкса, ни әйтер идең. Десантчыларны ут ачып каршылаган дошман да тик ятмый. Тозакка эләккән кош кебек, учларына тупылдап төшәргә торасың. Бәлки парашютыңны ычкындырып та азапланмаслар, шушылай җилгә җилбердәп торган килеш шарт-шорт атарлар да китәрләр. Мондый хәлдә яхшылык көтү кыен, чөнки безнекеләр, аяклары исән-сау җиргә тиюгә, алдан тәгаен әйтелгән урынга — сунарчылар алачыгына ашыгачак. Текә яр өстендә «менә мин!» дип серәеп утырган ялгыз имән түгел, әнә теге карурман тартачак десантчыларны.

Кәрим елардай булып ирепен тешли, яктырып килгән күк йөзенә текәлеп, кай тирәгәрәк төшүен билгеләмәкче була. Ләкин самолетта килгәндә лейтенант Чукреев: «Сукыр кеше дә күрерлек»,— дигән билгеләрнең, ичмасам, берәрсе күзенә чалынса. Юк, лейтенант әйткән җил тегермәне дә, юл чатында торган биек кәшәнә[1] дә күренми. Аның каравы, кинәт зур дәрьяның куәтле сулышын тоеп, Кәрим бөтенләй аптырауга калды. Булмас, алай булырга тиеш түгел, дип күңеленнән күпме үҗәтләнмәсен, ул Днепрга якын гына төшүен аңлады. Самолетның ялгышуын хәтта күз алдына китерү дә кыен иде, Кәрим бар гаепне үз өстенә алды: «Һава агымына эләккәнмен, парашютыма баш була алмаганмын»,— дип уйлады ул. Ә бит Чукреев, Днепрдан егерме чакрым ары төшәбез, дип аңлаткан иде. Самолет моторына снаряд ярчыгы тиюен, шунлыктан десантчыларга биш кенә минутка элегрәк сикерергә боеруларын белми иде Кәрим. Немецлар оборонасының ике эшелоны уртасына туры килүен дә соңрак белде. Ә хәзергә мәгънәсез, очраклы шушы бәладән котылу юлын табарга тырышып, ул тирә-якта яңгыраган атыш тавышына колак сала, аста, үзән уртасында, дөрләп янган печән эскертеме, ниндидер бинамы янында чайкалышкан шәүләләрне күзәтә.

Хәле мөшкел иде егетнең: әгәр немецлар килеп чыкса, ул һичнинди каршылык күрсәтә алмаячак. Корал-ярагы, парашют элмәкләренә кысылып, култык астына табан шуышкан, автоматы, гранаталар сумкасы кымшандырырлык та түгел. «Җанлы мишень мин»,— дип уйлады Кәрим, көяләнеп. Шушы күңелсез уйны җөпләгәндәй, күкне яктырткыч пулялар сызымы каеп үтте.

Очраклы ярдәмгә өметләнеп, шушылай асылынып торудан мәгънә юк. Кәримнең аягын көзән җыера башлады, парашют элмәге кыскан кулбашы сулкылдап сызлый иде. Үзен әсир иткән имән кәүсәсенә ябышырга тырышып, ул җан ачуы белән атынырга тотынды. Тик моннан берни дә барып чыкмады, аяк-кулы гына баягыдан да яманрак сулкылдады, күкрәгенә беркетелгән «РБ» рациясенең батареялар тартмасы авырттырып иягенә бәрелде. Туктарга ярамый, ярамый! Ул, парашют җепләренә ябышып, бар көченә өскә тартылды һәм, ниһаять, автоматының җай гына алга шууын тойды. Җиңел сулап, шабыр тиргә баткан маңгаен учы белән сыпырды, автоматының салкын көбәген сыйпап куйды.

Тик куанычы күпкә бармады, яр астында үлән кыштырдаганы, кемнеңдер уфылдап тын алганы ишетелде. Тәне эсселе-суыклы булып,

[1] Кәшәнә — часовня.

Кәрим затворны артка күчереп куйды, автоматын әлеге тавыш килгән якка, караңгы яр астына төбәп:

— Кузгаласы булма, атып үтерәм! — дип кычкырды.

Имән төбенә үрмәләп менеп житкән карачкы әллә аңлады бу искәртүне, әллә юк — аһылдап жиргә ауды да, русчалап:

— Исәрләнмә, яме... Тын алганны көт. Берәр әмәлен табарбыз,— диде.

Кәримнең кабыргасына ниндидер каты нәрсә килеп терәлде, ул да түгел, гәүдәсе агач кәүсәсенә таба бара башлады. Ниһаять, кулы кытыршы имән кайрысын тойды. Тырнакларын каера-каера, ул бар көченә зур гына ботакка ябышты.

— Я, кызурак кылан, хәзер бастырып килеп житә тегеләр,— диде Кәримнең коткаручысы.— Ишетәсеңме?

Астан, вак куаклык арасыннан, эт өргәне, ят телдә акырышкан тавышлар торган саен ачыграк ишетелә. Парашютны агачтан ычкындырып, яшереп торырга вакытлары юк иде. Коткаручысын төсмерләп тә өлгерми, Кәрим аның артыннан йөгерде. Бәладән котылу куанычы, татлы төер булып, тамагын өйки, буыннарын язылдырып, бөтен тәненә тарала. Җилкәсенә аскан йөгенең авырлыгын да тоймый, ул, йөгәнен салып качкан кырыкмыш тай сымак, оча-калка алга омтылды.

Ах-ух килеп бер тын йөгергәч, юлдашы туктады, тирә-ягына колак салды, жиргә утырып, итек табанына ябышкан балчыкны кырып ташлады. Шушы шөгыленнән туктамый гына:

— Кайсы бригададан син? — дип сорады.

Кәрим үз бригадасының шартлы номерын әйтте. Сине үлемнән коткарган кеше белән качышлы уйнап торыр чакмы? Күренеп тора — безнең солдат, житмәсә, Кәрим аны кайдадыр күргән кебек әле.

— Үзебезнеке булып чыктың,— диде солдат та.

Тавышыннан куанганын да, ризасызлыгын да белү кыен иде. Хәер, ризамы син, юкмы — язмыш синең юлыңа коты чыккан шушы үсмер солдатны чыгарып куйган икән — сыкранмый-нитми кабул итәсең. Нигә әйтсәң дә, моннан ары ялгыз түгелсең. Файдасы тиярме, юкмы — әмма иптәшле булдың.

— Яры-й,— диде солдат,— фриц торып калды шикелле... Мине танымыйсыңмы соң? Я? Соң Рябчиков лабаса мин, оружейный мастер! Таныдыңмы? Вот, молодец! Ваня Рябчиков белән хур булмассың!

Әйе, бу, чынлап та, корал-ярак төзәтүче оста, телең, халык әйтмешли, шайтан төкергән, жор сүзле Ваня Рябчиков иде. Моннан бер-ике ай элек, бригадалары Мәскәү янында торган чакта, Кәрим аның мастерскоена мушкасы кыйшайган өч-дүрт автомат алып барган иде. Ваняның әллә нинди көйле догамы, такмакмы әйтеп, батыраеп тотынуы бүгенгедәй исендә. «Жили-были дед да баба, ели кашу с молоком. Рассердился дед на бабу — хлоп по пузу кулаком!» — дип, Рябчиков, аңгармастан, аның корсагына төртергә үрелгән булып, тегесе ике кулы белән сагаючан хәрәкәт ясагач, кара майга буялып беткән бармаклары белән Кәримнең борынын кысып алган иде. Тагын шунысы да хәтерендә — солдатлар, Рябчиковтан ишеттем дип, әледән-әле һәртөрле көлке сүз, әдәп ягы чамалы мәзәк сөйләп, эчләрен уып көлешә торган иде...

— Алай да йомшак урын сайлагансың, молодец. Мин каты юл өстенә килеп төштем,— диде Ваня көлеп,— нишләптер танымыйм сине, әллә яңаларданмы?

— Нишләп яңалардан булыйм ди! Өч ай инде Чукреев карамагында.

Яшь солдатның үпкәләвеннән Рябчиков хәтта кәефләнеп үк китте. Елмаеп:

— Серкәң су күтәрми икән. Зарар юк, гарьчел кеше яуда да сынатмый ул,— дип куйды.

Кәрим эре-эре атлаган юлдашыннан калмаска тырышты, шабыр тиргә батса батты, сынатмады. Баягы куркуы да онытыла төшкән иде. Ни дисәң дә, Рябчиковның киң җилкәле таза гәүдәсе, ышанычлы адымы күңелгә ныклык өсти, алан-йолан каранмаска, ирләрчә сабыр булырга өнди. Шулай да аның «яңаларданмы әллә?» дигән соравы һаман ярсыта иде әле Кәримне. Вакыты булса, сөйләп күрсәтер иде ул аңа. Әнисенең кара хаты килгәч, ул фронтка китү әмәлен эзли башлады, комсомол райкомын, военкомат бусагасын таптады, шуннан Любага серне чиште, дәү әнисенә хат язып калдырды... Бер эшелоннан куып төшергәч, икенчесенә утырды, караңгы тәрәзәләренә аркылы-торкылы кәгазь тасмалар ябыштырган Мәскәүгә мең бәла белән килеп җитте. Боларны сөйләү әллә ни кыен түгел дә, мактанчык дип уйлавы бар. Ә менә десантчыларга ияреп китүен, парашют белән ун тапкыр сикерүен (унбиш дип җибәргәндә дә зыян итмәс!), өч ай дигәндә радистлык һөнәренә өйрәнеп алуын сөйләми калдырырга ярамый. Югыйсә, тапкан сүз: «Яңалардан!» Дары иснәмәгән, янәсе, борын асты кипмәгән!

Шушыларны уйлый да Кәрим, кулын куенына тыгып, моннан бер атна элек кенә күкрәгенә лейтенант Чукреев үз кулы белән беркетеп куйган гвардия билгесен сыйпый, түш кесәсендәге йолдызның (Зиннур абыйсының бүләге!) үткер очына бармагын тидереп ала.

— Китер әнә тегене, тартмаңны, әзрәк булышыйм,— диде Рябчиков, арттарак калган юлдашына борылып.

Ләкин радист иңбашын гарьчел җыерып, чырт итеп теш арасыннан төкерде дә адымын тизләтте.

Нәкъ шул мәлне алдагы куак арасыннан автомат тырылдап ата башлады, Кәрим җиргә ауды һәм шундук агач артына поса-поса килгән дәү гәүдәле немецны күреп калды.

— Чү, атмый тор, минем арттан шуыш,— дип пышылдады Рябчиков.— Төбәп атмый кабахәт, куркытмакчы була, терелэй алмакчы...

Ул аркасына биштәрләп аскан брезент сумкасын кабаланып чишеп, Кәримгә бирде:

— Ул-бу була калса, кара аны, сакла. Монда минем бөтен инструмент...

Шуннан җиргә сеңә язып, немецка таба шуыша башлады. Сәгатьләр буена сузылган бер минут вакыт узды. Немец та, Рябчиков та таң алды караңгылыгында эреп югалдылар. Еракта, үзәннең аргы ягында, автомат утларыннан күк яктырып китә, ләкин атыш тавышы монда килеп җитми.

Тирә-якка колак салып, Кәрим йөрәгенең ярсып тибүен онытырга тырыша, автомат сабын чытырдатып кысып, кулының мәкерле калтыравын басмакчы була. Күзе Рябчиков киткән якка, әрәмәлекнең серле караңгылыгына төбәлгән. Ләкин анда шылт иткән тавыш юк.

Ул инде, иптәшенең эзеннән шуыша башламакчы булып, алга омтылган иде, шул мәлне берьюлы диярлек ике автомат чәчәп ут ачты. Берсенең тавышы — тимергә тимер белән суккандагы кебек, тупас, ят: немецныкы, «шмайсер» автоматы, дип уйлап өлгерде Кәрим, башын басып; икенчесе, саңгыраурак авазлысы — безнеке, Рябчиковныкы.

Тагын бер минут үтүгә бөтенләй башка җирдән, уң яктан, уфылдап, немецның автоматын иңенә аскан Рябчиков килеп чыкты. Буш кулы белән Кәримгә ымлады, ачы сүгенеп:

— Сыпырттык, туган! Койрыкка баса кабахәтләр! — диде...

Тагы үргә, якын ук калган урман сызыгына карап йөгерделәр. Кәрим алдан, Рябчиков аз гына арттанрак.

Йөгерә торгач, иптәшенең нишләптер өлгерә алмавын тойды Кәрим. «Куркудан шулай әлдерә», дидер әле Рябчиков»,— дип уйлады да, оялып, адымын әкренәйтте, байтак артта калган Рябчиковны көтеп алды.

Рябчиков, янтая биреп, сул кулы белән күкрәген басып килеп җитте дә «ыһ!» дип сыгылып төште. Азрак тын алгач, баягысыннан да әчерәк сүгенеп:

— Юк! Рябчиковны болай гына бөгә алмассың!..— дип, урыныннан кузгалды. Тик шундук, ирексездән чүгеп, тагы җиргә ауды.

Кәрим ни эшләргә белми әвәрә килде, иптәшенең шинель итәгенә буялган канны күргәч кенә аның җәрәхәтләнүен аңлады. Шашынып, кабаланып, Рябчиковның бил каешын, шинель каптырмаларын ычкындырды, лычма юеш гимнастеркасын күтәрде. Җәрәхәте күкрәктән астарак, корсагының сул ягында иде. Җентекләп карарга форсат юк. Кәрим, кулы калтырап, тамагына килеп бөялгән үксү авазын чак басып, Рябчиковны, баланы биләгән төсле, бинт белән чорнарга кереште.

— Җәлләмә, ныграк кыс, ныграк...— дип, Иван, терсәгенә таянып, авыр гәүдәсен күтәрергә, ярдәмләшергә, тешен кысып ыңгырашмаска тырышты. Эш беткәч: «Кара син аны, бөтенләй җиңеләеп киттем ләбаса! Хәтта элеккедән дә шәбәйдем!» — дип шаярткан булды. Автоматына таянып, аягүрә басты.

Тик ике-өч адым да атлап өлгерә алмадылар. Алдан, сай гына чокырдан, десантчыларның юлын кыеп, бозау хәтле этен озын каешка тагып алган немец килеп чыкты. Эт беренче мәлдә боларны сизми калды, күрәсең, хуҗасын урманга табан тартты. Шушыннан файдаланып, десантчылар күз ачып йомган арада җиргә яттылар да ата башладылар.

— Кая атасың, пешмәгән! Немецка төзәп ат, немецка! — дип җикердә ярсыган Рябчиков.— Кабаланма, калкынганын көт! Овчаркасын үзем дөмектерәм.

Дошман хәйләкәр булып чыкты. Еландай боргаланып, әле уңга, әле сулга күчте, патронын саклапмыдыр — абайлап, кыска-кыска чират белән атарга тырышты. Ләкин күп тә үтмәде, котырынып өргән овчаркасы ыргырга әзерләнгән килеш чинап җибәрде дә ачулы ырылдап тынып калды.

— Чәчрәде! — дип куйды Рябчиков, кыргарак шуышып.

Немец бик әзгә генә аптырауга төштеме, башын калкытып, этенә күз салуы булды, нәкъ шушы мәлдә аңа әллә Кәримнең, әллә Рябчиковның пулясы тиде.

Кәрим бугазын буган шатлыктан сикереп торды, дошманны онытып, ике-өч ыргуда үлән басып киткән мина чокыры эргәсенә, Рябчиков янына барып җитте.

Рябчиков ник эндәшми? Өлгерергә, тизрәк качарга кирәк! Атыш тавышына немецларның бөтәннәре дә килеп җитәр. Ә ул кузгалырга ашыкмый, маңгаен чокыр читенә терәп, чүкәеп утыра. Әйтерсең нидер югалткан да шуны үлән арасыннан эзлиме, яңа гына чык төшкән салкын җирне үбәме...

— Ваня! — дип пышылдады, йөрәген курку баскан яшь солдат.— Ни булды сиңа? Нигә болай ятасың?!

Рябчиков бөтен гәүдәсе белән дер-дер калтырый, куллары үләнгә ябышкан. Кәрим аны сак кына әйләндереп, чалкан яткырды да коты очып читкә тайшанды: иптәшенең бите кара кан баскан тоташ чи ярага әйләнгән иде.

— У-у-х, кабахәтләр...— Рябчиков, яшь бала сымак, үксеп куйды.— Канатын каерды Ваньканың җир йоткыры фашистлар! Капут Ванькага...

Сугышны, кан коешны тәүге мәртәбә күргән яшь солдат аңа нинди ярдәм күрсәтә алсын? Әгәр җанын биреп, Ваняны саклап кала алса, һич икеләнми эшләр иде ул моны. Юк шул, мөмкин түгел. Сугышта һәркемнең үз язмышы...

Битен, муенын юеш чүпрәк белән сак кына сөрткәч, Рябчиков әзрәк тынычлангандай итте. Җәрәхәте авыр, чигәсенә шартлагыч пуля тигән. Янак сөяген җимереп, тамагына үткәнгә охшый. Тын алган саен авыз читеннән кып-кызыл күбек чыга.

Сул күзен көрәнсу-кызыл шеш каплаган. Кәрим ныклы бер карарга килеп, корал-ярагын кулбашына асты да, иелеп, иптәшен җай гына торгыза башлады. Ләкин Рябчиков, әле генә йокысыннан уянган кеше сымак, исән күзен чак ачып, әкрен генә эндәште:

— Куй... Юкка интегәсең...

Чынлап та, Кәримнең көче җитәрлек түгел иде шул аңа. Ваняның кин җилкәле дәү гәүдәсе, йомшарып, җиргә сеңеп бара, аяк-кулы, буынсызга әйләнеп, изрәп төшкән. Иплэп яткырудан башка чара юк. Кәрим, кулы калтырап, аның иренен флягасын якынайтты, ләкин Рябчиков суны йота алмады, кан катыш сыекча муенына, ялангач күкрәгенә агып төште. Кызгылт сыекча эзенә текәлгән дә Кәрим, үкереп елап җибәрмәскә тырышып, кара янган иренен тешли.

— Син... нит, кит җәһәтрәк...— дип гырылдады Рябчиков.— Тизрәк урманга сыпырт... Үзебезнекеләргә әйт: Ванька Рябчиков сынатмады... фрицны дөмектереп үлде, диген... Документларны, инструментны ал...

— Юк! Икәү китәбез! — диде Кәрим, аны кабат торгызырга омтылып.

Рябчиков Кәримнең кулын этәрде, иренен ялап алды да, чак ишетелерлек итеп:

— Менә хикмәт, очрашканнан бирле искә төшерергә тырышам, чак килеп таныдым сине,— дип сүзен дәвам итте.— Радистлар бер малайны ай буе яшереп асраган, дип сөйләгәннәр иде... Шул малай син буласың инде, алайса...

— Сон...

— Ни дип монда алып килделәр сине... күрәләтә үлем гарасатына?.. Үзең тагылгансыңдыр әле...

— Үзем,— диде Кәрим, гадәтенчә иңбашын җыерып.— Әлбәттә, үзем,— дип кабатлады.— Якташым Бакиров авырып киткәч, аның урынына куйдылар.

— Тукта, тукта,— дип, Рябчиков калкына бирде.— Беләм бит мин синең ул якташыңны! Бик һәйбәт беләм... Бахыр Фаинаны шул юлдан яздырды... Эх, Фаинка, Фаинка, Ванька Рябчиков ярамады сиңа, җилкуар, янәсе, күп сөйли... Тел сөяксез инде ул, кайчакта эч пошканнан юкны бар дип фәстерәсең. Ә чынын әйткәндәме — хатын-кызның күз карашыннан коелып төшәм мин. Куркам... Куркам да, җәллимен дә шуларны...

Рябчиков, туктап, сулышын рәтләде, хәлсезләнгән кулын чак күтәреп, Кәримне аркасыннан сыйпап куйды да тагы сөйләп китте. Ул әйтерсең күпме вакыт күңелен борчыган, юшкын булып утырган авыр кичерешләреннән арынырга тели иде.

— Бая сине рәнҗетеп ташладым шикелле. Пешмәгән, дип ычкындырдым... Үпкәләштән булмасын, яме... Ару егет булып чыктың... Ә якташың, теләсәң ни әйт,— кәнтәй ул! Әшәке кәнтәй һәм куркак җан. Шайтаным да чирләми ул, туган, алдашып калды. Фаинканың фатир хуҗасы Сима әбекәйдән сорарсың әле... Бакиров үз аягын үзе җәрәхәтләп шештерде, ди...

— Ялган! — дип сикереп торды Кәрим. Кабат чүгәләде, Рябчиковның хәлен онытып, беләгеннән тотып алды. Ишеткән хәбәре шул тикле яман һәм куркыныч иде — ул, коты очып, иптәшенең йомылып барган күзенә текәлде: — Ничек инде... кеше үз аягын җәрәхәтләсен!!

Ул Бакировның елмаюдан кысылган шешенке кабаклы күзен, бит уртасы чокыраеп торган түгәрәк йөзен, пилотка читеннән кабарып чыккан кара бөдрәләрен күз алдына китерде, башын артка ташлый биреп,

сузып жырлаган моңлы жырларын хәтерләде. Юк, Кәримне үз итмәде Бакиров, якташ дип өзелмәде, сер бирмәде. Аралары якын түгел иде, тик моннан гына кешене азгынлыкта, куркаклыкта гаепләргә ярыймыни? Ялгышадыр Ваня. Булмас, алай булырга тиеш түгел!..

Рябчиков еш-еш тын ала башлады. Очкынланып елтыраган сау күзен әледән-әле керфеге каплый — җәрәхәтле солдат, әйтерсең авыр эштән талчыгып, черемгә китәргә җыена. Менә ул, сагаеп, тирә-якка колак салды, «т-с-с» дип кулын күтәрә бирде дә, иренен чак кыймылдатып:

— Ишетәсеңме? Тыңла әле, тыңла... Торналар оча,— диде.

Чынлап та, әле яктырып җитмәгән аяз күктә торна тавышы ишетелә иде.

— Эх, күренмиләр шул... Тагын бер генә күрсәм дә үкенечтә калмас иде,— дип көрсенде Рябчиков.— Нигәдер малай чактан ук яратам шул торна тавышын. Бәләкәй чакта, торна өере күрсәм, кеше күзеннән качып елый торган идем...

Кәрим иптәшенең кулын кысып куйды. Нидер әйтеп аны юатырга, сугышта яраланмый буламы кеше, кайгырма, савыгырсың, бер әмәлен табып үзебезнекеләр янына гына җитик, дип дәртләндерергә теләде. Ләкин ирене язылмый, курку алган йөрәге ярсып тибә, торналар канатыннан чәчелеп калган сагышлы моңнан күңеле тулыша иде.

Рябчиков тагы сүз башлады. Кәрим, үксүен басып, эндәшми ятып тор, дисә дә, Ваня туктамады:

— Яктыра... Рация кирәктер тегендә, көтәләрдер. Тизрәк кит. Немецлар хәзер җанвар аулаган сымак сагалап торачак безнекеләрне... Син нитмә, туган... уйлама. Фаинканың үчен кайтара, дип... Төкерәм мин ул Бакировка. Эт белән эт булганчы... Ә Фаинкага сәлам әйт кайткач. Фотокарточкасын әниемә җибәргән идем, булачак килене, янәсе... Бичара әнием...

Шулай диде дә Рябчиков, гырылдау катыш уфылдап, иркен тын алып куйды. Әйтер сүзен буып, тамагыннан шаулап кан китте. Менә ул, күзен зур итеп ачып, кулы белән нindидер ишарә ясарга тырыша, ләкин эндәшә дә, хәрәкәтләнә дә алмый, бары тик тамак төерен кылкылдатып кан ага. Кинәт бөтен гәүдәсе дерелди, көзән җыергандагы кебек тартыша башлады, аяклары сузылып турайды, башы кырга янтаеп төште.

Кәрим аның күкрәгенә ятып, «Иван, Ваня!» дип эндәшеп карады. Кулын тотып, кан тамырын капшады. Тамыр, хәлсезләнеп, бер-ике тапкыр беленер-беленмәс кенә типте дә тынып калды. Ваня, шушы бер сәгать эчендә кичергән коточкыч газаплардан котылып, мәңгелек йокыга талган иде.

Тыела алмый елаган Кәримне аякка бастырырдай, йөрәген тетрәткән, аның томалаган фаҗига урыныннан алып китәрдәй көч юк иде бу мәлдә. Үлем белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очрашкан яшь солдат куркудан, башын диңкеткән кайгыдан сыгылып төшкән иде. Елап күңеле бушангач та әле ул, таң яктыра башлауга карамастан, китәргә ашыкмады, мәет өстенә ирексездән коры үлән йолкып өя-өя, уйсызхиссез калгып утырды.

Күктә тоныкланганнан-тоныклана барган йолдызлар әкренләп сүнә; урман артындагы ерак болытларның читен алсу-сары ялкын каймалый, чиркандырып таң җиле исә, чыкка дымланган шинелен каплый биреп, Кәрим тирә-якта яңгыраган сирәк атыш тавышына колак сала. Башта сискәнергә, сагаеп иелергә мәҗбүр иткән сугыш авазлары хәзер аның ваемында да юк. Колагы нindидер бүтән бер тавышны аулый, менә бу илаһи таң мәлендә аеруча тупас булып тоелган гөрселдәү арасыннан нечкә кыл чыңына охшаш нәфис моңны эзли.

Чынлап та, шундук әлегә күзгә күренмәс кояшның алтын нуры балкытып җибәргән һавадамы, Кәримнең үз күңелендәме, зарлы иңрәү бу-

4*

лып, торна тавышы яңгырады. Сак кына канат җәя башлаган көй агымына бирелеп, ул күзен йомды.

Торыйк-торыйк! — торна тавыш бирсә,
Нәкыш чиккән җебем чуала...

Кайчандыр, кемнәндер — дәү әнисеннән бугай — ишетеп, күңел түрендә бикләнеп калган шушы җыр исенә төшүгә, буыннарын камырга әйләндереп, Кәримне татлы йокы изрәтте.

* * *

Череме күпмегә сузылгандыр, усал ырылдау тавышына сискәнеп, ул күзләрен ачты. Чокыр ярына күтәрелеп караса, күзе белән генә түгел, җаны-тәне, гөрселдәп тибәргә тотынган йөрәге белән тоеп, коточкыч хәлне күрде. Яңа күтәрелеп килгән саргылт-кызыл кояш, офыкның яртысын диярлек биләп, дөньяны нурга коендыра, ә балкып янган шушы дәү түгәрәкнең нәкъ уртасында, тешен ыржайтып, бая дөмегеп җитмәгән овчарка тора!

— У-у-х, кабахәт фашист! — дип, Кәрим чокырдан атылып чыкты да, бөтен ачуын туплап, автомат сабы белән этнең башына сукты.

Рухын богаулаган, аңын томалаган ваемсызлык хисе әзрәк җибәргәндәй итте. Ул, кабаланып, чокырга сикереп төште, Ваняның гәүдәсен плащ-палатка белән япты да урманга карап атлады.

Урманга якынайган саен тау текәләнә барды. Күтәргән йөгенең авырлыгын тоймаган төсле, Кәрим алга иелә биреп, гел атлавын белде. Батареялар тартмасының тар каешы иңбашына батып бара, Рябчиковның брезент сумкасыннан сурайган ниндидер тимер кисәге кабыргасын өйки, аркылы-торкылы аскан автоматлар атлаган саен ботына сугыла. Күкрәгендә нәрсәседер янып, көл-күмергә әйләнде аның, җанының мөһим бер өлеше йокысыз үткәргән шушы төннең хәвефле мажарасында югалып калды. Уналты яшьлек үсмер дип әйтүе кыен иде хәзер аны. Күтәргән йөге генә түгел, күңелен айкаган кичерешләре шулай хәрәкәтенә олпатлык, сабырлык өстәде, якында гына тырылдаган пулемет тавышына, куаклар кыштырдавына игътибар итмәслек көч бирде. Ул хәтта баш өстендә ярылган шрапнельдән дә читкә тайчанмады, иңбашын, кычыткан чаккан төсле, нидер көйдереп алгач та адымын үзгәртмәде.

Урманга җитәргә күп булса йөз-йөз илле адым ара калгандыр. Кәрим, уралып-сырмалып үскән куаклыкка борылмый, үҗәтләнеп, ялангач тигез үргә атлады. Бердәнбер теләге — тизрәк үзебезнекеләрне табу, батареясыз рация күтәреп йөргән сержант Толкунов белән очрашып, десантчыларга шул тикле зарур элемтәне бәйләп җибәрү иде. Билгеле, Толкунов рәхмәт әйтмәс аңа. «Кисәттем лейтенантны, бу имгәктән эш чыкмасын алдан белеп тордым»,— дияр. Дөрес сүзгә җавап юк. Юньле кеше хәтта үзе теләп тә ялгыз агач өстенә төшә алмас иде...

Радистын югалтуга, рациясын эшләтер әмәл тапмауга шартлар чиккә җитеп ачуланган Толкуновны күз алдына китергәч, Кәрим ирексездән адымын тизләтте. Менә ул билбау буе күтәрелгән кояш нурында чык энҗеләре җемелдәшкән үрнең соңгы киртләченә карап йөгерә. Артта пулеметлар тырылдавы ешайды, аяк астыннан балчык чәчрәтеп, пулялар выжылдады. Кинәт якында гына ачы сызгыру тавышы ишетелде. Бераздан — тагы, аннан тагы... «Шул! — дип уйлады Кәрим.— Толкунов!» Урман читендәге куак өстенә аһылдап егылып, ул шартлы сигналга җавап бирергә тырыша, тик чатнап ярылган иреннәрне һич ипкә килми, сызгыру урынына авызыннан ысылдау гына чыга.

Торырга, алга атларга кирәк! Сызгыру кабатланмады, димәк, десантчылар аны күрмәгән. Алар хәзер урманга кереп юк булачак!

Корал-ярагын шалтыр-шолтыр китереп, аягүрә баскан иде, тамагы карлыккан берәү якында гына:

— Әй, кайда олактың? Җир йоттымы әллә? — дип тавыш бирде.

Кәрим, кабаланып:

— Пароль? — дип кычкырды да җәһәт кенә читкә тайпылды.

Җавап урынына баягы тавыш:

— Тор, тор, чәбәләнмә! Үзебезнекеләрне танымыйсыңмы әллә? — дип, Кәримгә якынлашты.— Төшер пушкаңны, я абайламастан атып егарсың...

Бер минут элек, үзебезнекеләрдән кемне генә очратса да, Кәрим аның кочагына атылырга, кичергән куркуы, Рябчиковның үлеме, кояшка үрмәләгән ерткыч овчарка турында түкми-чәчми сөйләп бирергә әзер иде. Тик, аягүрә баскач, автоматларын аска каратып торткан ике солдатны күрде дә атлый алмый катып калды.

Тәбәнәк буйлы, киң җилкәле кыргыз егете разведчик Мәхмүт Җакиевне ул авызына капкан кап-кара трубкасыннан гына таный алды. Җакиевнең өс-башы, бүрс талаган кебек, тетелгән, ертык гимнастерка астыннан күренгән ак күлмәгенә кан катыш туфрак укмашкан. Көл кебек агарып суырылган йөзе, йомылыр чиккә җитеп кысылган күзе, хәлсезләнеп салынып төшкән кулы — бөтенесе аның коточкыч арганлыгын күрсәтеп тора. Толкуновның кыяфәте аннан да яман: башы кан таплары саркып чыккан пычрак бинтка уралган, җирән төк баскан йөзе берничә урыннан күгәргән, сул кулы муенына эленгән бил каешына асулы. Чандыр буйлы, какча Толкунов элеккедән дә озынрак, ябыграк булып калган иде...

Бер-берсенә текәлешеп, күпмедер вакыт кымшанмый басып торгач, Кәрим, башын иеп, Толкуновка табан бер адым атлады да кыюсызланып туктады. Тик нигә соң каты бәгырьле, кырысрак холыклы сержантының күзен яшь томалады, иреннәре дерелдәп китте?

Кинәт Толкуновның ике метрлы дәү сыны алга чайкалды. Сержант автоматын ыргытып, сау кулы белән Кәримне кочаклап алды да, әйләндереп, куе үлән өстенә екты, яратып аркасын дөмбәсләргә тотынды. Шуннан, сикереп торып:

— Яле, яле, болай әйлән, күргәндәй булыйк! — дип куанып хырылдады.— Мәхмүт, кара әле, сап-сау бит бу! Ә син ни сөйләгән идең?..

Мәхмүт калгып торган җиреннән, көтмәгәндә житез кузгалып, болар янына ашыкты.

— Кайда югалдың син, шайтан малае? Әзли-әзли җан калмады!..— дип сүзгә катнашты. Кәримне башыннан сыйпады, төрле җиреннән капшап карады, бер адым артка чигенеп, тагы якынайды. Телен шартлатып: — Теп-тере! Вәт, молодец, егетең! — дип аптырап әвәрә килде.

— Кайда йөрдең бу заманга чаклы? — диде Толкунов та, гадәтенчә кырыс кыяфәткә кереп.— Самолеттан бергә сикердек бит!

— Агачка эләктем,— диде Кәрим, аска, үзән ягына ымлап.— Анда Рябчиковны... үтерделәр...

Толкунов, радистның сүзе беткәнен дә көтми:

— Йөрисең шунда,— дип борын астыннан мыгырданды да кинәт кызып китте.— Нигә син, күзен алган кигәвен кебек, тап-такыр ялан буйлап атлыйсың? Артыннан немец шрапнель яудыра, ә ул, исәр, посып та тормый... Ә моны ни пычагыма күтәреп йөрдең? Соң бит бу иләккә әйләнгән!..

Шулай диде дә Кәримнең аркасыннан батарея тартмасын каерып алды. Чынлап та, тартманың бер почмагы умырылган, әллә ничә җирен пуля тишеп чыккан иде. Сержант аны куак астына, тирән чокырга ыргытты.

— Ə монысы нәрсә тагын? — дип, сумкага үрелде.— Инструмент дисеңме? Ташла чокырга!

Кәрим ике куллап сумкага ябышты.

— Юк, Рябчиковныкы ул... Тапшырырга кушты, бирмим!

— Йөрт, алайса, йөк аскан чегән кебек. Көчең ташып торадыр! Ə менә автоматларың өчен рәхмәт әйтергә була...— Толкунов Рябчиковныкы белән немец автоматын кулбашына асып алды да: — Я, җитте! Таярга кирәк моннан,— дип, башы белән урманга ымлады.

— Анда Рябчиков калды. Кем җирли аны? — дип карышты Кәрим.

Толкунов дәшми генә агач арасына атлады. Җакиев, авыр көрсенеп, кулын Кәримнең иңбашына салды да, аны җиңелчә алга этәреп, сержант артыннан төште.

— Сугыш бу, туган...— дип, баш чайкап куйды.

Хәзер, иптәшләренә килеп юлыккач, соңгы ике сәгать эчендә булып үткән вакыйгалар Кәримгә төштәге сымак тоела иде. Еракта гөрселдәгән туп тавышлары да, үзәндә яңгыраган сирәк атыш та кайдадыр бүтән җирдә, аның язмышыннан читтә төсле. Рябчиковның үлеме исә, Толкунов белән Җакиевнең үзләре дә теләмичә шулай игътибарсызлык күрсәтүеннән соң, гаҗәпкә каршы, Кәримнең күңелен баягыдай әрнетеп тормый инде. Тик шунысы уйландыра: ничек инде бу — кеше яшәп килә-килә дә кинәт күз алдында юкка чыга? Бәлки ул тумаган дадыр, Рябчиков дигән солдат гомумән булмагандыр? Тик менә бит аның куркыныч минутта да онытмаган, һичшиксез, иң зарур нәрсәгә исәплагән сумкасы, документлары... Рухы, уй-хыяллары, моңача кылган эше, сөйләгән сүзләре — бөтенесе төш. Кешечә тәрбияләп тә күмелмәгән гәүдәсе — чын. Ул үлән баскан мина чокырында череп, туфракка әйләнергә дучар ителгән...

Тагы шунысы аңлаешсыз, гайре табигый бер хәл: нигә әле икесеннән нәкъ менә Рябчиков үлеп калды. Моңарчы да сугышны күргән, акыллы, булдыклы солдат ни эшләп пуля белән аймылыша алмады? Шуларны уйлагач, Кәрим тетрәнеп китте. Нәрсәсен аңламаска?! Рябчиков бит баягы бәрелешнең икесендә дә иң хәвефле өлешне үз өстенә алды, иптәшен аралап, утка керде! Ə син, һични булмаган төсле, аны җир куенына тапшырырга да куркып, урман шырлыгына кереп посмакчысың...

«Юк,— дип уйлады Кәрим,— туктап сержантка әйтәм дә, кире барып, җирләп киләм Рябчиковны». Ул инде Толкуновка дәшәргә авызын ачкан иде, тегесе, тешен кысып ыңгырашты да:

— Привал, егетләр! Баш чатнап бара...— дип, сукмактан читкә чыкты. Коралларын җиргә куеп, утырып алгач, Кәримгә эндәште: — Ни әйтергә идең? Рябчиков хакында булса, авыз ачасы булма! Беләсеңме, анда,— Толкунов кулы белән кайдадыр ишарә ясады,— безнекеләр күпме ятып калды? Ə син балавыз сыгарга торасың. Баста!..

Кәрим дәшмәде, читкәрәк китеп ятты. Җакиев, тәмәкесез трубкасын чупылдатып суыра-суыра, тау селәүсене сымак сак басып, әле тегендә, әле монда йөри, тирә-якка колак сала. Кәрим аның сугышка кадәр зоотехник булып эшләвен, фронтка үзе теләп китүен, Великие Луки тирәсендәге десантта катнашуын ишеткәне бар иде. Мәхмүт ике-өч айдан бирле, тәмәке ташлыйм дип, буш трубка суырып йөри, иптәшләре исә, җае чыккан саен шаяртып, аңа папирос тәкъдим итәләр. Әнә шул Мәхмүт аны десантчы итте. Югыйсә, авылга кире кайтарып җибәрәләр иде.

Кәрим командиры Толкуновка күз салды. Әллә яралы булудан, әллә берәрсенә ачуы килеп, Толкунов үзалдына мыгырдана иде. Бүтән радистларның сөйләвеннән Кәрим аның фронтка ничек эләгүен дә ишеткәне бар.

...Сугыш башланырга ике-өч ай калганда гына Толкунов, заводта ниндидер авариягә юл куеп, бер елга хөкем ителә. Болар торган калага

дошман якынайгач, эшнең нидәнлеген сизгән Федор Толкунов төрмә ишеген җимереп чыга да, тоткыннарны коткарып, көнчыгышка таба алып китә. Ниндидер кечкенә бер калага житеп, хәрби комендатурадан корал таләп итә. «Вәт шулай-шулай, иптәш командир, өстебездәге җинаятьне каныбыз белән юарга телибез»,— ди. Менә-менә дошман камавына төшәргә торган частька эләгеп, Толкунов фашистлар белән тәүге канлы бәрелешләрдә катнаша, юлдашларының күбесе кырылып кала, үзе исә, җәрәхәтләнеп, тылга озатыла. Ул вакытлардан бирле ике елдан артык гомерен Федор я фронтта, я госпитальдә уздыра, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә...

Аның белән очрашуы — үзе бер тарих Кәримнең.

1943 елның җәй урталарында ачлыктан йончыган, өс-башы ертылып, ташкүмер корымына буялып беткән Кәрим, фронтка юнәлүче эшелонга эләгеп, Мәскәүдән чыгып бара иде. Тик менә ничәнче мәртәбә инде ниндидер станциядә аны тагы тамбурдан куып төшерделәр.

Ярсып чапкан поездның соңгы вагоны күздән югалганчы карап торды да ул юлдан байтак читтә аһылдашып-көлешеп кое суы белән юынган солдатлар янына барып басты. Башта аңа игътибар итүче булмады. Менә алар калай тартмаларын пөхтәләп җыештырдылар да, агач күләгәсенә утырып, табын әзерләделәр, Кәримнең төшенә дә кермәгән консерваларын ачып, итне хуш исле арыш икмәгенә кушып ашый башладылар.

Бу могҗиза табынны каш астыннан гына күзәтеп торган Кәрим, төкреген йотып, башы әйләнүдән егылып китмәскә тырышып, җиргә чүгәләде, аркасын агачка терәп, күзен чытырдатып йомды.

Сөйләшкән сүзләренә колак салып, зәңгәр якаларына җиз канат беркеткән бу солдатларның яңа рация сынап йөрүче десантчы радистлар икәнлеген төшенеп алган иде инде ул. Ачыгуы онытылды, кызыксынуын җиңә алмый, ирексездән, тоныкк елтыраган күк тартмаларга табан шуышып куйды.

— Әй, кара танау! Сыпырт моннан! — дип, солдатларның берсе Кәримнең җиңеннән тартты.

Ләкин озын сәфәре вакытында ул инде бер хакыйкатькә төшенеп алган иде: тамагы туйдымы — солдат иң мәрхәмәтле кешегә әйләнә, күңеле тамаша тели, яшь булса, малайлык гадәтләрен хәтерләп, шаярырга тотына, олырак яшьтәгесе, бала-чагасын уйлап, Кәрим кебек үсмерне күрде исә, эреп төшә. Шуңа ул артык исе китмәгән кыяфәт белән тупасрак итеп:

— Җәлмени сиңа? Харап...— дип, кире борылып утырган булды.

Солдат кружкасындагы чәен аягүрә генә чөмереп бетерде дә, туры килгән тамашадан файдаланып, тел чарлап калу мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска тырышты. Йөз-йөз илле адым җирдә, чыр-чу килешеп, исемсез-максатсыз мәңгелек сәфәрләрен тагы дәвам итәргә җыенган чегән таборына табан ымлап:

— Әллә таярга уйлыйсыңмы тегеләр яныннан? Синсез ни эш кыйрата алар? — дип көлде.

Аның сүзен бүтән солдатлар да эләп алды:

— Әйтерең бармы! Мондый башлыкларыннан аерылгач, таяксыз мосафирга әйләнә дә куя инде алар!

— Әй, таптыгыз сүз! Ат эзли ул. Тавык төшенә тары керә дигәндәй, чегән ятса-торса ат белән саташыр...

«Кара танау» дип эндәшкән солдат Кәримнең каршысына чүгәләп утырды:

— Я, нигә дәшмисең? Күрәзәлек кылып җибәр булмаса, буш итмәм!

Иптәшләре аны көлә-көлә читкә этеләр:

— И надан! Чегәннең хатын-кызы гына күрәзәче була бит ул. Ә моңа ат кирәк, ат булмаса, әнә синең ипи капчыгың да ярап торыр. Аң бул! Я, ни әйтерсең, егет! Эшләр ничек?

— Эш ару, тик корсак пустой,— дип елмайды Кәрим, солдатларның шук сүзенә, шаяруына туры китерергә тырышып.

Ул арада чегәннәр, кыйку-сөрән салып, шыгырдавык арбаларына төялешеп, юлга төште дә рәшә дулкынында йөзгән яшь каенлык эченә кереп күздән югалды. Шунда гына Кәрим чегән түгеллеген әйтте. Баягы яшь солдат, үзе башлаган уенның бозылуына кәефе кырылып, буыннарын шартлатып киерелде дә читкә китте. Ләкин башкалары очраклы бу хәлне кинәт икенчегә борып җибәрделәр.

— Чегәнгә ни сан,— дип куйды олырак яшьтәге солдат,— бөтен ил кырмыска оясы кебек гөж килгәндә... һәркем юлда, берәү фашист туздырган оясын ташлап кача, берәү фронтка ашыга.

Эндәшми байтак вакыт уйланып утыргач, ул сикереп торды.

— Яле, чишен тизрәк! — дип боерды Кәримгә.

Күз ачып йомган арада аны тагы сырып алдылар, көлешә-көлешә, каешланып каткан иске пинҗәген, төсен аермас хәлгә җиткән күлмәген салдырып, юындырырга тотындылар. Юындырып бетергәч, бер түтәрәм икмәккә май ягып, консерва ите куеп, кулына тоттырдылар, янына пар бөркеп торган кайнар чәйле кружка куйдылар. Кәрим ачкүзләнеп азыкка ташланмады, тыйнак кыланырга тырышып, җай гына ашый башлады. Солдатлар исә, кызыксынып, уенлы-чынлы сорауларын яудыра торды. Һәм, ниһаять, сәфәре вакытында Кәримгә йөз тапкыр иштергә туры килгән төп мәсьәләгә килеп җиттеләр:

— Кая юл тоттың болай? — дип сорады «кара танау» дип эндәшкән баягы яшь радист.

Кәрим күңелендә уянган өметен яшерә алмады:

— Сине эзләп йөрим,— дип көлде дә, җитди төскә кереп: — Ал үз яныңа, үкенмәссең,— дип өстәде.

Тагы көлеш, шау-шу китте. Кәримнең башкорт малае икәнен белгәч, сүзгә катышмый рация белән булашкан кече сержантны җилтерәтеп китерделәр.

— Әй, Бакиров, таныйсыңмы бу шырт чәчне? Якташың икән ләбаса! Бәлки авылдашыңдыр әле, бичәкәеңнән сәлам китергәндер,— дип, солдатлар аның саен гү килеп хахылдашты.

Бакиров дигәннәре, ачулы мыгырданып, кул селтәде, читкә тартылды, ләкин иптәшләре, аеруча Володя Петров дигән әлеге яшь радист, аның ай-ваена куймый:

— Юк, юк, Фатих, сөйләшеп кара, бәлки шыттырадыр! — дип, аны аягүрә баскан Кәрим каршысына этәрде.

— Я,— дип дәште Бакиров башкортчалап,— күрмәгәннең күргесе килә, күргәннең эче китә, дигәндәй, нимә кыдырасың монда?

Кәримнең гаҗәпләнүенә каршы, Бакиров аны әрләп ташлады, бу кыяфәтеңдә адәм көлдереп йөрисең, дип орышты, кайтып китәргә димләде. Ләкин солдатларның бүтәннәре пышылдашып сөйләште дә нинди-дер шук бер карарга килде, күрәсең, Кәримне үзләре белән алып китеп, кичен җирән чәчле, озын буйлы мәһабәт сержант каршысына бастырды.

Сержант баягы Бакировтан да яман ачуланырга тотынды:

— Олактырыгыз моны, шайтаныма кирәкме ул?! Тапканнар эш, балалар бакчасы ачарга уйлыйсызмы? — дип, Петровның тетмәсен тетте.

Ләкин Петров бирешергә уйламады:

— Соң бит, иптәш сержант... ике айдан унсигезем тула ди ләбаса... Барыбер солдатка алыначак...

Толкунов, какча, озын буйлы Кәримне баштанаяк карап чыккач, әзрәк йомшый төштеме — мыскыллабрак:

— Кая, документыңны күрсәт әле,— диде.

Кәримнең ГСО таныклыгыннан башка бер документы да юк иде.. Комсомол билетын пинжәк эченә тегеп яшергән иде, аны телгә дә алмады. ГСО катыргысын алай-болай әйләндергәләп торды да Толкунов, чырт итеп төкереп:

— Липа! — дип борылып китмәкче булды.

Нәкъ шунда Жакиев яклап чыкты да инде Кәримне.

— Син нәрсә, сержант! Нинди документ таләп итәсең? Документы — теле аның,— дип, Кәримгә кыргызча эндәште. Жакиевнең кыргыз икәнен Кәрим соңрак белде, ә ул чакта, аптыравыннан күзен түгәрәкләндереп, Мәхмүтнең күп сүзе аңлаешлы булуын тойды.

Жакиев радистлар белән киңәш-табыш итеп өлгергән, күрәсең, үзенең артык төпле түгел фикерен үҗәтләнеп Толкуновка сөйләвен белде:

— Эшнең башы документтамыни, Федя? Кеше булсын! Ә моннан бер дигән радист чыгачак, киендереп кенә җибәр! Аннан үзеңне уйла. Теге вакыт, кырык беренче елны, нинди документың бар иде?

Шушы дәлил Толкуновның каршылыгын тәмам җиндә шикелле. Радистлар, разведчиклар белән сүз куешып, Кәримне командирлар күзеннән айга якын яшереп йөрттеләр, үз азыкларыннан өлеш чыгарып, ашатты-эчерттеләр, өс-башын юнәттеләр. Шул арада ул, солдат тормышына иялэшеп, радистларның катлаулы һөнәрен өйрәнеп өлгерде. Тыңлаучан, зирәк акыллы үсмер егет, яңа дусларының куанычына, күзгә күренеп төс алды, көчкә утырып, авыр батарея тартмасын ыһ итми унунбиш чакрым җиргә күтәреп йөртә башлады.

Ләкин яңа килгән рацияләрне сынау чоры үтеп китте, моннан соң радистлар күбрәген я казармада, я бригада штабында эшләргә тиеш булдылар. Радистлар взводына менә-менә командир билгеләнәчәк. Ул килгәнче Кәримне чын исәпкә кертү әмәлен эзләп, иптәшләре баш ватты. Кеше инә түгел, күпме яшереп асрыйсың аны, тәвәккәллик, штабка барыйк та әйтик, коеп куйган солдатны кем урамга куып чыгарсын дип, торкан җирдән сындырырга өндәүчеләр дә булды.

— Юк,— дип, Толкунов бу киңәшне кире какты.— Анда барып җиткәч, эшнең ахыры билгеле инде. Баягыча, бер документсыз, кеше... Көне-сәгате белән эзен себертәләр...

Взвод командиры итеп билгеләнгән лейтенант Чукреев яшь-яшь егет булып чыкты. Толкунов Кәримнең мажарасын сөйләп биргәч, эчен тотып күзеннән яшь чыкканчы көлде дә:

— Яле, яле, күрсәтегез әле миңа шул качкынны! — дип, яшь радистны чакырырга кушты.

Кәрим, кереп, чын солдатларча, җиренә җиткереп, килүен хәбәр иткәч, Чукреев аны кыса башлады:

— Өйдә кемнәрең бар? Ала-ай... Хат яздыңмы соң дәү әниеңә? Ала-ай... Мондалыгыңны беләләрме?

Егет ык-мык итте, кызарып-бүртенеп, дәшми-нитми аска карап тик торды.

— Аңлашылды,— диде Чукреев, иягеи учлап,— яле, утыр әле!

Толкунов Кәримнең кабыргасына төртеп:

— Я, ни дип аңгыраеп торасың? — дип пышылдады.

Лейтенант Кәримнең алдына бер бит кәгазь, ручка куйды да:

— Яз! — дип боерды.— «Кадерле дәү әни! Минем өчен һич тә борчылма. Өйдән чыгып киткәч, мәрхәмәтле язмыш мине менә дигән һәйбәт кешеләр белән очраштырды...» Яздыңмы? «Аеруча Федор Толкунов дигән сержант, үз итеп, җил-янгыр тидерми йөртә, хәрби һөнәренә өйрәтә. Мин хәзер данлыклы армиябезнең солдаты. Хат язып тор, дәү әни, менә адресым...» Хәрби почта номерыңны яз. Булдымы? «Солдатларча кайнар сәлам җибәрәм» диген.

Кәримнең маңгаен бөрчек-бөрчек тир каплады, ышаныргамы моңа,

юкмы дигәндәй, бер Чукреевка, бер Толкуновка карап, хатын өчпочмаклап бикләде, эре итеп адресын язды. Лейтенант алчак елмаеп:

— Рядовой Атнабаев! Сезне Петров рациясенә запас радист итеп билгелим. Кабатлагыз боерыкны!..— диде.

Кәрим әнә шулай десантчы-радист булып китте. Озакламый бөтен бригаданы парашют белән сикерергә өйрәтә, көне-төне, алсыз-ялсыз солдат уены уйната башладылар. Рация башлыгы булуы белән бергә, Толкунов взвод командиры Чукреевның ярдәмчесе дә итеп билгеләнде. Сержант Кәримне яшь дип аяп тормады, башка солдатлардан аермыйча, аларны күпме йөгертсә, моннан да шул тикле үк таләп итте. Уеныңны белән көлеп:

— Солдат икмәген бушка ашатмыйлар. Бер зур кеше: «Өйрәнгәндә кыен булса, яуда җиңелгә төшә»,— дигән. Ул-бу җирең чиләнмичә чын солдат була алмассың. Аңладыңмы? — дип, Кәримне үзенчә дәртләндерә торды.

Соңгы көннәрдә, кырык өченче елның көзенә табан, өйрәнүләр аеруча катлаулана, авырая төшкәч, ял итәргә туктаган мәлдә десантчылар еш кына:

— Болай булгач, озакламабыз... Атнабаевны казарма сакларга калдырырбыз да — выжт дошман тылына! — дип шаярта башладылар.

Петров кына, әтәчләнергә торган Кәримне җәлләп:

— Кайгырма, туган! Бәхетеңә боларның берәрсе, мөгаен, парашют белән сикергәндә аягын сындырмый калмас. Әнә шунда инде лейтенант синең алдыңа тезләнеп: «Зинһар өчен, иптәш Атнабаев, коткар бәладән!» — дип ялыныр. Хөрт радист булсаң, Володька Петров үз янында йөртер идемени сине? — дип сөйләнде.

Кәрим, иңнәрен сикертеп, сер бирмәгән булды, ләкин үзенең запас радист хөкемендә йөрүен искә төшергәч, бригада сагаеп көткән заданиегә ничек эләгү чарасын уйлап баш ватты.

Дөнья хәлләрен командирларның тын алуыннан, штаб тирәсендә уралучы писарьларның мәгънәле итеп тамак кыруыннан, тагы әллә нинди билгеләрдән, ым-ишарәдән сизеп өйрәнгән солдат халкы бригаданың менә-менә фронт сызыгы аръягына җибәреләчәген дә көне-сәгатенә хәтле ачыклаган иде инде. Нәкъ шул мәлне Толкунов рациясендә радист булып йөргән Бакиров авырып китте.

Петровка җитә калды. Кәримнең аркасын бала башы хәтле йодрыгы белән дөмбәсләп:

— Әйткән идеме сиңа абзаң! Китәбез, туган, болай булгач! Кикригеңне текә тот!..— дип әвәрә килде.

Чынлап та, бер-ике көн үтүгә Кәримне лейтенант чакыртып алды. Гадәтенчә, ияген учлап, ишекле-түрле йөрде дә, дәшми генә ымлап, аны тышка алып чыкты. Сагаеп, ни ишетәм инде, дип борчылып атлаган Кәримне, кинәт беләгеннән эләктереп, баш аша очырды. Кайдандыр килеп чыккан Жакиевнең аптырап калган егеткә:

— Сак бул, Атнабаев! Хәзер пычак белән чәнчә! — дип кычкыруы булды, чак аягүрә басып өлгергән Кәримнең баш өстендә финка ялтырады.

Эшнең нидәлеген аңлап өлгергән иде инде Кәрим. Озын буйлы, житез хәрәкәтле Чукреевның кизәнгәнен көтеп, чүгә төште, яшен кебек ялтыраган пычактан чак кына читкә тайпылды да «дошман»ның беләгеннән эләктереп алды. Лейтенант әллә көтмәгән иде мондый хәрәкәтне, әллә юрамалый юл куйды,— әмма Кәрим, еландай боргаланып, аның пычаклы кулын иңбашына салды да бер секундка гына аркасына төшкән авыр гәүдә астыннан атылып чыкты. Чукреев йөзтүбән җиргә капланды, Кәрим аның кулын каерып, пычагын тартып алды.

Өс-башын кага-кага елмаеп аягүрә баскан лейтенант:

— Кулны сындырасың дип торам! Нинди усал, әl — дип беләгеи уды. Шуннан, жиде-сигез адымда торган дәү чыршыга төбәп, финкасын ыргытты.

— Кабатла! — дип боерды Кәримгә.

Чукреевның финкасы яртылаш диярлек агач кәүсәсенә кадалган иде. Кәримнеке исә сабыннан тотуга жинел генә килеп чыкты. Бу күнекмәнең кыенлыгы шунда иде — финканы очыннан түгел, сабыннан тотып ыргытырга кирәк. Әгәр дә тиешле тизлек булмадымы, пычак ук кебек туры очмый, әйләнә башлый, агачка я сабы, я кабыргасы белән барып бәрелә. Кәрим туры ыргытырга өйрәнде өйрәнүен, тик менә аның Чукреев я Толкунов сымак, финкасын яртысына тикле агачка кадарга көче житенкерәми иде әле.

Күнекмәне кимендә егерме тапкыр кабатлаткандыр лейтенант. Буш трубкасын чуылдата-чуылдата чүкәп утырган Жакиев:

— Кабаланма, ыграк кизән! Пычакны ыргыткан чакта бөтен гәүдәң белән алга авыш! — дип киңәш бирә торды.

Соңыннан Кәримне рациядә эшләтеп, машинада егерме биш чакрымнар ары киткән иптәшләре белән элемтә бәйләтеп карадылар. Иртәгесен лейтенант аның Толкуновка икенче радист итеп Бакиров урынына билгеләнүен белдерде.

Ләкин Толкунов кинәт кызып китте:

— Алмыйм мин ул имгәкне, теләсәң ни эшләт, иптәш лейтенант! — дип, озын кулларын селтәп каршы төште.— Аның әле сарык бәрәне көтеп йөрер чагы! Бүтән кеше бир...

— Бүтән кеше юк. Үзең дә беләсең,— диде Чукреев.— Әзләргә дә вакыт юк, иртәгә эшелонга төяләбез...

Ике тәүлек буе поездда барганда, аннан, парашют киеп самолетта утырганда Толкунов, чыраен сытып, Кәримне рациянең берәр жире бозылганда ничек төзәтергә, кайсы сәгатьтә, кайсы дулкында эшләргә өйрәтте, имтихан алгандай, кабат-кабат тикшерде, кисәтте. Гажәпкә каршы, радистның зирәклеген, үткенлеген күргән саен кашы жимерелә барды, ачуы кабарды.

— Әйтерсең илдә солдат беткән, бала-чаганы интектереп йөртмәсәләр...— дип мыгырдады.— Ни шайтаныма күнәргә иде мин ахмакка! — Шуннан тимердәй каты бармакларын Кәримнең иңнәренә батырып: — Кара аны, авызыңны ачып йөрмә, батареяны сакла!.. Акыллы бер үлгәнче, исәр биш үләр — тиешле-тиешсез кәпрәймә! Сизеп калсам, песи баласы кебек буып ыргытырмын...— дип пышылдады.

* * *

... Ял иткән арада шушыларны хәтерләде Кәрим. Чалма кебек итеп марля уралган башын тотып, иптәшләренә аркасын биреп яткан Толкуновка карады да, ачынып: «Менә хәзер буып ташласаң тап-таман инде...— дип уйлады.— Ни файда күрдең миннән? Кайдан табарга телсез калган рацияне эшләтер батареяларны? Штаб начальнигына элемтә кирәктер, ул безне эзлидер...»

Шушы уйны сержантка әйткән иде, тегесе борылып ятып:

— Элемтә, элемтә...— дип йөзен жимерде.— Кемгә кирәк синең элемтәң? Штаб самолетын атып төшерделәр, бу тирәгә, күп булса, йөзләп десантчы сикергәндер... Безнекеләр хәзер Черкас урманында, ә ул моннан унбиш чакрым...

— Соң, шунда китик без дә!

Толкунов торып утырды.

— Аучы белән аю турындагы әңгәмәне ишеткәнең бармы? — диде.— Юкмыни? Тыңла алайса: «Аю тоттым, аю! — дип сөрәнли икән берәү.

Алып кил монда! — диләр моңа. Бармый бит,— дип җавап бирә аучы. Соң, үзең кил, алайса,— дигәч: Җибәрми шул! — дип кычкыра, имеш, бахыр аучы...» Менә шулай эшләр, Кәрим дус. Немец җибәрсә, китәбез генә... Бар, Җакиевне чакыр.

Кәрим ыргып тормакчы булган иде, кулбашы авыртуга «ыһ» итеп, бөгелеп төште.

— Бу ниткән эш тагы? — диде Толкунов, аның янына килеп. Эх, син, хәсрәт сугышчы! Яралангансың лабаса! Нишләп башта ук әйтмәдең? Чишен!

— Нинди яра ди ул? Юктыр...— Кулбашының әрнеп сызлавыннан Кәрим үзе дә шиккә төшкән иде.

— Юктыр, юктыр, имеш... Яле, чиш диләр сиңа! Гимнастеркаңны да сал, күлмәгеңне дә,— дип хырылдады сержант.— Ә ябыклыгын күрегез моның! Каклап киптергәннәрмени!

Ул Кәримнең кулбашын нәрсә беләндер эчеттереп уарга тотынды.

— Ярый әле, сөягеңә тимәгән икән... Я, киенсәң дә була.

— Ничек. Хәвефле түгелме? — дип, Кәрим аның күзенә карады. Тегесе йомшаргандай итеп:

— Хәвеф дисеңме? Монда, туган, адым саен муеныңны өзәргә торалар. Тик син җебеп төшмә, яме. Эт сыртындагы яра сымак, ике-өч көндә, сыпырып ташлагандай төзәлер,— дип елмайды.

Боларның булашканын күреп якын килгән Җакиев тә:

— Һи-и, җәрәхәтмени бу! Песи тырнаганнан да бәләкәй бит,— дип юаткач, Кәрим бөтенләй тынычланды, иптәшләре артыннан төшеп, алга атлады.

Юллары, барган саен югарыга үрмәләп, я адәм аягы басмаган караңгы, дымлы шырлык аша бормаланды, я яшь каенлы аланнарга алып чыкты. Төнге кичерешләре чак кына басыла төшкән Кәрим көзге ят урманның матурлыгына беренче тапкыр игътибар итте. Колач житмәс мәһабәт агачларны кыеклап төшкән яктылык аралый, карасу-яшел, сары, чия-кызыл төстәге яфраклар талгын җилдән җилфердәшә. Табигать әйтерсең сугышка, үлем һәм кыйралышка үч иткәндәй, бәйрәмчә ясанган да жиңү тантанасы кичерә. Үзенә яшәү биргән җир-әнкәсенә сутлы җимешләрен, тук орлыкларын бүләк итә, хуш исләрен чәчә. Башын артка ташлап, зәңгәрсу күк йөзенә карый да Кәрим, иркен сулап, ирәвән асманда утлап йөргән ап-ак болыт-бәрәннәрне күзәтә.

Тик болытларны бәрән итеп күз алдына китерүе булды — рухын биләгән тылсым юкка чыкты, уйлары бүтән якка күчте.

«Сержант сүзе дөп-дөрес,— дип уйлады ул,— бәрән көтеп йөрергә генә шул сина! Кирпеч чаклы батарея тартмасын сакларга да кулыннан килмәде, һавада хәзер күзгә күренмәс радио дулкыннар, адашкан бәрәнен эзләгән көтүче малай кебек: «Кама», «Кама!», мин — «Волга», «мин — «Волга», нигә җавап бирмисең?» — дип безне чакырадыр. Их, Рябчиковка түгел, сиңа ятып калырга иде үлән баскан мина чокырында...»

Уйлары, урманны аралаган бу беленер-беленмәс сукмак төсле, тагы кискен борылыш ясый: акылы, яшәүнең могжизалы көчен, үлемнең дәһшәтле серен аңларга тырышып, читлектәге кош сымак талпынасугыла. Табигатьнең шушылай бәйрәмчә купшыланган, җанга тыныч рәхәтлек вәгъдә иткән мәлендә кешенең үлеп юкка чыгуы коточкыч хаксызлык булып тоела иде...

Өйдә чакта сугышны бүтәнчәрәк күз алдына китерә иде шул Кәрим. Күрше-күләнне, туган-тумачасын зар елаткан кара хатлар түгел, хәтта үз әнисенең яки Зиннур абыеның үлеме ничектер вакытлы бер кайгы сымак тоела торган иде. Күңел түрендә менә сугыш бетәр дә югалган, һәлак булган авылдашлары шау-гөр килеп кайтып төшәр дигән өмет чаткысы көйри иде. Бүген исә ул беренче тапкыр сугышның чын фаҗи-

гасен күрде, кеше гомереңең өзелүенә шаһит булды. Зиннур, Харрас абыйларының, Фазыл жизнәсе белән Мәгъсүм кодаларының, үз энисенең, дистәләгән авылдашларының тормыш юлы, кинәт кайдадыр юк булган бу урман сукмагына охшап, аяусыз жуелуын, йөрәге кансырап, янадан кичерде. Бичара дәү энисенең: «...Кыр казлары кайта язлар житкәч, солдат кына кайтмый бер киткәч...» дип такмаклап, күз яше түгеп елаганы хәтерендә. Әйе ләбаса! Көз артыннан салкын кыш килә, аннан тагы яз якынлый. Табигатьнең кабат яңаруын туктатыр көч юк, бу үзгәреш мәңгелек. Тик үлгәннәр генә кайтмый...

Шуннан Бакировны уйлый. Дөньяның гарасаты купкан бу заманда кемнең дә булса посып калырга, үз йөген бүтәннәр җилкәсенә күчерергә тырышуы һич кенә дә башка сыйдырыр нәрсә түгел. Юктыр, дип уйлый Кәрим, булмас, Рябчиков ялгышкандыр. Нишләп кеше үз тәненә үзе зыян-заурат салсын? Бервакыт Бакиров, консерва ачканда кулы киселеп, җәрәхәтем бозылмаса ярар иде, дип куркып йөргән иде. Шул кеше үз әгъзасына үзе кул күтәрә буламы? Китәр алдыннан медсанбатка барып, Кәрим аны үз күзе белән күрде. Бакировның аягы гөбе кебек шешкән, башы уттай кызу иде. Шушы газапны кем үзе теләп алсын!.. Рябчиков та инде — Сима эби әйтте, имеш! Җитмешне узган карчыкка ышан син...

Арттарак калып атлаган Толкунов иптәшләрен куып житте дә:

— Ху-уш, Кәрим, немец белән ничегрәк танышуыңны сөйләмәдең бит әле,— дип, аның уен бүлдерде.

Кәрим сискәнеп китте. Берьюлы башына төшкән мең бәладән алҗып, үз-үзен күрәлмаган чакта кемнең сөйләшәсе килсен. Хәбәре кыска, буталчык булып чыкты, Толкуновка ошамады.

— Нигә син оялчан кызлар төсле авызыңда йөзек яшерәсең? — дип, сержант төпченергә, радистының башыннан үткән хәлләрне берәмлекләп сорашырга тотынды. Әйтерсең өчесенең дә алдагы язмышы Кәрим сөйләгәннәргә бәйле иде.— Әйе,— диде Толкунов, сорашып туйгач.— Шәп түгел эшләр... Алай да син балтаң суга төшкән сымак бәлтерәми тор. Табылыр берәр әмәле... Ә Рябчиков жәл. Мин аны күптән беләм, госпитальдә танышкан идек. Һәйбәт егет иде, әйтер хәлем юк. Тик нигәдер төрлечәрәк лыгырдыйлар аның хакында...

— Әнә шул шул! Өстенә бастың — лыгырдыйлар...— дип, Кәрим кызып китте. Күз алдында һәлак булган кешегә сүз тидертәсе килми иде аның.— Юкны чәйнәргә һәркем оста! Ә Ваня, беләсең килсә...

— Мин дә һәйбәт дидем ләбаса. Тик... күрәсең, сүзгә мавыгып, үз өстенә үзе чүп өюен тоймаган. Кемнең кемлеге маңгаена язылмаган шул, туган.

— Аныкы язылган! — дип каршы килде Кәрим.

— Юкка чәпчисең,— диде Жакиев, Кәримне култыклап алып,— Рябчиковны яманлап әйтми бит ул... Их, Ваня, Ваня, кылмаган гөнаһын да кылдым дип ычкындыра торган иде шул. Янәсе, егетлек күрсәтә. Шуны ишетепмедер — сөйгәне башка берәү белән чуалып киткән, имеш... Ул мескен кызыкай да гаепсездән гаепле булып чыга...

Кәрим, Рябчиковның соңгы сүзләрен хәтерләп, иптәшләренә сөйләп бирмәкче булган иде, тик бу мәхәббәт мажарасына бәйле башка хәлләрнең дә барлыгын уйлап тыелды. Толкунов та башланган әңгәмәне бүтән яккарак борып җибәрде:

— Кешене яхшы сүз белән искә алуын әйбәт, Кәрим дус, югыйсә бит, бу дөньяда берәү дә, фәрештә кебек, сөттән ак, судан пакь түгел. Тик син шунысын уйла: я, Ваняның ни зыяны тиде немецка? Өен бастымы, я җиренә хаслаштымы? Төкерде ди ул немецына! Юк, ярамадык кабахәт фашистка, әнә илгә ни каза китерде...— Толкунов күзеннән очкын чәчеп, хырылдап сүгенде дә: — Усалрак, кансызрак булырсың моннан болай! — дип йодрыгын төйде.

Алданрак атлаган Җакиев кулын күтәрде. Бу аның аң булырга кушуы иде. Автоматларын әзер тотып, аның янына барып җиткән десантчылар, агач ботагын аерып, юлларын бүлгән яр астына карадылар да шаккаттылар. Аулак үзәнне икегә ярып яткан тирән ерганак буйлап йөзләгән танк, ала-кола итеп буялган исәпсез-сансыз машина тезелеп тора иде. Бормалы-бормалы текә яр ышыгына поскан колонна корбанын сагалап яткан имәнеч зур еланны хәтерләтә иде.

— Да-а, сабан туй корырга булыр иде монда,— дип көрсенде Толкунов. Шуннан мәгънәле итеп Җакиевкә карап куйды. Их, рация эшләсә!.. Менә нәрсә, Мәхмүт... Петровның кайда егылганын хәтерлисеңме?

— Күземне бәйләп җибәрсәң дә табам мин ул ут йоттырган җирне!

— Яхшы,— диде сержант, күзен очкынландырып.— Анда агач арасында батарея тартмасы булырга тиеш. Бәлки исәндер...

— Аңладым, Федя,— дип, Җакиев, итеген салып, чолгауларын иплэп урый башлады. Корал-ярагын барлады, парадка әзерләнгәндәй, билен кысып буды, төймәләрен каптырды.

— Мин дә...— дип, Кәрим урыныннан кузгалган иде, Толкунов:

— Сиңа да эш табылыр! — дип, аңа аппарат тартмасын сузды. Мәхмүтне кочаклап: — Әйләнеп килергә бер сәгать вакыт бирәм. Ул-бу булып, аймылышсак, кич комбриг төркемен эзләп табарга тырыш,— диде.

Җакиев, Кәримнең кулбашына сугып алды да, йомшак кына басып, юлга чыкты.

Ике лампаның ватылуын исәпкә алмаганда рация исән иде. Кәрим запас лампаларны урынына куйгач, Федор, кәефләнеп:

— Ә хәзер радиограмма әзерлибез! — дип, сумкасыннан карта, кәгазь, каләм чыгарды. Телен аркылы тешләп: — Менә бит ул безгә кирәк үзәнкәй, нәкъ үз генәсе! Квадратлары болай була...— дип сөйләнә-сөйләнә кәгазь битенә нидер язарга кереште. Кәримгә, урман читенәрәк чыгып, самолеттан күренердәй билгеләрне табарга кушты.

Батарея кайтса — рация көйләнә.

Эшләре ярты сәгатькә дә бармады. Бер-берсенә әйтмәсәләр дә һәр икесе, борчылып, Җакиевнең хәвефле сәфәре хакында уйлый, сиздерми генә ул киткән якка күз сала иде.

— Лейтенант та шушы тирәдә түгелме икән? — дип, Кәрим әллә Толкуновтан сорады, әллә үз-үзенә эндәште.

— Минемчә дә шулай... Тик таба алмадык, тизрәк ычкынырга туры килде... Үлгәннәр калды, яралыларны алдык та урманга сыздык.

— Кайда соң ул яралылар?

— Сөйләшү буенча, теге вышка тарафына үтәргә тиешләр,— дип, Федор үзән арьягына, күрер күзгә дүрт-биш чакрым җирдәге биек калкулыкта торган вышкага ымлады.— Без сине эзләп калдык... Тик бу тәңгәлдән үзән аша чыгып булмас, үргәрәк үтәргә кирәк булыр...

Сержантның теле ачылганын күреп, Кәрим аның ничегрәк җәрәхәтләнүен сорады.

...Федор, дөрләп янган печән эскертенең эргәсенә генә төшеп, парашютын ычкындыруы була, өстенә, терелэй элэктерергә ниятләп, өч фашист ташлана, җиргә егып, кулын каера башлый. Толкунов бөтен көченә тартыла, тибенә, тик сиздермәстән басып алган өч кешегә ничек каршы торсын. Алай да бер секундка гына бушанган кулына финкасын эләктереп, фашистларның берсен чәнчеп ташлый, шуның автоматын, көбәгеннән тотып, тагы берсенең башына суга. Ләкин читкәрәк шуышып өлгергән өченче немец ата башлый. Әгәр Җакиев килеп җитеп, фашистны атып екмаса, Федорның хәле мөшкел: ул, башын тотып, куак төбенә ауган иде. Бәхеткә, җәрәхәте артык куркыныч түгел. Мәхмүт аны

жәһәт кенә бәйли дә атыш барган урман читенә карап йөгерә. Безнекеләрне кысрыклап урата башлаган немецларның артында кәтмәгәндә гранаталар гөрселди, чәчәп ике автомат ут яудыра... Толкунов белән Жакиевнең килеп өлгерүе эшне хәл итә. Дистәләп мотоцикл якынлашуын күреп, десантчылар, яралы иптәшләрен күтәреп алалар да, урман эченә кереп югалалар. Җәрәхәтләнгәннәр арасында бригада командиры да була.

Толкунов белән Жакиев урман читләп күпме йөрмәсеннәр, Чукреевне дә, автоматчылар взводының командирын да таба алмыйлар. Күрәсең, алар олы юлның аргы ягына төшкәннәрдер, чөнки анда да танга хәтле атыш барды.

Кәримнең уен яралы комбриг белән киткән төркем били иде. Анда ничәләп кеше булуын, төркемнең кайда юнәлүен төпченеп сорашырга тотынды.

Толкунов десантчыларның кырыктан да артмавын, аларның да уңлабы җәрәхәтләнүен, төркем башында — бригаданың начхимеме, начфинеме — ниндидер моңарчы ул күрмәгән майор торуын сөйләп бирде.

Сүзгә мавыгып, билгеләнгән бер сәгать вакытның үткәнен тоймый да калганнар. Жакиев һаман юк. Толкунов, борчылуын сиздермәскә тырышып, урман грушасы төбенә коелган җимешләрне җыеп йөри, Кәрим агач арасыннан үзәнне күзәтә.

Һавада безнең солдатлар яратып «кукурузник» дип йөрткән кечкенә самолет күренде. Менә ул Кәримнәр тирәсендә божра ясап әйләнде дә үзән чокыры буйлап бормаланган юл өстеннән очты, әйләнеп килеп, тагын кирегә үтте.

— Эх, сукыр! Күрә буламы соң инде,— дип, Толкунов Кәрим янына килеп утырды.— Болары да хәйләкәр. Яр астына посканнар да, ичмасам, берәрсе ялгыш атып җибәрсә!.. Ә безнең Мәхмүтне җир йотты.

Шул мәлне Кәрим үзен бигрәк тә күрәлмый иде. Я инде, рация шаулап эшләп утырса хәзер! Фронт сызыгы Днепрның аргы ярында гына. Тавыш биргән теләсәң кайсы радиостанциягә тот та: «Фәләнфәлән квадратта дошман техникасы посып ята. Ут бирегез шунда!» дип сал идең хәбәрне. Ун минут эчендә җир белән тигезләп ташлар иде безнең самолетлар...

Тик Кәримнең пошынуы озакка бармады. Аста, юлның төрле өлешендә, кайдандыр очып килгән ике-өч снаряд ярылды да шушы очраклы сымак тоелган гөрселдәүдән соң үзән эчендә кыямәт купты. Юк, моны бер-бер артлы яңгыраган шартлау дип тә булмый иде. Җирне туктаусыз гүләү тетрәтте, тамырлары белән актарылып чыккан юан агачлар, коточкыч аждаһалар кебек, һавага күтәрелде, үзән өстен тузан катыш төтен басты.

— Ят! Ят! Монда шуыш!..— дип ярсып кычкырды Толкунов. Төбе су юудан җанвар оясы кебек уелган имән тамыры астына поскач, Кәримнең колагына: — Менә моны музыка дисәң дә ярый! «Катюшалар» җырлый, туган! — диде.

Аулак урын табулары да хәерлегә булды, чөнки миналар ара-тирә болар яткан яр башына да төшеп ярыла иде.

— Җәлләмә, дөмбәслә фашистны! Уңгарак ал, шулай! — дип, Федор куанычыннан ярсып сөрән сала, кулын селтәп, безнең артиллеристларга команда биреп торгандай кылана, ә тегеләре әйтерсең аның тавышын ишеткән сымак, утны үзәннең әле бер, әле икенче очына күчерәләр.

Ярты сәгатькә сузылган ут гарасаты кинәт тынып калды. Колаклары тонган ике десантчы, өннәреннән чыгып, яр читенә ашыкты. Үзән буйлап тартылган җил-тузан болытын ерак борылма аръягына, урман читенә кысрыклый, юл өсте ачыкланганнан-ачыклана бара.

Ниһаять, десантчыларның күз алдына коточкыч күренеш килеп басты. Әле күптән түгел генә корбанын корыч кыршауга буып яньчер-

гә әзерләнеп яткан имәнеч елан токмач кебек турап ташланган иде. Кая карама, ярга үрмәләп туктаган, борыннары җиргә төртелгән танклар өсте-өстенә өелешкән машиналар дөрләп яна. Оясы туздырылган кырмыскалар сыман немец солдатлары әрле-бирле йөгерешә.

Куанычыннан түбәсе күккә тигән Толкунов Кәримнең аркасын төя, күзен елтыратып:

— Менә, ичмасам, эшләделәр! Изделәр измәсен...— дип хырылдый.— Тик безгә насыйп булмады, соңладык... Димәк, өлгеррәк егетләр бар, ә?! Чукреев эше түгелме икән?

Кайдандыр килеп чыккан унлап штурмовик немец колоннасын тәмам җир белән тигезләргә тотынды.

— Концертның икенче бүлеге башлана! — диде Толкунов.

Ләкин монысын карап тормаска, китеп юк булган Җакиевкә каршы атларга, аны табып, яралы комбриг төркеменә барып кушылырга булдылар. Атлый торгач, Толкуновлар дошман белән бәрелешкән җиргә үк җиттеләр. Иртән һәлак булган десантчыларның мәетләре кайдадыр югалган. Гильза өемнәре, канга буялган шинель кисәкләре, алюмин котелоклардан башка күп булса дүрт-биш сәгать элек аяусыз сугыш барганын раслардай бүтән билге калмаган иде монда.

Кире борылудан башка чара юк иде. Толкунов, өнсез-тавышсыз, җай гына атлап, нидер уйлана, маңгаен җыерып, иртәнге бәрелештә каймыккан кулын уа, беләген бер турайтып, бер язып, ипкә китереп азаплана. Баягы шатлыкның эзе дә калмаган иде.

Менә Мәхмүт тә китеп югалды. Кәрим моңа үзен әрли, әгәр ул батареяны саклый алган булса, Җакиев мондый хәвефле сәфәргә китмәс иде. Очраклы рәвештә бригададан аерылулары җитмәгән, инде бер имгәк аркасында иптәшләре кыенлык кичерә...

Әйе, хәзергә яу язмышы артык миһербанлы түгел иде шул десантчыларга. Тирә-яктагы хәл-әхвәлне ачыклаганчы да ничәмә табышмакны чишәселәре бар. Ә ул табышмакларның һәрберсендә үлем хәвефе яшерenгән. Бердәнбер юанычлары — исән калулары иде, тик моңа нинди хак түләнүен уйласаң, маңгай чәчең үрә торыр.

Кәримнең күңелсез уйларын җөпләгәндәй, аяз күктә торналар кычкырыша. Кыш якыная шул. Очар кошлар сугыш дип тормый, мәңгелек сәяхәтләренә ашыга. Ниндидер дәһшәтле вакыйга алдыннан бик әзгә генә, ихтимал, атна-ун көнгә генәдер, тыныбрак торган фронт сызыгы тәңгәленнән, сагышлы моң чәчеп, торналар оча.

Торна өере тип-тигез, очлы почмак ясап, кояшка карап омтыла. Табигатьнең тылсымлы куәте аларны, ашкындырып, җил-давылларга каршы юл ярырга, нинди генә хәвефләргә карамый, алга, аяз ирәвәнлеккә табан очарга кыстый. Җир әйләнүен, ел мизгелләрен үзгәртерлек көч булмаган кебек, очар кошларны да туктатыр әмәл юк. Хәерле сәфәр сезгә, изгелекле җан ияләре!

Тик бу ни хәл? Ук кебек алга омтылган торна өере нигә болай кинәт тузгып, тырым-тырагай оча башлады? Десантчылар, эшнең нидәлеген аңларга тырышып, карашлары белән күк йөзен айкаган арада, мамыктай күпереп торган сирәк кенә болыт өеме арасыннан ике самолет килеп чыкты. Берсенең канатына кызыл йолдыз, икенчесенә сары тәре төшкән.

Һавада пулеметлар татылдады, ике самолет, бастырышып, бер югары үрләде, бер, уктай, аска ташланды. Ә торналар һаман шушы тирәдә өерелә.

Бавыры өзелеп төшкәндәй булды Кәримнең. Их, акылы җитәме соң инде бу кошларның тизрәк хәвефле урыннан качарга. Әнә берсе, юк, икесе, канатлары тузып, җиргә төшеп китте, ә куышып очкан самолетлар, сиреналарын улатып, тагы торна өеренә якынайды.

Сагышка бирелгән Кәрим, бичара кошларны коткарырлык көче булмауга ачынып, адымын тизләтте.

— Их, эше хөрт, ахрысы, безнекенең...— дип, Федор да кул селтәде. Чынлап та, Кәрим туктап кабат күккә караса, кызыл йолдызлы самолет, кырга янтая биреп, яу урыныннан ераклаша, немец исә, аны атып төшерергә кулайлап, яңадан борыла иде. Ләкин дошманның ярты минутка гына күздән югалуы булды, безнең самолет, кинәт юнәлешен үзгәртеп, күккә үрләде. Болыт арасыннан самолетын ажгыртып килеп чыккан немец бик әзгә генә аптырап калды шикелле, нәкъ шул мәлдә аның өстендә туп шартлады. Хәзер инде немец самолеты кача иде. Озак та үтми, ул, артыннан кап-кара төтен койрыгы сузып, җиргә капланды.

Тузгышып очкан торналар, көчкә бер-берсен табып, йөрәк әрнеткеч тавыш белән кычкырыша-кычкырыша, чак өзелми калган юлларын дәвам иттеләр. Тик, гаҗәп, һәлак булганнарының урыны буш иде. Ике очы тоташкан почмакның як-ягында берәр торна сыярлык кына ачык урын калган иде.

* * *

Күз алларында булып узган очраклы фаҗигадән йөрәге тетрәгән ике солдат, озак вакыт башларын иеп, тавыш-тынсыз атладылар.

Һәрберсе үзенең аянычлы фикер җебен сүтеп, җай гына китеп барганда кинәт:

— Тукта! Күтәр кулыңны! — дигән тавыш ишетелде.

Сукмактан читкә ыргып өлгермәделәр, каршыда өч десантчы күренде. Берсе разведчиклар взводыннан икән — радистларны танып, кабаланып сөйләргә тотынды. Бу өчәүгә — үлеме, тереме — Толкуновны эзләп табарга кушылган. Отрядка рация кирәк икән. Алар, батарея тартмасы күтәргән Жакиевне ярты сәгать элек кенә урман төпкеленә, комбриг отрядына озатканнар.

Урман барган саен караңгыланды, сукмак ерып йөргесез шырлык, сазламык иңкү аша бормаланды. Ул да түгел, сакта торган автоматчылар яныннан узып, тирә-ягын куе урман ышыклаган, биек текә яр ураткан кечкенә аланга килеп чыктылар.

— Да-а...— диде Толкунов, алан өстендә чатыр ясап кушылган мәһабәт агачларга күз салып.— Монда ятып, сугыш беткәнен дә ишетми калырсың.

Кечкенә буйлы, ыспай киемле майор, кап-кара мыегын сыйпап, Толкуновның докладын тыңлап та тормый сүгенергә тотынды.

— Абайлабрак, иптәш майор! — диде Федор, яралы комбриг эргәсендә утырган Таня исемле сестра кызга ишарәләде.— Хатын-кыз бар монда...

— Телләшмә! — дип җикерде майор.— Бу нинди партизанщина! Төз басып тор офицер каршысында! — Сагаешып калган десантчыларны күздән кичереп, ачуын басарга тырышты. Эре кыяфәткә кереп әйтте: — Приказ шул сиңа, сержант: элемтә бәйләп, фронттан самолет чакыр!

Майор җилкәсе аша баш бармагы белән комбригка таба күрсәтте дә, кырт борылып, алан читендәге яр астында нидер чокып азапланган десантчылар янына китте.

Мәхмүт тапкан батарея тартмасы исән булып чыкты. Радистлар, лагерьдан байтак читтә торган үр өстенә менеп, рацияне корып җибәрделәр. Комбригның шартлы исемен әйтеп чакыруларына фронт рацияләренең берсе шундук җавап бирде, шифрланган радиограмманы кабул итеп алгач, унбиш минут кына көттерде дә, майор тәгаенләгән сәгатьтә, билгеләнгән җиргә самолет төшәчәген хәбәр итте.

...Һәм менә кояш урман артына яшеренеп күп тә үтмәде, десантчылар, аркылы-торкылы тасма сузып прожекторлар яктырта башлаган күккә карап, түбән генә очкан кечкенә самолетны озатып калдылар.

Җакиев трубкасын ыргак чупылдатырга тотынды. Лач итеп төкереп, кыргызча сүгенеп куйды.

— Нәрсә сөйләнәсең? — диде Толкунов.

— Нәрсә булсын... Комбригны саклый алмадык, өерле пешмәгән! Теләсәң нәрсә әйт, әмма теге кара майорга күңел ятмый, Федя.

Толкунов үзе дә, ачуын басарга тырышып, уртын чәйни иде.

— Китәләр аны полковник белән, самолетка утырып...— дип мыгырданды.

— Төкердем самолетыңа! Урын булса, әнә кан косып яткан өчәүне озатыр идем әле. Аларны ни эшләтәбез хәзер?

— Соң сөйләште бит инде майор летчик белән...

— Сөйләште, сөйләште! — дип, Мәхмүт үҗәтләнүен белде.— Немецны кабат самолет үткәрергә исәр дисеңме әллә? Тот капчыгыңны!

Самолет кунган аланга снарядлар төшеп ярыла башлаган иде. Десантчылар кабаланып лагерьга таба атладылар.

— Әнә күрдеңме? — диде Җакиев.— Алар хәзер уч төбендәге кебек тотачак бу урман кишәрлеген... Ичмасам, врачы да юк. Шушы сестрага калдымы инде көнебез? «Танечка, аягым өзелде, Танечка, күкрәгемә пуля тиде!..» Ярый ла курчакларын онытып калдырган булса...

— Бәйләнде бит, э,— диде чыгырыннан чыга башлаган Федор.— врач кирәк, имеш! Син башта сугыш әле немец белән, аннан күз күрер. Ә сестрага сүз тидерәсе булма!

— Кайсы сестра? Таняны әйтәсеңме?

Кәрим моны берәр нәрсә уйлап сорамады, әлбәттә. Аэродромда самолетка төялгән чакта десантчыларның: «Таня, безнең янга утыр!» «Таня ул-бу була калса, шүрләмә, яме; мин монда!» дип шаяртканын, адәм күтәргесез сумка аскан кызыкайның исә комбриг утырган самолетка карап йөгерүен хәтерләгән иде ул.

Әмма радистының әчкерсез соравы болай да чак тыелып килгән Толкуновка җитә калды.

— Син тагы ни шайтаныма сүзгә кысыласың? Вәт бәйләнчек!..— дип адымын ешайтты.

Кәрим, аптырап, иңбашын җыерды, Мәхмүт исә:

— Менә шулай, энем, пәһлеваннарны да егарлык көч бар дөньяда,— дип, күңелсез генә елмайган булды.

Дәрмансыз калып йончыгын десантчыларның яр читенә коры яфрак өеп ятуы булды, алан уртасына җыелырга дигән боерык бирелде.

Майор, кемдә нинди ашамлык булса, бөтенесен строй алдына җәелгән плащ-палаткага салырга кушты. Ләкин солдатларның күбесе капчыкларын иртәнге бәрелеш вакытында югалтып бетергән иде. Бар азыкны гадел генә бүлешеп тамак ялгадылар да, иртәгесен ишәк кайгырткан, дип көлешкән булып, ятарга җыена башладылар. Җакиев кешегә күрсәтми генә Кәримгә кечкенә төргәк куйды.

— Бар, шым гына Таняга илтеп кил. Федор бирде, диярсең...

Кәрим аннан-моннан гына әмәлләгән куышка карап юнәлде.

Җәрәхәтләре җиңелрәк солдатлар, ара-тирә ыңгырашып, уяу йокыга киткән. Авыр җәрәхәтлеләрнең берсе йөзтүбән яткан, күрәсең, аркасына пуля тигән; икенчесенең, курчак кебек итеп, башы, ике кулы марляга чорналган; тагы берәүсенең коточкыч юанаеп киткән аягы агач ботагына асып куелган. Кырдарак боларга күз-колак булырга куелган берничә десантчы, тәмәке утын шинель җиңенә яшереп, пышылдап сөйләшә-сөйләшә, тәмәке тартып утыра. Танымаса да, Кәрим алар белән баш кагып исәнләшеп, кайгылы кыяфәттә тезен кочаклап утырган сестра янына чүгәләде.

— Таня...— дип эндәште.— Нигә елыйсың, Таня?

Кыз Кәримгә утырырга кушып ымлады, түш кесәсеннән кулъяулык алып, тиз генә күзен сөртте дә:

— Ни булды? Берәр дару кирәкме әллә? — дип сорады.

— Юк. Болай гына.

— Син радист бит әле... Я, ни хәбәрләр ишетелә?

— Ишетелми,— диде Кәрим, йомышын йомышлап тизрәк китә алмавына ачуы килеп. «Елап утырса да, тәпчененргә ярата, күрәсең, бу кызыкай. Күпне белсәң, тиз картаерсың...»

Шулай уйлады уйлавын, тик үзе дә аннан артыгын белми иде шул. Башта батарея юкка көенделәр, ә хәзер, Жакиев ярдәме белән эш көйләнгәч кенә, һич көтмәгән бәла килеп туды. Рациянең майор куышында бикләнеп ятуын әйтеп буламыни бу житен чәчле кызыкайга? Ә көндез, радистлар фронт радиостанциясе белән элемтә бәйләп, самолет чакырып кайткач булган хәлне бәла дими, тагы ни дисең?

Эш болай булды. «Менә, ичмасам, безнең дә бер файдабыз тиде», дип куанышып кайткан радистларны майор түземсезләнеп көтеп утыра иде. Аръяктан алынган өч-дүрт сүзлек кенә җавапка күз йөртеп чыкты да:

— Яхшы, яхшы, хезмәтегез онытылмас! Ә хәзер рацияне китереп куегыз! — дип, баш бармагын җилкә аша куышка таба төртте.

Толкуновның:

— Бүтән десантчылар белән элемтә...— дип сүз башлавына, кызарып-бүртенеп:

— Молчать,— дип җикерде. Тирә-ягына карана-карана, пышылдауга күчте: — Болар язмышы өчен кем җаваплы? Минме, синме, сержант? Әнә шул шул!.. Рацияне немец пеленгага тотса, лагерьның көле күккә очачак.

— Соң, ни пычагыма безгә бу лагерь? Ял итәргә килмәдек бит! Кайсы ерганакка төртелмә — дошман гаскәре посып ята. Разведка кирәк, элемтә...

Майор күзен кыса биреп, башын бер читкә янтайтып, Федорга карап торды да:

— Башбаштаклыкка юл куймам! — дип ысылдады.— Отряд сугышырга сәләтсез, бердәнбер чара — фронт килеп житкәнен көтү. Моннан ары лагерьдан чыгып йөрмәскә! Буйсынмаган кешене үз кулым белән атачакмын! — диде, пистолет кабурасына шапылдатып сугып.

Шулай итеп алар рациясез калды. Толкунов, сөмсере коелып, көн буе нидер уйлады, аулак җиргә утырып, картасын җентекләп тикшерде, ниндидер билгеләр белән чуарлап бетерде. Бер сәгатенә, бер баеп барган кояшка карап, кич булганын көтте.

Кәрим, шул күңелсез хәлләрне уйлап, Таня янына нигә килүен дә онытып иде шикелле. Тегесе пышылдап үзе сүз башлады:

— Ишетелми, дисең инде... Бригада кайда булды соң? Федор нәрсә ди? Әллә ул да шушы зәхмәт чокырында посып ятарга җыенамы?

Кәрим беләгенә ябышкан кызның кулыннан көч-хәл белән ычкынып аягүрә басты. Шулай да күңеле эрегәндәй иткән иде аның. Таняның ярсынып яудырган сораулары аның үз борчуларына аваздаш иде.

— Кулсыз калдырасың бит,— дип көлгән булды да, кесәсеннән баягы төргәкне чыгарып, Таняга сузды.— Федор җибәрде...

— Нәрсә соң ул? — дип, кыз да сикереп торды.

Иңбашына салган шинеленең шуып төшүенә игътибар да итми, балалар төсле, куанычыннан әвәрә килгән кыз әлеге борчылуларын бер минутка гына онытып иде. Кәрим, Федорның самолет озатып кайткандагы сөенечен кыланышын хәтерләп, нигәдер күңеле тулуын тойды. Ярый әле, Таня үз эше белән мәшгуль иде.

— Шоколад икән! Нинди һәйбәт булды әле, ичмасам, җәрәхәтле

солдатларга бирермен,— дип сөйләнә-сөйләнә төргәкне сумкасына яшерде.

Күпме вакыт бергә хезмәт итеп, сержантының сөйгәне барлыгын белмәгән егет, бердән, аңа әзрәк үпкәләсә, икенче яклап, горурлык тойгысы кичерә иде. Шушындый сылу кыз һич тә башка берәүне яратмаган, ә нәкъ менә Толкуновны, Кәримнең сержантын сайлаган! Бу хәл үзе генә дә Таняны башкаларга охшамаган изге җан иясе итә иде.

— Син нит... Таня, үзең дә аша,— диде Кәрим, баягы кырыслыгыннан оялып.— Мин тагы китерермен.

Җавап урынына Таня аның кулын сыйпап куйды. Китәргә уйлаган радистны туктатып:

— Федя әйткән иде дә, нишләптер онытам да куям исемеңне. Кәрим дисеңме? Кавказданмы әллә син? Ә-ә, башкортмыни? Укыганым бар сезнең Салаватыгыз турында. Батыр егет булган!..— дип ихлас сөйләп китте. Шуннан тын гына көлеп: — Федяга әйт, килсен. Башын рәтләп бәйләрмен, ичмасам, югыйсә, төрек солтаны шикелле йөри...— дип, Кәримне озатып калды.

Толкунов бая яткан урынында юк иде.

— Каядыр китте,— диде Мәхмүт.— Хәтта миңа да әйтмәде. Җилкәсенә ике автомат асып алды да юк булды... «Йокла, йокла», ди миңа. Әйтерсең йокы ала күзне мондый чакта...

Җакиев плащ-палаткасын агач ботаклары, коры яфрак өстенә җәеп яткан да карашын ерак йолдызларга төбәгән. Кәримнең Таня белән ничек очрашуын тыңлап бетергәч, озак вакыт дәшмәде: нидер уйлап, көрсенде, торып утырды, дусын кулбашыннан кочаклады.

— Яхшы иттек әле теге шоколад белән,— дип, боек, басынкы тавыш белән сөйләп китте.— Шатланды дисеңме? Бик әйбәт... Сугыш дип мәхәббәттән ваз кичәргә ярамый. Әлбәттә, мәхәббәт чын булса, якташың Бакировныкы сымак булмаса, дим... Башын әйләндерде бит Фаинканың. Өйдә бичәсе, бәләкәй малае бар, нигә шулай кыланадыр. И шайтаныма искә аламмы! Ә шоколадны сержантка әйтә күрмә! Белеп калса, җаныңны алыр.

— Бәрәкәт, ул бирмәдемени шоколадны? Алдау була лабаса болай...

— Уй-бай, нинди алдау ди? Яхшы ният белән эшләнгән эш алдау булмый ул, туган... Их, тизрәк бетсен иде бу сугыш! Җыелып безгә килер идегез кунакка. Ыссык-Күл буена чыгып, казанасар идек... Минем Мәйрәмем кунак сыйларга шул тикле әүвәс ул!.. Әнә шунда инде тотабыз да әйтәбез: «Менә шулай-шулай, ардаклы [1] Таня дускай, теге вакыт шоколадны сиңа Федор түгел, үзебез биргән идек... Вәт кызык булыр!.. Бәлки әйтмәбез дә. Нигә әйтеп торырга? Куансын әйдә адәм баласы, кыңгырау булып зыңласын!

— Балаларың да бармы, Мәхмүт агай?

Җакиев тын гына көлеп куйды.

— Каян булсын! Әле хатыным да юк минем...

— Ә теге... Мәрьям — кем соң ул?

— Мәрьям — сезнеңчә була. Бездә — Мәйрәм... Бер кыз инде ул. Кәләш үк дип әйтә алмыйм, әмма да илле чакрым станциягә озата килде, истәлеккә кулъяулык бирел җибәрде.

Җакиев тагы көрсенде, төрепкәсен әйләндергәләп куйды.

— Тәмәке төтенен яратмый...— Шул алама нәрсәңне ташламасаң, кайтып күземә күренмә, дигән хатында. Өйрәнгәнче буш төрепкә суырырга туры килә...

— Матурмы соң? — дип сорады Кәрим.

---

[1] Ардаклы — хөрмәтле.

— Мәйрәмне әйтәсеңме? И матур гынамы! Саф йөрәкле кыз ул, туган. Аилдә бер уңган, куй караучы. Тәскә-биткә килгәндә, Таняга кара да аны күр: томрап торган озын кара чәчле, айдай якты йөзле. Буйга гына әзрәк кайтыш булса булыр...

«Бөтенләй киресе икән,— дип көлде Кәрим эчтән генә.— Таня житен төсле сары чәчле, какча яңаклы...» Тик үпкәләмәгәе дип Мәхмүткә ул хакта әйтмәде, сүзне икенчегә борып, көндез майор житкергән хәбәрне сорашырга тотынды.

— Арыткан икән алай да,— диде Жакиев, плащ-палаткасына урапып.— Әйдә, ят син дә. Батырга да ял кирәк, дигән борынгылар.

Кәрим, һаман киреләнеп:

— Шул инде, йокларга гына калды. Әйтерсең безнекеләр Берлинга барып житкән...— дигәч, Мәхмүт кызды да китте:

— Сержантның белеп әйтә бәйләнчек дип... Тигәнәк икәнсең син! Ят тизрәк. Федор кайтса, күрсәтер күрмәгәнеңне.

Ни тикле арымасын, күзен йокы алмады Кәримнең. Иртәнге кичерешләренә, шик-шөбһәләренә яңалары өстәлде. Вакыт әйтерсең пружина сыман кысылган да, айга-елга житәрлек вакыйганы шушы бер көн эченә сыйдырган иде. Менә аңар моңарчы бөтенләй диярлек белмәгән өлкән дусларының тирән серләре ачылгандай булды. Баксаң, беренче карашка кырыс рак тоелган Толкунов гашыйк булып йөри, имеш! Өрлекгәй егет шул нечкә билле кызыкайның исемен ишетүгә үк ничегрәк коелып төште... Шуннан ул ничәмә мең чакрым жирдәге сөйгәненең сүзен екмый, гаделлек саклап, тәмәке тартмый чыдаган Мәхмүтне уйлый; авыр яралы солдатларның хәлен жиңеләйтер әмәл тапмавына кайгырып елап утырган Таняны искә төшерә. Толкуновның хәсрәте бүтән шул, бичара кызыкайга игътибар итәргә форсат кайда аңа! Димәк, дип фикер йөртә Кәрим, Таняга күз-колак булу, кирәк чакта кулдан килгән ярдәмне күрсәтү — минем өстә...

Кайда йөри икән бу сержант? Әллә Черкас урманына, дошман белән аяусыз сугышкан бригадага киттеме, югыйсә? Юк, булмас, китмәс ялгызы. Әгәр ул әйләнеп кайтмаса, мондагы десантчылар белән бергә Кәрим дә, Жакиев тә немецларның бу тирәдән үзләре качканын көтеп ятарга тиеш булып чыга...

* * *

Төн таңга авышканчы уйланып яткан Кәрим Мәхмүтнең дә йоклавын тоя, тик дәшми, хәтта ойый башлаган беләген кузгатырга кыймый. Күз алдында тагы шушы бер тәүлек эчендә булып үткән төрле вакыйгалар теземе чиратлаша. Текә яр читендә торган ялгыз имән, усал ырылдап, кояш өстенә үрмәләгән овчарка, үзән уртасында тырым-тырагай йөгерешкән соры шәүләләр, дөрләп янган танклар, әллә нинди жан әрнеткеч тойгы калдырган торналар чыңы... Талчыккан жаны ял сорый, тик борчулы уйлар кыршавыннан котылу жиңел түгел.

Бер уйласаң, адәм үтмәс сазламык әйләндереп алган менә бу аулак алан — бүтән берәр планета сымак. Ярты дөньяны ялмаган сугыш ялкыны әйтерсең чиксез галәмнең фикер житмәс ерак бер почмагында дөрли. Тик Кәримнең йолдызлар янып торган, әле бер, әле икенче тарафта гөлт итеп яктырып киткән төнге күккә каравы була — зиһене жиргә әйләнеп кайта. Курку хисеннән арынып житмәгән иде әле ул. Шулай да «Дуглас» самолетының ачык ишегеннән колак ярып гүләгән кара упкынга сикергәндәге, бер ялгызы имән ботагында асылынып торгандагы яки Рябчиков белән хушлашкандагы тойгылары сүрелә төшкән иде инде. Юк, анда да үлем куркуы кичермәде, бары тик үз-үзеннән курыкты.

Әйе, әйе, дошман каршысында җебеп төшмәсәм ярар иде, дип борчылды ул. Ләкин һәр түмгәгеп, сикәлтәсен аңа калкан итәргә торган дымлы җир яшь солдатка куәт бирде. Кулбашын авырттырып типкән автоматы чәчәп ут яудыра башлагач инде, Кәрим гади генә бер хакыйкатьне төшенеп алды: өлгер бул, үләсең килмәсә, алдыңда пәйда булган дошманыңны үзең үтереп кал. Колагында әллә кайчангы, әле авылда чакта ук радиодан ишеткән дәһшәтле өндәмәнең көйдергеч сүзләре яңгыраган дай булды: «Үтер, улым, фашисгны!»

Шушыларны уйлый торгач, Бакиров исенә төште. Әгәр Рябчиковның сүзе дөрес булса, Бакиров — иң бәхетсез кеше бу дөньяда! Әйе, бәхетсез. Чөнки ул үзенең көчсезлегенә, газиз җанының күбәләктәй зәгыйфь булуына ышанып, арысланны мингерәүләтердәй көче барлыгын онытkan...

Мәхмүт черемгә китте шикелле, иренен чупылдатып, дымлы, курач плащ-палаткасын иңбашына тартып куйды. Кәрим аркасын куеп ятып, шинель итәген аның өстенә шудырды. Сизгер Җакиев йокы аралаш, ризасызлык белдереп:

— Уй-бай, ни дип йокламыйдыр инде бу шайтан баласы...— дип мыгырданды.— Нәрсә уйлыйсың?

— Әй, бер буш нәрсә шунда... Ярый, йокла, йокла.

— Йокларсың сезнең белән,— дип, Мәхмүт төрепкәсен кармалап алып авызына капты.— Ул сержанты! Ул солдаты!.. Я, сөйлә.

— Сөйлә, дип... Искитәрлек хәбәр түгел лә ул... Сорашмакчы гына идем. Ни... Мәхмүт агай, әгәр дә берәр солдат нитсә... заданиегә бармас өчен кулын, я аягын зыянласа...

— Шуннан да акыллырак уй килмәдеме исәр башыңа? Юньле сүзме дисәм... йокла, давай! — диде дә Мәхмүт, кабат җайлап ятарга җыенып: — Монда, туган, Җакиев белән түгел, трибунал белән киңәш итәргә кирәк,— дип кинәнеп иснәп куйды.

Кәрим дә, телен тешләп, кешене юкка уятуына үкенде, башын шинеле астына тыкты, тик Җакиев кинәт торып утырды да Кәримнең шинелен өстеннән сыдырып алды. Төрепкәсен сыбызгы сыман сызгыртып, хырылдавык тавыш чыгарып бер-ике суыргач:

— Сүзгә күчсәк тә ярый,— диде пышылдап.

Тартай теленнән табар. Я, ни әйтәсең хәзер, йомгакның очын сүтеп куйгач? Рябчиковның хәбәре — әлегә ни бары гөман, дөреслек ягы үтә чамалы. Аны расларлык бер генә төпле дәлиле дә юк Кәримнең. Ә телиме соң әле ул андый дәлилнең булуын? Кая инде, болай да арыган зиһененә, ичмасам, шушы хәсрәт өстәлмәсә... Шуңа ул, күнеленнән Рябчиков белән бәхәсләшеп, сүз әйтә алмый. Абайласаң, Рябчиков та бит Бакировның хәлен очраклы рәвештә генә белгән, Сима әбинең сүзе аның ярсулы күңеленә шик салган... Ләкин бу шикне ничек сызып ташлыйсың? Хәл эчендә яткан, менә-менә дөнья белән исәп-хисабын өзәргә торган кеше нахак сүз сөйли буламы? «Үч алудан түгел, Фаинканы җәлләп әйтәм...» дип кисәтмәдемени ул?

— Я, нигә дәшмисең? Төн уртасында уятты да хәзер ләм-мим...

Тик Кәрим һаман сүзен башлый алмый, Рябчиков, ихтимал, теге карчыкның хәбәрен ялгыш аңлагандыр дип, Бакировны якларга тырыша. Әйе, әйе, мөгаен, нәкъ шулай булгандыр! Ул инде койрыкны сыртка салырга, «Әй, Мәхмүт агай, һич тә шаярганны аңламыйсың икән?» — дип, эшне уенга борырга ниятләгән иде, Җакиев үзе кулын Кәримнең иңбашына салып:

— Бакировны, якташыңны әйтәсеңмени? — дип сорады.

Кәрим, сискәнеп, үзе дә сизмәстән, Мәхмүтнең беләгеннән тотып алды, һәм шушы ярсулы хәрәкәте аның фикерендәгене фаш итте дә куйды. Чигенер, ул-бу дип акланыр юл калмаган иде, баш кагып, Җакиевнең соравын җөпләде.

— Хуш... Әллә үзе ычкындырдымы? — диде тәмам йокысы ачылган Жакиев.— Тик кара аны, егет, ут белән уйныйсын түгелме?

— Әллә инде, утмыдыр, сумы — үләр алдыннан Ваня Рябчиков әйткән иде...

Кәрим сөйләп бетергәч, Жакиев байтак вакыт дәшми уйланып утырды. Егет инде әйтеп ташлавына үкенә башлаган иде, ниһаять, Мәхмүт, кабат телгә килеп, кыргызча ачулы мыгырданып куйды да:

— Хәбәрең йөрәкне куй мае кебек эретә торганнардан түгел. Бүтән кешегә сөйләп үрчетмә торсаң да ярар...— дип сүз башлады.— Дөресен әйткәндә, минем дә күңелне шиккә охшаган нәрсә тырнап килде килүен, тик аннан ни мәгънә. Кыскасы, әлегә оныт Бакировны, ансыз да баш чатнаган чак. Исән-сау әйләнеп кайтыйк эле — күз күрер...

Рухын изгән йөкне уртаклап бүлешкәнгәдерме, Кәрим, жинел сулап, шинеленә ураңды. «Әйе, Рябчиков инде сөйләгән хәбәрен раслый алмас, ә Бакировның, кирәге чыкса, үзен акларга теле бар. Ай-һай, жинел эш түгел бу!» — дип уйлады ул, борчулы черемгә чумып...

Таң алды булдымы икән — караңгы упкынга очкан төсле, бастырылып саташкан, сискәнеп, йокы аралаш автоматын чытырдатып кыскан Кәрим, эргәсендә генә пышылдашкан тавышка уянып, колагын тырпайтты.

— ... Ишеткәнсеңдер кичәге сабан туй шавын? Әйткән идем дә, Чукреев эшедер дип. Дөрес булып чыкты. (монысы — Федор тавышы).

— Ә ничек хәбәр итә алган? — дип сорады Мәхмүт.

— Нужа печән ашатыр, ди...— Чукреев тапмыйммы соң инде рәтен! Унлап кына солдаты белән тоткан да немецның рациясен басып алган. Төнлә булса бер хәл, көпә-көндез!.. Их, егетләр жәл... Сашка Вихрев белән сезнең лейтенант, тагы ике солдат ятып калды, ди.

Жакиевнең төрепкәсе гадәттәгеннән дә ныграк хырылдый, чинап сызгыра башлады.

— Я, аз гына черем итеп алыйк,— диде Толкунов.— Иртәгә лейтенантның хәбәрен әйтеп, Кәримнән сөенче алырлык булды. Син кара, Мәхмүт, күз-колак бул егеткә...

## Ничә яшьтә син, солдат?

Иртәгесен Кәримнәр соң гына уянды. Көн шактый ук яктырып, урман кош-корт шавына тулган иде. Томаннан арына башлаган аланда жанлылык. Кечкенә лагерь күптән аякка баскан, солдатлар аптыраган кыяфәттә арлы-бирле йөгерешә, туктап, кулларын селтәп, нидер сөйләшә. Федорның соравына десантчыларның берсе:

— Син нәрсә, күктән төштеңме әллә? — диде дә үз сүзеннән үзе көлеп куйды. Янәсе, күктән төшми, кайдан төшсен десантчы.

— Я, ыржайма юкка, сөйлә! — дип, Федор аягүрә басты.

— Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, командирсыз калдык,— диде солдат һәм кабаланып сөйләргә тотынды.

Ыгы-зыгының сәбәбе аптырарлык та иде шул — отряд башлыгы майор Левин каты яраланган иде.

... Майор, ике автоматчыны ияртеп, таң белән разведкага киткән. Автоматчыларның әйтүенчә, ул, картасына карап, отряд тукталган урманның киң дәрья сымак жәйрәп ятмавына, ә вак-вак корама төсле, уйдым-уйдым бүленеп, күп жирендә тар гына тасма булып сузылуына бик нык хәвефләнә икән. Күрәсең, шул хәвефне тикшереп карарга, кул астындагы иллеләп десантчының язмышын дөрес хәл итүенә үз-үзен тагы бер тапкыр ышандырырга уйлагандыр.

Урман читенә чыгып, киң карангы ерганак ярына ятканнар да болар каршыдагы кечкенә авылны күзәтә башлаганнар. Ара якын, бинокльдән карганда хәтта өйләрнең тәрәзә рамнары, бакча ышыгына поскан чуар машиналарның номерлары күренеп тора. Көн иртә булганлыктан, тирә-якта шылт иткән тавыш, хәрәкәт юк, бары тик үнлап немец, бербер артлы тезелешеп, авыл читендәрәк торган иске сарайга таба китеп баралар...

— Ах, кабахәтләр! — дип сүгенә дә майор, дошман төркеменә төзәп, кулындагы снайпер мылтыгыннан ата башлый. Немец солдатларыннан әллә берсен, әллә икесен яралап өлгерүе була, сарайга якын түгәрәк үр буеннан эре калибрлы дошман пулеметы «даг-даг-даг» килеп ут ача. Боларның баш өстендә, агач ботакларын токмачтай турап, шартлагыч пулялар ярыла, десантчыларның берсе, кукрәген тотып, авып төшә, икенчесенең автомат сабын пуля ярчыгы чарпалап ташлый.

— Артка! Урманга! — дип кычкыра да майор, торып йөгерә. Нәкъ шушы мәлдә аягын пуля тишеп чыга...

Кәримнәр майор землянкасы янына барганда, анда бөтен отряд җыелган иде инде. Солдатларның кайсысы тәмәке пыскыта, кайсысы, пышылдап, соңлабрак килгәннәргә дөнья хәлен аңлата. Агач кәүсәсенә аркасын терәп утырган майор ыңгырашмаска тырышып тешен кыскан. Кәгазьдәй агарып калган йөзенә, зур соры күзләренең курку катыш газап белән елтыравына караганда, ярасы җиңелгә охшамый.

Таня, ничәнче тапкыр инде аның аягын бәйләргә омтылды, майор җикеләнеп:

— Кулыңнан килерме соң? Ярасы азып, соңыннан аякны кисәрлек булмасмы? — дип сорады.

— Җитте, иптәш майор, тик ятыгыз! — диде Таня, ачуланып.— Монда миннән башка медик юк. Белгәнемчә тәрбиялим...

Эше беткәч, сагаешып калган десантчыларның сораулы карашына ул:

— Госпитальгә җибәрәсе иде дә бит...— дип пышылдап җавап бирде дә куышы янына китте.

— Врач чакырырга кирәк,— диде Җакиев.— Шуңа да ярамагач, ул рация нәрсәгә...

Майор әллә ишетте аның тәкъдимен, әллә юк — дәшми күзен йомды. Землянкага табан омтылган Кәримне ишек төбендә торган автоматчы туктатты.

— Я, нигә карап каттыгыз? — диде майор, күзен ачып.— Таралышыгыз! Офицерлар — минем янга!

Отрядтагы ике офицерның берсе урынынннан да кузгатырлык түгел иде. Ул, күкрәге яраланып, кан косып, саташып ята, уттай кайнар иренен чак кыймылдатып: «Сергей, Сергей! Уңгарак күчер утыңны! Граната белән дөмектер кабахәтләрне, граната белән!..» дип һаман да яу алып бара. Таня аны таңга хәтле үк үләр дигән иде. Юк, көрәшә һаман, яшәү даулый. Ярый инде, врач килеп җитсә, операция ясаса, җылыга урнаштырса...

Икенче офицер, юка гәүдәле, яп-яшь кече лейтенант, дугасы сынган түгәрәк күзлеген төзәтә-төзәтә, майор янына чүгәләп утырды. Бу Кәримнәр бригадасының тәрҗемәчесе иде. Кичәге аяусыз бәрелештә сынатмаганга охшый: күзе-башы күгәреп чыккан, муены шарф ураган төсле, марляга чорналган, кулында «шмайсер» автоматы.

— Да, туган, болай ни... синә эш тә юк шул монда...— диде майор, кече лейтенантка күз сирпеп.

— Эш житәрлек, иптәш майор! — диде кече лейтенант, автоматын сыйпап.— Солдатның эше — сугыш...

Майор дәшмәде, һаман шушы тирәдә таптанып торган Кәримне ымлап үзе янына чакырды да:

— Бар, сержантыңны җибәр минем янга,— диде.
Федор киткәч, Жакиев Кәримнең колагына:
— Эшләр көйләнә, Кәрим дус, Чукреев табылды,— дип пышылдады.
— Нигә соң сержант белән бергә килмәгән?
— Нигә, нигә... Алар бит ерганакның аръягына төшкән. Ә ерганак үзәне буйлап юл уза. Юлда ни барын үз күзең белән күрдең. Федор әйтә...
Жакиев сүзен бетерә алмады, кашы җимерелгән Федор әйләнеп килде. Иптәшләренең сораулы карашына игътибар да итмәстән, ачулы мыгырданырга тотынды:
— Һаман үзенекен тукый майор. Юк, ди, дошман белән очрашмаска, солдатларны сакларга, фронт сызыгы килеп җиткәнен көтәргә... Нигә, мин әйтәм, ул сызык җил искәннән күчәмени? Давай, дим, без дә күчерешик. Исән чакта атлаган саен һөҗүм итәргә, кулдан килгәнчә сугышырга кирәк. Ә безнең кулдан күп нәрсә килә!
Сержант, кинәт суынып, уйчан кыяфәт белән аланны күзәтә башлады. Эшсезлектән, билгесезлектән аптыраган десантчылар, вак-вак төркемнәргә бүленеп, берәүләре, сагаеп, еракта гөрселдәгән сугыш шавына колак сала, икенчеләре, нидер сөйләшеп, тыйнак кына көлешеп куя.
— Ай-һай, сайлап тапканнар урынын, ә! — диде Толкунов кабат телгә килеп.— Тозак бит бу, җәтмә! Уңлап автоматчы урап алса, чыгып өлгерерлек тә түгел... Минемчә, монда яралылар гына калырга тиеш. Аларны сакларга өч солдат җитә... әйбәтрәк урын табылгач, бөтенесен дә бергә күчереп алырга... Ә хәзергә, отрядны өчкә бүлеп, тирә-якны күзәтә башларга, азык-төлек хәстәрләргә...
— Синең ихтыярда булса, йомран төсле, посып та ятмас идек болай. Маршал ясарга иде сине,— дип, Жакиев күңелсез генә елмаеп куйды.
— Маршал — үз урынында, солдат — үз урынында. Икесенә дә эш җитәрлек,— диде Федор.
Шунда гына ул үзенең майорга урынбасар итеп билгеләнүен әйтте. Иптәшләре, бу хәбәргә куаныргамы, борчылыргамы, дип аптырап торган арада, сержант, аягүрә басып, өс-башын төзәтте дә алан уртасына атлады. Күп тә үтми, солдатларны сафка басарга чакырып, боерык яңгырады.
Отряд тезелгәч, Федор иң башлап һәр солдатның корал-ярагын барлап чыкты. Аннан десантчыларны үз теләкләре белән өч төркемгә аерды. Һәр төркемгә берәр кул пулеметы туры килде, автомат һәм карабиннар тигез бүленде.
Төркем командирлары итеп Толкунов Жакиевне, тәрҗемәче кече лейтенантны һәм олырак яшьтәге олпат кыяфәтле автоматчы сержантны билгеләде. Шуннан кече лейтенантка лагерьны сакларга, Мәхмүткә һич кичекми азык әзерләргә кушты да, төркемнәрнең берсен ияртеп, каядыр китеп барды.
Толкуновның җитди усал кыяфәтеннән, ышанычлы хәрәкәтеннән аның ниндидер хәвефле сәфәргә җыенуы сизелә иде. Кәримнең, әлбәттә, сержант белән бергә буласы, ул ниятләгән эштә катнашасы килә иде, тик Толкунов авыз да ачырмый:
— Кушканны үтә. Кара син аны, яралыларны сакларга калдырмавыма рәхмәт әйтәсе урында ризасызлык белдереп тора. Марш үз группаңа! — дип кырт кисте.
Һәм менә Кәрим, яңа командирына якынрак булырга тырышып, иптәшләренә күз сала-сала, гомерендә беренче тапкыр хәрби заданиегә китеп бара. Кырыклап кешене канәгатьләндерерлек азыкны кайдан эзләүләрен, нәрсә табачакларын Кәрим генә түгел, хәтта Жакиевнең үзе дә белмидер, мөгаен. Ә хәзергә ул, күрәсең, разведка ясап карарга, тирә-якка күз салып, нәрсәнең кай җирдәрәк ятуын ачыкларга уйлаган-

дыр. Группаның яртысын иртән майор яраланган төштә урман читенә якын гына аланда калдырды да, биш-алты десантчыны ияртеп, авыл ягына сузылган тирән ерганакка таба шуышты.

Дымлы, караңгы чокырны, адәм үтмәслек булып, уралып-чорналып үскән тигәнәк, тал, кычыткан басып киткән. Атлаган саен аякка кабак зурлык сазлы балчык ияре, я итек табанын куптарырдай куе ләпек, имәнеч сазламык очрый.

— Ходай каргаган җир икән,— дип мыгырданды Жакиев. Ләкин Кәрим күреп тора, башына төшкән язмышка сыкрап әйтми моны Мәхмүт, киресенчә, ирләргә хас җаваплы эш табуына канәгатьләнеп әйтә.

Ниһаять, ике-өч йөз метрга сузылган мәхшәр юлны үтеп, әрәмәлек читенә җиттеләр, вак куак астына ятып, авылны күзәтә башладылар. Шик-шөбһә салырдай тавыш ишетелми. Фронт сызыгына якын авылларга хас борчулы тынлык, бушлык. Тик десантчылардан күп булса утыз адым чамасы арырак торган кечкенә өйдә генә җан әсәре барга охшый — морҗадан, күгелҗем дебеткә охшап, нәзек кенә төтен җебе күккә үрли. Өйнең тәрәзә капкачлары ябулы, тәбәнәк болдырда зур соры песи кояшта кызына.

Ун минут ятканнардыр, йорттан чыккан-кергән кеше күренмәде. Жакиев иптәшләренә аң булырга кушты да өйгә таба үрмәләде. Менә ул, автоматын әзер тотып, аягүрә басты, тирә-ягына каранып, тавышларга колак салды. Өй эчтән бикле булды, күрәсең: Жакиев ишекне сак кына шакыды да, аяк тавышы ишетепмедер, читкәрәк китте. Яртылаш ачык ишек авызында арык гәүдәле, чәче-сакалы тырпайган карт күренде. Мәхмүт, аның белән нидер пышылдашып, өйгә кереп китте, аннан озата чыккан картка тагы нәрсәдер әйтеп, әрәмәлеккә табан ымлады да иптәшләре янына ашыкты.

Нәрсәсе беләндер Кәримнең авылдашы Гатау бабайга охшаган, ләкин яше анықыннан байтак олы, кыяфәте йончу карт озак көттермәде, тезенә җиткән озын пинҗәк төймәләрен каптыра-каптыра, агачлыкка карап атлады. Десантчыларны күреп, ул һич тә аптырамады, иске танышларын очраткан сымак, һәрберсе белән күрешеп чыкты. Аның игътибарын тарткан бердәнбер нәрсә — солдатлар кулындагы автомат булды шикелле. Сөйләшкән арада да ул әле бер, әле икенче десантчының коралын сыйпый, түгәрәк дискысын селкетергә уйлап, тотып куя.

— Ошыймы? — дип сорады Жакиев.

Картның җавабы тел очында иде шикелле:

— Бичәмени ул ошарга? Атып карамыйча каян беләсең...— диде.

Әкрен генә көлешеп алгач, Жакиев сүзгә күчте. Карт монда да артык уйлап тормады, җавабын күптән әзерләп куйган кебек:

— Соңладыгыз, улларым. Немец сездән өлгеррәк булып чыкты. Ашлык сукканчы эндәшми торды да, вакыты җиткәч, бар булганын сыпырды да алды,— диде көрсенеп.

Бабайның әйтүенә караганда, якын-тирәдә немецның азык-төлек склады юк, авылда торган дошман солдатларына көненә ике тапкыр кайдандыр тәгәрмәчле кухня ашарга китерә икән.

— Немец автоматын салдырып алырга көч кирәк,— диде карт, Жакиевнең автоматына ымлап.— Авыл халкы азаккы телемен бирер иде — үзе ач. Шулай булгач, оланнар, баш тирәли уйларга кала инде... Хәер, старостаны кысканда ул-бу чыгуы ихтимал. Теләсәгез, чакырып китерәм мин аны...

Десантчылар урманга борылырга, ә карт алар янына старостаны алып килергә сүз куештылар.

— Килерме соң? — диде Мәхмүт.

— Килү генәме? Юргалап, аягы сынса — мүкәләп барып җитә ул. Хәзер ул сатлык җаннар еландай боргаланачак безнекеләр алдында!..

Чынлап та, Кәримнәрнең киредән урманга керүенә бер сәгать тә узмады, куаклык арасында башта баягы кечкенә, елгыр карт күренде, аның артыннан түгәрәк кара сакаллы, олы гәүдәле, аксаграк кеше килеп чыкты.

Карт, иңенә аскан сумкасын чишеп, солдатларга алма өләшергә кереште.

— Азык кирәк,— диде Жакиев, старостаның сәламенә җавап биреп тормыйча.

Староста, сакалын учлап, уйланып торды, шуннан җайлырак җир табып утырып, аягын язды да:

— Нигә кешегә? — дип сорады.

— Анысы синең эш түгел! Кара син аны, белә, мәлгунь, ни сорарга! — дип, карт нечкә тавыш белән кычкырып җибәрде.— Әйтә күрмә, командир, хәзер немецка житкерә ул!

— Шауламый тор әле, Платон бабай... Ярамый икән, әйтмәсен. Тик, үзең беләсең, мин дә әллә ни эш кыйрата алмыйм. Тапсам берәр капчык кукуруз табармын.

Картка житә калды. Старостаның алдына ук йөгереп килеп, җир төсенә кергән кара йодрыгын аның борын төбендә селки-селки, төкерек чәчеп тәтелдәргә кереште:

— Юк дисең инде... Ә син уйлый төш! Баш тирәли фәһемләп кара! Я? Искә төшмиме?..

Староста, мыек астыннан ипсез елмаеп, әтәчләнеп барган картка ни әйтергә белми аптырап калды. Ул әндәшмәгәч, Платон бабай чүгәләп ике кулының имән бармагын, мөгез кебек итеп, баш өстенә куйды да:

— Мә-ә-ә! — дип мөгрәп җибәрде.— Инде дә аңламыйсыңмы? Ай-һай, хәйләкәрсең син, Петро Онуфрич! Әллә инде, немецның артын ялый торгач, зиһенеңне йоттыңмы? Кыскасы шул: үгезне китер егетләргә!

— Туктап тор, бабай...— дип, Жакиев кулын күтәрде.— Менә нәрсә, әфәнде дисәмме, гражданинмы... димәк, үгезең бар булып чыга, ә?

— Үгез, үгез... Юкны сөйли ул, төшенә кергәнне лыгырдый. Авылда тавык, кош-корт калмаганда үгез каян булсын...

Староста, сүз беткәнне аңлатып, урыныннан тормакчы булган иде, ике ягыннан ике автоматчы иңбашына кагылгач, көрсенеп, тәмәке урый башлады.

— Алдый, иптәш командир! Ышана күрмә. Әйдәгез, мин беләм кайда яшереп асраганын.

— Ярык барабан син, Платон бабай — менә кем! — дип староста иңбашыннан десантчыларның кулын селтәп төшерде дә аягүрә басты. Ачынып елмайгандай итте.— Тфү, телеңә тилчә төшкере! Кайдан белеп өлгергән...

Карт тәкәббер кыяфәттә сакалын сыйпап куйды.

— Платонның белмәгәне юк! Тик, күпме баш ватмыйм, бер нәрсәгә акыл житми: ни дип асрыйсың ул үгезне? Немецка дә бирмәдең, инде үзебезнекеләрдән дә яшерәсең...

Староста аңа, чебен куалаган кебек, кул селтәде дә, сагаешып, күзләреннән нәфрәт атып торган десантчыларга борылды. Кырыс тавыш белән сүз башлады:

— Менә нәрсә, иптәшләр...

— Капка астындагы кәкре койрык сиңа иптәш,— дип мыгырдады Платон бабай.

— Әйе... Теләсәгез ни эшләтегез, үгезне бирмим,— дип украинчалап сүзен дәвам итте староста.— Бирә алмыйм, чөнки ул минеке түгел, колхозныкы. Суеп ашарга уйласагыз, ите тамагыгызга торыр. Сугыш чыккан елны үзем, Архангельск ягына барып, нәселгә дип алып кайттым

мин аны. Ягъни колхозның сыер токымын яхшыртырга... Фашистны куып олактыргач, кабат тотынырга чамалыйм...

— Башта синең үзеңне чамалап карарга кирәк әле. Стенага терәп, ни рәвешле фашист ялчысы булып йөргәнеңне сөйләтергә...— дип, Платон карт тагы түзми сүз кыстырды.

— Сөйләтерләр...— дип куйды староста.— Ярый, мина китәргә вакыт. Күз бәйләнгәч, нәкъ шушы җиргә ике капчык пешкән кукуруз китерербез. Һәйбәт, туклыклы азык, тоз гына юк.

Солдатлар инде, бу сатлык җан безне кәкре каенга сөяп китмәкче, үгез урынына тозсыз кукуруз биреп котылмакчы дип, сукранышa башлаганнар иде, нидер уйланып, төрепкәсен авызының әле бер читенә, әле икенчесенә күчереп дәшми торган Жакиев, тын булырга кушып, кулын күтәрде. Маңгаен җыерып, җилкәсен кашуына карагaнда, ул табышмак чишеп азапланган кешене хәтерләтә иде. Менә төрепкәсен чупылдатып бер-ике суырды да старостага карамый гына:

— Авылда ни хәлләр бар? — дип сорады.

— Билгеле инде ни хәл булуы...— дип җавап бирде староста.— Фронт эргәсе. Днепрга моннан дүрт чакрым, ә анда, яр буйлап, немецның оборона сызыгы үтә. Менә шулай... Авыл саен юл сакларга пост куелган, бездә дә унбишләп кеше иде, үткән төндә эсэс солдатлары килеп тулды. Хәзер бөтенесе кырык-илле кеше. Этләре, минометлары бар. Урманны тарап чыгарга җыеналар бугай...

— Кайчан? — дип сорады десантчыларның берсе, тирә-ягына каранып.

— Хәзер барып белешермен,— дип көлемсерәде староста.— Төнәген энем Максимка күрше авылда булган иде. Анда да шул ук хәл, ди. Фронттан бер взвод автоматчы чакырып алганнар. Сездән куркалар. Хәер, сезнекеләр юаш халыкка охшый алай...

Жакиевнең шешмәк кабаклы күзендә ачу елтырап китте, ләкин ул, ярсуын басып, старостаның кинаясын аңламаганга салышты. Иптәшләренә утырып ял итә торырга кушты да, старостага ымлап, читкә атлады.

Кире әйләнеп килгәндә Мәхмүтнең чырае ачылып, йөреш-торышы бөтенләй үзгәргән иде. Хәйләкәр елмаю очкынланган кысынкы күзенә, сак кына басып атлавына карагaнда аны усал, көчле җанвар сагалаган аучыга охшатырга мөмкин иде.

Көзге кыска көн кичкә саркый. Кояш инде, шактый түбән тәгәрәп, урман киртләчләгән офыкка чумарга якынлаша. Ерганактан эчкелтем төтен катыш салкынча дым тартыла. Тирә-якта ирәвән тынлык. Хәер, ныграк колак салсаң, кайдадыр исәпсез-сансыз машиналар гүләвен дә, туплар гөрселдәвен дә ишетергә булыр иде. Тик сугышның табигый бу авазы сискәндерми инде солдатны, аның колагы якындагы тавышларга сагаючан. Яфрак кыштырдадымы, пешкән җимеш тупылдап җиргә төштеме — десантчылар, сагаешып, күзләрен түгәрәкләндереп, шырлыкка текәлә, автомат сабын кыса. Һәр кыштырдауга игътибар итеп, бер-берсенә карашкан яшь солдатларын күздән кичерде дә Жакиев, юри кычкырыбрак:

— Их, урманның матурлыгы! Сугыш беткәч, мотлак күрергә киләм. Тик җәй килергә кирәк... Монда якында гына Канев каласы, анда Шевченко кабере диләр...— дип сөйләнеп куйды.

Солдатларның берсе шундук:

— Нигә сөрәнлисең? Әкренрәк...— дип пышылдады.

— Ә син иркенрәк тын ал, сулышыңны кысма. Үзебезнең җир бу, туган, нигә куркырга? Фриц посып ятсын! — диде Жакиев.

Мәхмүтне кисәткән солдат аңа якынрак шуышып ятты, хәзер командирына пышылдап дәшсә дә, ишетелерлек сүзен нигәдер кычкырыбрак әйтергә булды:

— Юкка ышандың теге сатлыкка. Ычкындырмаска иде...

Мәхмүт аны аркасыннан кагып куйды, елмаеп, нидер әйтергә җыенган иде, лагерьга җибәрелгән элемтәче әйләнеп кайтып, Жакиевне урман эченә чакырды.

Күпме баш ватмасын, Кәрим командирының нәрсә уйлавын белә алмады. Тик шунысы ачык: Жакиев аксак староста китерәсе кукурузны гына көтеп утырмый монда. Лагерьга элемтәче җибәрүе дә юкка түгелдер. Нидер бар уенда, нидер тәвәккәлли... Ә старостаны, чынлап та, җибәрмәскә кирәк иде. Син аннан азык көтәсең, ә ул десантчылар керфек какмый күзәткән, карасу-яшел төскә кереп караңгылана барган баягы ерганактан түгел, бөтенләй икенче яктан немецларны ияртеп килеп чыкса? Үгезен тартып алырга, ә үзен агачка терәп атарга иде аны!..

Агач арасыннан Жакиев күренде. Аның артында ук житез, кискен хәрәкәтле, өс-башы, корал-ярагы, хәтта башына ураган марлясы чипчиста Толкунов килеп чыкты. Ул, аягын аерып басып, шәп-шәп атлап, десантчыларга баш кагып кына үтте дә урман читенә, сакта торган солдатлар янына ашыкты.

«Менә ничек,— дип уйлады Кәрим.— Сержант үзе килгәч, юкка түгелдер. Башлана болай булгач...» Нәрсә башланырын белмәсә дә, ул хәзер ниндидер мөһим вакыйга көтелүенә шикләнми иде инде. Әнә бит Толкунов белән Жакиев, сакчылар яныннан әйләнеп килеп, карта җәеп салдылар, кызып-кызып пышылдашырга тотындылар. Эшләре беткәч, Толкунов алып килгән солдатларны да Жакиев төркемә янына чакырып утырттылар. Нәкъ шушы вакытта староста күренде. Ул, чынлап та, ерганак үзәненнән түгел, бүтән яктан килеп чыкты. Староста артыннан кулларына немец автоматы тоткан, аркаларына зур-зур капчык аскан өч кеше ияргән иде.

Аларның берсе — күпереп торган ап-ак мыеклы, йомры, зур гәүдәле кеше, капчыгын җиргә куйды да, тыны кысылып, сүзне танышудан башлады:

— Гай. Яшерен өлкә комитетыннан...— Ул нидер әйтергә уйлаган Толкуновның беләген кысып куйды.— Беләм, беләм, сержант... Мин монда үтеп барышлый гына... Менә, мәйтәм, күрим әле егетләрне... Сүз шул: бүген төнлә фронт сызыгына якын авылларда немецларның җәза отрядларын туздырырга карар ителде. Бу акциянең максатын төшенәсездер. Черкас урманындагы сезнең бригадалар баш-күз алганчы дошманның игътибарын бу якка тартырга. Ә азык...— Гай, йөнтәс, саллы йодрыгын селтәп, һаваны чүкеп куйды.— Горпищевоны үз өстегезгә аласыз, дип ишеттем. Безнең кул житәрлек түгел иде, рәхмәт. Калган ягын Василенко иптәш белән хәл итәрсез. Ә син борчылма, Петро Онуфрич, бичәкәең белән кызыңны кунак сыенда тотарбыз...— дип елмайды.

— Безгә врач кирәк иде, Гай иптәш, авыр яралылар бар,— диде Жакиев.

Гай әз генә уйланып торды да:

— Иртәгә,— диде.— Әйе, иртәгә менә шушы иптәш килер. Яралыларны безнең базага күчерергә туры киләчәк. Анда сезнекеләр байтак хәзер.

Шулай диде дә Гай старостаны кысып кочаклады, аның янында басып торган бөдрә чәчле, купшы яшь партизан белән кул биреп хушлашты. Әледән-әле сиздерми генә сәгатенә күз салган юлдашын ымлап чакырып, урман эченә кереп китте.

— Менә, командир, кукуруз китердек,— диде Василенко йөкләрне күрсәтеп.— Әзрәк икмәк, май, өч-дүрт банка ит консервасы да табылды.

— Яхшы...— диде Федор. Шуннан солдатларга үз кулы белән ике-

шәр баш пешкән кукуруз өләшеп бирде дә төеннәрне лагерьга озатырга кушты. Сәгатенә карап: — Унбиш минуттан кузгалабыз,— дип өстәде.

— Менә сиңа староста! — дип куйды десантчыларның берсе.

— Колхоз үгезен немецның борын төбендә ике ел күрсәтми асраган, ә? — дип икенчесе элеп алды.

— Һай, бар булгыры!

Күнелләре күтәрелеп киткән солдатлар, көлешә-көлешә, башлы килеш пешерелгән кукуруз ашый башладылар.

Кайдандыр килеп чыккан Платон бабай, иске берданкасын агачка сөяп, Василенко алдына тезләнде, ике кулын күкрәгенә басып, еламсырап сөйләргә тотынды:

— Туйдыручыбыз, сакчыбыз! Рәнжемә инде, Петро Онуфрич, исәр картның лыгырдавына! Ай-һай, хәйләкәр дә хәйләкәр, әмма да синдәй мут булмас бу дөньяда! Ходай саклады гөнаһтан, югыйсә бит, ничәмә тапкыр, шул берданканы тотып, юлына чыктым... Ә үзем уйлыйм: кем, мәйтәм, немецның фәлән җиренә борыч кыстыра? Тәки акыл җитми! Баксаң, синең эшең икән, колхоз башлыгы!

Василенко, иелеп, картны култык астыннан кочаклап алды, кечкенә бала күтәргән сымак, җилтерәтеп аягүрә бастырды. Мыек астыннан елмаеп:

— Беләбез, Платон бабай, синен этлекләрне дә беләбез. Я, әйт әле, кем немецның казанына тавык тизәге салды? Кем узган кыш обер-лейтенант машинасының тәгәрмәченә кадак тыкты? Бөтенесе дә билгеле! Менә фашистны дөмектерик әле. Күз күрер. Үзең әйтмешли, чамалап карарбыз. Кумушкә кайнатканыңны да искә алмый булмас...

— Ай-вай, аксакал, көндез мин барганда кумушкә кайната иденме әллә? Морҗаңнан төтен чыга иде бит,— дип көлеп Жакиев тә старостаның сүзен куәтләп җибәрде.

— Юк,— диде Платон бабай, аска карап.— Юк, берданкага кургаш эретә идем бу юлы. Утсыз ничек эретәсең аны, кызган табада тәгәрәтми?..

Солдатлар, көлешеп, картны берсе махорка, икенчесе «Беломор» белән сыйлый башладылар. Ләкин ул папиросны иснәп кенә карады да, башын чайкап, кесәсеннән зур калай тартма чыгарды, саргаеп беткән иске газета кисәгеннән дәү «кәҗә тоягы» төрде. Һавага ут кебек ачы сасы төтен таралды. Хәтта сугыш чыкканнан бирле тәмәкенең авызга алмас зәһәрләрен тартып караган солдат халкы, бу төтеннән чәчәп, читкә тайпылды.

— Бәлки минеке ошар? — диде бөдрә чәчле партизан, чабулары кырпулы, купшы күн курткасын ычкындырып. Күен кесәсеннән сигарет чыгарганда ул, ихтыярсыздан кыланган төсле, пинжәк якасына беркетелгән өр-яңа «Батырлык өчен» медален күрсәтеп куйды.

Немец сигареты солдатларга ошамады.

— Мук ни дә, бу ни...— диде берсе.

— Хасияте шул, имеш,— диде икенчесе,— ешрак тартсаң, бичә-чәчә искә дә төшми, ди. Безнең махоркага җитәме соң!

Шулай да яшь партизанны сырып алдылар. Һәркем күз кырые белән генә аның түшенә карап куя, медаль иясенә сүз куша. Десантчыларның күбесе дошман белән беренче тапкыр йөзгә-йөз очрашырга әзерләнгәнлектән, медальле егет аларның карашында ут-су кичкән батыр иде.

Кәримне кызыксындырганы да, әлбәттә, сигарет түгел иде. Ул, җаен китереп, үзенә кирәкне төпчи, партизан егет белән дуслашу ягын кайгырта:

— Исемең кем? Ничә яшьтә син?

— Максим,— дип җавап бирде купшы партизан.— Ә синең исемеңне беләм инде мин: Кәрим — дөресме?

— Яшең, яшең ничәдә?

— Яна елда унсигезем тула,— диде Максим, олы кыяфәттә папиросын суырып.

— Алдаша,— дип, Платон бабай чырк итеп көлеп куйды.— Шыттыра. Ул ни рәвешле унсигез тула ди? Бүгенгедәй хәтеремдә, мәрхүм Грицко белән энием Килинаның туе бер мең дә тугыз йөз дә егерме бишенче елның көзендә, ягъни моннан төп-төгәл унсигез ел элгәре булды. Ә ни өчен хәтерлим? Чөнки үзем башкода булып бардым... Менә хикмәт, синең сүзеңә ышансаң, туйдан бер ел элек туган буласың лабаса!

— Син үзең шыттырасың, Платон бабай! — дип олылыгын онытып, малайларча нечкә тавыш белән кычкырып җибәрде Максим.

— Чәпчемә, зирек тәртә! Атаң мәрхүмгә охшап, син дә, ай-һай, җиңел холыклы булмакчысың,— диде карт.— Хәер, җаны теләгән елан ите ашаган — әйдә, миңа калса, тагы биш яшь өстә. Тик фашист кулыннан шәһит киткән ата-анаңны юкка рәнҗетәсең. Өйләнешмәс борын бала тудырырга алар юньсез кеше идемени? Шөкер, ил күрке булып яшәделәр...

Максим сүрелә төшеп иренен кысты. Нидер әйтергә авыз ачкан иде, өлгермәде — бер читтәрәк сөйләнеп утырган Федор, Мәхмүт һәм Василенко солдатлар янына килделәр.

«Мин — уналтыда, Максим — унҗидедә, Федор белән Мәхмүт егерме өчтә,— дип уйлады Кәрим.— Платон бабай ничәдә икән? Мөгаен, җитмештә бардыр инде. Тик картайдым дип тормаган, тутыгып беткән иске берданкасын тотып, яуга чыккан. Димәк, ул да, без дә — солдатлар. Дошман танклары ермачлап, туплар актарып бетергән, ялкын ялмаган җиребез — бөтенебезнең газиз тәнгә. Горпищево авылының төрле тәңгәленнән шәм төсле калкып чыккан әнә ул тупыллар, тол бичәләр кебек, боегып утырганда, аяз күктә торналар иркен очар әмәл булмаганда кем җан тынычлыгы тапсын? Сугыш булмаса, Василенко, автомат асып, үз җирендә үзе посып йөрер идемени? Староста исемен күтәрер идемени? Юк, хуҗа булып йортын кайгыртыр, кыр эшләрен уйлый башлар иде.

Ә хәзергә барыбыз да солдат. Халыкның яше-карты яуга күтәрелгән...

Үпкәләбрәк читкә карап торган Максимны уйлады Кәрим. Баксаң, язмышлары уртак икән аларның. Икесенең дә ата-аналары һәлак булган, икесе дә яшьләй кулына корал тотып сафка баскан. Дөрес, Кәримнең әлегәчә әллә ни кыйратканы юк. Максимга житәргә иртә әле аңа. Медальне бит биегәнгә бирмиләр. Мөгаен, әнә Платон бабай кебек, немецның кухнясына тизәк кенә салмагандыр... Шуңа да Кәрим задание вакытында мөмкин хәтле партизан егеткә якынрак булырга күңел беркетеп куйды.

* * *

...Иске сарай эргәсендәге постка һәм староста өендә оялаган эсэс отрядына берьюлы һөҗүм итәргә булдылар. Толкунов монда да эшнең иң авырын үз өстенә алды. Василенконың әйтүенә караганда, аның өен немецлар, чынлап та, табышын саклаган козгын төсле, тәүлек буе күз яздырмый каравыллый, бакчадагы бронетранспортер рациясе аша штаблары белән туктаусыз хәбәрләшеп тора икән. Моннан тыш күршедәге йортларга, хуҗаларын куып чыгарып, өстәмә сак куйганнар.

— Юк, туганнар, өйгә, ни яктан гына сугылганда да сиздермичә якынлашу мөмкин түгел. Бердәнбер юл — ындыр артлап, сазлык аша чыгарга. Анда минем урылмаган житен җире мунча ишегенә үк килеп терәлә. Тик менә сазлыкны ничек үтәргә? Киң дә түгел түгелен, күп булса биш-алты адымдыр...— диде Василенко.

— Узган көз турап өйгән чыбык-чабыгыңны кая куйдың? — дип сорады Платон карт.

— Һай, картың! — дип Василенко сикереп торды. Юкка гына исәнеп йөрми икән бу тиктормас карт!.. Ләкин шунысы: шылтырап кипкән чыбык-чабыкны урыннан кузгата башласаң, төнге тавыш әллә кайдан ишетелмәсме?..

— Немецның игътибарын бүтән якка тартырга кирәк,— диде Федор, нигәдер Платон бабайга карап.

— Булдырабыз аны,— дип, бабай берданкасын сыйпады. Максимга карап куйды.— Тик соңыннан онытмасаң ярый да... Югыйсә, партизан отрядына алмадылар. Картмын, янәсе. Малай-шалаена тикле медаль тагып йөргәндә...

— Сөйләштек,— диде Федор.— Без күпер эргәсенә чыккач та авыл очында атыш башлыйсың... Хәер, менә сиңа ярдәмче,— дип, бер солдатына төртеп күрсәтте.

Сарай буендагы блиндажны юк итү Жакиев төркеменә йөкләтелде. Төркем операция урынына, урман эчләп, дүрт-биш чакрым урап, Днепр ягыннан чыгарга, авылда атыш башлану белән һөҗүмгә күчәргә тиеш.

Жакиев төркеме шундук кузгалып китте, чөнки юл күрсәтүче итеп билгеләнгән Максимның әйтүенә караганда, бу маршрут артык хәвефле түгел, әмма шактый ук авыр. Берничә тирән ерганакны, дошман машиналары туктаусыз узып торган таш юлны кисеп чыгарга туры киләчәк.

Юллары башта күзгә төртсәң күренмәс, дөм караңгы урман аша барды. Маңгайлары белән агачка бәрелмәс өчен солдатлар капшанып диярлек атладылар. Жакиев төркемнең әле алдына үтте, әле артта калып, тәмәке тартмаска, корал-ярак шылтыратмаска кушты. Командирның сак булырга боеруы һич тә артык түгел иде: урман өстендә немецларның «рама» дигән разведка самолетлары бөтерелә, җим эзләгән тилгән кебек, десантчыларны сагалый, кайдадыр ят телдә акырышкан тавышлар аермачык ишетелеп кала.

Бер кавым сөйләшми генә атладылар. Урман күзгә күренеп сирәгәя башлады. Юл, иңкүгә тартып, ерак йолдызларның тоныкнуры төшкән уйдым-уйдым кечкенә аланнар, эреле-ваклы ерганаклар аша үрмәләде. Менә урман тирән чокыр аша сикереп чыкты да, сирәк кенә куаклыкка әверелеп, үгез маңгае төсле текә янтайган такыр яр читенә килеп төртелде.

Төн караңгы булса да, Кәрим үзен шыр-ялангач чишенгән килеш урам уртасына чыгып баскандай хис итте. Бүтән десантчылар да, шым гына тамак кырып, бер-берсенә сыеныша, артта калган урманга үкенүчән-борчулы караш ташлап куя. Тик хәзергә анда борылып кайтулар юк шул инде! Сугышның аяусыз законы сезне, хәлдән таеп аруыгызга карамастан, алга әйди, сарай ышыгына поскан блиндаж янына ашыктыра. Ихтимал, шушы каһәр блиндажны җимерүдән меңәр чакрымга сузылган фронтның язмышы чак кына да үзгәрмәс, кечкенә десант отрядының тир түгеп, кан коеп табачак җиңүе дә сугыш барышына йогынты ясарлык вакыйга булмас. Кем белә, күпләрегез өчен бүгенге төн гомер азагыдыр. Ләкин сез инде туктый да, чигенә дә алмыйсыз. Солдат дигән изге исемегез бар...

Максим, ярның сөзәгрәк җирен сайлап, аска, кайдандыр бормаланып килеп чыккан сай ерганак эченә сикереп төште. Десантчылар аның артыннан иярде. Ерганак төбеннән чылтырап су акканы ишетелә, аяк астында ләпек лычкылдый. Алда, ерганакны буып, нindидер корылма сөрәеп тора. Корырак җир табып, утырып ял иткән арада Кәрим бу корылманың кечкенә генә күпер икәнен чамалап алды. Күп тә үтми, күпердән аллы-артлы ике машина гүләп узды. Шунда ук, пышылдап:

— Алга! — дигән команда бирелде.

Солдатлар юлга ташланды. Кәрим тезе белән нәрсәгәдер бәрелүен искә дә алмыйча, алар артыннан омтылды. Олы юл аша әллә йөгереп, әллә очып дигәндәй чыкты да аска тәгәрәде. Сикереп торып, алдз беленер-беленмәс күренгән әрәмәлеккә йомылды. Менә ул солдатларның башта берсен, аннан икенчесен, өченчесен узып китте, ә аяклары һаман алга әлдерә иде. Куак ышыгында яткан бүрәнәгә утырып, нидер эшләгән солдатны күргәч кенә Кәрим шып туктады. Бу — Жакиев иде. Күрәсең, ул баягы машиналар узганчы ук юлны аркылы чыккан да, кабаланмый гына чолгавын урап утыра. Командирының җайлап, хәтта өйдәгечә иренебрәк маташуы Кәримне шундук тынычландырды. Ул, шул тикле ярсып йөгерүеннән оялып, читкәрәк утырды да пычрак чәчрәгән автоматын сөртергә, гранаталарын, запас дискыларын барларга кереште.

— Җыелып беттегезме? — дип сорады Жакиев, иптәшләрен күздән кичереп.— Максим кайда?

— Мин монда, иптәш командир... Күз салып килдем, юл буйлап блиндаждан элемтә кабеле сузыла. Атыш башлангач та өзеп ташларга кирәк,— дип сөйләнә-сөйләнә, Максим Жакиев янына чүгәләде.

«Күрдеңме! — дип куйды Кәрим эчтән генә. Син күзең ак-караны аермый куркып йөгергәндә ул эш бетереп йөри»...

— Финкаң бармы? — диде Жакиев. Ул моны көндез кычкырып сөйләшкән өчен шелтәләгән Кузнецов исемле солдатка әйтте.— Бик әйбәт... Тик колагыңа киртеп куй: атыш башлангач!

— Аңладым, иптәш командир,— дип, Кузнецов учына төкереп куйды.

Төркем, икегә аерылып, зур сөзәк үрне урап ала башлады. Күп булса кырык-илле адым калган блиндаж үрнең нәкъ уртасында тора, аннан әледән-әле «дагылдап» аткан пулеметлар яктырткыч пуля сиптерә.

Үр киртләченә посып яткан десантчылар, сагаешып, авыл ягына колак сала, тик анда әлегә тынлык, ара-тирә немец сакчыларының алагаемга автомат тырылдатып алганы гына ишетелә. Ике-өч көн элек шаулап явып үткән яңгырдан соң дымга туенган җир һаман кибеп җитмәгән. Тез-терсәкләр шундук юешләнеп, тамакны коры ютәл өйки, тәнне ирексез калтырата башлады.

— Максим, Максим,— дип пышылдады Кәрим янында яткан партизан егеткә.

— Ни булды?

— Булмады... Бүтән партизаннар юкмыни бу тирәдә?

— Бар иде, хәзер, фронт якынайгач, көнбатышка күчтеләр. Кирәк хәтле генә калды...

— Немецны кугач нишлисең?

— Фронтка китәм,— диде дә Максим, бармагын иренenә басып, «т-с-с» дип сөйләшмәскә кушты.

Ләкин Кәрим түзмәде, бераз тын яткач, тагын сүз кушты:

— Медальне ни өчен бирделәр?

— Әй, булды инде...— дип куйды Максим. Янәсе, әллә ни кырган юк, әмма бушка да түгел.

— Алай да?..

Нәкъ шул вакыт авыл очында көчле шартлау яңгырады. Максимның:

— Платон бабайның берданкасы! — дип әйтеп өлгерүе булды, баягыдан кайтышрак тагы бер мылтык шартлады, аннан тагы...

Десантчылар — Жакиевнең сызгырганын әллә ишетте, әллә ишетмәде — ярсып алга, ныгытма торган түбәгә ташланды. Амбразура авызына гранаталар очты; траншея эчендә башта кычкырышкан, ачы сүгенгән тавышлар ишетелде, аннан автоматлар тырылдый башлады. Тыштагы сакчылар белән эшне бетергәч, десантчылар блиндаждан читтәрәк

торган землянкага һөҗүмгә ташландылар, чөнки постның күпчелек солдаты, сменадан бушап, анда ял итә иде. Ә хәзер алар, исләрен җыеп, аяусыз каршылык күрсәтергә тотындылар.

— Кая, булыш! — диде Максим, землянка авызына карап йөгергән Кәримне туктатып.

Икәүләп блиндаж ишегенә тол бәйләме беркеттеләр дә, нечкә чыбыкны суза-суза, ашыктырып торган Җакиев янына йөгерделәр.

— Ятыгыз! — дип кычкырды Максим.

Һаваны куәтле шартлау тетрәтте. Эчкелтем-татлы төтен таралгач, десантчыларның күз алдында юан-юан бүрәнәләре сураешып чыккан, асты өскә килгән ныгытма пәйда булды.

Землянка янындагы траншеяда һаман атыш гүли. Граната ыргытырга дип калкынган десантчы, башын тотып, чалкан әйләнеп төште, аның янына ашыккан икенчесе дә шунда ятып калды.

— Уратып алырга! — дип кычкырды Мәхмүт.— Арттан төшәргә!

Ике десантчы күз ачып йомган арада, траншеядан чыгып, иелә-иелә читкә йөгерде. Күп тә үтми, аларның берсе землянка түбәсендә күренде. Солдат сыек кына төтен пыскытып торган тимер морҗаны автомат түтәсе белән эчкә сугып төшерде дә землянка эченә бер-бер артлы граната ыргытты...

Тар-мар ителгән пост тынып калды. Җакиев солдатларын авылга, аяусыз атыш барган староста өенә ашыктырды.

Алар барып җиткәндә староста өе ялкынлап яна. Толкунов төркеме, атыша-атыша, урманга таба чигенә иде. Кәрим, Җакиевтән күз яздырмаска тырышып, киртә аша урамга сикерде, безнекеләрне кысрыклап йөгергән кара шәүләләргә төзәп ата башлады. Ике ут уртасында калган фашистлар урам читенә сыенып, кире староста өенә, аннан, ындыр артлап, олы юлга таба сибелделәр.

Нәкъ шул вакыт яктырып килгән күктә самолет күренде. Аны, мөгаен, әле дөрләп янган бронетранспортер дөмеккәнче үк рациядән чакырып өлгергәннәрдер. Немец козгыны эшнең нидәлеген бик тиз аңлап алды, күрәсең — түбәннән генә очып үтте дә кире борылды. Ышыкка поса алмый калган десантчылар өстенә мина ыргытырга, пулеметтан ут яудырырга тотынды.

Урманга житеп килгән иптәшләреннән калмаска тырышып, Кәрим аһылдап йөгерүен белде. Аның алдыннан курткасын җилбәгәй җибәргән Максим, шинель итәген бил каешына кыстырган Җакиев йөгерә иде. Толкунов егетләре күренми, алар, мөгаен, урманга барып җиткәннәрдер инде.

Якында гына аллы-артлы ике мина шартлады. Кәримнең башы шаңкып китте. Ул күз алды караңгылана баруын тоеп тешен кысты. Тагы бер омтылса, урман читендәге текә яр ышыгына җитәчәк. Тизрәк, тизрәк! Баш өстендә самолет гүләве көчәйгәннән-көчәя, эч-бавырыңны айкап, буыныңны алып, җиргә сеңдерә. Менә самолетның тырым-тырагай йөгерешкән десантчылар турысыннан, имәнеч аждаһа сымак, ажгырып узуы булды, артына карый-карый иптәшләрен ашыктырып-дәртләндереп йөгергән Җакиевнең аяк астыннан гына гөрселдәп ут өермәсе калкып чыкты. Коточкыч шартлаудан миңгерәүләнеп, Кәрим йөзтүбән капланды...

* * *

Исенә килгәндә, ул йомшак итеп түшәлгән коры яфрак өемендә ята иде. Күзен ачса — тирә-як тып-тын, һавада төрле төстәге матур күбәләкләр канат җилпеп оча, югарыда агач ботаклары җай гына чайкала. Ул үзен, парашюты эләгеп, имән ябалдашында асылынып торгандай

хис итте. Тик нигә соң болай якты? Рябчиков аны таң атканчы ук ычкындырган иде ләбаса! Парашют җепләре дә күренми...

Кәрим, кулын сузып, автоматын алмакчы булды, ләкин беләкләре, гер таккан диярсең, кымшанмады да. «Парашют әлмәгенә кысылгандыр, менә хәзер иннәремне иплә бргак язам да...» дип, чак кузгала башлаган иде, аның кыштырдавына кемнендер җир астыннан килгәндәй тоньк тавышы ишетелде:

— Уяндыңмы? — Вакыт, торсаң да ярар...

Әкренләп төнге маҗаралар исенә төшә башлады Кәримнең. Блиндаж янындагы кыска, ярсулы бәрелеш, баш өстеннән гүләп очкан «рама», янгын яктысында чайкалышкан, җан-фәрман йөгерешкән карачкылар...

Башының шаулавы басыла төшеп, колагында урманның тоньк, мөлаем тавышлары яңгырый башлагач, ул абайлап кына терсәгенә таянып торды да каршысында утырган Федорны күрде.

Якын-тирәдә бүтән беркем юк. Толкунов, ваемсыз кыяфәттә бер ноктага караган да, кулында Җакиевнекенә охшаган, кисәү башы төсле кап-кара төрепкәне әйләндерә. Кәримнең күңеле шомланып китте, тик ярсып тибә башлаган йөрәген басарга тырышып:

— Мәхмүт кайда? — дип сорады.

Толкунов дәшмәде, нигәдер, күз ялтырап, читкә карады.

— Федор! — дип кычкырыбрак дәште Кәрим.— Ник әйтмисең? Мәхмүтне сорыйм бит!

Җавап урынына Толкунов башы белән читкә ымлады. Ул күрсәткән якка борылды да Кәрим, берни аңламый, аптырап калды. Мәхмүт юк иде анда. Хәер, шул тирәдә булса, тавыш ишетүгә үзе дә эндәшер, я сунарчы сымак йомшак басып килеп җитәр иде. Ни булган бу сержантка? Шаярта дисәң, кыяфәте болытлы, Кәрим ана якынрак шуып утырды да соравын тагы кабатлап өлгермәде, Федор, башын тотып, җиргә ауды.

— У-ух, бәйләнчек сагызак! — дип хырылдады ул, үксеп.— Җәзала әйдә, из Толкуновның мие черегән ахмак башын! Юк Мәхмүт, юк! Аңлыйсыңмы син, ангыра бәрән? Саклый алмадым, шундый асыл егетне саклый алмадым...

Кәрим йөрәксенеп урыныннан сикереп торды, әле генә Толкунов ымлап күрсәткән якка ике адым атлап, туктап калды. Каршысындагы вак кына чиялек ышыгына чит-чите кәс белән капланган ком катыш кара балчык өеме сыенган иде. Кәрим, үз-үзен белештерми, башы әйләнеп, кабер эргәсенә бөгелеп төште, салкын балчыкка битен куеп, күзен йомды.

— Мәхмүт агай, Мәхмүт агай! — дип дәшә иде ул күңеленнән, йомшак туфракны сыйпап.— Нилэр булды сиңа? Нигә болай вакытсыз китеп бардың? Тор. Ыссык-Күленә юл ерак бит әле. Анда Мәйрәмең зарыгып көтәдер...

Күпме яткандыр Кәрим, Толкунов килеп иңнәренә кагылуга, йокыдан уянган кеше сымак, күзен ачты. Толкуновны танырлык та түгел: бите кара янган, яшь томалаган күзендә әйтеп бетергесез газап, әрнү, нәфрәт. Ул Кәримне, иңбашыннан кочаклап, бер секундка гына күкрәгенә кысты да аягүрә торгызды.

— Әйдә, Кәрим, озакладык, көтәләр,— дип, урман куелыгына карап атлады.

Кәрим канлы ярага әйләнгән күңеленең әрнеп сулкылдавына чара таба алмый, тагы кабер өстенә иелде. Кесәсеннән тотылмаган ак кульяулык чыгарып, аны чия агачына ныгытып бәйләп куйды, финкасын алып, ике-өч адымда торган юан юкәнең кайрысына дәү «М» хәрефе уйды. Шуннан гына башын агачка терәп тыела алмый үксегән сержанты янына барып басты.

— Гафу ит, туган,— диде Федор, өс-башын рәтләп.
Ник гафу үтенүен аңларлык түгел иде: бая кычкырынганын искә алганмыдыр, дусын югалтуны, шулай кеше күзенә күрсәтеп, авыр кичерүен уйлаганмыдыр...
Кәрим төпченеп торыр хәлдә түгел иде. Канаты каерылган кош төсле, башын аска иеп, сержанты артыннан китте.
Алар озакламый иптәшләренә барып кушылдылар.

* * *

Отряд кайтканда лагерь аякка баскан иде. Авыр яралыларны аннан-моннан гына әтмәлләп алган носилкага яткырганнар, үз аяклары белән барырдайларының кулында таяк. Кече лейтенантның әйтүенә караганда, юл күрсәтүче партизаннар озакламый килеп җитәргә тиеш икән, шуңа тоткарлык булмасын дип алдан ук әзерләнеп куйганнар.
Толкунов баш кагып кына ризалык белдерде дә носилкада яткан майор янына барып утырды. Кәрим дә, аларга якынрак урын табып, Танянын бушаганын күтәргә булды, чөнки башы чатнап авырта иде.
— Ничә кешенең башына җиттең? — диде майор, әллә ярасы сыкраудан, әллә ачуыннан тешен кысып.
Федор әрепләшеп тормады, гаепле кеше сымак, аска карап, төнге операциянең нәтиҗәсен сөйләргә кереште. Барлыгы дүрт кешенең үлеп калуын, өч кешенең җиңелчә яралануын, дошманның ким дигәндә егерме солдаты һәлак булуын, моннан тыш бронетранспортер, ике йөк машинасы, өч-дүрт мотоцикл һәм юл саклап торган ныгытманың юк ителүен кыскача гына аңлатып бирде.
— Ике пулемет, унлап автомат, байтак патрон кулга төшердек. Отрядны ике-өч көн асрарлык сохари, каклаган май, консерва табылды,— дип, Толкунов сүзен бетерде.
Майор байтак вакыт уйланып ятты. Шуннан төркем командирларын чакырырга кушты. Киләсе кешеләр килеп беткәч:
— Кадерле лачыннарым! — дип, тантаналы кыяфәттә сүз башлады.— Кызганычка каршы, сезне юл башлап, кабат яуга алып керергә язмады. Командирлык вазифасын сержант Толкуновка тапшырам... Дошманга үлем!..
Көтелмәгән бу купшы сүздән аптырап, иңбашларын җыерган иптәшләренә карагач, Федор елмаеп куйды.
— Әйе,— диде көрсенеп.— Сугыш уен түгел. Син дә үтерәсең, сине дә үлем сагалый.
— Төрттермә, сержант! Мин бит, барчагызга да яхшылык теләп, оборонага күчәргә уйлаган идем. Тыңламадың, күпме кешене әрәм иттең. Инде болары өчен ил алдында җавап бирергә туры киләчәк,— дип, майор, кулын җәеп, тирә-ягына күрсәтте.
— Бирербез! — диде Федор. Ул урыныннан торды, төркем башлыгы итеп билгеләнгән Протасов дигән солдатка отрядка азык өләшергә кушты.
Ул арада Таня яралыларны карап бетереп, Кәрим янына чүгәләде. Радистның контузияләнүен җиткергәннәр, күрәсең:
— Я, ишетәсеңме инде хәзер? — дип, аның учына сәдәфтәй генә ак дару салды.— Яле, эч тизрәк,— дип, фляга тоттырды.
Сестра, нәзек бармакларын җитез хәрәкәтләндереп:
— Федорга ни булды? Нигә шул тикле сөреме коелып кайтты? — диде.
— Жакиевне үтерделәр. Сержантның дусын...
— Жакиев?! Мәхмүтнеме? — дип, Таня сикереп торды. Кулыннан сумкасы төшеп китте — Федор янына йөгерде.

Аларның ни сөйләшкәнен ишетмәде Кәрим. Ишетмәде, ләкин күз белән күреп тә аңларлык иде. Таня, Толкуновның автомат каешыннан тотып, нидер әйтте, тегесе читкә борылды. Таня башын иеп, боегып, кире килде. Кәримнең иңнәренә маңгаен куеп, үксеп еларга тотынды.

Кәрим, Таняга кушылып елап җибәрмәс өчен, юрамалый тупасрак итеп:

— Алай балавыз сыгар булгач, өеңдә генә утырыр идең... Бар, әнә кече лейтенант чакыра үзеңне! — диде.

Кызый, күзен сөртеп, кабалана-кабалана сумкасын җыештыра башлады. Шул вакыт Кәрим Федор янына килгән партизан егет Максимны күрде. Разведкадан кайткан Максимның нинди хәбәр китерүен тәгаен генә белмәсә дә, сизенә Кәрим: яхшылык көтү кыен бу хәлдә. Туздырылган эсэс оясы белән пыран-заран китерелгән постның үчен алмый каламы соң немец! Мөгаен, Максим шул хакта берәр нәрсә белеп килгәндер. Әнә бит Федор, хәсрәте зур булса да, үзен кулга алып, тагы гадәтенчә кырыс, җитди кыяфәткә кергән. Кулы белән һаваны телеп, нидер сөйли, нидер аңлата.

— Нишлибез хәзер, китәбезме берәр якка? Ишетмәдеңме? — диде Кузнецов, Кәрим янына килеп утырып.

Кәрим баш чайкады. Кузнецов кесәсеннән елтырап торган бәләкәй генә пистолет чыгарып Кәримгә бирде.

— Мә, миннән бүләк булсын. Ал, ал, миңа монысы да җитеп торыр,— дип, муенына аскан «шмайсер»ны сыйпап куйды.— Үземнекен ташлап китәргә туры килде. Сабына пуля тиеп, юнышкы сымак, чәрдәкләп ташлады.

Солдат гадәтенчә Кәрим дә бүләккә бүләк кайтарырга тиеш иде. Ул, һич уйлап-икеләнеп тормый, кесәсеннән сөяк саплы, биш-алты япьле пәкесен алып, Кузнецовка бирде.

Кузнецов, пәкенең барлык япьләрен ачып, чәнечке-безләрен барлап, үткерлеген тикшереп чыкты да, балалар сымак куанып, телен шартлатты.

— Менә бу — әйбер, ичмасам! Җәл түгелме?

Кәрим ваемсыз кыяфәттә иңнәрен сикертеп куйды. Кузнецовның, кинәт боегып, чырае караңгыланды.

— Кара әле, Кәрим,— диде, пәкене Кәримнең түш кесәсенә салды.— Син нитмә... Жакиев җәл, әлбәттә. Андый кешене көндез шәм яндырып эзләсәң дә табып булмас. Тик нишләмәк кирәк, сугыш, туган...

«Эх, Кузнецов, Кузнецов,— дип уйлады Кәрим, яңа иптәшенә күңеле эреп.— Белмисең шул син Мәхмүт агайның миңа ничаклы якын, кадерле булуын! Аңламыйсың күңелемдә нинди йолдызның сүнүен...»

Кузнецов иптәшенең хәлен аңлый иде — күрсенеп читкә китте. Күп тә үтми, Толкуновның кузгалырга кушкан боерыгы ишетелде. Солдатлар, һәркайсы үз урынына басып, урман шырлыгына атлады. Кәрим, үчекләнеп, рацияне аркасына асты, батарея тартмасын күтәрергә үзе теләп ризалашкан Кузнецовка ымлап, алга, колонна башына, ашыкты.

— Бәлки, партизаннар базасына китәрсең? — диде Толкунов, төсе качкан Кәримгә. Ләкин Кәрим җавап биреп тормады, иңбашын җыерып, атлавын белде.

Тирән чокыр ярына җиткәч, отряд икегә бүленде. Кече лейтенант кул астындагы ун кешелек төркем, яралы солдатларны алып, көнбатышка табан сузылган чокыр буйлап китәргә тиеш иде. Максимның әйтүенә караганда, партизаннар иң хәвефсез юлны сайлаган, сукмаклары гел шул чокыр эчләп, адәм аягы басмаган сазламык үзәне буйлап тартылачак, ярты чакрым саен партизан дозоры тора. Әгәр ул-бу булмаса, якты күздә үк базага барып җитәчәкләр.

Десантчылар кайсысы кочаклашып, кайсысы кул бирешеп хушлашкан арада, чокырдан Василенко белән кечә Гайны озата киткән яшь

партизан килеп чыкты. Василенко үзе юл башлап алып китәсе төркемне күздән кичерде дә Толкунов янына килде, авыр көрсенеп:

— Их, яна Горпищево,— диде.— Авылга биш-алты машинага төяләп немецлар килеп тулды. Урманны тарап чыгарга җыеналар. Миномет коралар. Димәк, башта концерт була, сизәсеңдер, сержант. Әллә, мин әйтәм, бергә базага китәбезме?.. Юк, дисең инде. Я, ачуланма, юлны аркылы чыгарга өлгерерсеңме дип шикләнүем.

— Өлгерергә кирәк! — диде Федор, йодрыгы белән һаваны ярып.— Анда Чукреев көтә.

— Ярый, хәерле сәгатьтә!

— Платон бабай кайда? — диде Кәрим.

Староста аска карап дәшми торды да, тавышы карлыгып:

— Максимны үзең белән ал, сержант. Бу тирәдә күзен йомган килеш тә адашмый ул,— дип хушлаша башлады.

Урманның төрле төшендә миналар шартлый башлаган иде инде. Василенко аксый-туксый кече лейтенант янына ашыкты. Тегесе, кул болгап, кузгалырга кушты.

Шунда гына Федор, радистлар арасында торган Таняны күреп, аның янына тиз-тиз атлап килде дә:

— Ни эшләп торасың, йөгер тизрәк! — дип кычкырды.

— Кая йөгерим? — диде кызый, шактый җыйнаклап калган сумкасын рәтләп.— Минем урыным шунда. Яралыларга бүтәнчә ярдәм күрсәтә алмыйм. Ә анда врач...

— Соң бит... беләсеңме, безне ни көткәнен?

— Сезгә... сиңа ни — миңа да шул. Бәлки, кирәгем тияр,— дип, Таня бирешергә теләмәде. Сүз көрәштерүдән мәгънә чыкмасын аңлатып, читкә борылды.

Кәрим, сержантның сөмсере коелган йөзенә күз сирпеп:

— Молодец! — дип, Таняның иңенә кагылып куйды.

— Ну, ярый, үзегез карагыз, сезне иркәләп торырга форсат тимәс! — диде Федор һәм, түземсезләнеп, тирә-ягына караган Максимга таба атлады. Икәүләп карта өстенә иелделәр.

Һавада, десантчыларны эзләп, немец самолеты әйләнә, бер якын ук төшеп, бер ерагаеп, миналар гөрселди, авыл ягында дистәләгән мотор гөрелдәве ишетелә. Толкунов егерме биш кешелек отрядын, тозакка әйләнгән урман полосасыннан тизрәк алып чыгарга ниятләп, олы юлга табан ашыктыра. Менә бит, кая монда бер-берсеңнең хәтерен саклап тору! Тизрәк юлга, аннан Черкас урманына! Ләкин ничек ул юлга сиздермичә якын барырга? Үч иткәндәй, бу яктагы урман полосасы, юлдан йөз-йөз илле метрлар чамасы урында өзелеп, сөзәк яр читенә чыга. Шуңа күрә отряд урман полосасының юлга якынрак булган җирен эзләп, кадерле минутларын әрәм итә.

Юллары кинәт тирән ерганак читенә барып төртелде. Федор, иркен сулап, иптәшләрен чокыр эченнән аска әйдәде, нәкъ шул мәлне артта абалап эт өргән, кычкырышкан тавышлар ишетелде, пулемет тырылдый башлады.

— Тизрәк! — диде Федор. Туктап, десантчыларны янынннан үткәрә торды.— Пулеметны минем янга!

Алдагылар, юлны аркылы чыгып, ком-ташлы текә ярга үрмәләп менә башладылар. Максим әллә ни арада агач ботагына озын җеп бәйләгән дә солдатларны өскә тартып менгерә. Менә Кузнецов белән Таня биек ярның аръягына чумдылар. Тагын берничәсе күтәрелде. Аста күп булса биш-алты кеше калып бара.

— Максим! Бая сөйләшкән җиргә алып бар отрядны! — дип кычкырды Федор, яр читенә ятып.— Без туктатабыз боларны. Йөгерегез!

Артта гүләгән атыш тавышына колак сала-сала, отряд, урман куенына чумып, күздән югалды...

* * *

... Рация өстенә иелгән Кәрим: «Мин — «Кама», мин — «Кама»!..» дип, нинди дә булса берәр радиостанция белән элемтәгә керергә тырыша. Әшкә тотынганына бер сәгать бардыр инде, ник кенә бер радист җавап бирсен! Хәтта элекке көндә комбригны алырга самолет җибәргән «Сокол» да дәшми. Хәер, ул, бөтәннәр белән элемтә бәйләп, әледән-әле тавыш бирә, тик нигәдер Кәрим белән генә сөйләшергә теләми.

— Буламы-юкмы? — дип, Кузнецов әледән-әле сорап җанны үртә. Ана ни — алма пеш, авызыма төш! Аппарат янына утыртыр иден — кулыннан килми, батарея тартмасын ватмый йөртсә дә, риза инде.

Эх, Федор монда булса! Юк шул. Олы юлда немецлар белән атышып калганнан бирле тавыш-тыны юк. Эзләргә җибәрелгән солдатларның икесе кайтмады, икесе буш кул белән әйләнеп килде. Шундый борчулы чакта элемтә булса да җинелрәк булыр иде.

— Син кайгырмый тор әле, Кәрим, нит... кабаланмый гына тагы бер карап чык рацияне. Бәлки, бозылган-ниткән җире бардыр,— дип киңәш итте Кузнецов.

— Мең кат карадым инде,— дип, Кәрим, мыгырдана-мыгырдана, плащ-палаткага бөркәнеп, кесә фонарен кабызды.

Рация эшләмәсә, башта батареяны тикшер, дип өйрәтә торган иде Федор. Батарея имин, димәк, аппаратны карарга кирәк. Лампалар яна, якын-тирәдәге радиостанцияләр генә түгел, хәтта Мәскәү тавышы күршедәге кебек аермачык ишетелә. Димәк... тукта, тукта, ә нигә соң «Прием» дип язылган ноктадан «Передача» дигәненә күчергәндә, чырт иткән тавыш юк. Әй, ачык авыз! Сәгать буе юкка кычкырып утыргансың лабаса! Үзең ишетәсең, ә синең тавышыңны һичкем ишетми, чөнки тапшыргычың эшләмәгән.

Кәрим, тирләп-пешеп, күчергеч тотканы сүтеп алды да сызгырып җибәрде. Тотка оясына бармак башы зурлык таш кысылган иде.

Радист:

— Эш көйләнә болай булгач! — дип, шинеленә уранып яткан Кузнецовны кабат төрткәләп уятты. Әшен бетереп: «Сокол», «Сокол», мин — «Кама», җавап бир!» — дип чакыруы булды, тегесе шундук телгә килде:

— «Кама», мин — «Сокол», тыңлыйм сине».

Куанычының чиге юк иде Кәримнең. Үлем, кан белән узган шул ике тәүлек вакыт эчендә бу аның беренче тапкыр рәхәтлек тойгысы кичерүе булгандыр. Үзе дә сизмәстән кычкырыбрак эндәште бугай — Кузнецов аның җиңеннән тартты:

— Нигә кычкырасың шул хәтле? Кайда икәнеңне онытма! — диде.

Чукреев калдырып киткән радиограмманы тапшыргач, «Сокол» белән ике сәгать саен элемтәгә керергә сүз куешып, Кәрим әз генә черем итеп алырга булды.

Күзләрен йокы алмаган десантчылар элемтә янаруын ишеткәннәр иде инде. Берәм-берәм рация янына җыелып, бу шатлыклы хәбәр турында иркенләбрәк әңгәмә корырга уйладылар. Тик Кузнецов аларны якын да җибәрмәде, Чукреев отряды белән очрашканнан бирле керфек какмаган радистны борчымаска кушты. Йокыга китеп барган Кәримнең колагына өзек-төтек сүзләр генә ишетелә иде инде:

— Булдыклы малай...

— Эт аруын сиздермәс, бүрегә сыртын кабартыр, диме...

— Әй, лыгырдык! Беләсең килсә, безнең язмыш радист кулында хәзер...

— Әйтерең бармы! Көнең шул юеш танауга калгач...

... Күк зәңгәр. Болытлар ак. Федор белән Таня, аларга ияреп Кәрим җылы якка очып баралар. Торнага әйләнгәннәр. Канат кага-кага сөйләшәләр. Һавада Җакиев тавышы булып моңлы җыр ишетелә.

«Әй, иркле кошкайлар,— ди Мәхмүт.— Юлыгыз Ыссык-Күл турысыннан үтәдер. Минем җан сөйгәнемә сәлам әйтегез! Туктап ял итәр булсагыз, ул казан асар, бүлтерек[1] суеп кунак итәр. Бәрәннең башы — Федорга!.. Мәйрәмгә җыр җырлагыз. Моңлы кыз ул Мәйрәм, җыр ярата. Һәйбәт җырласагыз, кымыз белән сыйлар. Алдырның[2] беренчесе — Кәримгә!..

Басынкы холыкны Җакиев моңлы тавыш белән сөйли, Кәрим сулыгып-сулыгып елый...

Болытлар куера, кара-кучкыллана, Җакиев такмаклап сөйли башлый.

«Әй, очар кошлар, ди. Юлыгыз авыр, ял итегез, йоклагыз! Аннан тагы юлга! Мин туйга көтәм сине, дуслар... Бакировны беләсезме? Күрерсез, килеп җитәр. Кит дияргә дәлилегез юк...»

... Кәрим күзен ачып җибәрде. Караса — Җакиев тә, торналар да юк, иптәшләре кайсы кая авып йокыга киткән. Батарея тартмасын кочаклап, Кузнецов бөгәрләнеп ята. Аның эргәсендә, аркасы белән агачка сөялгән килеш, Протасов оеп утыра. Таня, дару сумкасын мендәр итеп, Кәримнең аяк очына җайлашкан. Арырак әкрен генә сөйләшеп сакчылар йөри...

Кәримнең соравына сакчыларның берсе Толкуновның да, Чукреевның да һаман кайтмавын хәбәр итте.

«Сокол» билгеләгән вакыт җиткән иде. Кәрим, рациясен көйләп, аның белән бәйләнешкә керде, яңалык юклыгын белдерде дә кабат ятты. Тик йокысы качкан иде инде. Баягы төше, йөрәген иңрәтеп, күз алдыннан китми, колагында Җакиевнең сагышлы тавышы, тузгышып очкан торналар чыңы яңгырый. Төше өнгә, өне төшкә бәйләнә, фикере чуала. Юк, болай гел уйланып ятарга ярамый, торырга кирәк.

Иптәшләрен уятмаска тырышып, тын гына кузгала башлаган иде, Таня, пышылдап:

— Нигә йокламыйсың? — диде. Җавап биргәнне дә көтми, Кәрим янына килеп утырды.

Кәрим сизә: кызый төн буе керфек какмый чыккан. Йокы кайгысымыни кешедә, әнә бит Федор һаман юк. Бәла-казага тарымаса, Толкунов отрядны әллә кайчан эзләп табар иде...

Җакиевнең туфрагы суынып өлгермәс борын, инде Толкуновның да югалуы коточкыч гаделсезлек булып тоела иде аңа. Федор алай тиз бирешмәс, бер әмәлен табып, немецлар кыршавын ерып чыгар, дип өметләнә иде. Ә менә хәзер, әллә шомлы төш тәэсиренә бирелеп, әллә югалтуларга күнегә башлаган күңеленең ниндидер шикчел искәртүенә колак салып, вакыт узган саен өмете кимегәнен тойды. Шуңа Таня көткән сүзләр теленә килми, ә рыяланудан, буш гәп сатудан мәгънә юк, дип дәшми иде.

Урман яңгыратып кычкырган байгыш уфылдавына сискәнеп, сестра Кәримгә сыеныбрак утырды да:

— Сүз дәшмәскә ант иттеңме әллә? — диде.

Җавап урынына Кәрим аның кулын сыйпап куйды. Их, ичмасам, бер генә юату сүзе тапсаң ни була!

— Юк, юк, булмас, ышанмыйм! Менә күр дә тор, кайтыр! — дип ярсып пышылдады Таня.

---

[1] Бүлтерек — сарык бәрәне.
[2] Алдыр — тустаган.

Аның ашкынулы өметеннән Кәримнең дә эченә җылы йөгергәндәй итте. «Чынлап та, шул тикле зарыгып көткән кешесе булгач, ничек югалсын ул! Бәлки, безне тапмый йөридер яки иптәшләренең берәрсе яралангандыр да шуның белән җәфа чигәдер»,— дип уйлады.

Әйе, әйе, сугышта моның ише генә очраклы хәлләр була инде ул. Тәгаен үлгән, кара пичәтле хаты килгән ничәмә кешенең соңыннан саусәламәт кайтып төшүен ишеткәне бар иде Кәримнең. «Өметсез — шайтан, ди торган иде дәү әнисе,— кече улы Харрасын уйлап.— Көтик, төшкә гелән ак күлмәк киеп, елмаеп керә. Исәндер ул...» Кәрим үзе дә, иптәшләренә юлыкканчы, башта агачка эләгеп, азактан Рябчиков белән икәүләп немецлар кыршавыннан ычкына алмый иза чикмәдемени? Ә Федорның хәле бигрәк тә хәтәр, чөнки ул өч-дүрт кенә солдат белән ничәмә дистә дошманның юлын кисеп калды. Шундый хәвефле эшкә йөрәге җиткән кеше котылу әмәлен дә тапмый булмас. Көтәргә, сабыр итәргә кирәк...

Шул уйларын сөйли торгач, аларның дөреслегенә Кәрим үзе дә тәмам ышанды. Мөгаен, шулайдыр, берәр очраклы хәлгә тарып кына кайтып җитә алмыйдыр. Тәвәккәлләр Федор, җаен табар... Таня исә, җинел сулу алып, балалар төсле куанып китте. Кичәдән бирле авыз ачып бер сүз әйтмәгән, йөзенә елмаю чыкмаган кыз, кинәт сүзчәнләнеп, хыялларын сүтә башлады:

— Сугыш беткәч, Федор белән безнең якларга китәргә вәгъдәләштек. Беләсеңдер инде, ул бит Воронеж өлкәсеннән. Күрдем мин аның туган якларын, искиткеч матур урыннар... Тик дингез буена җитәме соң инде! Федор да шулай ди... Ә безнең Новороссийск каласында җаны теләгән эшне сайлап ала ул. Күңеле тартса, матрос була, күңеле тартмаса, заводта эшли, яки кораб ясый.

Кәримнең йөрәгенә ниндидер моң кагылып үткәндәй булды. Ул торна иңрәвен дә хәтерләтә, дингез шавын да...

— Ә ниндирәк ул диңгез? — диде Кәрим.

— Зур. Күзең дә, уең да җитмәслек зур,— диде Таня.

— Ә төсе нинди, зәңгәрме?

— Әйе, зәңгәр дә. Ләкин диңгезнең төсе мең төрле. Бер карасаң, күксел рәшә булып уйный, шуннан күп тә үтми, көрәнсу, яшькелт-зәңгәр, я алсу төскә керә. Вакыты белән хәтта, эрегән кургаш кебек, каракучкылланып ята...

Уй йомгагын сүтә-сүтә, әле тын гына елмаеп, әле әкрен генә көрсенеп, караңгы күккә текәлеп яткан Таня кабат торып утырды.

— Кара әле, Кәрим...— дип сүз башлады ул һәм шундук туктап, әйтәсе фикерен барлап алды.— Син ачуланма, яме... Күптән сорашыйм дим, һич җае чыкмый... Нишләп болай солдатка китәсе иттең? Сер түгелме?

— Сер дип... Сере шул инде аның — шулай килеп чыкты.

— Ә теге вакыт Федорлар алмаса? Барыбер кайтмас идеңме?

— Кайтмас идем,— диде Кәрим, тиешсез әңгәмәне туктата алмавына үкенеп.

Ә нигә шулай килеп чыкты, ә бүтән төрле түгел? Кәримнең дәү әтисе моны язмыш дияр иде: «Маңгаена ни язылса, шуны күрми хәлең юк. Тәкъдир йөртә бәндәне...»

Тәкъдир микән?

Таняның соравына Кәрим: «Шулай килеп чыкты»,— дип җавап бирде, ләкин күңелдә җавапның икенче яртысы да әзер:

«Шулай булырга тиеш!»

Әйе, аның фронтка китүе очраклы хәл түгел, бу хәвефле һәм җитди адымның үз сәбәбе бар...

## Юлга чыгар алдыннан

...Дөм караңгы көзге төн. Сибәләп яуган яңгыр астында салам түбәләре җебеп утырган ваемсыз кыяфәтле авылда җан иясе күренми. Хәер, түбәнге очтарак бер өйнең ябык тәрәзә капкачы аша зәгыйфь кенә нур саркыла. Әллә кура эчендә, әллә чолан астында эт улаганы ишетелеп кала. Шуннан тагы тирә-якны тынлык баса.

Өй эчендә дә матәм тоткан йортларга хас моңсу тынлык. Мае шакты кимегән шәм караңгылык белән тартыша, мич астыннан әчпошыргыч чикерткә көе сузыла.

— Ә-ә-ә... Әлли-бәлли-бәү...

Япь-яшь ана, сәкегә утырып, аягына салган мендәргә оланын яткырган да, тын гына такмаклап, аны тирбәтә. Менә ул яше тулмас борын ятим калган нәниенең өстенә иелде. Сабый, төшендә иренең чупылдатып, маңгаена тамган кайнар яшь тамчысын да тоймый елмая.

Таң якын. Бер-берсен уздырып кычкырган әтәчләр тавышына ана сискәнеп куйды, кемнәндер баласын саклагандай, ирексез хәрәкәт ясады да, калгып, тагы күзен йомды. Өч-дүрт көн рәттән авырып, керфек какмый елаган сабый бүген тынычланды. Әле әнә чирдән котылуын тоядырмы, кинәнеп елмая, бәләкәй йодрыкларын мендәргә ташлап, изрәп йоклый. Шылт иткән тавышка сискәнеп күзен ачкан әнисе әрнүле куанычыннан тыела алмый елый...

Әй, ана! Канатың каерылып егылгач, йөрәгеңә шифалы тамчы булып, соңгы газапларыңны бәләкәчеңнең шул елмаюы җиңеләйткәндер. Мәрхүм ирең Сәлим сымак, син дә бит анын киләчәге, бәхете дип җан аттың, көрәштә яндың. Чыдам булдың. Берегез арысландай батыр коммунист, икенчегез авылның ялкынлы комсомолы идегез. Пар торна булып очтыгыз. Берегез егылгач, аның юлын икенчегез — әни кеше, син дәвам иттең...

Улыңны да атасы кебек кыю көрәшче итеп үстерергә ант иткән идең син. Тынгысыз, шаулы заман иде. Толлык кайгысын озак иркәләргә вакытың булмады, моңа горур табигатең дә юл куймады. Төн йокыңны аямый эштә кайнадың, укыдың. Ирең васыять иткән бөек хыял сиңа канат бирде. Улың үсә төшкәч, яшьтән үк тынгы бирмәгән врач булу теләгеңә ирешер юл ачылды. Сигезе тулар-тулмас улыңны дәү этисе белән дәү әнисенә тапшырып, калага киттең.

Иртәгә юлга чыгам дигән көнне улыңны атасының кабере янына алып бардың.

Сәлим авыл зиратыннан читтәрәк күмелгән иде. Куәтле ботакларын тырпайткан йөз яшәр ялгыз имән, кабер рәшәткәсе өстенә иелеп, ялсызкизүсез сакта тора. Тирә-якта япь-яшь, буйчан үсентеләр, билгә җиткән куе үлән.

Син, үрелеп, рәшәткә эчендәге таш багананың очына беркетелгән йолдызны сыйпадың: вакыт табып, рәшәткәнең дә, йолдызның да буявын яңартканда ару булыр иде дә бит, өлгермәдем шул, дип көрсендең. Шунда улың син сагаеп көткән сорауны бирде. Күз яшьләрең кипкән иде инде, сигез ел гомер аз түгел, шулай да, улың атасын сорагач, елемый түзә алмадың.

— Аны кулаклар үтерде,— дидең син, балаңны күкрәгеңә кысып. Елаганыңны күргәне юк иде аның, аптырап күзеңә карады. Күңелең бераз бушангач, сүзеңне дәвам иттердең: — Яңгырлы, суык көзге төн иде. Эт улаганга йөгереп чыксам, капка төбендә җигүле ат торганын шәйләп алдым. Йөрәксенеп атлыйм, абынам, сөрлегәм... Әтиең суынып беткән иде инде. Йөрәген ядрә телгән... Ә син ул чакта җиде айлык сабый идең. Үсә төш әле, колынчыгым, аңларсың...

Әйе, аңлар Кәрим. Аңлар да бердәнбер юлны сайлар. Ул моны бәлки артык мәгънәләп тормый: «Шулай килеп чыкты. Шулай булырга тиеш!» — дип кенә бәяләр. Ләкин ул көннәр алда шул әле, үсә төшүләре кыен. Гатау бабасы: «Имән әкрен үсә, улым, ни өчен дисәң, чөнки ул каты агач, бирешмә»,— ди дә бит, әгәр син нибары тугыз-ун яшьтә булсаң, әти дип өзелеп эндәшер кешең булмаса, бирешми нихәл итәсең. Малайлар аңлыймыни аның хәлен?

Мазһар ялан аякка киеп алган өр-яңа күн итегенә кунган тузанны учы белән сөртә-сөртә:

— Әтием каладан алып кайтты,— ди.

— Иртәгә әти белән базарга барабыз. Мүкләк тананы сатабыз,— дип җибәрә Сәки. Моны ул мәңге тиктормас кулында берәр агачнымы, әшкә яраклы тимер кисәгенме әйләндерә-әйләндерә, олыларча җитди кыяфәттә әйтә. Кыланышын күр, әйтерсең Сәки атасына тагылып йөрми, әйтерсең атасы аңа ияреп бара. Сәки булмаса, базарның бер почмагы китек булачак.

— Әти туп алып кайтты,— ди өченчесе.

— Әти урманга киткән иде, кайтыр инде...

— Әти... Әти... Әти...

Һәр вакыт шулай. Атасыз бала сирәк очрый иде шул Кәрим үскән заманда. Әгәр син малай икәнсең — синең, һичшиксез, әтиең була. Барысының атасы бар. Берсенеке — яшь, икенчесенеке — олы. Барыйның атасы Гатау бабай япон сугышында сугышкан, Мазһар атасы Хәбибулла абзый тирә-якта дан тоткан көрәшче. Аз сүзле ул, аны «юаш Хәбибулла» дип йөртәләр, ә ябык гәүдәле, чирләшкә адашыннан аерыр өчен «аю Хәбибулла» дип тә җибәргәлиләр.

«Аю» диярлеге дә бар. Бер көн Хәбибулла абзый, янгырда лычма булып кайткач, бичәсенә мунча ягарга кушкан, ди. Үзендә юкны күршекүләннән сорыйсың бит инде. Иләк кирәкме, чиләкме, кунакка барырга толыпмы... Агач-таш чамалы, бөтен авылга өч мунча. Менә шул, Мазһарның әнисе, урам аша чыгып, Сәлмән картларга барса, карчыгының биле сызлап, кәефсезләнеп йөргән чагы, имеш. «Кунак көтәбез, мунчабызны чын ясау итеп юып куйган идем, бүтән кешедән сорап кара»,— дип чыгармасынмы моны!

Хәбибулла — юашын юаш та бит, женен котыртып җибәрсәнме?! Аяк асты тынганны гына көтеп тора да бу китә Сәлмәннәр мунчасына. Бастырыкны нигез астына тыгып бер каеруы була, мунча авып та китә. Соңыннан Сәлмән карт, Хәбибулланы чакырып алып, бик әйбәтләп сыйлап, мунчасын яңадан бураткан, дип сөйләделәр...

Ләкин авылның иң күзгә күренгән кешесе — Барыйның атасы Гатау бабай иде.

Була бит шундый кешеләр — син аны һич кенә дә бер сүз белән әйтә алмыйсың. Гүя ул, дөньяның яхшы-яманын туплаган да бу сыйфатларның, ичмасам, бер-икесен генә дә азагынача үзенеке ясый алмаган. Тагы шунысы гаҗәп: аның беренче караулда күңелгә ятмастай тоелган кыланышы көтмәгәндә уңай нәтиҗә бирә дә куя.

Дәү әнисенең: «Нигә син, Гатау карт төсле, бер эшеңне бетерми, икенчесенә тотындың әле?» — дигәнен еш ишетә иде Кәрим. Чынлап та, Барыйлар ихатасына барып керсәң, яртылаш буралган кое бурасымы, урачәсе юк чапа я сыңар тәгәрмәчле кул арбасымы — кая карама, җиренә җиткерелмәгән, очлап куелмаган әллә нихәтле эш күзгә ташлана торган иде. Өенең урам як тәрәзәләренә ямь-яшел белән сары катыш буяуга буятылган купшы капкачлар эленсә, ихата эченә караган тәрәзәләрнең капкачы түгел, хәтта пыяласы да бөтен булмас, буш өлгеләре кара күзгә хәтле иске бишмәт я мендәр тыгылган көе өңрәешеп торыр иде.

Гомерен җиңел-җилпе эштә: я каравыл торып, я бау ишеп, я камыт-ыңгырчак төзәтеп үткәрсә дә, сугыш башлангач, Гатау бабайга да төпкә җигелергә, сабанын сөрергә, авыр капчыкларны җилкәсендә йөртергә туры килде. Шуңа ул, тәртәдән чыкканчы йөк тарткан карт алаша сымак, йөргәндә башын иеп, бөкрәебрәк атлый. Япон сугышында имгәнгән аягы да ныграк сөйрәлә иде кебек...

Ә сугышка кадәр, Кәримнәр бала чакта, ул җор сүзле, әйбәт холыклы кеше иде. Кунак-төшем, туй мәҗлесеме, колхоз җыелышы, я актив киңәшеме — Гатау бабай катнашмаса, кашсыз йөзек, сусыз кашык булыр иде.

Япон сугышында үпкәсе шешеп, аягы җәрәхәтләнеп кайтканнан бирле: «Барыбер бер көн банзай булабыз инде, нигә ул чаклы җан атарга әле»,— дип яши торгач, ул елларда ук илләне үткән иде инде байгыш.

Гатау бабайның эш сөймәве дә үзенчә иде. Юк, аны ялкау дип булмый, тик ул башлаган эшендә чак кына тоткарлык килеп тудымы — ташлый да бүтәненә тотына. Мунча бурыйм дип урамга читән буена китереп өйгән бүрәнәсе, ким дигәндә, ун ел яткан булырга тиеш. Шул бүрәнә өстенә яшь-җилкенчәк җыелып утырыр да сәхәргәчә Гатау бабайның әңгәмәсен тыңлар иде.

Япон сугышына утыз елдан артык гомер үтеп киткән, аннары герман явы, революция давылы дөньяны айкап узган. Ә Гатау бабайның сүзе, ни хакта гына әңгәмә, киңәш-төңәш чыкмасын, шул япон сугышына барып ялганыр, шуның белән очланыр.

Кәримнең хәтерендә: көннәрдән бер көнне Гатау карт, һичнигә исе китмәгәндәй: «Бу япон дигәннәре харап бер шыксыз ерткыч икән. Олы башлы, кабан тешле, өрлектәй таза халык. Бичәләре — албастыдан ямьсез»,— дип сөйли башлагач, Хәсән күлендә сугышып кайткан Әхмәтсафа: «Анысын шыттырасың, бабай. Японның хатын-кызы — беренче сорт. Безнеңчә әйткәндә, во! — дип, баш бармагын иренәнә тидереп алды.— Ә ирләре безгә охшанкырый, тик буй-сын мәсьәләсе хөрт. Бәләкәйләр...» Гатау бабай аптырап калмады. Булса да булыр шул. Ни өчен дисәң, чөнки кырык елга якын вакыт үтеп бара. Халык үзгәрми буламы дип, аның сүзен җөпләп куйды.

Һай, бу бүрәнә өстендә ишеткән сүзләр! Кайсы чакта Кәримгә Гатау бабайның нәк әнә шул яртылаш чын, яртылаш уйдырма хикәяләреннән дөнья тарихы башланган сымак тоела. Әгәр шулар булмаса, балалык елларына ниндидер яктылык, җылылык җитмәс, ул еллар нурсыз калыр иде.

Менә Гатау бабай, тыңлаучыларның ышаныр-ышанмас кинаяле елмаюын да, «монысын шыттырдың, карт!» дип йөз ертып әйтүен дә игътибарга алмый, үз сүзеннән үзе ләззәт табып, кинәнеп сөйли. Балачагага бүрәнә өстендә урын калмый. Кәримнәр, бер-берсенә сыенышып, читән буена тезелешеп утыра да тылсымлы маҗаралар дөньясына чума. Тарих әкияткә, ялган чынга бәйләнә, дөньяның хикмәте, фәһеме ачылгандай була.

Мактанчыграк булыр иде бахыр Гатау бабай. Кешедән ким-хур түгеллеген раслар өчен юкны да бар дип ычкындырыр. Бер көн кисәү башы кебек караеп, яртылаш янып беткән төрепкәсен бүрәнә башына тукылдатып какты да:

— Ярый, оланнар, иртәгә бәйрәм түгел, кайтышыйк,— дип урыныннан торды. Тын гына кереп китсә, ни әйтәсең дә бит, юк: «Каладан алып кайткан яңа юрганны ябынып кына черем итеп алыйк, самурайның йөрәге янсын»,— дип өстәде бу.

Мазһар белән Кәрим кайтыр якка уңайлаганнар иде инде, егетләрнең шаркылдап көлешкәнен ишетеп, туктап калдылар.

Сүзгә мавыгып, игътибарга алмаганнар, төн шактый салкынча икән. Елгадан сөт сымак ак томан авылга таба саркыла, бер кат кына күлмәк аша, чиркандырып, таң җиле үтә. Кәримнең дә тизрәк кайтып, җылы урынга чумасы килә.

Малайлар, Гатау бабайның исни-исни каралты артыннан чыкканын, өйгә кереп киткәнен көтеп, читән буена постылар. Күп тә үтми, олы егетләр урам як тәрәзәгә барып капланганч, Кәримнәр дә шунда ашыктылар. Тәрәзәдә пәрдә-мазар юк, ай яктысында өй эче көндезге төсле күренеп тора. Ә егетләр, тавышларын басарга тырышып, эчләрен уа-уа көлешә.

— Уф-ф, үләм! — дип, җирдә ауный берсе.— Суйды карт, үтерде!

— Кара-кара, Гатау бабайның яңа юрганы морҗалы икән ләбаса! Уй-й, мең яшәгере!..

— Вәт сиңа яңа юрган!

Кәрим, җаен табып, тәрәзәдән караса, чынлап та, түр сәкегә сузылып яткан Гатау бабайның күкрәге турысында гына морҗага охшаш нәрсә сереп тора. Баксаң, ул иске тунын ябынып яткан да, шунын каешланып каткан җиңе сураеп калган, имеш...

«Морҗалы юрган» атна-ун көн авыл халкының теленнән төшмәде. Ләкин картның кырык ямаулы туны кебек, бизәкләнеп беткән исеменә монысы ябышмады. Күрәсең, фәкыйрьлектән көлү гөнаһ саналгандыр. Ә малайлар өчен ул картайганчы «Банзай бабай» булып калды.

Банзай бабайдан халык күпме генә шаяртып көлмәсен, Кәрим өчен барыбер якын, барыбер үз кеше, аның күңел серләрен аңлаган изге җан иясе иде. Аның бу ышанычы бер вакыйгадан соң бигрәк тә ныгыды.

Кәримнең дәү этисе көнозын тик тормас, кулыннан чүкеч-балтасы төшмәс тынгысыз карт булды. Бер көн, кура астында тукылдап, нидер юнәткәнен ишетеп барса, Әхмәтгәрәй карт, өч-дүрт банка буяуны иске чиләккә бушатып, изеп утыра.

— Көннәр һәйбәт тора, рәшәткәне буятам әле. Һә дигәнче кибеп чыга ул,— ди.

Ике кешегә күпкә барамыни — төш житкәнче урам як койманы ялт иттереп буяп та бетерде болар. Чиләк төбендә ике-өч илле буяу калды. Шул мәл авыл советы секретаре Самат әссәләмәгаләйкүмләп килеп керде. Шым басып атлавына, читкә борылып гаепләрәк төсле елмаюына караганда — налог сораргадыр, мөгаен. Болар өйдә сөйләшкән арада Кәрим чиләкне алды да ындыр артлап зиратка йөгерде.

Кабернең тимер рәшәткәсе тутыгып, караеп беткән иде. Кәрим шул тикле мавыгып эшкә тотынды, янына Банзай картның килеп басуын да тоймый калды.

— Менә монысы егетләрчә,— диде карт, аны сискәндереп. Төрепкәсен тутырды карт,ияк очында гына тырпаеп үскән сирәк сакалын сыйпап, уйга калды. Байтак шулай сүзсез басып торганнан соң: — И гомерләр... Арысландай ир иде... Сәлимҗанны әйтәм,— дип куйды.

Сәлимҗан дип Кәримнең атасын әйтүе, югыйсә, халык аны Сәлим дип, коммун Сәлим дип кенә искә ала.

— Таки сүзен сүз итте Сәлимҗан. Ни өчен дисәң, чөнки җанын фида кылса кылды, мәгәр авылны тазартты кулактан. Әртилен дә көйләп җибәрде...

Ул кадәресен Кәрим белә иде. Шуңа күрә бабайның сүзенә колак салмыйча, эшен дәвам итте. Картлар бер сөйләргә тотындымы — сөйли инде ул.

Гатау карт ул көнне коммун Сәлим турында улы Кәрим ишетмәгән нәрсәләрне сөйләде.— Кәрим, эшен онытып, пумаласын үзе дә сизмәстән бер тирәдә ышкый-ышкый, дөньясын онытып тыңлады аны. Әкрен-

ләп көн кызуланды, баш өстендә жиз кыңгырау булып зыңлаган тургай тавышы ишетелмәс булды.

— ... Кыдырач бай белән Әптерәхим мулладан гомер куркып яшәде халык. Курыкмаслыкмыни? Мал дип мал, акча дип акча шуларда. Син, ачтан аягың сузып, бөнзай бул — уенда да юк ул самурай токымының... Әнә урам уртасында утырган таш лафка Кыдырачныкы иде. Мәктәбегез — шул ике карунның өй-каралтысын атаң мәрхүм күчертеп салды. Моңысы соңыннан. Ә әртил чыкканчы халыкны кан елатты мәлгуньнәр, ни өчен дисәң, чөнки заман үзгәреп житмәгән иде...

Әртил хәбәре килеп житкәч, Сәлимҗан җыен җыйдырды. Әнә Ычтапан урысның Әләксәе, Хәбеш энесе Зиннур — өчесе алмаш-тилмәш сөйли, әй аңлата болар, әй тукый. «Менә шулай, агай-эне, моннан болай ызан яру, межа бүлү бетте, җирне, мал-туарны кушабыз да, бергә көн итә башлыйбыз»,— ди болар. Халык авышырга гына тора, ни өчен дисәң, чөнки без — ярлылар үз файдабызны шунда ук фәһем иттек. Кыдырачларга бу хәл ошамый. Кызарып-бүртенеп кычкыралар — бал эчеп килгәннәр: «Син соң, босяк, нәрсәңне кушасың? Миннән ун баш ат, дүрт баш сыер, ургыч, өч сабан, э синнән нәрсә? Җан бирергә торган йөз яшьлек бияме? Акылың алтын икән!» — ди берсе. Икенчесе: «Гомергә ат-тун күрмәгән өерле йолкышның бүресен улатам дисең инде! Бичәләрне дә әртил ясыйсыңмы?» — дип хахылдый...

Ну, иң авыры җир мәсьәләсе иде.

«Чамала, Сәлим, өч аршин җир сиңа да табылыр!» — дип янаучылар да булды. Чак бугазга бугаз килешмәделәр. Тегеләр дә бирешми. Әләксәй, кесәсеннән алтатарын чыгарып: «Посмотрим!» — ди... Кыскасы, ай дигәндә әртил булып эшкә тотындык. Әмәлгә калгандай, ул елны актарылып иген уңды, көн коры чакта эскертләп бетердек. Ни өчен дисәң, чөнки көч кемдә? Бердәм халыкта. Эленке-салынкырак йөргән, бәхетен читтә эзләгән кайсы бер агай-эне дә безнең якка аумасынмы! Җыелышып, игеннең бер өлешен сатарга, машина алырга киңәш итештек. Хөкүмәт трактор бирде. Китте эшләр хутка! Ну, теге мөртәтләр барыбер тынгы бирми бит. Тиктолмалдан бер эскерт бодай көлтәсе төн чыкканчы янып бетте, биш-алты баш атыбыз үлде. Сизәбез — шулар кулы. Волостьтан килеп, тикшереп йөрделәр, очын таба алмадылар. Тотылмаган карак — карак түгел.

Сәлимҗан җае чыккан саен кисәтә килде. Бирешмәбез дошманга, бер көн килеп тамырларын корытырбыз, дияр иде мәрхүм. Үзе, ябыгып, яңаклары суырылып, карасы коелып йөрде ул көннәрне. Янды, көйде, төн йокысын йокламый ил байлыгын саклады. Иллә мәгәр үзен саклый алмады...

Гатау карт, урыныннан торып, Кәримнең кулыннан пумаласын алды да рәшәткәнең калган өлешен үзе буяп бетерде.

— Әзрәк кызыл буяу бар иде, улым. Барый белән килеп, йолдызын да буяп куярсыз инде...— диде.

Карт бераз сүзсез торгач, Кәримне башыннан сыйпап:

— Атаң изге юлда шәһит булды, балам. Атам юк дип кимсенмә, илдә чыпчык үлми, түзем бул...— диде дә аксаклап үз юлына китте. Шуннан бераз баргач, туктап, артына каерылды, кулын сузып, яшь имәнлеккә ымлады: — Әнә агачтан гыйбрәт ал, үсә эни канаты астында...

Кәрим, Гатау карт артыннан йөгермәкче булып, омтылып куйды. Шул чак кинәт, төшлеккә җиткән кояшның зурайганнан-зурая барып, туп-туры үзенә таба тәгәрәвен, битен, чәчләрен көйдергеч ут ялмавын тоеп, «аһ» итеп сыгылып төште. Күз алдында кап-кара ялкын өерелде дә дөньяны тынлык басты.

* * *

Башына эссе капкан иде Кәримнең. Әнисе аны төрле дару, сөт-катык эчереп, ике-өч көн урамга чыгармый асрады. Кәрим, әлбәттә, аңа карамас, әнисе юкта җаен табып ычкыныр иде, дәү әнисе саклап утыра. Аз гына кузгалыр хәл юк, мендәрең иплеме, чәй эчәсең килмиме, дип шундук килеп җитә.

Кәрим көне буе өйгә кайтмаган әнисен уйлап ята.

Уңган кеше аның әнисе. Җәй буена утау утап, көлтә бәйләп, яшь-җилкенчәккә баш булып, басудан кайтмый. Ул да булмый, авылда медпункт ачам дип, көн аралаш районга чаба, яңа салынган бинаны юып-җыештырып, курчак өе кебек итеп зиннәтләндереп гомере уза.

Кәрим әнисенең уңганлыгына, Гатау бабай әйтмешли, «афтаритле» булуына сөенә.

Ул тынычлана, ләкин Гатау картны искә төшерү белән, кайчандыр ул сөйләгән вакыйгалар зиһенен чуалта. «Борын Күсәк-бей дигән бер батыр булган,— дип сөйләр иде Гатау бабай.— Атасы Бабсакны Каракөлембәт дигән явыз үтергәч, Күсәк-бей, атамның каруын кайтарам, дип яу күтәргән. Зур кырылыш купкан, илле мең батыр бер яктан, илле мең — икенче яктан, ук-сазактан, кылыч-сөңгедән үтеп, үлем тапкан...» Революциядән алда гына әле күрше авылның бер кешесе, сунарда чакта ялгышлык белән дусын атып үтергәч, мәрхүмнең уллары, «үч алабыз» дип, моны сагалый башлаганнар, шуңа күрә ул картайганчы казак арасында мөсафирлык кичергән, имеш. Искелек касафаты, томаналык, иблис фигыле ди иде Гатау бабай. Әгәр Кәрим атасының дошманнарын очратса, кулында мылтыгы булса, ата алыр идеме?

Кәримнең башы уттай кыза, фикере чуала. Атар идем, дип кычкырасы килә. Юк, үзенең ятим булып үсүе, әнисенең һаман басылмас кайгысы өчен генә дә түгел — дошман булганнары өчен, фашист яклы булганнары өчен атар иде. Ә кулаклар белән фашистларның бер чыбыктан куылганына Кәрим һич кенә дә шик тотмый.

Саташып, кычкырып елап уянып китсә, янында ни арададыр кайтып кергән әнисе белән дәү әнисе утыра. Әнисе йомшак кына итеп битеннән сыйпый, юата:

— Куй, балам, юкны уйлама. Нинди үч ул?

Кәрим әнисенең ай-ваена куймый торып утырды.

— Кем соң, әни? — дип күзенә карады.

— Белмим... Күпме ел гомер узды... Атаң болай үч алырга йөрүенне хуп күрмәс иде...

Шул сөйләшүдән күп тә үтми, Кәрим савыгып урамга чыгуга атна тулганда, әнисе китеп тә барды.

Алар дәү әниләрендә торалар иде.

Әнисе китәр алдыннан Кәримне иртәнге үз өйләренә кереп чыгарга булды. Ишек ачып керүгә, кешесез өйләргә хас тынчу һава биткә бәрелде. Бер тәрәзәнең капкачын ачып, өстәл янына утырдылар.

Байтак вакыт сүзсез утыргач, әнисе:

— Җылы кулда савыт-сабаны, китапларны дәү әниеңнәргә күчер. Башка нәрсәләр торсын,— диде.

— Нигә, әни? — диде Кәрим.— Без инде үзебездә тормабызмыни?

Әнисе: «Юк ла, нигә тормаска!» — дип елмайса да, Кәримнең күңелен борчу алды. Сизендеме икән әллә ата йортының мәңгелеккә бикләнүен, учакның сүнүен? Әнисе дә, сәер итеп, әле бер әйберне тотып карый, әле икенчесен. Стенада эленеп торган сурәтләрне ала, пөхтәләп иске газетага төрә. Дәү әниеннең сандыгына бикләгез»,— дип, Кәримгә суза.

Әнисе, ни тикле ваемсыз, шат күренергә тырышмасын, бу юлы баш-

ка китүләренә караганда ничектер борчулырак күренде Кәримгә. Август башында ук кабаланып юлга чыгуы да сәеррәк тойгы калдырды.

Авыл халкы Кәримнең әнисен гел хөрмәтләп телгә алыр иде. «Чая, тырыш бичә булып чыкты бу Галия, тагы ике ел укыса, харап зур духтыр итеп куялар, ди... Тик менә Кәрим генә жәл, атасызлыгы җитмәгән, ана иркәсеннән дә мәхрүм...» — дип кайгыртып сөйләгәннәрен еш кына ишетә торган иде ул. Башкачарак сүзләр дә булмады түгел, әмма Кәрим аларына я колак салмас, я тиешле җавабын бирер иде.

Бер көн Сәкиләр янында уйнап йөргәндә, йөгерешеп аргач, су эчәргә керделәр. Сәкинең әнисе Гайнижамал җиңги әллә нинди ят бер әби белән чәй эчеп утыра икән.

Кунак әби:

— Кем балалары болар? — дип кызыксынгач, Гайнижамал җиңги:

— Монысы...— Мазһарга төртеп күрсәтте.— Хәбешнеке. Әнә монсы аю Хәбибулланыкы. Монысы Банзай Гатауныкы. Монысы коммуна Сәлимнеке...

— Ах-ах, шулаймыни? — дип, әби урыныннан кузгалды. Камзул кесәсеннән ике-өч бөртек борчак кәнфит алып, Кәримгә сузды.— Нинди зур малае бар икән, узган гомернең ни... Ничә яшьтәсең? Уникедәмени? — дип әвәрә килде.— Атасыннан яше тулмый калды, дигәннәре истә шул. Әниең исәнме соң, балам? Һаман шул духтырлыкка укып йөриме?

— Тере ятим инде бу бала,— диде Гайнижамал җиңги.— Әнисе ни... чәчен кыркытып, марҗага әйләнеп бара. Ул нинди бетмәс уку? Өч ел укыды, тагы бер елы бар, диме... Иргә чыгарга йөри, имеш...

Әбинең сүзен ишетмәде Кәрим. Үз-үзен онытып:

— Алдыйсың! Укуын бетерә дә авылга кайта ул! — дип, сулы чүмечне әллә табын уртасына, әллә Сәки әнисенең өстенә ыргытты да ярсып чыгып китте.

Кояш сүнгәндәй булды аңа. Көне буе болында йөрде, аулак җир табып, үләнгә ятып, туйганчы елады. Теләр-теләмәс кенә өйгә кайтса, дәү әнисе орышып каршы алды. Кырысрак шул Сәкинә карчык. Ул дигәнчә булмадымы — үзе дә тынмас, кешегә дә тынгы бирмәс иде.

— Әниеңнән хат бар. Кая, укы әле. Өйдә син була торып күршегә йөгеримме тагы?

Кәрим хатны дәү әнисенең кулыннан тартып алды, күз йөртеп чыкты. Берәмлекләп укып та өлгермәде, ләкин күңел күзе белән, йөрәге белән тойды — Гайнижамал җиңги сөйләгән шомлы хәбәр, я шуңа ишарә ясаган сүз анда юк иде. Кәрим, дәү әнисен гаҗәпкә салып, аны кочаклап әйләндерергә тотынды.

— Тәүбә, тәүбә әстәгъфирулла! Бу нишләвең, балам. Укы инде. Ни язган, кайтам дигәнме әллә?

Дәү әнисе, ах-ух итеп, сәке йөзлегенә утырды, Кәрим тынычлана төшкән иде инде — укый башлады.

«Әти, әни, колынчыгым Кәрим! — дип язган иде әнисе.— Исәнсаумын. Уку башланганчы кайтып әйләнермен, дип тора идем, булмас, ахрысы. Моннан ары, уку белән бергә, хәрби мәктәп курсантларына үзем дәрес бирә башлыйм. Эш күп, ләкин бу хәвефле заманда кул кушырып утырып буламы? Минем өчен көенмәгез.

Кәрим, китап һәм башка кирәк-ярагыңны, өстеңә пальто алып җибәрдем. Хат артыннан ук барып җитәр. Тырыш, балам, һәйбәт укы. Дәү әниеңне тыңла».

Соңгы сүзләрне Кәрим әчтән генә укыды. Ләкин дәү әнисе нәкъ әнә шул сүзләрнең барлыгын сизенгәндәй:

— Бетте дәме? — дип үкенеп куйды.— Һай, бу килен! Булыр да булыр, мондый тынгысыз җан булмас. Ни дип ул ир-ат арасына барырга күңгәндер? Ходай үзе саклый күрсен... Янә тагы бер укып бир әле.

Ул хатны өч кат укытты, чырае ачылып, яулык очы белән күзен сөртә-сөртә: «Сәлимҗаным булса, болай итеп урыс арасында йөртер идеме соң инде»,— дип такмаклады.

Дәү этисе кайткач, хат тагы ике-өч тапкыр укылды, Кәрим инде аны яттан белә иде. Дәү этисе хатны үзенчә юрады:

— Киленне әйтәм — атаң мәрхүм колачы анда. Һы! Тәки энә командир булачак егетләрне укытып йөри инде, ә! Биек оча, биек. Юлын тапты, азамат ирең торырлык.

Шуннан ул ишек төбендәге чөйдә эленеп торган кием-салым арасыннан кешелеккә тоткан кара постау пинжәген алып киде, җәй буе башыннан салмаган колакчынын килене бүләккә алып кайткан яңа эшләпәгә алмаштырды. Хатны түш кесәсенә тыкты да:

— Идарәгә барып кайтам,— дип чыгып китте.

Ул кичке аш вакытына гына әйләнеп кайтты. Кәефләнеп, сүзне һаман килененә борды, идарәдә кемнең нәрсә дип аны мактап телгә алуын бәйнә-бәйнә сөйләде. Шуннан, бер арада карчыгы чыккач, кет-кет көлеп, Кәримгә пышылдады:

— «Дәү әниеңне тыңла», дигәнен тәки укымагансың безгә, ә? Ишетеп калса, ай-һай!..

Дәү этисенең ачуланмавын күргәч, Кәрим дә, батыраеп:

— Болай да тыңлыйм бит инде,— диде.

Әнисе хакындагы килде-китте сүзләр ишетелмәс булды, малай күңелендәге юксыну тойгысын горурлык алмаштырды. Кәримнең зиһенен бүтән вакыйгалар да билэп алган иде: «Суык август башларында атасы белән бергә колхоз төзеп йөргән, авылда «комсомол башлыгы» булган, ә хәзер очучы-истребитель Зиннур абыйлары ялга кайтып төште.

* * *

Бер көн Кәрим кайдандыр кайтып керсә, дәү әнисе:

— Әллә кайда йөрисең, Мазһарын килгән иде. Испаниядә сугышкан Зиннур кайткан ди бит. Дәү этиең дә шунда китеп батты... Бакчага каз тулган, куалаучы гына да юк, ичмасам,— дип, гадәтенчә орышып каршылады.

Каз куу эшмени ул! Кәримнең киртәгә басып бер-ике сызгыруы булды, казлар, каңгылдашып, уттан качкан сымак юк булдылар. Ышанычлырак булсын өчен артларыннан таш ыргытып, Кәрим Мазһарларга йөгерде. Гатау бабай әйтмешли, ни өчен дисәң, чөнки Зиннур — Мазһарның атасы Хәбибулла агайның туган энесе.

Мазһарны күрсәң! Абыйсының уч яссылыгы ялтыр каешын биленә буып, башына зәңгәр читле өр-яңа фуражка киеп алып, болдырда конфет суырып утыра. Шәп егет тә соң Мазһар! Каешны шунда ук дусына бүдырды, кәгазьле бер уч конфет бирде. Мактануына да һич ачу килми.

— Вәт, малай,— ди бу күзен елтыратып.— Түшендә орден! Кызыл байрак ордены... Бер вакыт елга якын югалып, хаты килми торган иде бит — шунда Испаниядә булган...— Мазһар кабалана-кабалана сөйли, гадәтенчә бутала, сүзләрнең яртысын йота, кулын селти. Башка вакыт булса, Кәрим, кабыргасына төртеп: «Нигә, авыз эчендә ботка пешерәсең? Иплэп сөйлә!» — дип үртәр иде, хәзер ярамый. Вакыты бүтән.

— Әйе бит, хәтерлисеңме? Әтием командирына хат яздырып та йөргән иде... Ничәнче ел иде әле?

Кәрим алай да түзмәде, дусының беләгеннән тотып селекте:

— Я, исемдә, исемдә. Чутырдама шул хәтле. Кәнфитең качмас, юньләп сөйлә...

— Әй... минем белән көрешкәндә, нипачарам дип, кулын күтәргән иде, йодрыгы — баш хәтле. Каешы икәү. Монысын миңа бирде...

— Но пасаран,— дип тәэтте Кәрим.— Фашистны үткәрмибез дигән сүз була безнеңчә.— Ә үзе ишектән күзен алмый. Өйдән ара-тирә көлешкән, «һай, ирең!», «афарин!» дигән авазлар ишетелеп кала. Кәрим, Мазһарның җиңеннән тартып, ишеккә ымлый. Әллә ни арада Барый да килеп җиткән дә икенче беләгенә ябышкан.

«Ярый инде, дуслык хакына алып керсәм керим, югыйсә, мин үзем күреп туйдым» дигәндәй, Мазһар теләр-теләмәс кенә ишек тоткасына үрелде.

Өй эче, колхоз җыелышы диярсең,— шыгрым тулы, гел ир-ат. Күбесенең авызында озын саплы, алтын бизәкле папирос. Түтен өстәлдә бөркелеп утырган самавар тирәсендә болыт булып урала да, яссы күк тасмага әверелеп, түрдәге ачык тәрәзәгә сузыла. Зиннур — бакырдай булып кояшка янган тулы йөзле, кырлач-текә борынлы, киң кашлы чибәр кеше — кителен ычкындырып җибәреп, бер аягын икенчесе өстенә чалыштырып утырып, һәр сүзен йотлыгып тыңлаган халыкка нидер сөйли.

Малайлар, соклanудан телсез калып, әле командирның якасындагы өч кубикка, әле түшендәге орденына, әле куәтле хәрәкәт ясап кулын селтәвенә карыйлар да бер-берсенең бөеренә төртешәләр.

— ...Син шулай дисең дә бит, агай, кем әйтмешли, көч саламны да сындыра. Фашистта иде шул көч. Нык торырга кирәк, алар белән йөзгә-йөз очрашасы, бугазлашасы көн алда әле... Шунда ул ишек төбендә таптанып торган малайларга игътибар итте дә: — Нихәл, егетнең асыллары! Үсеп буламы? Кем батырлары болар? — дип елмаеп урыныннан торды.

— Бар, бар, күрешегез,— дип, ишек төбендә чүгәләп утырган ирләр малайларны түргә табан төрткәли башладылар.

— Син Сәлим малае булырга охшыйсың,— диде ул Кәримгә, олылар белән күрешкәндәй кул биреп.

Кәрим исә кулын бушата биреп, йодрыклап җилкә турысына күтәрде дә, кызарып:

— Но пасаран! — диде.

Һәм шул чак ул кинәт очып киткәндәй булды. Зиннур абыйсы аны күтәреп алып, күкрәгенә кысты.

— Молодец,— диде ул, аны идәнгә бастырып.— Сәлимҗан агайга охшасаң, лачын йөрәкле егет булырсың. Шуннан аның кепкасына алтын читле кызыл йолдыз беркетеп бирде.— Сакла, Испанияне урап кайткан йолдыз ул! — диде.

Куанычыннан ни эшләргә белмәгән Кәрим ишеккә үрелде, тик Мазһарның әнисе җиңеннән тотып алган да: «Кая атлыгасың шул хәтле, менә күчтәначтән авыз ит»,— дип, аңа печенье, конфет суза. Нигә ул — печенье! Кешенең кепкасында Испаниядән әйләнеп кайткан йолдыз янып торсын да, син шуны туйганчы карый да алма! Халык алдында бала-чагадай кепка әйләндерә башлау килешми бит инде.

— Һай, мең яшәгере!

Ишек ачылып китеп, такмаклап сөйләнә-сөйләнә, Гатау карт килеп керде:

— Балыкта йөреп, ишетми калганмын. Гаеп итә күрмә, улым. Болар ни... рәтләп каршылый белдеме, юкмы? Ни өчен дисәң, чөнки җиде яшәр юлдан кайтса, җитмеш яшәр күрешә килер, дигән борынгылар. Һай, бәрәкалла, һай машалла! Әссәләмәгаләйкүм, улым!

Малайлар бер-берсенә төртештеләр дә болар ике куллап күрешкән арада чыгып сыздылар.

Мазһарның билендә баягы каеш, Барый куанычыннан телсез кал-

ган: кулында чын компас! Менә ул, ачык капканы күрми, койма аша урамга сикереп төште дә чак телгә килде:

— Их, күпме эзләгән идем бит мин моны. Адашып йөрүләр бетте моннан соң!

Кәрим, кепкасын чишеп, йолдызны сыйпый. Мазһар, күкрәгенә табан шуышкан кыска күлмәген каеш астына кыстыра-кыстыра, эре кыяфәт белән арттанрак килә. Кәрим, үзе дә сизмәстән, зират юлына төште.

Карт имәннең яфракларын шаулатып, салкынча кичке җил исә. Шәфәкъ ялкыны офык читендә тау сыртлары кебек куерган болытларны каймалаган. «Нык торырга кирәк, ул фашист белән йөзгә-йөз очрашасы көн алда әле», дигән сүзләр Кәримнең колагыннан китми. Әнисе дә: «Мондый хәвефле заманда...» — дип язган иде бит. Сугыш хәвефеме? Булмас, батырчылык итмәсләр. Итсәләр инде — үлемнәре шул булыр!.. Но пасаран!

Кәримнең күңелен биләгән ярсулы хис дусларына да күчкән иде.

— Давай,— ди Мазһар, күзен елтыратып,— бүгеннән башлап мәңге дус булырга ант итешик!

— Фашистларны үткәрмәскә!..

— Зиннур абый кебек, Кәримнең атасы кебек батыр көрәшче булырга!..

Малайлар бер уч туфракны өчкә бүлеп, иң татлы җимеш чәйнәгәндәй чәйниләр. Балчыклы кулы белән күзен сөртеп, Барый битен пычратып бетергән. «Күзгә чүп керде», дип мыгырдый. Мазһарның маңгаен борчак-борчак тир каплаган. Кәримнең иңнәренә кулын салып: «Сәлим агайны әнә шул фашист яклылар үтергән»,— ди.

Кәрим, тылсымлы әкият дөньясына барып кергәндәй, таңгача йоклый алмый, күңел кошы канатланып, әллә кайларга оча. Үзе, мендәр астына кулын тыгып, кепкасын эзли дә йолдызчын үткер очлары бармагына төртелүдән әйтеп бетергесез рәхәт таба.

* * *

Йокысыннан Мазһар килеп уятты. Малайлар карангылы-яктылы, Зиннур абыйларын алып, елга буена кармак салырга киттеләр. Юлда аларга Барый белән Сәки килеп кушылды. Барый әллә ни арада тирәякның картасын сызып алган да, компасына карап юлны билгели.

— Давай, бер җыр өйрәтәм,— ди Зиннур.— Русча.

Иң элек ул беренче куплетның сүзләрен ятлатты, аннан көен көйләп берничә тапкыр үзе җырлап күрсәтте дә, буш кулын селти-селти, көр тавыш белән сузды. Малайлар, бик тиз отып алып, җырга кушылдылар:

**Если завтра война, если завтра в поход...**

Үзәндә җыр яңгырый. Әйтерсең бу Зиннур абый да, унбер-уникө яшьлек дүрт малай да түгел, ә дошманнарга каршы яуга күтәрелгән Кызыл Армия шулай авааз сала.

Зиннур абыйлары киткәч тә әле ул малайларның иң яраткан җыры булып калды. Аны пионер сборында да, төнгелеккә ат көтәргә чыккан да да җырлый торган булдылар. Канатларында куәт тоя башлаган очар кош сымак, йөрәкләре җилкенә, күкрәкләре киңәеп китә малайларның, нинди генә дошман очраса да, җиңәрләр төсле тоела...

Менә алар елганың текә борылыш ясап тал куаклары арасына кереп югалган җирендә кармак сала башладылар.

Зиннур абыйлары кармагын җимләп тәкрекләде дә:

— Алтын чабак йөгереп кап, яр башында ялтырап ят! — дип суга ыргытты.

Малайлар тын гына көлешеп алды — янәсе, летчик, кызыл командир, ә үзе ырым-шырымга ышана. Ләкин Зиннур абыйлары, күрәсең, балык җене кагылган кешеләрнең берсе булгандыр. Кашларын җыерып, дөньясын онытып, калкавычка текәлгән. Малайлар кычкырыбрак сөйләшә башладымы, я кармакларын шапылдатып ыргыттымы — җитди төс белән бармак яный, «тс-с-с» дип, тын булырга өнди. Калкавычы селкенгәнен күрсә, үзе дә утырган җиреннән калкына, түземсезләнеп, кулларын уа, бөтен кыяфәте, чырае су төбендәге балыкны тыны белән тартып алырга җыенган кешене хәтерләтә.

Менә бер вакыт Мазһар, суга егылып төшә язып кабалана-кабалана, кармак чыбыгын баш аркылы артка ыргытты. Шактый зур чабак һавада яшен булып ялтырады да шап итеп суга төшеп юк булды. Мазһар, һич исе китми, кармагын яңадан җимләргә җыенды. Чөнки төшеп калган, җепне өзеп качкан балык һәр вакыт иң зурысы булса да, малайлар өчен бу артык искитмәле хәл түгел. Ычкындымы — ризыкка язмаган. Ә Зиннур абыйлары өчен бу зур югалту иде.

— Ах, шайтан алгырысы! — дип кычкырып җибәрде ул. — Я, кем инде кармакны йолкып тарта? Бер дигән чабакны әрәм иттең. Балык дигәч тә, исәр дисеңме әллә син аны? Син хәйләкәр — синнән битәр ул хәйләкәр...

Китте бу Мазһарны кыздырып. Малайлар хәтта, шөрләп, бер-берсенә карашып алдылар. Ләкин Зиннур абыйлары ничек тиз кызып китсә, шулай ук тиз суынды, чөнки нәкъ шул мәлне аның ике кармагының да калкавычы бер батып, бер калкып тора башлады.

Малайларның эше мөшкел иде. Кеше башына өч-дүрт вак алабуганы санамаганда, табышлары — юк исәбе. Кояш күтәрелә — балык чиртми. Ә Зиннур абыйлары ике кармагын алмаш-тилмәш алып тора, симез чабакларны сулы чиләгенә сала тора. Малайларның балыктан гайрәтләре чикте, Зиннур абыйларының җилкәсен җыерып ризасызлык белдерүенә игътибар да итми, чырык-чырык көлешә, юк эшне бар итеп, әледән-әле куаклык арасына кереп югала башладылар. Менә, ниһаять, Зиннур абыйларының да калкавычы селкенмәс булды. Ул сәгатенә карап:

— Ярый, батырга да ял кирәк. Яле, чыбык-чабык җыегыз, шулпа пешерәбез,— дип кычкырды.

Печәнчеләрдән берәм-сәрәм калган карлыганны чүпләп йөргән җиреннән Кәрим аланга атылып чыкты. Тиз үк учак юнәтеп җибәрделәр.

Балык шулпасын Зиннур абыйлары үзенә генә билгеле бер ысул белән исләр китәрлек тәмле итеп пешергән иде. Мактый-мактый ашадылар. Зиннур абыйлары, балалар сымак кабынып, балыкны сөягенә хәтле чупылдатып суыра, шулпаны борычлап торып эчеп җибәрә дә эх! дип куя.

Кәрим түзмәде:

— Абый, Испаниядә малайлар балык каптырамы? — дип сорады. Янәсе, сүзне ерактан уратып башлый инде.

Иптәшләре аңа мыскыллы караш ташлады. Шулай да Зиннур абыйларының капыл уйчанланып китүен, чырае караңгылануын күреп, якынрак шуып утырдылар.

— Испаниядә дисеңме? — Зиннур агай папиросын кабызды, уртын чокырайтып, кат-кат йотлыгып суырды. — Авыр анда хәзер...

— Ә нигә безнекеләр күбрәк гаскәр җибәреп фашистларны тар-мар китермәде? — дип, Мазһар сикереп торды.

— Эх, батырлар! — дип ачынып елмайды ул. — Эш көчтә генә дә түгел иде шул... Хәер, килер ул көн — Испания фашизм төрмәләрен җимереп ташлар.

Зиннур абыйларына тел ачкычы килгән иде шикелле. Юлдашлары, тын да алмый, аның авызына карап торалар. Ул сузылып ятып, кулындагы үлән сабагын тешләп, җай гына сөйләп китте:

— Менә безнең Яубаткан авылының өскә җимерелергә торган кыялы тавы да, шаулап утырган карурманы да юк. Бердәнбер байлыгыбыз — менә шушы елга. Алмашыр идегезме бүтән бер җиргә шушы тугайларны, шушы әрәмәлекләрне?

Малайлар, командирның тел төбен бик үк аңлап җиткермәсәләр дә:

— Юк, юк...— диештеләр.

— Кеше гомеренең иң кадерле вакыты итеп бала чагын, дөньяның иң матур җире итеп туган җирен саный шул...— диде ул, үзалдына сөйләгәндәй. Аннары малайларга да ишеттерерлек итеп әйтте: — Әйе... сагындыра туган яклар. Колач киереп печән чапкан чаклар искә төшсә, эчләр өзелеп китә... Сезгә хәзер ничә яшь? Уникеме дисезме? Сезнең яшьтә мин, таң сарысы белән торып, энә-ә, умарта куагына барып, тышаулы атларны тотып алыр да сабанга китәр идем. Иртән һава салкын, чыкка чиркана-чиркана, ялан аяклап йөгерәсең, ә артыңнан тубыкка җиткән үлән өстендә кара-кучкыл эз сузылып кала... Кояш төшлеккә авышкан саен ныграк кыздыра, атларны кигәвен сыра, чыгымчылый башлыйлар. Күз яше белән елаган чаклар була торган иде. Ташлап кайтыр идең, койрык ябышкан. Кулак көчле иде шул әле. Кыдырач байдан кыш көне үк әҗәткә алып ашалган. Түзәсең... Ә барыбер сагындыра. Сабанын көйле булса, атларың тыңлап, эшең күзгә күренеп уңай барсамы — күкрәк киереп сулыйсың да, тургай сайравыннан исереп, җырлап җибәрәсең. Атлар, януарың, колакларын кайчылап, синең уеңны аңлаган сымак, тагы да елдамрак, тагын шәбрәк атлыйлар...

Боларны нигә сөйли икән, Испаниягә ни бәйләнеше бар аларның, диебрәк бер-берсенә карашып утырган малайлар әкренләп Зиннур абыйлары тасвирлаган гади генә куанычларның тылсымына бирелделәр. Юк, аларга Кыдырач ише карун байларга хезмәт итәргә дә, көчләре җитмәс авыр эш эшләргә дә туры килмәде. Ләкин бу сүзләр шундый якын иде аларга, шундый таныш!

— Игенченең, җир кешесенең шул изге куанычын тартып алдыңмы — аның яшәве яшәү түгел, күңел кошы читлеккә бикләнә,— дип дәвам итте ул.— Әйе... Безнең интернациональ бригадага инде-ин фронт тоткан испан отрядының пулеметчы Хосе исемле кеше белән дуслашкан идек. Кояшка көеп, ярылып беткән испан җире төсле, куллары беләүләнеп каткан, йөзен тирән җыерчыклар ергалаган, имәндәй нык егет иде. Мадридтан өч-дүрт чакрымдагы авылның ярлы крестьяны... Фронтта әз генә тынлык булып торамы, патрон ташучы булып йөргән уналты яшьлек улына пулеметын тапшыра да авылына кайтып китә иде. Җир эшкәрткәнне, тир белән сугарганны ярата. Фетнәчеләрне җиңгәч тә, икмәк ашамый торып булмас. Бер-ике сәгать чокчынып киләм»,— дияр иде.

Зиннур абыйлары көрсенеп тагы тәмәкесен кабызды. Кара-кучкыл йөзе суырылып киткәндәй булды.

— Шуннан, шуннан, агай? — дип түземсезләнде тыңлаучылар.

— Шул... фашистлар Мадридка басып кергән көнне һәлак булды. Ике кулы, кан катыш туфракка буялып, пулемет тоткасына ябышкан, чак аерып алдык... Улы калды. Республикачылар Франция границасына таба чигенә башлагач, командирыннан рөхсәт сорап, авылына кайтты. «Әнием авыру, сеңлем өч яшьтә генә, аларны кемгә ташлап китим», ди. «Коралыңны тапшыр»,— диде командир. Һәм Хуан — исеме шулай иде — атасыннан калган пулеметын, карабинын, гранаталарын янында басып торган испан егетенә сузды. «Боларын да»,— диде командир, малайның нидер тырпаеп торган сумкасына ымлап. Хуан эндәшми генә

сумкасын чиште дә аның эчендәге нәрсәләрне шылтыратып җиргә түкте. Карасак, тырма тешләре, агач сука очына куя торган тимер башак, кечкенә генә урак... Командир малайны күкрәгенә кысты. Шул тикле яуда чыныккан баһадир кеше иде — түзмәде, үксеп елап җибәрде. Иелеп баягы тимер-томырны сумкага тутырды, биштәрен бәйләп Хуанның аркасына асты.

— Испания җиңелә буламы шундый лачыннары үскәндә?! — диде ул, малайны озаткач...

Зиннур абыйлары түш кесәсеннән күн тышлы кечкенә генә куен дәфтәре чыгарып, бер фотокарточка алды.

— Менә ул батыр.

Сурәт кулдан кулга китте. Күе бөдрәләре маңгаена төшкән, үткен карашлы, озын буйлы ябык малай, Кәримнәрдән бер-ике яшькә генә олы булса булыр, ә янында карабин, бил каешында граната. Малайлар сурәтне сак кына әйләндереп, язуын укымак булдылар, ләкин аңламадылар. Зиннур абыйлары тәрҗемә итеп бирде: «Без мәңге бергә. Фашизм үтә алмас! Хуан.»

— Ул исәнме икән? — дип, дулкынланып, Кәрим Зиннур абыйсының күзенә карады.

— Их, монда булса!..— диде Мазһар.

Барый, сиздермәскә тырышып, күзен сөртеп куйды.

Авылга, ничектәр, тынып уйчанланып кайтты малайлар.

* * *

Алар ниндидер хәвефле дә, мавыктыргыч та дөньяга кергән иде. Зиннур абыйлары генерал Лукач, Хосе Диас, ялкынлы Долорес турысында, төрле илләрдән испан халкының азатлыгын сакларга килгән батырлар турысында сөйләде, малайларның уй-тойгыларына, хәттә үеннарына өр-яңа юнәлеш бирде.

Тик бу хәл озакка бармады. Бер көн көтү каршыларга дип Мазһарлар тирәсеннән узып барышлый Кәримне дусы чакырып алды.

— Абыем китә,— диде ул күңелсез генә. Штабыннан хәбәр килеп төште.

Шул кичне үк, колхозның нәсел айгырын җигеп, Хәбибулла агай Зиннурны станцага озата китте.

Хушлашырга ярты авыл җыелган иде. Кәрим Зиннур абыйсына якын барыр әмәл тапмый аптырап бетте, ниндидер бик кирәкле сүзен әйтә алмый калуына, ул сүзнең телгә килмәвенә үрсәләнде. Менә Зиннур абыйлары озатучылар белән күрешеп чыгып, тарантаска менеп утырды, елмаеп хушлашты һәм, якын килә алмый читтә торган малайларны күреп, уң кулын йодрыклап, иңбашы турысына күтәрде. Өч дус — Кәрим, Мазһар, Барый — шул ук хәрәкәтне кабатлап, абыйларының кинәт җитдиләнеп киткән йөзенә соклану катыш борчылып карап калдылар.

* * *

...Сугыш чыгар алдыннан Кәримнен күңелен кузгатып калган икенче кеше — Степан карт булды.

Җәй гомере — бер сулыш дигәндәй, тугайдагы чалгы чыңы, басудагы ургыч шавы белән сиздерми генә ямьле җәй үтеп китте. Көзге йончу көннәр дә артта калды. Яңгыр явып сафландырган һавада җылы якка очучы торна тавышлары чыңлый, үрмәкүч пәрәвезләре елтырый иде.

1940 елның октябре иде. Бер көн Кәрим мәктәптән кайтып капка ачуга, дәү әнисенең кемнедер әрләгәнен ишетеп, сагаеп калды. Өйгә керсә, колхоз председателе ишек төбендәге эскәмиягә утырган да нидер сөйли. Әхмәтгәрәй карт, башын иеп, сүзсез генә камыт төзәтә. Сәкинә карчык, ишекле-түрле йөреп, кунакның бер сүзенә биш сүз белән җавап кайтарып тора:

— Аллам сакласын! Кертәмме соң чит кеше?! Кертәмме соң? Башларымны ташка орсам орам, әмма дә ләкин кертмим чит кеше! Менә шушы кортка әйткән иде диярсез!

— Соң бит, Сәкинә инәй,— дип, карчык тын алырга туктаганда председатель ашыгып сүз кыстыра,— хакын түлибез, ремонтын үткәрәбез. Өегез буш торып черегәнче, ичмаса, акчалы буласыз...

— Хак түлиләр! Әстәгъфирулла! Чит кешегә төяк биреп, акча ашап ятам буламы? Ачтан үлгәнең артык. Авызыңны да ачма! Әнә үзеңнең арап кебек куш өең бар, бер ягын бушат та керт...

Дәү әтисе Кәримне чакырып алды.

— Улым, әнә персидәтел агаең йомышка килгән бит әле. Ни эшлик икән? Степан бабаеңны беләсең инде. Бөтенләй безнең авылга күчеп килергә булган. Ну, кыш якын, өен күчереп өлгертә алмый. Кыскасы, язга хәтле синең өеңне сорап тора.

— Бирик,— диде Кәрим, уйлап та тормый.

Дәү әнисе, тузынып, ал сатиннан тегелгән киң күлмәгенең итәген ялкындай өерелдереп чыгып китте.

Степан бабай — зур җирән сакаллы, якты зәңгәр күзле карт — колхозның яшелчә үстерүчесе, Кәримнең дәү әтисенең дусы иде. Җитмәсә, аның улы Алексей агай Кәримнең атасы белән бергә колхоз төзеп йөргән, җан дус-сердәш, көрәштәш коммунистлар булганнар.

Бәләкәй чагында Кәримне, әз генә тыңламый башласа, дәү әнисе әйткәнчә, кәҗәсе тотса, «әнә Степан карт килә, капчыгына салып җибәрербез!» дип куркытыр иде. Дәү әнисе картның хезмәт көненә тигән яшелчәне авызына да алмас:

— Ходай сакласын, шул урысның бисмилласыз кыярын ашап утырырга... Әллә ни гомер итеп, суганнан башка яшелчә җимеше күрмәдек тә, бер дә ятып үлмәдек,— ди торган иде.

Менә шул Степан карт, авыл халкын җиләк-җимеш, яшелчә үстерергә өйрәткән, башкортны үз итеп, гомеренең соңгы елларын алар язмышына бәйләгән кеше, күп тә үтми, Кәримнәрнең бикле торган өенә күчеп килде.

Дәү әтисе Степан картны гел хөрмәтләп телгә алып, карчыгын:

— Соң бит, ахмак бичә, илгә кот китерәм, дип тырышкан изге бәндә бит ул. Аның динендә ни эшең бар? Һәй, исәр, һәй, надан,— дип үгетләр иде.

Урамнан үткәнен күрсә, туктатып сөйләшер:

— Здрава, Степан гадук,— дияр иде мәрхүм. Мал-мало отдыхәй, маяныкы старуха өйдә юк. Хочешь, чәй пьем.

Ә Степан карт, кесәсеннән кыярмы, шалканмы чыгарып Кәримгә суза да, җиз торбадан чыккан кебек көчле тавышын яңгыратып көлә-көлә:

— Смогри, Әхмәтгәрәй, старуха узнает — бәлә будет... Ладно, чәй пить — не драва рубить,— дип өйгә керергә ризалаша.

Кәримнең русча белүе, Гатау карт әйткәнчә,— ипилек-тозлык кына. Шулай да, дәү әтисе белән Степан бабайның сөйләшкәненә колак салып, ул сыны катып көлә торган иде. Әңгәмә аңлаешлырак булсын дипме, картларның берсе — үзе белгән хәтле русча, икенчесе ватып-җимереп башкортча сукалый. Ике телнең сынык-саегыннан үзләре генә төшенерлек гаҗәеп тел хасил була.

— Ну, как живем-можем, Ахмет дус?

— Хараша. Мал-мало хворал, баба баня топил, крепкий чәй пил. Иртәгә базар гуляем. Твоя как?

— Моя — старый алаша. Хожу! Иртәгә в Култанайский базар тоже яшелчә тащим. Председатель акча ярата...

Сүз әкренләп дөнья хәлләренә күчә.

— Ох, порохом пахнет,— ди Степан бабай.— Туго будет с Гитлером...

— Аллах поможет.

— Жди, поможет...— Степан бабай, чәен җай гына чөмерә, уйчанланып, самавардан күтәрелгән буны күзәтә.— Помнишь, Алексей янына барган минеке? Ул теперича завод директоры бит. Танки делает. Много танков...

Кәрим түзмәде, дәү әтисе каршысына барып басты:

— Бабай, нәрсә ди ул, танкы диме? Сугыш буласымыни?

— Һы, син нишләп чәрелдисең монда! Бар, бар, келәт ишеге ачык иде, онытканмын. Кош-корт тулгандыр...

— Кума аны,— диде Степан бабай,— мал-мало белсә дә, зарар не будет. Тик син сөйләнеп йөрмә, Каримка. Сугыш төтене исе килә. Утсыз күмер кызмый ул.

Дәү әтисенең кашы җыерылганны күреп, Кәрим тышка атылып чыкты...

* * *

Степан карт күчеп килгәннән бирле Кәримнәрнең өе бәйрәм төсе алды. Саламы череп, яртылаш коелып беткән каралты түбәләре юнәтелде, киртә-кура кош-корт та үтмәслек итеп ныгытылды, өйнең ярык-йорыгы сыланды, кышкылыкка нигез салынды.

Иртәләрен Кәрим тәрәзәдән тышка, үз өйләренә карарга, ап-ак итеп сылап, акбурлап җибәрелгән морҗадан күгелҗем төтен күтәрелүен күзәтергә күнегеп китте.

Сәкинә карчык та тәрәзәдән шул якка карый, күрсенә, «тәүбә, тәүбә» дип, авыз эченнән укынып куя да, кулын кушырып, башын бер якка янтайта биреп, нидер уйлый.

Карчык белән оныгы арасында сүзсез-өнсез, кызыклы бер көрәш бара. Дәү әнисе, Степан карт күчеп килгәч, ике йорт арасындагы кечкенә капканы тимер чыбык белән бикләп куйды. Шул тәңгәлгә генә чыбык-чабык өйде, баз куышы янында торган көйлесен тәгәрәтеп күчерде. Кәрим, аның кайдадыр киткәнен сагалап торып, капканы яңадан ачып куйды. Карчык моңа сүз әйтмәде, иртәгесен оныгы мәктәптән кайтуга тагы бөтенесен дә үзенчә эшләде. Бу хәл көн дә диярлек кабатлана, әйтер сүзен авызына йомарга гадәтләнмәгән Сәкинә карчык ләм-мим дип эндәшми, үҗәтләнеп үз дигәнен итә, ә Кәримгә көлке — ул дәү әнисе эшләгәннен тагын киресен эшләп куя.

Степан карт Люба исемле оныгы белән генә тора иде. Аларның Рославль дигән кечкенә генә авыллары ул елларда ук бетеп бара иде инде. Олы юлдан читтә, сусыз-инешсез, мал йөртер, печән чабар тугае да булмаган авыл, юньлерәк урын эзләп, күрше Елизаветинога күченә башлаган иде.

Степан бабайның оныгы Люба башкортчаны бик тиз өйрәнеп алды. Ярты кышка кадәр рус теле укытучысының өендә берүзе сабак алып йөрде дә Кәримнәр классына төшеп укыды да китте.

Ул көзне Степан бабайның яшелчәләре котырып уңган иде, колхозның бердәнбер кечкенә машинасы кәбестә, кыяр, помидорны базарга ташып та, калага озатып та өлгерә алмады. Карт авыл халкын, өй борынча диярлек йөреп, кыяр тозларга, суган бәйләргә өйрәтте, кичлә-

рен Кәримне үзләренә чакырып, Люба белән икесен яшелчә орлыгы тазартырга, аны кечкенә генә капчыкларга тутырырга кушты.

Эш арасында картның теле тик тормый. Ул я берәр мәзәк сөйләп көлдерә, я үзенең Митрофанов дигән байда ялчылыкта йөргән елларын, карчыгының, шул йорт эшендә имгәнеп, мантый алмыйча дөнья куюларын хәтерләп күрсенә. Аның иң яратканы — шигырь тыңлау. Любасы да, әгәр туктатмасаң, сәгатьләр буе шигырь сөйләргә риза; дүртәр-бишәр битле шигырьләрне яттан сөйләп чыга. Ләкин Степан карт сүзне иплэп кенә Кәримгә бирергә тырыша, аның ватып-җимереп сөйләвеннән көләргә генә торган Любаны тыеп:

— Молодец! — дип, Кәримне мактый. Әйтерсең ул яттан сөйләгән шигырьне һич тә Пушкин я Лермонтов түгел, Кәрим үзе чыгарган.— Ничек диден әле? — дип төпченә.— «Жалок тот, в ком совесть нечиста...» дидеңме? Нәкъ өстенә бастың! Ике нәрсә кешене бизи, Каримка, берсе — батырлык, икенчесе — намус. Башкасы — ну, ничек әйтергә сина... кояшка үрләгән үлән төсле әнә шул ике сыйфатка тартыла.

Шуннан ул, байтак вакыт үткәч, Кәрим бая шигырь укыганда ычкындырган хаталарны төзәтә башлый:

— Чорного «түгел», «чорнава» дип әйтергә кирәк. Аннан ул нинди «утомительно грелит?» «Гремит» булырга тиеш. Гром гремит, пустое ведро гремит...

Бу сөйләшүләр бушка китмәде. Степан бабайның өйрәтү-төзәтүләре өстәмә бер сабак була иде. Аның әңгәмәләреннән Кәрим рус сүзенең үзенә генә хас мәргәнлеген, ниндидер куәтле дә, нечкә дә моңын абайлый башлаган иде инде. Хәтта аңламаган сүзләрен дә (яңгыравыклы булганнары өчен!), эчке бер аһәң белән үзалдына кычкырып кабатларга ярата иде. Шар сукканда яки кар бәрешкәндә жилле сугып, чәпкә тидерсә, «Так его, растак любезного!» — дип куяр; Мазһар я Барый белән көрмәкләшкәндә, егылса, Степан карт сымак итеп: «Лиха беда начало», дип әйтә иде. Мәгънәсен белү кайда! Матур яңгырый, шуңа кабатлый ул.

Ә Степан карт жае чыккан саен:

— Зирәк малайка син. Тиз смекаешь. Давай, минем белән дә, Люба белән дә русча гына сөйләш,— дип искәртеп куя да, Кәрим башкортча эндәшсә, юрамал ишетмәгәнгә салыша, я, «режь, не понимаю» дип, ике кулын ике якка жәеп җибәреп, шап итеп ботына суга.

Бу хәлләрдән Сәкинә карчык та читтә калмый.

— Урыска әйләнеп беттең инде. Әнә сабынлап юу кулыңны. Нәрсә ашатты, авызың майланып беткән...— дип сукрана.

Кәрим рус теле дәресен кычкырып кабатлый башласа, колагын басып, укына-укына чыгып китә. Оныгы аның артыннан, коты очкан кеше булып:

— Господи, помилуй! — дип кычкырып кала.

Әхмәтгәрәй карт, авыз эченнән нидер мөңгерәп утырган жиреннән торып, эшен читкә куя.

— Урыс теле — дөнья ачкычы, улым,— ди.— Алай да дәү әниең белән юкка хаслашасың. Надан кеше, авылның иң олы карчыгы дисәң дә ярый...

— Килегә көче житә әле,— дип көлә Кәрим.

Дәү әтисе дә кеткелдәп көлә, хәйләкәр төс белән күзен кысып, пышылдап кына:

— Ә син аны мунча артына ук тәгәрәтеп куй,— дип котырта.

Ул елны көз бик коры, жылы килде. «Әбиләр чуагы» әллә ничаклыга барды. Шулай да таң алдыннан кыраулата, якын ук килеп житкән кышның салкын сулышы тоела башлаган иде инде. Авылда басу эшләре күптән тәмамланган, бөтен халык чыр-чу килеп, һайт-һайтлап молотилка әйләндергән ындыр табагына күчкән иде.

Степан карт ни кыларга белми әвәрә килә, чөнки колхозда яшелчә кайгысы түгел — кар төшкәнче ашлык сугып бетерергә ашыгалар. Бердәнбер ышаныч — мәктәп балалары. Дәрес тәмам булу белән аларны бакчага алып китәләр.

Степан карт балаларны «молодцы, молодцы» дип алдан ук мактап каршы ала, яңа гына тоз сеңә башлаган кыяр, кып-кызыл эре помидор белән сыйлый. Хәтта күз карасыдай итеп саклаган ике-өч бөртек алмагачының җимешен дә кызганмый.

Балалар помидор җыешырга барган иде. Бер-ике сәгатьтә Степан бабайның куышы янында зур ике өем хасил булды.

Кояш, ялгыз тирәк таңгаленә житеп, офыкка якынлашкан. Үзән эргәсеннән салкын тарта башлады.

— Кырау төшәр, ахрысы,— ди Степан карт.— Бик вакытлы җыеп алдык. Давай, төйибез.

Помидорны кәрзинләп-кәрзинләп ящик арбага тутырдылар, калганын калын итеп салам белән каплап яптылар.

— Кич кереп чык, Каримка, покалякаем,— дип, Степан карт малайларны озатып калды. Мазһар белән Кәрим, атка утыртып, помидорны колхоз келәтенә бушатырга алып киттеләр.

Бакчадан чыгып, тигез юлга төшү белән малайлар, сүз куешкан кебек, икесе берьюлы: «Если завтра война...» дип җырлап җибәрделәр.

* * *

Тагын нинди вакыйгаларны искә алыр иде икән Кәрим? Мөгаен, сугыш чыккач, хәрби киемнәр кигән, якасына шпал таккан әнисенең ике көнгә генә кайтып китүен, кыр казы бәбкәсенең бозга катып, туңып үлүен хәтерләр...

... Соңгы кайтуында әнисе, гадәттәгегә караганда, күбрәк өйдә булды, кайнатасы белән кайнанасына ярдәмләшергә, улына ныграк игътибар итәргә тырышты. Ләкин ике көн вакыт үтте дә китте, сугышның заусыз законы яшь хәрби врачны юлга ашыктырды.

— Я, әти, хушлашыйк,— диде Галия, аны гомерендә беренче тапкыр кочаклап.— Рәхмәт сиңа, әткәй... Рәнҗемә инде, дошманны җиңгәнче Кәрим тагын сезнең өстә кала...

Картаеп, кечерәеп калган Сәкинә карчык килененә бәләкәй генә бер янчык сузды.

— Күп урын сорамас, кесәңдә йөрт... Өеннең нигез туфрагы... Кәримең өчен хафаланма, без бар — ул бар. Үзеңне саклый күр, балам. Ут эченә керергә ашыкма, ят күзгә чалынмаска тырыш... Харрасымны очратмассыңмы... һич кенә дә үлгән кебек түгел миңа, төшләремә гелән ак күлмәкләр киеп, елмаеп-көлеп керә,— диде.

Кәрим әнисен авылны чыкканчы озата барды. Алар, тарантастан төшеп, сүз куешкан төсле, зират сукмагына борылдылар.

Житдиләнеп ябыгып киткән улын кочаклап, Галия рәшәткә янына тезләнде, басынкы, моңсу тавыш белән:

— Менә тагы килдем, Сәлим... Тере булсаң, бергә китәр идек...— дип пышылдады.— Улыңа тиешле игътибар бирә алмадым, үпкәләмә инде. Хәер, син аңларсың, рәнҗемәссең... Син миңа: «Тоткан юлыңнан тайпылма, туры атла, йөрәгең курку белмәсен»,— дигән идең. Тыныч йокла, Сәлим, мин синең юлыңнан тайпылмам...

Таза айгыр алга, болытлар куерган алсу офыкка табан элдергән юлдан күзен алмый карап калды Кәрим, әнисенең ак кулъяулыгы, кош канаты төсле, һавада талпынганын гомергә хәтеренә сеңдереп калды...

* * *

Кече улы Харрасның кара хатыннан өшәнеп киткән Әхмәтгәрәй карт, инде килене дә фронтка китеп баргач, тәмам буынсызланды. Болай да аз сүзле кеше, сәгатьләр буе бер ноктага текәлеп, сүрән кыяфәттә уйланып утыра торган булды. Сиксән ел гомерендә кайгыхәсрәтнең иң авырларын күтәреп, сабырлыкка, күндәмлеккә өйрәнеп беткән карт, шулай, капыл йомшарып, дөнья белән исәп-хисабын тәмамларга җыена башлагандыр, күрәсең.

Алдырыр көн яздырыр, ди. Иң үкенечлесе шул булды — Кәрим белгәннән бирле авыру-сырхау күрмәгән дәү әтисе, олыларга кушылып елап йөргән арада, бер-ике көн генә ятты да дөнья куйды.

Кайчандыр шау-гөр килеп торган йорт, тузгыган кош оясы кебек, тынып калды. Һәркемне үз урынына куючы, өйдә-курада каты тәртип саклаучы, дистәләгән еллар буе күнегелгән йолаларны тайпылышсыз үтәүче Сәкинә карчыкның кырыс тавышы ишетелмәс булды. «Үтте дәмени бу гомер?» дигән төсле, ул хәзер кирәге беткән җиһазларга заманында бөртекләп җыелган мал-туарларына, мөлкәтенә аптыраулы караш ташлый. Я теге әйберне, я монысын, беренче күргәндәй, әйләндереп-әйләндереп тора да ни рәвешле итеп эшләргә икәнен тапмый, теләсә кайда калдырып китә.

Киртә-курадагы ир-ат хәстәре генә түгел, өй эшләренең дә күбесе әкренләп аның өстенә күчә барды. Кәрим эштән тайчанмады, әлбәттә, тик йортын чын ясау итеп тотарга күнеккән дәү әнисенең шулай ваемсызлануы, сүлпәнлеге борчый иде аны.

Бу хәл авылдашларның игътибарыннан да читтә калмады.

— Дәү әнием йончу күренә, улым. Йорт тирәсеннән алай озак күз яздырма, ни өчен дисәң, чөнки дөнья хәлен белеп булмый...— дип, бер көн иптәшләре белән тимер-томыр җыеп йөргән Кәримне Гатау карт кайтырга ашыктырды.

Степан бабай исә җилкәсен кашып торды да:

— Болай ярамый, Каримка, эш табарга кирәк әбиеңә,— дип, идарәгә юнәлде.

Күп тә үтмәде, колхоз парторгы, авылның әби-сәбиен җыеп, фронтка бияләй-оекбаш, шарф кебек җылы әйбер әзерләргә кирәклеген аңлатты, бу эшкә Сәкинә җиңгине баш итеп билгеләк, диде.

Баштарак әллә ни әвәслек күрсәтмәгән карчык тора-бара батыраеп китте. Әйтерсең ул гомере буе нәкъ менә шул максатка омтылган да, менә хәзер морадына җитеп, бөтен көч-куәтен, вакытын яраткан эшенә бирә иде.

Кышын төннәр буе Кәримнәрдә эш кайнады. Хәзер, өмәчеләрнең колхоз биргән керосинына алданып, Сәкинә карчык өенә әби-сәби генә түгел, бичә-чәчә, кыз-кыркын да җыела торган булды. Яңадан җан кергән, элеккедән дә ныграк шау-шулыга әйләнгән өй илнең кара кайгысын, күз яшен, сарач куанычын бергә туплагандай тоела иде. Чынлап та, хатын-кыз, кичке эшен бетереп, җыела башлауга газета тоткан укытучымы, Гатау картмы, яраланып кайткан Хәбибулла я бүтән берәр солдатмы килеп керә. Әңгәмә аның саен куера, көндәлек сүз әкренләп дөнья хәлләренә барып тоташа, көрсенү-уфтанулар, шыпырт кына елаулар белән тәмамлана.

Менә шул эреле-ваклы тәшвишләре, хафа һәм йөз елмайткан сирәк шатлыклары белән сугышның беренче хәвефле кышы үтеп китте. Кәрим укуын бетереп, колхоз эшенә тотынды. Халыкка ни — миңа да шул, дип бригадир кушканны көтми, олылар тирәсендә уралды. Җир кыртышы кибеп, нәфис яшел үләнгә күмелә башлаганнан кара көзгәчә я басуда булды, я ат белән урман эшенә йөрдә.

Тыштан караганда, тормышында күзгә күренердәй вакыйга да, телгә алырдай үзгәреш тә юк иде. Дөрес, Кәрим буйга тартылды, тавышында, карлыккан кешегә охшап, калын авазлар барлыкка килде, карашында нииндидер монсу уйчанлык пәйда булды. Беренче күргән кеше аны унбише белән барган үсмер димәс, унҗиделәргә чыккан егет дип уйлар иде. Гәрчә соңгы вакытта Степан бабайның Любасы Кәримне күрүгә кызарып аска караса да, малай үзе йөрәк тәшвишеннән азат иде әле. Шуңа ул йомрыланып, матур булып үсеп килгән кызыкайны ике ятып бер төшендә дә күрмәде.

Бер көн дәү әнисе Кәримгә казларны алып кайтып ябарга кушты. Ун-унбиш көн биклэп ашаткач, аларны өмә ясап суячаклар. Кәрим бу бала-чага йомышына теләр-теләмәс кенә ризалашып, төн чыкканчы юка боз каплаган күл буена атлады.

Җәйге шау-шудан арынып, җир тыныч ял көткән, ап-ак төшләр күреп йокларга әзерләнгән чак. Көз күптән үтеп китсә дә, кыш башланмаган иде әле. Ара-тирә каңгылдашып очкан йорт казлары гына күренеп кала, очар кошлар исә бу замангача әллә кайчан китеп беткән иде инде.

Нидер уйлап, җай гына атлап барганда Кәримнең артында аяк тавышы ишетелде. Ул да булмый:

— Мөмкиндер бит?..— дип, Люба килеп җитте.

Кәрим дәшмәде, иңбашын җыерып, атлавын белде.

Каз көтүен эзли-эзли, күлнең «убыр күзе» дип йөртелгән тәңгәленә үк барып чыктылар.

Казлар, ниндидер сәер уен уйнагандай, биешәләр. Әле каңгылдашып күл читенә йөгерешеп баралар, әле, канат кагып, яр башына ашыгалар. Мондый гаугага нәрсә сәбәп булды икән, дип аптырабрак калган Кәрим тирә-ягына каранган арада Люба, учы белән битен каплап:

— Ах! — дип ыңгырашып куйды.

Кәрим дә эшнең нидәлеген аңлаган иде инде. Иөрәге сыкрап, күл уртасына текәлде ул. Җәй үтеп, ниндидер сырхаумы, җәрәхәтме аркасында мантый алмый, канат-кауры үсми калган бәбкә кыр казы елтырап торган бозга катып туңган иде.

Шул очраклы, мәгънәсез фаҗига әйтерсең ниндидер ым-ишарә, язмыш искәртүе сымак, ике үсмернең күңелен шомландырды. Люба, күз яшен сөртергә онытып:

— Ичмасам, җирдә дә үлмәгән... Нигә генә күл уртасына керде икән,— дип такмаклап елый.

Кәрим аны юатырга теләп беләгенә кагылуга, кызы тагы да ярсыбрак еларга кереште.

— Уф, нигә генә килдем икән, нигә генә күрдем икән бу коточкыч хәлне! — дип, Люба Кәримнең күкрәгенә башын куйды.

— Люба,— диде Кәрим, тамагы карлыгып. Тирә-ягына каранып алды.

— Нәрсә бар?

— Юк та... Моннан болай минем арттан йөрмә, яме.

— Нигә?

— Малайлар көлә...

— Көлсеннәр! Аларның ни эше бар?

— Алай да йөрмә,— дип, Кәрим казларын куарга китте. Люба исә, ниндидер бер карарга килде, күрәсең,— үксүен басып, авылга таба йөгерде.

Кичен ул, Кәримне чакырып чыгарып, кыр казын боз кыршавыннан коткаруын, яр башына күмеп куюын хәбәр итте...

Иртәгесен мәктәптән кайткач, Кәрим утынлыкка чыкты. Ничәмә ел буе янгырда юешләнеп, кояшта какланып яткан адәм күтәргесез каен

кискәләрне чөйләп ярырга тотынган иде, янына Степан бабай килеп басты.

— Бирешмиме әллә? Кая, мин дә азрак буын язып алыйм,— дип, нигәдер кызарып киткән малайның аркасына шапылдатып сукты да «эһ» дигәнче ике-өч түмәрне ботарлап ташлады. Туктап тын алган арада: — Дәү әнием арумы? Кара аны, егет, ярдәмләш, эшкә мавыгып артык өшәнеп китмәсен, Люба да булышыр,— дигән иде, кайдандыр килеп чыккан Сәкинә карчык:

— Өшәнердән үттек инде. Яшьләрдән калышмаска әле исәп,— диде.— Үзең ни хәл, Степан? Любаң күренми. Сау-сәламәттер бит?

— Сәламәт...

«Нәрсә болар, сүз куешканмы әллә? Люба да Люба дип авыз сулары корый. Әйтерсең бүтән сүз беткән!» — дип уйлады Кәрим.

Карчык нидер әйтергә, Степан карт белән киңәш итәргә уйлыймы икән — китәргә ашыкмый. Шул ук вакытта сүзен дә әйтә алмый, иренен бөрештереп, каш астыннан гына карап тора. Ниһаять, күнелендә тартышкан хисләрен ачыклады шикелле, яулыгын төзәтә-төзәтә, сүз башлады:

— Кара әле, кем... Степан агай, төнәген халыкны, сәвиткә чакырып, читтән кайтучыларга фатир бирергә димләделәр, диме... Миңа әйтүче булмады. Сәкинә карчык, янәсе,— надан кеше, иске фикерле... сорашыйм, дигән идем: кайсы җенеснеке алар?

Карт аңламыйча Кәримгә ияк какты.

— Милләтләрен сорый,— дип аска карады Кәрим.

— Ә-ә, анысымы?.. Үзебезнең милләт, Сәкинә. Ленинград белән Украинада нинди чит милләт булсын? Әйтмәкче, болары сугыш чыккач та Уфага килгән, төрлесе төрле җирдә эшләп, башкортчаны да өйрәнеп беткән, диләр. Әле авылда кеше җитешмәгәч, үзләре теләп күчә икән...

— Шулайдыр дигән идем аны! Харрасым югалганчы хат саен украин җирен мактап язды... Сәлимем, шул Ленинградны бер күрсәм, һич үкенечем калмас иде, дип җан атты, мәрхүм... Кара син, ә! Әнә билсез яткан Сәлмән карчыгы белән чатан Гатавына хәтле: «Килә күрсеннәр, өемнең түре — аларныкы, тапканым — уртак!» — дип яхшатланып йөргәндә, кул кушырып, читтән карап тораммы! Тетмәсен тетәм әле персидәтелнең.

Китәргә җыенган дәү әнисен туктатып, Кәрим дә сүзгә катышты:

— Ни эшләп якшатлансын алар? Гатау бабайның: «Өем хан сарае түгел түгелен, иллә мәгәр ярый икән — рәхим итсеннәр. Тәяксез калган мөсафирга ярдәм итү — һәрберебезгә фарыз»,— дигәнен үзем ишеттем.

— Гатау белгәнне без белмибез, дисеңме?.. Шөкер, минем дә өем чын ясау. Олы якны бүгеннән бушатып бирәм,— дип, Сәкинә карчык, җәт-җәт атлап, авыл советына юнәлде. Капкадан чыкканда: — Кәрим, самаварны яңартып җибәр, балам. Хәзер кайтып житәрмен. Степан бабаең белән чәй эчә торыгыз,— дип кычкырды.

Болар икесе берьюлы көлеп җибәрделәр.

— «Кайсы җиргә утырды? Кайсы чәшкедән эчте?» — дип, Кәрим, дәү әнисен үчекли башлаган иде, Степан бабай, житдиләнеп, аны орышып ташлады.

— Монысы артык, Каримка, юкка рәнҗетәсең олы кешене. Нича әйтсәң дә, әйбәт күңелле кеше ул... Ә чәйгә килгәндә...

— Чәй пить — не дрова рубить! — диде Кәрим. Балтасын түмәргә чабып, картны өйгә чакырды.

Тик чәй эчәргә язмады аларга бу көнне. Авыр эшкә ярамый башла-

ганнан бирле почта ташырга куелган Гатау картның атын күреп, Степан бабай капкага таба атлады.

— Бар әле, сораш, хат-хәбәр юкмы икән? — диде Кәримгә.

Гатау карт, Кәримне күреп, атын туктатты.

— Такта чәй тапкан идем, яртысы дәү әниеңә булыр,— дип, арбасыннан төшми генә чәйне урталай бүлде, учында авырлыкларын чамалап торды да бер кисәген Кәримгә бирде.

— Безгә хат юкмы, бабай?

Җавап урынына карт зарланырга тотынды. Шунда гына Кәрим аның кызмача булуын сизде.

— Аптыраган...— диде Гатау карт еламсырап.— Озаккарак китте бу сугыш. Хак сүз: хәзер кырык беренче ел түгел түгелен, ни өчен дисәң, чөнки безнекеләр көн дә фашист самураеның томшыгын җимерә. Тик тәмам чәнчелдергәнче күпме арысландай ирләр зая буласы бар... Юк, булмый миннән бу пушты эше. Сөрлегеп егылганчы таш ватарга, сыер янына җигелеп сабан сөрергә ризамын, иллә мәгәр моңа кул бармый. Ни өчен дисәң, кара кайгы ташыйсың адәм башына...

Кәримнең йөрәге жу итеп китте, нигәдер күз алдына кичәге кыр казы бәбкәсе килеп басты. Куркудан күзен түгәрәкләндереп, ул Гатау картның җиңенә ябышты.

— Яле, сәвиткә кертим дә бу хәсрәт сумкасын, атны көтүгә җибәрим,— диде карт, дилбегәсен кагып. Үзе кебек үк йончу, арык алашасы, башын иеп, яшьләнгән моңсу күзен хуҗасына сирпеп, чак кузгалып китте.— На-а, рәхмәт яугыры нәмәстә! Бер аягыңны алганчы, икенчесен эт ашар, ни өчен дисәң, чөнки...— дип, Гатау бабай аты өстендә чыбыркы шартлатып алды.

— Ни сөйли бу карт? — дип, Степан бабай урам уртасында басып калган Кәрим янына килде. Кәрим дәшми генә баш чайкады да авыл советына китте. Карт аның артыннан иярде.

Алардан алда гына авыл советына киткән дәү әнисе, болар барып кергәндә, башын өстәлгә салып, өнсез-тавышсыз елый. Гатау карт, гаепле төстә аска карап, ишек төбендәге эскәмиядә утыра, авыл советы башлыгы — агач аяклы Хәбибулла агай — тәрәзә буена баскан да йодрыгын йомарлап, маңгаен стенага терәгән иде.

Степан бабай эшнең нидәлеген шундук аңлады, күрәсең, кемнәндер курыккан кебек, Кәримне, кочаклап, күкрәгенә кысты. Кәрим тартыла, картның кулыннан ычкынырга тырыша, тегесе җибәрми. Күпмедер вакыт шулай тавыш-тынсыз көрәшкәннән соң малай, аның куәтле кочагыннан арынып, өстәл янына барып басты.

Өстәл өстенә салынган зур пыяла, күлне каплаган яшь боз төсле, тәрәзәдән төшкән кояш нурында тонык ялтырый, шул чиксез дәрья уртасында, кичәге бичара кыр казы сымак, уч яссуыдай гына кәгазь кисәге агарып ята. Кара читле кәгазьнең ташка басылган, йөрәк өшеткеч миһербансыз хәрефләре арасына «майор Атнабаева» дип кара кара белән язган ике генә сүз кысылган иде...

* * *

Сталинград!.. Берничә ай буе бу дәһшәтле, горур сүз телләрдән төшми кабатланды. Ниһаять, авыр көрсенеп, дөнья җиңел тын алды, йөрәкләрне өмет җылысы иркәләде. Ләкин дөньяның үз колачы, авылның үз исәп-хисабы. Сталинградтагы җиңү Яубаткан халкына да зур сынау булды. Авыл өстендә, шатлык җырына кушылып, аһ-зар өерелде. Галия Атнабаева артыннан үк тагы дүрт кешенең үле хәбәре килеп төште. Кәрим бу кайгылы исемлектә Зиннур абыйлары да булуын күреп тетрәнеп китте.

Алгы көндә ни эшләрен ачык кына күз алдына китермәсә дә, Кәрим сабырсызланып яз житкәнен көтте. Аяк асты сарыккач, җәяүләп районга барды, төрле оешмаларның ишеген шакып, бер ай вакытын әрәм үткәрде.

Аның нигә район юлын таптавы һичкемгә билгеле түгел иде. Кызыксынып төпченгән кешегә ул: «Әниемнең кәгазьләрен юллыйм»,— дип кенә җавап бирде. Алай да Люба сизенде, юлдан арып кайтып, кара көеп утырган Кәримне бер көн аулакта тотып, ай-ваена карамый серен чиштерде.

— Ох, Карим! — диде ул азактан.— Синең урыныңда булсам, мин дә нәкъ шулай эшләр идем... Дәү әниең өчен хафаланма, өйдәшләрегез һәйбәт, аннан... мин дә бар бит әле,— дип аска карады.

Өстеннән тау-таш төшкәндәй булды Кәримнең.

Шул сөйләшүдән атна-ун көн үтүгә ул тәвәккәлләп юлга чыкты...

## Әңгәмәнең азагы

... Таң алдыннан гына чеyemгә киткән Кәримне Чукреев кайтып үятты. Йокысызлыктан күзе кызарган, йончу, сүрән кыяфәтле лейтенант Кәримнең Федорны соравына баш чайкап кына җавап бирде дә фронтка радиограмма җибәрергә кушты. Кәрим кәгазь битенә эре-эре итеп язылган саннарның дошман гаскәре тупланып яткан аулак төбәкләр икәнен аңлады.

Радиограмманы кабул итеп, ярты сәгатьләр чамасы үттергәч, «Сокол»ның тавышы кабат ишетелде. Ул: «Сез кунакка чакырган урыннар хуҗаларның күңеленә юш килде»,— диде дә десантчыларга яр читенә якынлашырга, Днепр аша чыгачак ротаны каршыларга боерык тапшырды.

Бу хәбәр отрядның язмышын аеруча кискенләштереп, бүтән якка борып җибәрде. Черкас ягына үтү ни тикле кыен булмасын, анда берьюлы ике бригада хәрәкәт иткәнлектән, дошман гаскәре урман эченә сыенып тора алмый. Максимның әйтүенә караганда, беренче ике-өч чакрым араны үтү генә авырга төшәчәк иде. Аръягы — ирәвән яшел киңлек, дистәләгән чакрымнарга сузылган куе шырлык. Ә монда бөтенләй киресе. Мәһабәт елганың сул як ярына килеп терәлгән Беренче Украина фронты гаскәрләренә җан аямый каршылык күрсәтергә әзерләнеп, фашистлар тау-ташлы, сирәк урманлы уң ярның буеннан-буена, кош үтмәслек итеп, «Днепр валы» исемендәге оборона сызыгы корганнар. Олы юл түгел, хәтта кечкенә сукмакларга хәтле күзәтү астында.

Дөрес, рота чыгачак җир, картага караганда, адәм аягы басмаган ташландык урынга охшый. Моны Максим да раслады. Тик әнә шул дүрт чакрым араны ничек итеп сиздермичә узарга?

Кәрим рациясен җыештырып бетерер-бетермәс, тирә-якта миналар шартлый башлады. Немецлар, күрәсең, радиостанциянең кайсы тәңгәлдән торып хәбәрләшүен аңлап өлгергәннәрдер. Лейтенант десантчыларны хәвефле җирдән читкә ашыктырды.

Патроннарын атып бетерә язган, арыган-талчыккан кечкенә төркем өчен иң авыр сәгатьләр башланды. Дошман оборонасының мыжгып торган үзәге аша Днепрга үтү әмәлен эзләп, Чукреев десантчыларны бер урыннан икенчесенә күчерде, немецлар белән очрашмаска, очрашканда исә отрядны тизрәк хәвефсез җиргә алып китәргә тырышты. Ләкин, ул ни тикле саклык күрсәтмәсен, дүрт-биш кешесен югалтты, соңгы бәрелештә Кузнецов һәлак булды, ана ярдәм күрсәтергә омтылган Таняның күкрәгe яраланды. Лейтенант рацияне күтәреп йөртергә ике десантчыны

билгеләде, чөнки моннан соң сестрага күз-колак булу, аны саклау, тәрбияләү бурычы Кәрим өстенә төшкән иде.

Отряд эз яздырып, немецлар сизмәстәй тоелган аулак юлны сайлап йөри торгач, төнлә рота чыгасы таңгалгә якынлашты. Протасов белән Максим отряд узачак араны тикшереп килделәр. Аларның әйтүенчә, «Сокол» билгеләгән урын аулак, машина түгел, хәтта җәяүле кеше дә көч-хәл белән генә ерып үтәрлек вак агачлык, камыш үскән сазламык икән. Дошман игътибарын тартмас өчен әлегә яр читенә чыкмаска, урман грушасы әлморан, чия куаклары каплаган тау өстенә менеп, ялгы туктарга булдылар.

Иреннәре көлсу төскә кереп чатнап ярылган, йөзе сурылып киткән Таня, носилканы җиргә куюга, ыңгырашып, күзен ачты. Су эчергәч, җиңел тын алып, менә ничәнче тапкыр инде Федорны сорады. Аның бу соравына туры җавап бирмәскә күнеккән иде Кәрим.

— Сөйләшмә, Таня, тыныч ят. Озакламый үзебезнекеләр белән очрашырбыз, эшләр җайланыр,— дип юаткан булды, тик яралы кызый азапланып булса да сүзен дәвам иттерде.

— Федор күрсә, рәнҗер инде, сүземне тыңлап, партизаннар базасына китсәң, болай имгәк булмас идең кешегә, дияр...

— Юкны сөйлисең, Таня. Менә аз гына ял итәрбез дә...

Тик бу юлы да ял итәргә туры килмәде десантчыларга. Утырып өлгермәделәр, тау битләвенә сакка куелган солдатларның берсе:

— Немецлар! — дип кычкырып җибәрде.

Шундук аяусыз атыш башланды, гранаталар гөрселдәп шартлады. Чукреев «әһ» дигәнче аякка баскан отрядына тауны уратып үткән тирән ерганак эченә йөгерергә кушты да, фашистларның юлын кисәргә ике солдат калдырып, үзе атыш яңгыраган җиргә ташланды.

Таняны күтәрергә кушылган десантчылардан берсенең сикереп торуы булды, башын тотып, чалкан авып төште; икенчесе, Кәрим белән бергә, носилканы алып агачлыкка карап йөгергәндә егылып калды. Ун-унбиш адымнарда гына гүләгән яу-атыш тавышларына колак та салып тормый, Кәрим носилканы тау итәгенә чормалып үскән куаклыкка сөйрәде. Тик ялгызы гына юлны дәвам итәрлек түгел иде. Ул һушсыз яткан сестраны куе үлән баскан вак агачлык арасына урнаштырды да, автоматын кысып, бер секундка гына уйга калды. Пулеметчылар янына йөгерергәме, әллә, ни күрсәк тә бергә, дип хәзер аннан башка кыл кыймылдатырлык та хәле юк Таня янында калыргамы?

Нәкъ шул вакыт Максимның:

— Лейтенант! Бу якка йөгер! — дип кычкырганы ишетелде.

Максим үзе күренми, уба өстендә пәйда булган Чукреев, посып та тормый, аякларын аерып баскан көйгә, кулындагы пулеметыннан ут яудыра; аңардан чак кына читтәрәк тагы бер пулемет татылдый.

Чукреев аягүрә баскан көе атышкан арада икенче пулемет кинәт тынып калды. Акырышып-сүгенешеп, автоматларыннан ут чәчә-чәчә, немецлар килеп чыкты. Чукреевның зур гәүдәсе агачлыкка кереп юк булды.

Фашистлар пулеметчыларга типкәләп карап, үлек икәнлекләренә ышангач, әле генә Чукреев сикереп төшкән ерганакка ябырылдылар. Тик алдагылары куаклык читенә дә барып җитә алмады, дошман төркеменең нәкъ уртасында аллы-артлы ике граната шартлады. Атыш тагы бик аз гына дәвам итте дә тирә-якны тынлык басты. Немецлар, яраланган солдатларын күтәреп, кире киттеләр.

Үлем бу юлы да читләтеп үтте Кәримне. Моңа ышаныргамы-юкмы дигәндәй, ул икеләнебрәк автоматын төшерде: немецлар тирә-якка карана-карана күздән югалганчы кузгалмый ятты да, борылып, Таняга күз салды.

Носилка буш иде.

Кәрим урыныннан сикереп торды, ярсып типкән йөрәген басарга тырышып, кичке караңгылыкның шомлы күләгәләре куера башлаган зак агачлыкны карашы белән араларга кереште. Таня, битен салкын җиргә терәп, биш-алты адымда гына куак төбендә ята иде. Кәрим, йөгереп барып, аны сак кына чалкан әйләндерде дә ирексездән читкә тайпылды. Кызый күкрәгенә граната кыскан, ә кечкенә генә пистолеты, көпшәсенә балчык тулып, үлән арасында ята иде.

Таняның буыннары ап-ак булып агарган нәфис бармаклары арасыннан, тонык елтырап, гранатаның шакмаклы кабыргасы күренә. Уң кулының чук бармагына дүңгәләк эленгән. Сестра әз генә кузгалса да, үлем йомган шул кечкенә дүңгәләк урыныннан суырылып чыгачак!

Кәрим, тир бәреп чыккан маңгаен җиңе белән сөртеп, Таняга якынлашты, тын алырга да куркып, аның кулына үрелде. Ләкин бармагына эленгән дүңгәләкне җай гына бушата башлауга, кызыкай кинәт:

— Якын килмәгез, кабахәтләр! — дип кычкырып җибәрде дә, кизәнеп, сул кулын артка ташлады.

Колак тондыргыч шартлаудан башы диңкеп, Кәрим үз гәүдәсе белән Таняны каплады...

* * *

Кәримнең тәвәккәллэп ерганакка төшүенә ике сәгатьләр булды инде, атлаган саен сөзәкләнә барып, бормаланып сузылган ерганакның әле һаман очы-кырые күренми. Баш өстендә, ике текә ярны бергә кушып, агачлар чатыр корган, якында гына чылтырап чишмә акканы, тупылдап тамчы тамганы ишетелә, куе яфрак арасында йокысы бүленгән кош-корт кыштырдап куя, шомлы тавыш белән күкеләр хәбәрләшә.

Күзгә төртсәң күренмәс караңгы чокыр ярыннан дошман ныгытмалары үтә, күрәсең. Ара-тирә кычкырган, автоматтан аткан тавыш ишетелеп кала, аннан тагы дөньяны җан өшеткеч тынлык баса.

Аяк астында лычкылдаган су Кәримне туктарга мәҗбүр итте. Юк, болай ярамый, Таняның хәле аңсыз да авыр; әгәр өс-башы юешләнсә, тагын да начарланыр. Ул носилка очына бәйләгән бавын чишеп алды, аны нигәдер пөхтәләп җыйды, кабаланмый гына кесәсенә тыкты. Әйе ләбаса! Егылыр чиккә житеп арыган егет, үз-үзен алдап, шулай ял итмәкче була. Ләкин туктарга ярамый, алга, гел алга барырга кирәк. Ул тагын носилка өстенә иелде, ыңгырашмаска тырышып тешен кыскан сестраны сак кына торгызып, корырак җиргә сөяп утыртты.

Менә ничәнче тапкыр инде Таня, бик азга гына аңына килеп:

— Куй, Кәрим, юкка азапланасың... һәлак итмә үзеңне... Калдыр шунда,— дип иңәлде.— Гранатам җәл... һичнидән курыкмас идем...

«Әйе, курыкмас идең,— дип уйлады Кәрим көрсенеп. Граната шартлаган мизгелне хәтерләде.— Ярый әле, Таня кулын артка ташлауга, гранатасын тартып алып, читкә ыргытып өлгердем...»

Кәрим тирә-якка аз гына колак салып торды да, колагы шаулаудан чайкала-чайкала, иптәшләре китеп юк булган якка таба атлады. Таняны хәзергә калдырып торды. Иң мөһиме — носилканы шудырып төшерергә кулай, сөзәгрәк яр табу иде. Байтак йөргәч, ярның янгыр суы юудан такыраеп беткән урынын билгеләп, Таня янына борылды.

Бер генә уй бораулый иде аның миен: тизрәк юлга төшәргә, аңсыз да байтак солдатын югалткан отрядка өстәмә тәшвиш салмаска, чөнки Чукреев Таня белән Кәримне эзләргә кеше җибәрәчәк. Днепр аша чыгачак ротага ярдәмләшер берничә десантчы вакытын бушка әрәм итәргә тиеш булачак.

Уйланып кире атлаганда Кәрим Максимга юлыкты. Юлыкты дип әйтү кыен иде моны. Партизан егет, колач ташлап, йөзтүбән ята. Кәрим аның, немецлар тау өстенә килеп менгәч: «Лейтенант, бу якка йөгер!» — дип кычкырганын хәтерләде. Димәк, ул, командирны саклап, аңа хәвефле җирдән чигенергә вакыт биреп, дошман белән йөзгә-йөз торып калган.

Финка белән тар гына чокыр казып, Кәрим ныклап танышырга да өлгермәгән яңа дусын җир куенына тапшырды. Күз алдына һәлак булган Ваня Рябчиков, Мәхмүт, Кузнецов, Платон бабай килеп басты. Алар соңгы сулышларына хәтле сугыштылар. Аларның яшәп бетелмәгән гомерләре, бөреләнгән шатлыклары, кайнаган изге нәфрәтләре — бөтенесе сиңа мирас булып калды. Ихтимал, йөрәгең ярсып көткән батырлыкның әлегә тәүге баскычын гына үткәнсеңдер, ләкин үлем, кан, кыйралыш эчендә алган сабакларың — үч һәм нәфрәт сабагы булды, «Ватан» дигән сүзнең бөек мәгънәсен аңладың. Исеңдәме, Кәрим, туган туфрак хакында Зиннур агаең сөйләгән сүзләр? Испан малае Хуанны да хәтерлисеңдер. Ватан!.. Шул батырларның көч-куәтен арттыра, кешегә талмас канат бирә, рухын очар кошка тиңли...

Кәрим әйләнеп килгәндә Таня урыныннан торырга азаплана иде. Кулын алга сузып йөгергән иптәшен күрүгә ул:

— Юк, үзем! Атлый алам мин...— дип, кычкырды да, ыңгырашып, Кәримнең беләгенә ауды.

...Ул вакыттан бирле тагын өч сәгать вакыт узды. Ә юлның әле һаман очы күренми. Кәрим тәмам хәлдән тайды, ләкин, ял итәргә утырсам, йоклап китәрмен дип курыкты, караңгы ерганак төбендә адым саен очраган сикәлтәгә, чокыр-чакырга, ташларга абына-абына алга барды. Моннан соңгы сәфәре тагын да авырлаша, чөнки хәле беткән Таняны носилкадан алып җилкәгә күтәреп барырга туры киләчәк.

Баштарак Кәрим, менә-менә Чукреев җибәргән десантчылар килеп чыгарлар да носилканы күтәрешеп алып китәрләр, дип өметләнгән иде. Тик, күпме генә көтмәсен, күзен чекерәйтеп, караңгы ерганакны күпме генә күзәтмәсен, көткән ярдәм килмәде. Күрәсең, ул әллә ничә тармакка аерылган ерганакның тиешле тармагын, иптәшләре киткәнен сайлый алмагандыр.

Кабат һушын җуйган сестраны мең бәла белән җилкәсенә салып, Кәрим, аяк астындагы күзгә күренмәгән баткакны лычкылдата-пыскылдата, юлын дәвам итте. Бераз атлагач, алда тоныкына яктылык күренде. Тар, тирән ерганак төбендәге сазлыктан күтәрелгән авыр ис, күңелен болгатып, тәмам хәлен алган иде Кәримнең. Кинәт битенә саф һава килеп бәрелде, каршыда сирпелеп калган яктылык киңәя башлады.

Кәрим үҗәтләнеп алга барды. Анда, ярыннан чыгардай булып, мәһабәт зур елга шаулый, су өстен, ажаган яктысы сымак, аркылы-торкылы прожектор нурлары телгәли иде...

Мәскәү, 1971.

# ЛӘБИБӘ ИХСАНОВАГА 50 ЯШЬ

*Күренекле балалар язучысы, «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Ләбибә Фәиз кызы Ихсановага быел август аенда 50 яшь тулды. Язучының иҗатына багышлап, республикабызның мәктәпләрендә, Казанның Пионерлар сараенда әдәби кичәләр үткәрелде.*

*Тантаналы юбилей кичәсендә Татарстан язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» журналы редакциясе Ләбибә Ихсановага түбәндәге котлау адресын тапшырды:*

*«Хөрмәтле дустыбыз, каләмдәшебез Ләбибә ханым! Сине әдәбият дөньясына «Көмеш елга» алып килде. Аннары Син «Җир астында җиде көн» йөреп, илебез балаларына табигатьнең гаҗәеп серләрен ачып бирдең. Бала күңеленнән дә саф, бала күңеленнән дә ышанучан берни дә юктыр. Илебез балалары «Саралан малайлары»на кушылып, «Робинзоннар лагеренда» йөрделәр, революция елларының «Очкын»ын тоеп, «Ана көндәлеге» белән танышып, сиңа рәхмәт хисләрен белдерделәр.*

*Синең китапларың рус, украин, эстон, чуваш телләрендә сөйләшә башлады.*

*Без, каләмдәш дусларың һәм редакциядә бергә эшләүче хезмәттәшләрең, синең балалар күңелен рухи баетырлык талантлы әсәрләр язып, илебезнең яшь буынын тәрбияләүгә багышланган иҗатыңны олылыйбыз. Без шулай ук Синең язучыларның алгы сафында торып, күренекле җәмәгать эшлеклесе: «Ялкын» журналы редакторы, Татарстан китап нәшрияты редакторы, Язучылар союзының партия оешмасы секретаре булып эшләгән эшләреңне ихтирам итәбез. Инде менә ничә еллар буе «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре вазифасын тыныч күңел, нык кул белән алып барасың.*

*Республикабыз хезмәт ияләре Синең иҗатыңны, җәмәгать эшендә армый-талмый эшләвеңне олылап, Сине берничә мәртәбә Казан шәһәр советына депутат итеп сайладылар, республикабыз хөкүмәте Сиңа «Татарстанның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирде.*

*Хөрмәтле Ләбибә ханым, Син уңышлардан баш әйләнүне белми торган әдибә, алтын юбилеең иҗатың гөрләп чәчәк аткан хәлдә килдең. Моннан соң да шул алтын сыйфатың сакланыр дип ышанабыз. Сиңа озын гомер, бетмәс-төкәнмәс иҗат шатлыклары, бәхет телибез. Бәйрәмең котлы булсын!*

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.
«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ».

Ләбибә Ихсанова

# ГАМБӘР КЫЗЫ ЗӨЛФИЯ

хикәя



Фәрхинур апа, тиз генә кереп чыгыгыз әле,— диде редактор, безнең бүлмә ишеген ачып.

Аның тавышын ишетүгә иптәшләрем күтәрелеп миңа карадылар. Нигә чакыра? Әллә газетада хата киткәнме? Берәр җитди хәл булганда гына бүлмәгә үзе кереп чакыра ул. Ә эш турында иртәнге киңәшмәләрдә сөйләшеп бетерергә ярата.

Күңелгә шик төште. Чыннан да, ни булды икән? Язып утырган кәгаземне ак ягы белән каплап салдым да, күзлегемне әләктереп, редактор бүлмәсенә киттем.

Мине көтүе булдымы, әллә уйлануы идеме — мин кергәндә ачык тәрәзәдән урамга карап тора иде. Ишек тавышына борылып, өстәл янына килде.

— Утырыгыз әле, Фәрхинур апа,— диде үз итеп.

Редакторның ягымлы тавышыннан бераз тынычланып, өстәл янындагы кәнәфигә килеп утырдым. Сүзен көтеп йөзенә карадым. Башында бер бөртек кара чәч юк, гел аппак, кырыкта гына бит әле үзе. Кеше тиз агара хәзер дигән уй күңелгә килеп китте.

— Яшьләр барында сезне ерак юлга чыгарып җибәрү дә кыен инде. Шулай да, Фәрхинур апа, анда мин сезнең баруыгызны теләр идем,— диде ул. Өстәлдән бер конверт алып каршыма килеп утырды.— Укыгыз әле менә шушы хатны...

Аның исеменә язылган конвертны ачып, машинкада басылган ярты битлек хатны укып чыктым.

«Редактор иптәш! Ярдәм итүегезне үтенәбез. Менә нәрсә: алдынгы сыер савучыбыз Зөлфия комсомол оешмасының дәрәҗәсен төшерә. Оешманың карарларына буйсынмый. Яхшы эшләгәне өчен вымпел биргән идек, алмады. Вымпелны үзе дә алмый, бүтән савымчыларны да алга чыгармый. Шуның аркасында социалистик ярышның кызыклы формаларын тормышка ашыра алмый торабыз. Безгә хәзер нишләргә?

*Комсомол комитеты секретаре Солтанов*».

— Ник алмый икән соң? Сәбәбен язмаган,— дидем мин, хатны кайтарып биреп.

— Менә шул шул. Принципмы бу, әллә гади бер кирелек кенәме? Яхшы эшләүче холыксыз кешеләр дә була бит. Коллективның теңкәсенә тиеп торучылар. Ул әле яшь кеше. Сөйләшеп кайтырга иде үзе белән... Сезне өйрәтеп торасы юк инде, Фәрхинур апа.

Укый башлагач та редакторның тел төбен аңлаган идем. Елмаеп күзенә карадым да:

— Корреспондент фактлар җыеп йөрүче генә түгел, корреспондент ул тәрбияче дә, кирәк чакта ярдәмче дә,— дидем.

Киңәшмә саен әйтергә яраткан үз сүзләрен исенә төшергәнгә, редактор рәхәтләнеп көлеп җибәрде, аннан җитдиләнде, кулын йомшак кына итеп ялтыравыклы өстәлгә куйды һәм:

— Кайчан бара аласыз? — диде.

— Якты Күлдән алып кайткан материалымны бетерим дә...

— Ике көннәнме?

— Ике көннән.

Яфрак селкенерлек кенә җилдә дә чайкала-чайкала очкан кечкенә самолетта сәгать ярым азаплангannan соң, июль аеның коры тузанын йотып тагын бик озак машинада чапкач, саргаеп килгән арыш басуында яшел куак очлары күренде. Без якынайган саен алар ишәйделәр, биегәйделәр, куаклар арасыннан телевизор антенналары да күренгәли башлады.

— Әнә, Тельман колхозы шул була инде,— диде шофер егет.

— Килеп җитәбез дәмени? — дигән булдым. Ә үземне сәер бер тынычсызлану биләп алды. Әлеге комсомол комитеты секретаре Солтанов корреспондент килмиме дип авыл башында ук көтеп торадыр, машинадан төшәргә ирек бирмәс, ай-ваема карамый, фермага алып китәр дә теге «кире беткән» кызый каршына китереп бастырыр кебек тоелды. Ә минем әле үземне рәткә китерәсем, юл тузаннарын кагып аласым килә иде. Сыер савучы кызыкайга мин тышкы кыяфәтем белән дә «басым ясарга» тиеш.

Зөлфия белән без икенче көнне очраштык.

Солтанов мине мотоциклына утыртып, җәйләүгә алып килгәндә сыерларны савып озатканнар, чиләк-бидоннарны юып бетереп киләләр, кызларның кайберләре өс-башларын алыштырып авылга кайтырга тора иде.

— Зөлфия кайда? — диде Солтанов, килеп туктауга.

— Каен урманында. Сине көтеп утыра,— диде кызларның берсе көлеп.

— Арадан кара мәче үткәч, көтүләр ю-у-ук инде ул,— диде икенчесе.

— Шаяртмагыз әле! — диде Солтанов, усал булырга тырышып,— кеше эш белән йөргәндә...

Савымчыларның берсе, олырак яшьтәге хатын, егетне кызгандымы, әллә шәһәр кешесе алдында уңайсызландымы, иптәшләрен шелтәләп алды:

— Җитәрегез сезгә, шыркылдыклар! Авыз җырырга гына торалар! — Ул безгә якын ук килде, кулын сузып.— Ә-әнә ул Зөлфия,— дип, болын ягына күрсәтте.

Җәйләүдән шактый читтә ак халатлы кыз бер күренә, бер югала иде. Иелеп чәчәк җыя иде бугай ул.

Солтанов мотоциклын кабызды:

— Утырыгыз, корреспондент иптәш, мин сезне а дигәнче...

— Юк, Солтанов, рәхмәт, мин үзем... үзем танышыйм әле Зөлфия белән,— дидем.

Зөлфия пәйгамбәр чәчәкләреннән такыя үрә иде. Мине күргәч, такыясын артына яшерде. Чибәр иде ул, ак халат аңа килешә иде, мин сүз башламый озаграк тордым, ахры, ул үзе дәште.

— Исәнмесез, апа.

— Исәнме, Зөлфия. Әйдә, танышыйк...

— Кичә әйткәннәрие инде корреспондент килде дип.

Безнең сүз тагын өзелде. Мин тагын аңа төбәлдем. Җиңнәрен сызганып җибәргән дә ак халаттан яшел болын уртасында басып тора. Маңгаена төшкән бала чәчләрен җил чуалта. Аның кай җиредер, нәрсәседер минем күптән күргән бер танышымны хәтерләтә иде бугай. Кем иде ул? Кайчан, кайда очрашып аерылышкан кешем ул минем? Ачык кына булып искә дә төшми үзе. Менә-менә күз алдына килер сыман тора да тагын югалып, үрти. Ә күңелдә бик рәхәт, бик җылы бер тойгы кала. Бәлки мин билгесез ул кешене юкка гына хәтерләргә тырышамдыр. Бу сөйкемле кызны күреп соклану хисем шулайдыр бәлки. Бу минутта редакциягә килгән хатны да, үземнең нинди эш белән йөрүемне дә уйлыйсым килми иде. Үзем дә көтмәгәндә:

— Матур җырлыйсыңдыр син, Зөлфия? — дип куйдым.

— Каян беләсез?

— Тавышың моңлы икән.

— Әллә тагын,— диде ул.— Менә әнием җырлый мине-ем!

Шунда ул беренче тапкыр күзен күтәреп миңа карады. Кояш нурында җемелдәп торган җитен чәчәкләредәй күренде миңа аның күзләре. Ул елмаерга тырышты. Ләкин әрнү катыш газаплы иде бу елмаю. Мин бит сезнең белән очрашмас өчен болынга чыгып киттем, нигә инде артымнан килдегез, дип әйтә кебек иде бу күзләр. Кинәт күкрәгемә кысып сөясем килеп китте аны. Кызым кебек итеп. Җил тузгыткан бала чәчләрен маңгаеннан сыпырып җибәрәсем килде. Була бит сөйкемле кешеләр! Бер очрашуда күңелне яулап алалар. Зөлфия дә шулай. Мин аның иңбашыннан кочып алдым да:

— Әниең белән таныштырырсың әле, Зөлфия,— дидем.

Кызның иң кадерле хисләренә кагылуым аның күңеленә үтеп керү өчен түгел иде. Шундый сөйкемле кыз үстергән, матур да җырлый торган ханым белән танышу теләге чын-чынлап туды миндә. Бу танышлык миңа Зөлфияне дөресрәк аңларга ярдәм итәр дигән уй соңыннан гына килде.

— Әниемне күрергә теләсәгез әйдәгез хәзер безгә,— диде Зөлфия, сүзне турыдан-туры фермадан башламавыма куанып,— бүген өйдә ул. Иртәгә укучылар белән Казанга китәләр. Экскурсиягә.

— Әниең укытучымыни?

— Әдәбият укытучысы.

Кызның көйләгәндәй аз гына сузып сөйләвен тыңлыйм, тыңлаган саен кемнедер искә төшерәсе килү теләге көчәя генә бара. Я инде, тырыш инде әз генә, дим хәтеремә, нигә шул кадәр ялкауланасың...

— Сез килә дигәч шикләнеп калган идем,— дип, юлда Зөлфия тагын сүз башлады.— Чын менә. Райкомолдан килгән инструктор белән сөйләшкәндә дә ул хәтле каушамаган идем.

Ул такыяга үрелгән чәчәкнең ак таҗын берәм-берәм йолкып килә. Башка вакытта сөя, сөйми дип юравы булыр иде. Ә хәзер, белеп торам, аның уе да, күзе дә чәчәктә түгел. Сизелер-сизелмәс кенә дерелдәгән бармакларыннан кызның борчылуын күрәм.

Сүз кушарга ашыкмадым. Аның болай кинәт ачылып китәрен көтмәгән идем. Кешенең күңеле тулган чак. Сөйләсен.

— Чын менә. Районлагы алдынгы савымчыларның барсыннан да артта барам, ә миңа, әйбәт эшләгән өчен дигән булып, вымпел бирә-

ләр. Алмадым. Кызлар ачуны китерә, беләбез инде «Якты тормыш»-тагы Нәсимә апаны куып җитәргә тырышасың, вымпелны азсынасың, сразы герой алмакчы буласың, диләр. Ә безгә вымпел да ярап тора, үзең алмасаң, бүтәннәрнең юлына аркылы төшмә, диләр. Дөрес түгел бит, апа?

Күңелем Зөлфия ягында. Инәдән дөя ясауны яратмыйм. Кечкенә генә эшне дә зур итеп күпертүчеләр бар. Редакциягә дә килә андый хатлар. Хезмәт алдынгысы, соклангыч нәтиҗәләр, алдынгы тәҗрибә. Теге дә бу... Берәр яңалыкмы дип, эшеңне ташлап шунда китәсең. Бактың исә бүтәннәр шау-шу күтәрми генә, гадәти бер хәл итеп, күптән шулай эшләп яталар...

Зөлфиягә җавап бирергә кирәк иде.

— Беләсеңме, Зөлфия, без бу мәсьәләне өчәүләп сөйләшербез. Әнең белән...— дидем.

Зөлфияне күргәч хәтерләргә тырышып та күз алдыма китерә алмый торган кешемне таптым бит, әй.

Без кергәндә кер үтүкли иде ул. Кызларныкы кебек нәзек биленә ак алъяпкыч бәйләп куйган. Дугаланып торган кара кашы, каш астыннан җылы бөркеп караган күзләре... Кеше белән сөйләшкәндә дә кызарырга гына торган нәфис ак йөзле Зөлфияне әнисе кызы дип кем әйтер. Аларның охшашлыгы күз карашларында, җанны эретерлек эчке җылылыкларында иде булса кирәк.

Хуҗа ханым безне күргәч, эшен куеп, каршыга килде.

— Рәхим итегез, түрдән узыгыз,— дип кулын бирде.

— Гамбәр дип әйтимме?

— Гамбәр шул,— диде ул, кулын җибәрмичә күзләремә карап торды да кочып ук алды.— И-и, Фәрхинур! Синме бу, җаным?

Ә Зөлфия бу очрашуны көтмәгән иде, билгеле. Безнең шулай күрешүебезгә аптырап та, куанып та, ни эшләргә белмичә басып торды.

Гамбәр минем яшь чактагы танышым иде. Берара сердәш булып та китә яздык. Мин әле ул чагында якты дөньяда яшәвемнән бүтән бер шатлыгым да булмаган үсмер кыз бала әбиемнәрнең Иж буендагы шомыртлы, миләшле авылларында кунак булып ята идем. Гамбәр миннән өч-дүрт яшькә олы, ирдән кайткан чибәр, яшь хатын. Иж елгасында паромчы булып эшли. Мин еш кына аның янына төшәргә, паромга утырып йөрергә яратам. Бергәләп су коенабыз.

Ни өчендер аның турында авылда гайбәт таралган иде. Бу ямьсез сүзләр хәтта миңа, бирədә әз генә торган кешегә дә килеп җитте. Бер көнне әбием дә су буена йөрүемне тыйды. Ышанмый идем мин бу сүзләргә, шулай да әбиемнең хәтерен саклап, берара Иж буена бармый тордым.

Аңа никадәр иярәнүемне, аны ничек юксынуымны шул вакытны гына белдем. Бер көнне түзмәдем, тагын Иж буена киттем.

Кояшлы, тыныч, гамьсез көн иде ул. Башларын ярга салып, кабыклары каезланган чи бүрәнәләр суда ята. Баш очында керәшәләр уйный. Су өстенә карап булмый, күз камаша. Яулыгымны кашыма ук тартып куйдым да, бүрәнә өстенә утырып, аякларымны җылы суга тыктым. Паром әле теге ярда. Бүрәнәгә бәрелеп су чупылдый, аргы яктан җыр ишетелә. Сүзләрен аңлап булмый. Сүзләрен елга өстеннән искән җилмә, дулкыннармы өзеп алып китә.

Ләкин көе барыбер күңелне әсир итә. Йөрәк кушып, күңел тулганда гына шулай җырлап була ул. Ә Гамбәрнең җырлавын тыныч кына тыңлап булмый. Әнә паром инде урыныннан кузгалды. Ул инде бирге якка якынлашып килә. Инде җыр да аермачык ишетелә башлады:

Сибла чәчәк җилләр искәндә лә,
Өзелә үзәгем исемә төшкәндә...

Бәхетле булсын бу бала дип, матурлыкны табигать аңа ал тутырып биргән иде. Әллә ни яхшы да киенеп йөрми үзе. Күргән саен бер күлмәк булыр өстендә: аклы ситсыга зәңгәр кыңгырау чәчәк төшкән. Шулай да яңа тегеп кигән диярсең. Кояшта янган тыгыз беләге, калку күкрәгендә дугаланып яткан кызыл мәрҗәне ул күлмәкнең агын ак, чәчәгенең зәңгәрен — зәп-зәңгәр итеп күрсәтә. Үрер-үрмәс салган толымнарның очлары сүтелеп киткән дә шомырт кара чәчләре зифа буена таралып тора. Әллә аның шул матурлыгын, пөхтәлеген, җыр белән юанган хыялый күңелен куралмыйлармы икән кайбер кешеләр? Колагыма ишетелгән ямьсез сүзләр белән күзем күргән матурлык икесе бергә аңыма сыймый иде. Гамбәр турында дөресен белергә теләдем:

— Авылда әллә нинди сүзләр йөри,— дидем дә куркып куйдым. Әгәр аның хәтере калса?

Гамбәрнең исе китмәде тагын:

— Унны бетергәч, җүләр булып, шахтадан кайткан егеткә кияүгә чыккан идем. Аерылдык. Шуннан гайбәт китте,— диде ул, гади генә итеп.

— Бер чыккач кайталармыни аны?

— Яратмагач кайталар икән шул.

— Ә нигә яратмадың?

— Костюмы гына матур булган аның...

Моңар каршы сүз әйтә алмадым. Ул вакыт әле мин ярату, семья кору шикелле хәлләрне китаптан гына укып белә идем. Шулай да аны юатасым килде:

— Казанга кит син, Гамбәр. Җырчы булырсың,— дидем.

— Соңга калдым инде мин аңар,— диде ул, су өстенә карап торгач,— барысына да соңга калдым бугай инде мин, Фәрхинур. Җырчы булырга да, яратырга да...

— Яратырга?

— Эх-х! белмисең әле син,— диде ул, үреп торган чәч толымын кинәт артка ташлап,— син китәсе кеше. Сиңа әйтсәң дә була. Җилгә сөйләгән шикелле. Бер кешене яратам мин, Фәрхинур.

— Ә ул?

— Минем яратуымны белми дә ул. Паромга кергәндә кайвакыт исәнләшергә дә оныта. Ә мин аның килгәнен көтә-көтә саргаеп бетәм. Бер генә күрсәм дә, күңелемдә бәйрәм була.

— Ул белмәгәч ярату буламыни? Хыялый син.

— Ул минем намусымны саклый. Җанымны түбәнсетергә юл куймый.

— Кем?

— Хыялым. Кешеләр теләсә ни сөйләсеннәр, ә минем намусым саф. Әй! Күз генә җитсен. Китәрмен дә барырмын Иж буеннан,— диде Гамбәр.— Университетка керергә телим, Фәрхинур. Укытучы буласым килә. Кайберәүләр монда эшләвемне гаеп итәләр. Ирсез хатын — йөгәнсез ат, диләр. Ә миңа әзерләнергә кирәген аңламыйлар. Унны бетергәнгә ике ел үтте, ике тапкыр да кулга китап тотып булмады. Монда вакыт күп. Китапларым да үзем белән...

Әйе, ул чакта да ышанган идем мин Гамбәргә. Ләкин әле ул бу хатынның ихтыяр көченә бәя биреп, акыл белән ышану түгел иде. Үзем дә яшь булганга, яшь кешенең хыялларына ышануым гына булган икән ул. Бер нигә карамыйча, ялгыш башланган тормыш юлын төзәтергә дә, явыз телләр тараткан әшәке сүзләрдән өстен булырга да, мәхәббәтнең җырларда гына җырланган сафлыгын сакларга да аңар бик зур ихтыяр көче кирәк булуын бары хәзер генә аңладым.

Юк, җил уңаена гына бара торган кешеләр түгел иде болар. Энисе дә, кызы да. Үз бәхетләрен үз юллары белән барып табарга яраталар. Зөлфиягә дә бит ферманың алдынгы савымчысы булып, комсомол комитетының күчмә вымпелын кулында тоту күңеллерәк булыр иде. Җыелышларда исемен телгә алырлар, бәлки район газетасына да язарлар иде. Әнә, Солтанов язарга ярата ул дип, Зөлфия үзе үк әйтеп тора.

Хәер, кәгазь язарга гына яратуы микән егетнең. Тәрәзә артындагы мотоцикл тавышына баядан бирле колак салып утырам. Тырылдап капка төбенә килеп туктый ул. Бераздан тагын китеп бара. Әллә кайлардан әйләнеп килә дә өй турында тагын тынып кала. Берсендә хуҗа ханым түзмәде, колакларын учы белән каплап китапка төбәлгән кызына эндәште:

— Әнә тагын әйләнеп килде, чыгып кер булмаса.

— Бик керәге барие,— диде Зөлфия. Үзе мәк чәчәге шикелле кып-кызыл булды.

Әни кеше дәшми генә башын чайкап куйды.

«Ай-һай, шулай микән, кызый?! Әнә кайчаннан бирле китабыңның шул бер битенә карап утырасың. Җүләрләнмә, чык. Синең дә аңар кирәгең бар. Таңга хәтле йөрсә йөрер, капка төбеннән китмәс»,— дип әйтә кебек аның күзләре.

...Мин ник килүемне искә төшердем. «Өчәүләп сөйләшербез. Әниең белән...» дигән идем. Инде менә уйга калып утырам. Мин генә хәл итә ала торган мәсьәләме соң бу? Ай-һай, авыр эшкә җибәрде редактор, авыр эшкә...

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**МАРТ-АПРЕЛЬ, 1972.**

«Советская Россия» газетасының 1 мартта чыккан санында 2 нче бит тулысы белән КамАЗга багышланган. «КамАЗны бөтен ил төзи» дигән баш астында газета автозавод һәм КамАЗ төзүчеләренең хезмәттәге энтузиазмы, төзелештә туган яңа алымнар һәм ысуллар турында сөйли, социалистик ярыш алдынгыларының портретларын бирә, илебездәге күп коллективларның автогигант төзелешенә керткән өлешләрен тасвирлый.

«Крокодил» журналы үзенә илле яшь тулган көннәрдә КамАЗда булды. Һәм үзенең 8 нче санында ул журналистларның, художникларның автогигантта алган тәэсирләрен сурәтли. Ул материаллар «Камада бар бер шәһәр» дигән баш астында чыккан.

«Крокодил» хәбәрчесе төзүчеләрне түбәндәгечә итеп күрә:

«Безнең бүлмәгә кереп-чыгып йөргән кешеләр бер-берсе белән саннар ярдәмендә генә аңлашалар, чәй янында да счетларыннан, арифмометрларыннан, логарифм линейкаларыннан аерылмыйлар. Хәтта янгын сакчылары да нәрсәләрдер хисаплап, блокнот битләренә саннар теркиләр. Хәтта милиционерлар да... Милиционерлар нәрсә ул! Миңа КамАЗга оратория язарга дип килгән бер композиторның әченнән генә саннар мыгырдавын карап торырга туры килде... Офыктан, ялан кыр уртасыннан башланып киткән күп катлы бинһая зур биналар, үз юлындагы кысан һәм кәкре тыкрыкларны, чалшайган агач йортларны, үзләренең язмышын сизенгәндәй җиргә сеңгән борынгы купец лабазларын юк итәитә, Кама елгасына таба ашкына».

«Ленинградская правда», «Волжская коммуна», «Марийская правда», «Советская Чувашия», «Адыгейская правда» газеталары да үзләренең март аенда чыккан саннарында КамАЗ төзелешенең барышы турында күп кенә материаллар биргәннәр.

Үзәк матбугат битләрендә март аенда күп кенә предприятиеләрнең, проект һәм фәнни-тикшеренү институтларының Кама автомобиль заводының беренче чиратын проектлаштыруны, төзүне һәм ходка җибәрүне тизләтү буенча социалистик йөкләмәләре басылып чыкты.

«Эшчеләр, галимнәр, фәнни-техник хезмәткәрләр Кама автомобиль заводы заказларын үтәүне һәр коллективта намус эше дип карыйлар һәм бу инициативага завод төзелеше белән бәйле барлык предприятиеләрнең коллективлары, министрлыкларның һәм ведомстволарның барлык оешмалары кушылыр дип ышанабыз»,— диелә йөкләмәдә.

**«Социалистическая индустрия»** газетасы (15 март) «Алдынгылар тәҗрибәсе — һәркемгә» дигән баш астында КПССның Татарстан өлкә комитеты пленумы турында хәбәр бастырып чыгарды. Анда «Социалистик ярыш оештыруны тагы да яхшырту турында» КПСС Үзәк Комитеты карарларын Чаллы шәһәре партия оешмасының ничек үтәве тикшерелә.

«500 дән артык бригада,— диелгән хәбәрдә,— Рәис Сәлахов җитәкчелегендәге монтажчылар коллективы үрнәгендә төзелеш темпларын тизләтү өчен ярыша».

Шул ук санда КамАЗдан СССР профсоюзларының XV съездына делегат итеп сайланган Социалистик Хезмәт Герое, СССР оештырылуга 50 ел тулу унае белән җөелеп киткән социалистик ярыш алдынгысы, эшче һәм коммунист Виктор Иванович Герасименконың портреты басылып чыккан.

**«Московская правда»** газетасында 25 мартта «Мәскәүлеләр Кама буенда кала төзи» дигән исемдә репортаж басылып чыккан. «Эшләрне тегәл оештыруда, монтаж-транспорт графикларын һәм технологик агым куллану — уңышларның серен мәскәүлеләр шунда күрәләр,— дип яза репортаж авторы.— Бу яңалыклар төзүчеләрнең «Һәр минутны эшкә җигик» дигән девизына тулысынча җавап бирә».

Ярославль мотор төзүчеләре КамАЗның беренче чиратын тизрәк сафка кертү буенча үзләренең социалистик йөкләмәләрен үтәү йөзеннән кыска вакыт эчендә күп кенә двигательләрнең яңа модельләрен ясадылар һәм сынадылар. Экспериментальь цехта сынаулар вакытында КамАЗ өчен ике двигатель яхшы нәтиҗәләр күрсәтте. **«Северный рабочий»** газетасы (12 март) бу турыда хәбәр итеп кенә калмый, ә КамАЗ өчен двигательләр әзерләүче конструкторлар, эшчеләр, сынау үткәрүче инженерлрлар белән дә үзенең укучыларын таныштыра.

Яшьләр тулай торагында кызлар язучы Майя Ганина белән очраштылар. Ремонт-инструменталь заводының зур ашханәсендә монтажчылар, шоферлар, төзүчеләр илебез башкаласыннан килгән «Улыбка» квартетын яратып карыйлар. Төзүчеләр индустриясе базасында Татарстанның халык артисты Илһам Шакировны кат-кат сәхнәгә чакыралар. Берьюлы егерме урында төзүчеләрнең культура университетлары дәресләре бара. Республиканың профессиональ музыкантлары ай саен КамАЗга килеп Чайковский, Шостакович һ. б. лар турында лекцияләр укый—болар турында 11 мартта чыккан санында **«Советская Россия»** газетасы яза.

«Камада яз» дигән репортажда **«Строительная газета»** (26 март) КамАЗда туган төзелеш индустриясе яңалыклары белән таныштыра, илебезнең төрле почмакларыннан килгән төзүчеләрнең тырыш хезмәтләре турында сөйли.

Менә экскаваторчы Борис Цораев. Ул Осетиядә туган. Ангарада һәм Урта Азиядәге төзелешләргә катнашкан. Биредә ул субай фундаментлар мастеры булып эшли. Аның эшләренең сыйфатын шуннан белергә була: экскаваторына кызыл йолдыз төшерелгән. Ә Сәмигулла Зәйнагетдинов Удмурдстаннан килгән. Ул да иң яхшы экскаваторчыларның берсе.

КамАЗда җитмеш өлкәдән, крайдан, республикадан килгән кырык милләт вәкилләре эшли.

«Чаллы шәһәре — СССР халыклары дуслыгының куәтле көчен практикада кабат сынау урыны»,— диелгән **«Советская Башкирия»** газетасында (2 март). Аннары газета укучыларны тугызынчы бишьеллыкның удар төзелешендәге эшләр белән таныштыра. «Башсантехмонтаж» тресты эшчеләренең тырыш хезмәтләре турында сөйли.

«Строительная газета»ның 3 март санында монтажчылар бригадасы җитәкчесе Рәис Сәлахованың хаты басылып чыккан. Ул анда барлык 15 союздаш республика төзелеш алдынгыларының тәҗрибә уртаклашулары кирәклеген әйтә. «Без моны шулай күз алдына китерәбез,— ди КамАЗ төзелеше ударнигы,— төзелеш һөнәренә ия булган иң яхшы вәкилләр үз тәҗрибәләре, ярыштагы яңалыклар, хезмәтнең эффектлы ысуллары — хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрә торган һәр нәрсә турында эшлекле сөйләшү алып барырга кирәк».

«Труд» газетасының 3 мартта чыккан санында КамАЗ төзүчеләрнең хезмәттәге уңышлары, көндәлек эшләре турында фоторепортаж басылган.

«Чаллы ит комбинаты, икмәк заводы, сөт заводы КамАЗ комплексының титул исемлегендә юк. Шулай да аларны КамАЗның иң мөһим объектлары рәтеннән телгә алалар»,— дип яза «Строительная газета» (8март).

«Тольяттида Идел автомобиль заводы корылмалары социалистик төзелеш индустриясенең үсешендә яңа баскыч булды,— дип яза «Труд» газетасы.— Ә КамАЗда төзү һәм монтаж эшләре тагы да кызурак темп белән алып барыла. Мондый темп белән алып барыла торган төзелеш эшләрен гадәти ысуллар, традицион технология белән генә башкарып чыгу мөмкин түгел. Биредә мәсьәләне новаторларча хәл итәргә кирәк». Газета 26 мартта чыккан санында КамАЗ төзүчеләрнең иҗади фикер йөртүе нәтиҗәсендә туган яңа алымнар, ысуллар турында сөйли.

«Строительная газета» (31 март) монтажлауның конвейер ысулына киң туктала. Бу яңалыкны куллану бүген үк инде матур нәтиҗәләр бирә.

«Стальконструкция» һәм «Центромонтаж» трестлары монтажчылары хезмәт җитештерүчәнлеген бер ярым-ике тапкыр арттырдылар. Вентиляция эшләрендә үсеш дүрт тапкырга артты, ә сантехник эшләрдә ике мәртәбәдән ашып китте. Болар хакында СССР Минмонтажспецстройның КамАЗ төзелеше баш идарәсе начальнигы М. Садаринов һәм Камгэсэнергостройның Автозаводстрой баш инженеры В. Альфиш яза.

«Известия» газетасының 3 апрельдә чыккан санында фотохәбәрче В. Сметанин «50 ел. Советлар Союзы буйлап» дигән баш астында КамАЗ төзүчеләрнең һәм Чаллы шәһәре кешеләренең кызыклы, күп яклы тормышын сурәтләп, фоторепортаж чыгарган.

«Советская Белоруссия» газетасы (4 апрель) Чаллы турында кызыклы белешмә биргән. «Яр Чаллы. Ике җенестәге 720 кеше яши, 136 йорт, чиркәү, училище, су тегермәне, 18 лавка, җомга көнне базар, өч ярминкә. Кама елгасы буендагы пристань. Анда яшәүчеләр иген игү белән бергә, бурлаклык һәм пристаньдагы эшләр белән шөгыльләнә» (Россия империясенең 1888 ел өчен географик-статистик сүзлеге).

Аннан газетада Чаллының хәзергесе һәм киләчәге турында языла. Бөтен халык төзелешендә Белоруссиянең дә өлеше зур. 1970 елда ук инде Минск автомобиль заводында «КамАЗ-5510» машинасының беренче үрнәге ясалды. Аннан соң тагын ике үрнәк машина эшләнде. Завод коллективы тәҗрибә үрнәкләрен камилләштерү эшен дәвам итә.

«Здоровье» журналының 4 санында Чаллы шәһәренең беренче торак районын сурәтләгән төсле фотолар бирелгән. Журнал, бу фотоларга аңлатма биреп, Яңа шәһәрнең 800 гектар мәйданга җәеләчәге, бишэр-егермешәр катлы йортлар салынуы турында яза. Шәһәр салучылар Мәскәү төзүчеләренең зур тәҗрибәсен киң кулланалар.

**«Правда»** газетасының үз хәбәрчесе 11 апрельдә чыккан **«Автоград калка»** дигән мәкаләсендә КамАЗдагы эшләр барышы, төзүчеләр алдында торган проблемалар турында яза.

«Кама автомобиль заводын төзүне партия тугызынчы бишьеллыкның иң мөһим халык хуҗалыгы бурычларыннан берсе дип билгеләде. Һәм күп меңле, күп милләтле, бердәм КамАЗ коллективы аны үтәп чыгар»,— диелгән мәкаләдә.

Монтаж эшләре мастеры Иван Григорьевич Давиденко Чаллыга командировкага килә. Ул да, башка юлчылар кебек үк, эшләремне бетерермен дә Украинага, туган ягыма, кайтып китәрмен дип уйлый башта. Көннәр үтә, атналар, айлар... Ә хәзер ул үз бригадасындагы егетләрдән башка яшәү мөмкинлеген күз алдына да китерә алмый. Алар — барысы да аның шәкертләре. **«Социалистическая индустрия»** газетасының 13 апрель санында басылып чыккан «Командировка» дигән очеркта әнә шулар турында сөйләнелә.

**«Экономическая газета»** (14 апрель) КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Табеев мәкаләсен бастырып чыгара. «Кагыйдә буларак, яңа, алдынгы алымнар партия оешмалары хезмәт иҗатка актив тарткан урыннарда туа»,— дип яза автор һәм КамАЗ төзелешендә иҗади инициативаның, социалистик ярышның киң колачлы үсешен мисал итеп китерә.

«Әйдәгез, бергәләп төзибез!»— дигән баш астында **«Советская культура»** газетасы (18 апрель) Кама автомобиль заводын төзүчеләрнең илебез культура һәм сәнгать эшлеклеләренә язган хатын урнаштырган.

«Төзелеш төзелеш инде ул,— дип язалар алар.— Бирелә иң әлек — эш. Әмма без шуны әйтергә телибез: эшчеләр, яшьләр средасында хезмәт белән бергә сәнгать белән кызыксыну да яши. Танылган артист, музыкант, җырчының килүе безнең өчен зур вакыйга».

**«Строительная газета»**ның 28 апрельдә чыккан бер мәкаләсендә Кама автомобиль комплексын төзүдә кече механизация ысулларын киң куллануның әһәмияте турында языла.

**«Жилищное строительство»** журналының 4 санында «Чаллы — автотөзүчеләр шәһәре» дигән мәкалә басылып чыккан. Анда архитектураның яңа казанышларын КамАЗда ничек файдаланулары турында әйтелә.

♦♦♦♦♦♦♦♦♦♦♦

Мәдинә Маликова

# ЧӘЧӘКЛӘРГӘ БАЙ ТОРМЫШ



Кай арада үтте соң әле бу кыш? Кама аръягыннан дымсу, салкын җил исә, сулышны иркенәйтә, йөрәкне җилкетә. Яз килә, яз. Әнә аръяктагы урман тагын да карасуланып киткән, озакламый ул яшәрер, аланнарда яз сәламе — зәңгәр умырзая чәчәк атар. Гидростроительләр урамыннан үткәндә, Разияның йөрәге сулкылдап куя. Юл читендә ак каүсәле яшь каеннар. Аларның нечкә тармакларында бөреләр бүртә башлаган, алардан яшел яфрак исе килә. Үсәләр каеннар, әнә бит Разиядан күпмегә биекләр инде. Әле кайчан гына утыртканнар иде аларны...

Көзге аяз, җылы, бераз ямансу көннәрнең берсендә Разия шушы йортның ишегеннән көрәк күтәреп чыккан иде. Ул тирә-ягына карап алды да асфальт җәелми калган, көзге яңгырлардан изрәгән җиргә көрәген батырды.

Төш вакыты узган чак иде, тулай торакка эштән арып егетләр кайта башлады. Күпләре ялгызы җир казып азапланган түгәрәк йөзле ханымга гаҗәпләнеп карыйлар, ләкин аны-моны дәшми узып китәләр.

Бераздан Разия янына бер егет чыкты, алар икәүләшеп нечкә каүсәле каен агачын утыртып куйдылар.

Егетләр ашый-эчә дә тәрәзәдән карый. Ә тышта көзге кояш дөньяны назлы нурга коендырган, әлеге ханым күңелле итеп эшли бирә. Җаны түзмәде егетләрнең, алар да берәм-берәм ишегалдына чыктылар. Шау-гөр килеп торган яшьләр өмәсе җыелды. Разия алып килгән агачлар гына җитмәгән иде ул чакта, прицеплы трактор табып, егетләрне тагын агач алып килергә җибәргәннәр иде. Тулай торакта яшәүчеләрнең тәрбияче Разия Хөсәенова белән танышуы шул рәвешле булган иде.

Кичен тулай торакның советы җыелды. Совет членнарының кайберләре көлемсерәп карады Разияга. «Элек тә булды андый... тәрбиячеләр»,— дип уйладылар егетләр. Ишек төбенә каравыл куйдырдылар, бүлмәләрдәге юылмаган савыт-сабаны карап йөрделәр, исерекләрне эзәрлекләделәр, «тәрбия эшләре» шуннан гыйбарәт иде.

Әмма яңа тәрбияче сүзен башка мәсьәләләрдән башлады. Кемнәр яши бу йортта? Унҗидедән алып алтмышкача яшьтәге ир-егет-

ләр. Яшьләр өчен җыр-бию түгәрәкләре оештырырга, кичәләр үткәрергә кирәктер. Олыраклар лекция тыңларга яратучан була. Кызыл почмакны бизәрбез, телевизор алып куярбыз. Шефлар янына барыйк, спорт кирәк-яраклары сорыйк. Дружина... Кечке мәктәптә укучыларга ярдәм... Карасана, эшлим дисәң эш күп икән!

— Сүзгә оста да бит, эше ничек булыр әле,— диделәр кайберәүләр, совет утырышы беткәч. Ләкин тулай торакта җанлылык иртәгесен үк сизелде: кызыл почмак кунак бүлмәседәй бизәлде, төрле түгәрәкләргә язу башланды, тәрбияче күпләр белән сөйләшеп, хәләхвәләрен сорашып өлгерде, шахмат такталарында каты бәрелешләр башланды.

Тулай торак ямьләнде, анда яшәү рәхәт, күңелле булып китте.

Ә бит Разия бу тулай торакка вакытлыча гына эшләргә куелган кеше иде. Чөнки Чаллыга килү белән ул: «Мин яңа төзелгән тулай торакта, үзем ишекләрен ачып кереп, эшне яңабаштан башлап җибәрергә теләр идем»,— диде. «Бик әйбәт,— диделәр аңа.— Әнә, 6/12 нче йорт төзелеп бетеп килә, шунда эшләрсең. Ә ул җитешкәнче, искесендә эшләп тор».

Иске тулай торакта да Разия: «Мин монда вакытлыча»,— дип тормады, бөтен күңелен, көчен биреп тырышты. Шул ук вакытта 6/12 нче йортта яшәячәк егетләрдән инициатив группа туплады. Ул группада төрле һөнәр ияләре бар иде: ташчылар, балта осталары, сантехниклар, электриклар. Гөнаһны яшереп булмый: яңа йортның әпен-төпен эшләнгән урыннары шактый иде. Ә оста күзе андыйны бик тиз күрә. Егетләр, эштән кайткач, ашап-эчеп алалар да, янә эш киемнәре киеп, яңа йортка чабалар. Тулай торакның шефы — 1 нче «Жилстрой» тресты — кирәк-яракны биреп тора. Осталар арасында комбинезон кигән тәрбияче йөри. КамГЭС поселогында бер итеп куйдылар йортны. Кызып китеп, проектчылар, архитекторлар күз алдында тотмаганны да эшләп куйдылар: подвалны чистартып, буяп, менә дигән спорт залы иттеләр. Балта осталары теннис өстәле ясап куйды, ә инде теннисның шарларын-җәтмәсен, башка спорт кирәк-яракларын «Хезмәт» спорт җәмгыятеннән сорап алдылар.

Тулай торакның ишекләре ачылу олы бәйрәмгә әверелде. Зур гаиләнең үз кулы белән салган яңа йортка күченүен күз алдына китерегез! Бу йортны ямьле, күңелле иткән хуҗабикә — Разия иде. Ул үзе дә ире Сәгыйт һәм улы Алмаз белән бер бүлмәгә күченеп килде. Аңарчы алар кеше өстендә тордылар, ә квартир чиратлары шактый ерак иде әле.

Түгәрәк эшләре тиз җайга салынды, совет председателе Рузалин Фәтхуллин да уңган егет булып чыкты. Шулай да тормыш һәркайчан да, аерата егетләр тулай торагында, шома гына бармый шул.

Тәрбияче, бигрәк тә эш урынына якын яшәсә, көнен дә, төнен дә эштә. Әнә баскычтан шау-шу ишетелә. Әгәр шунда Разия чыгып өлгермәсә... Әгәр салмыш егет кизәнгән кулын тыеп кала алмаса...

Нишләргә? Хулиганлык кылган егетнең эшен судка җибәргәме? Җәзасыз калса, аның ни кылансам да килешә икән, дип уйлап, тәмам азып китүе бар. Аннары башкаларның да пычак болгап «егетлек» күрсәтүне гөнаһсыз эшкә санавы мөмкин. Ата-ана канаты астыннан яңа ычкынган, мөстәкыйль яшәргә өйрәнмәгән малайлар шактый тулай торакта...

Икенче яктан караганда, егет кызганыч. Алай начар сыман күренми иде ул, ә Разия кешеләрне таный белә бит. Яңа шәһәрдә, зур төзелештә гомер юлын судтан башласа, егетнең харап булуы бар.

Ялгышырга ярамый иде. Тулай торак советы утырышына Разия анык бер фикер белән килде:

— Кичәге вакыйга безнең барыбызга да бик зур сабак булды,— диде ул.— Эшне кичәләр, лекцияләр белән генә чикләп, зур хата ясыйбыз түгелме? Безнең яшьләр буш вакытларында нишлиләр? Эшләп алган акчаларын нәрсәгә сарыф итәләр? Моны безгә белергә кирәк, күрәсең...

Советта бу турыда озак сөйләштеләр.

Ә егет җәзасыз калмады — аның тәртибен гомуми җыелышта тикшерделәр. Андыйларга игътибар көчәйде. Егетне башта кызыл почмакка дежур куя торган булдылар, үзешчән сәнгать түгәрәгенә чакырдылар. Шунда гына беленде: егет гитарада шәп уйный икән. Ниһаять, килде шундый көн, ул, беләгенә кызыл тасма бәйләп, башка дружиначылар белән бергә, шәһәр урамнарына тәртип сакларга чыкты. Аңа кызыл тасма биргәндә, Разия егеткә зур ышаныч белдерелгәнен артык күп вәгазь сөйләмичә генә аңлатып бирде.

Чыннан да үзгәрде егет. Түгәрәктә ул бер кыз белән танышты, бәлки, бу хәл дә аңа нык тәэсир иткәндер. Һәрхәлдә, ул тәрбияче ышанычын, сөйгәне ышанычынаклады.

* * *

Эш көненең үзәге, ә бер бүлмәдәге малайлар урын өстеннән дә кузгалмаганнар әле.

— Без кая барырга, кемнән кием алырга икәнен белмибез,— диләр алар.

Разия малайларның эш урынын эзләп китә. Баксаң, мастер аларның төзелеш мәйданына килгәнен көтеп утыра икән. Көннән-көнендә йөзләрчә кеше килеп, шактый өлеше кире китеп торган зур төзелештә мондый аңлашылмаучылыкларның булуы бер дә гаҗәп түгел.

Разия төзелеш мәйданнарында еш була.

— Эш урынында күрми торып, кешене тәрбиялим дип азапланасы да түгел,— ди ул.— Чөнки һәркемнең холкы-фигыле, кешелек сыйфатлары, беренче чиратта, үз эшен ничек башкаруында күренә, хезмәттәшләре белән мөнәсәбәтләрендә сизелә.

Тәрбиячесенең эш сәгатьләре көндезге сәгать икедә башлана. Ә көннең беренче яртысын Разия егетләр эшли торган бригадаларга йөреп үткәрә.

Ул беренче килгәндә, булачак завод һәм яңа кала урынында бихисап бульдозерлар, скреперлар, экскаваторлар җир актара, сау лынып кына килгән юлларда көчле машиналар кайный иде. Бу зур мәйданны күздән кичерүгә, дулкынланудан Разияның сулышы кысылды: аның бик зур төзелешләрдә эшләгәне бар, әмма мондый куәтне, мондый киң төзү мәйданын күргәне юк иде әле. Чагыштыра алганга күрә дә, ул монда барган вакыйгаларның тарихи әһәмиятен күпләргә караганда ныграк аңлады. Кичен тулай торакка арыпталып кайтып кергәндә бик гадәти, бик гади күренгән егетләр биредә баһадирлар булып тоелалар, алар хәтта үсеп киткән кебек күренәләр, аларның ихтыярына искиткеч куәтле машиналар буйсына.

Аларны шушы хәлендә күрми торып, бу хезмәтне ихтирам итми торып, тәрбияче буларак нәтиҗәле эш башкарып буламы? Юк, әлбәттә.

Разия шәһәрнең һәм заводларның үсешен күреп, күзәтеп торды, бу үсештә үзенең дә өлеше барын тоеп яшәде, һәр уңышка егетләр белән бергә сөенде, чын күңелдән куанды.

Ә менә тәрбия эше өчен җаваплы кайберәүләр бу җиңүләрне читләтеп үтә — төзелеш гөрелтесе аларга ишетелми иде кебек. Атнага бер тапкыр трест конторасына тәрбиячеләр җыела. Әз дә түгел, күп тә түгел — сиксән ике тулай торактан! Килеп утыралар, тәртип бозу, урлашу юкмы дип, бер-берсеннән сорашалар, тыңлаусыз егетләрдән зарланалар, тегене-моны сөйләшәләр дә таралышалар.

Түзмәде Разия, шундый сөйләшүләрнең берсе вакытында сикереп торды да:

— Нишләп без монда корыны бушка авыштырып утырабыз әле? — диде. — Мәгънәсезгә сүз боткасы пешергәнче, тәрбиячеләр мәктәбе ачарга кирәк иде. Менә без Братскида эшләгәндә...

Разия сүзен кызуланыбрак башлаган иде, башкалар аның сикереп чыгуын яратмас, каршы килер, дип, алдан ук бәхәсләшергә әзерләнеп тотынган иде. Әмма тыңлаучыларның йөзендә канәгатьсезләнү түгел, кызыксыну, җанлану күренде. Алар бит иренгәннән дә, ялкауланганнан да түгел, эш рәтен белеп җиткермәгәнгә, тәҗрибә юклыктан аптырап йөриләр икән! Теләк бар — осталык җитми, дәрт бар — дәрман юк аларда!

Разияның күп еллар Братскида тәрбияче булып эшләгәнен ишеткәч, аның ярсуына игътибар бирмичә, йотылып тыңлый башладылар. Мең төрле сорау яудырдылар:

— Эш планнарыңны сакламадыңмы? Кичәләрнең программасы юкмы? Сүз үтми торган егетләрне ничек йөгәнли идең?

Разия тынычланып китте. Әйе, Братскида ул күп тулай торакларда эшләде. Берсендә эшне җайга салгач, аны икенчесенә, тәртип ягы аксаган, тәрбия эше чыгырдан чыкканына күчерәләр иде. Анысын рәткә керткәч, өченчесенә, аннары дүртенчесенә... Планнары, анда уйлаган-кичергәннәре язылган дәфтәрләре бер өем. Барысы да исән...

Башкалар өчен файдалы күп нәрсә сөйләде Разия. Ләкин бар сорауларга да берүзе җавап биреп бетерә алмады һәм ул мөмкин эш тә түгел иде. Чөнки Братск төзелеше белән КамАЗ төзелеше арасында охшашлык булса да, аерма да бик зур иде. КамАЗның күләме дә башка, төзүчеләре дә икенче. Аннары һәр кеше күңеле — үзе бер дөнья, аның өчен әзер ачкычлар юк.

Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты: Разия атна саен тәрбиячеләр алдында чыгыш ясарга тиеш булды. Моңа әлекке тәҗрибә генә җитмәде, тагын күп нәрсә укырга, өйрәнергә, уйланырга туры килде.

Шулай итеп, тәрбиячеләрнең мәктәбе барлыкка килде. Трестның штат исемлегендә тәрбиячеләрнең укытучысы дигән берәмлек юк иде. Зур төзелештә бар нәрсәне дә алдан күреп бетерү мөмкин түгел икән, күп мәсьәләләр эш барышында хәл кылына. Тәрбияче-методист дигән штат берәмлеге барлыкка килде, шулай итеп, Разия Хәсәенова барлык тулай тораклардагы тәрбия эше өчен җаваплы кеше итеп куелды.

* * *

...Ханымның хәрәкәтләреннән дә, ябык йөзеннән дә, сөйләшүеннән дә коры, кырыс холыклы икәне сизелеп тора. Ул урындык кырыена уңайсыз гына итеп утыра, дулкынланып Разияның йөзенә карый.

— Нишләп сез, укытучылык эшен ташлап, тәрбияче булырга уйладыгыз әле? — дип сорый аннан Разия.

Ханым гаиләсе белән кеше почмагында яшәвен сөйли. Иренә якын арада квартира бирергә вәгъдә итмиләр икән, ә тәрбиячегә бүлмә бирергә тиешләр.

— Мин сезгә киңәш бирмәс идем,— ди Разия.— Тәрбияче эше бик авыр бит. Үкенергә туры килмәсме?

Ханым дәшми.

— Ярый алайса, эш белән танышып карагыз,— ди Разия күрсәтеп.— Сез урнашырга теләгән тулай торак артык зур түгел, анда акылга утырган кешеләр — инженерлар, техниклар яши. Җиһаз белән тәэмин ителгән, совет сайланган, дружина оештырылган, тик менә кызыл почмакта стендлар...

Разия тулай торактагы хәлне бөтен ваклыклары, нечкәлекләре белән аңлатып бирә. Әйтерсең ул аннан чыкмый утыра. Ә бит аның карамагында йөздән артык тулай торак!

Аннары сүз планнар төзүгә, методик күрсәтмәләргә күчә. Ахырда Разия әлеге ханымга тагын бер кат ныгытып уйларга киңәш бирә. Чөнки күреп тора: бу кеше рәтле тәрбияче була алыр микән, ай-һай! Батырлык күренми анда, дәрт сизелми! Ә ансыз тәрбияче эшен алып барып булмый.

Бәхеткә каршы, тәрбиячеләр арасында басканурынында ут уйнатып торучылар күбрәк.

Менә Александра Валентиновна Черемисина килеп керә, бүлмәне җанлылык, күнелле шау-шау белән тутыра. Йомры гәүдәле, шат холыклы, тиктормас бу тәрбияче Закарпатьедан әле күптән түгел генә килгән икән.

— Шыгырт-шыгырт ялтыравыклы читекләр белән, җиңел пальто киеп килгән идем, катып үлә яздым,— дип көлә ул.— Әле дә ярый, яңа танышларым киез итек табып бирде. Тик менә борын туңып җәфалады, суыкка күнекмәгән, чыныкмаган бит ул!

Башта Чаллыга Александра Валентиновнаның ире Игорь Владимирович килгән. Ул кием кисүче, Закарпатьеда бик кадерле һөнәр иясе булган, яхшы квартирда, һава-суларының шифасы һәм тау-урманнарының матурлыгы белән бөтен дөньяда дан тоткан табигать кочагында гомернең ахырынача яшәрбез, дип торганда, КамАЗ төзү турындагы хәбәр аларның күңелен алгысыткан. Дөрес, алар ташчы да, бетончы да түгел, әмма төзүчеләрнең тормышын ямьли торган һөнәрияләре.

Кием кисүче Черемисин, комсомол яшеннән чыгуына шактый еллар узуга карамастан, яшь егеттәй ашкынып, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән Чаллыга китеп барган. Ул дөрес уйлаган икән, чыннан да, төзелештә бетон, арматура турында гына уйламыйлар, кешеләрнең тормышын бизәү-ямьләндерү ягын да кайгырталар икән. Тәҗрибәле кием кисүчене кочак җәеп каршы алганнар, иң яхшы ательега эшкә урнаштырганнар, тулай торакта урын биргәннәр. Бер айдан аның янына Александра Валентиновна килгән.

Урамнардан үткәндә пөхтә, матур киенгән хатын-кызларның берничәсенә ымлап, тегүчебез:

— Мин теккән пальто,— ди икән.— Ничек? Мондагы кешеләрне гөл кебек киендерәчәкбез әле. Кибетләрдә тукымаларның менә дигәннәре тулып ята.

Ул шунда ук хатынын Разия янына алып килгән.

Яңа урында иң элек кем белән танышуың, нинди сүз ишетүең бик мөһим бит. Беренче таныш кадерле була, беренче очрашу гомер буе онытылмый.

Разияның мөлаем елмаюы, йомшак тавышы, җылы сүзе Черемисиннарны чиксез куандырган. Гомуми рух күтәренкелеге, киләчәккә яшьләрчә якты өметләр баглап яшәү, үзеңне бик кирәкле кеше итеп, кодрәтле кеше итеп тою Александра Черемисинага да бик тиз йоккан. Аның башында мең төрле план:

— Егетләр-кызлар татар, рус, белорус, башкорт көйләрен җырлыйлар. Мин аларга Закарпатье көйләрен өйрәтәм әле. Ул якларның матурлыгы турында сөйләргә уйлыйм, тау чәчәге — эдельвейс күрсәтермен, эдельвейс алып килдем мин Чаллыга!

Разия тыныч кына тыңлап утырган кебек, әмма аның канәгатьлеге йөзенә чыккан. Һәр кеше биргә үз милләтенең җырын-моңын, туган-үскән якларының гүзәллеген күңелендә саклап алып килә икән — үсеп килгән каланың рухи хәзинәсенә яңа асылташлар өсти дигән сүз. Нәкъ менә шундый янып-көеп йөрүчеләр кирәк тә мондый эштә, дәртле-картаймас күңелләр кирәк тә!

Александра Черемисина элек тә тәрбияче булып эшләгән, осталыгы сизелеп тора.

— Кызлар белән бер «хуҗабикә кичәсе» үткәрергә булдык әле,— ди ул.— Модалар карарбыз, ничек бизәнергә, кайчан нинди исләмайлар сөртү килешкәнен сөйләрбез...

Әйе-әйе, ташчы, штукатур, бетончы кызлар исләмайларның хикмәтле серләрен дә белергә телиләр.

Черемисиннар икесе дә иртәдән кичкә хәтле эштә. Игорь Владимирович та эш сәгатьләрендә генә өлгерә алмый, аңа заказлар бик күп. Әле менә төзүче егетләр җыр-музыка ансамбле оештырганнар, аларга күз явын алырлык костюмнар тегәргә кирәк.

Яшьлек яңадан әйләнеп кайтты аларга. Кичләрен «свиданиегә» баралар, якты урамнардан йөргән башка парлар кебек, киләчәккә планнар коралар.

— Урманнар бик ямьле, диләр, монда. Көннәр бераз җылыткач та барырбыз әле.

— Квартирны яңа шәһәрдән сорарбыз, анда бигрәк матур.

Аннары туганнарын да бу якка тарту турында уйлыйлар. Бер туганнары төзүче, килсен, үзен сынап карасын. Аның хатыны — авиатор. Яңа аэропортта эшләр.

— Кешенең эшен бик тиз күрәләр монда,— ди Игорь Владимирович.— Кулыннан эш килердәй кеше тиз күтәрелә.

Ә иртәгесен Александра Валентиновна тагын Разия янына йөгерә, чөнки ул аны иң якын дустыдай, туганыдай якын күрә.

* * *

Безнең һәркайсыбызда, теләсәк-теләмәсәк тә, туган-үскән, гомер иткән якларның үзенчәлеге, чагылышы сизелә. Ул безнең телебездә, холык-фигылебездә, кием-салымыбызда, гадәтләребездә. Шуңа күрә Мәскәү кешесе Ташкентныкыннан, Арча кешесе Сарманныкыннан аерылып тора.

Ә Чаллы кешесе, үсеп килгән яңа каланың гражданины нинди? Ул кайсы яклары белән башка шәһәр кешеләреннән аерыла? Моны әле хәзергә әйтеп булмый. Дөрес, Чаллыда зур төзелешкә хас рух күтәренкелеге сизелә, биредә кешеләр шат йөзле, нык адымлы. Ләкин ул гына әле кала гражданинының үз йөзе бар дияргә нигез бирми бит. Кала гражданины формалашсын өчен төрле яклардан җыелган кешеләрнең дуслашуы-туганлашуы, яңа гадәтләр, йолалар туу, бигрәк тә килгән кешеләрнең бу шәһәрне үз туган-үскән яклары кебек газиз, кадерле күрүе кирәк.

Кала салу — ул урам-урам яңа йортлар төзү генә түгел, каланың яңа гражданнарын тәрбияләү дигән сүз дә. Ә бу эштә — яңа каланың яңа гражданнарын тәрбияләүдә — тулай торак тәрбиячеләренең роле бик зур.

Шуннан соң инде тагын бер сорау туа: тәрбияче үзе нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

Бу турыда Разия бик күп уйланды. Ул үз тәҗрибәсеннән, башкалар эшен күзәтүләрдән чыгып, бик мөһим берничә нәтиҗә ясады.

Мәгълүм ки, тулай тораклар өчен тәрбиячеләр әзерли торган махсус уку йортлары юк. Бу эшкә гадәттә педагоглар яки культура-агарту белеме булган кешеләр алына. Тәрбияче педагог та, культура-агарту эшчесе дә булырга тиеш. Ләкин укытучылар бу эшне авыррак башкаралар, культура эшчеләренә ул җиңелрәк бирелә. Алар үз тирәләренә кешеләрне ансатрак җыялар, яшьләр белән тизрәк дуслашалар.

Ирләргә караганда хатын-кызлар тәрбия эшен уңышлырак алып баралар. Тәрбиячелең эше тавык чүплән бетермәслек күп, аның «ваклары», күзгә күренми торганнары да шактый, өстәвенә, алар даимилекне, түземлелекне таләп итәләр. Моңа ир-атның сабырлыгы җитми. Аннары шунысы: тулай торакларда бәйрәм-тантаналар, туйлар, туган көн табыннары булып кына тора. Күпләр андый бәйрәмнәрдә тәрбиячелең урыны түрдә булырга тиеш дип саный. Ихлас күңелдән чакыралар, үтереп кыстыйлар. Ир йөрәге ничек түзсен? Кайберәүләр түзә алмый, бәхетләләр исәнлегенә күтәрә бокалны. Андыйларның абруе шул бокалдагы хәмергә батып кала.

Өстәвенә, хатын-кыз булмаган йорттан гомумән кот кача бит. Күрәсең, бу кагыйдә тулай тораклар өчен дә дөрестер.

Ярый, тәрбияче булырлык кеше табылды, ди. Разия аның белән кара-каршы утырып сөйләшә.

Эшне нидән башларга? Алдарак без Разияның ике тулай торакта ничек эш башлаганын күргән идек инде. Лида Гыйбадуллина исә кешеләр белән үзенчә танышкан: бүлмәдән-бүлмәгә йөреп, һәрберсе белән сөйләшеп чыккан, һәркем турындагы мәгълүматларны калын дәфтәргә язып барган. Шул ук дәфтәргә кечке мәктәпкә йөрүчеләргә ничек ярдәм иткәнен, кемнәрне институтка әзерләү курсларына урнаштырганын, һәрберсенең җәмәгать эшләренә ничек катнашуын терки барган.

Ә күпләр эшне күңелле кичә үткәрүдән башлыйлар.

Күрәсез, монда катгый кагыйдә юк, эшкә һәркем үзенчә керешә.

Сөенечкәдерме, көенечкәдерме — тәрбиячеләрнең кулында эшнең ныклы тәртибен күрсәткән программа юк. Шуңа күрә бу эш һәр кешенең сәләтенә, инициативасына, көченә бәйле.

Аларга ярдәм йөзеннән оештырылган мәктәпнең дәресләре ай саен даими үткәрелә. Анда культура-агарту эшчеләре дә, җәмәгатьчелек вәкилләре дә, тәзелеш җитәкчеләре дә чыгыш ясый. Тәҗрибә уртаклашу өчен Разия Тольятти тәрбиячеләре белән дә тыгыз элемтә булдырды.

Тәрбиячеләр өчен методик кабинетлар булдырылды. Һәр ай өчен үрнәк план төзелә. Дөрес, ул планны һәркем үзенчә үзгәртә, тулыландыра ала, ләкин ул тәрбиячеләрнең эшендә зур ярдәм итә. Тулай тораклар бер-берсе белән ярышалар, ул ярышка нәтиҗә ясалып, алдынгыларга бүләк бирелеп тора. Тулай торакларның күбесендә яшьләр клуб оештырдылар. Аларны үзләренчә атадылар: «Аленушка», «Хуҗабикә», «Глобус», «Ватан сакчысы», «Дускаем» һәм башкалар. Бу исемнәрдән күренгәнчә, аларның һәркайсы үзенчә эшли: берсендә төрле илләрнең тормышын, төрле халыкларның сәнгатен өйрәнәләр, икенчесендә табын әзерләү, кунак сыйлау серләренә төшенәләр, өченчесендә армия хезмәтенә әзерләнәләр.

Егетләрне армиягә озату кичәләрен тасвирлау өчен аерым бер очерк язарга кирәк булыр иде. Ул кичәләрнең девизы да ни тора: «Илне уяу саклагыз, ә без сезне сагынып көтәрбез». Армиягә киткән

егетләр белән алар эшләгән бригадалар хат алышып торалар. Үзе озаткан егетләрне Чаллы көтеп ала. Узган елны хезмәтен тәмамлап, өч йөз егет кайтып төшкән иде, аларны кадер-хөрмәт белән каршы алдылар, төзелеш мәйданнарына алып бардылар, махсус пароход яллап, Кама буйларында йөрттеләр. Яшьләр төзелешне генә түгел, бу якларның табигатен дә күрсен, яратсын өчен эшләнде бу. Чыннан да, бу сәяхәт күпләрнең күңелендә матур истәлек булып калды. Яр буендагы урманнар, болыннар, кичке елганың моңсу сафлыгы, палубада солдатларның җыр-биюләре тиз генә онытылмас.

Тәрбия эше тулай торакларның стеналары белән генә чикләнми. Күтәрелеп килгән завод корпусларыннан ерак түгел вагоннардан торган поселок бар. Разия аларны да игьтибардан читтә калдырмады. Анда кызыл почмак ачуга, кичәләр, әңгәмәләр үткәрүгә иреште.

Узган кышны КамАЗга ярдәмгә йөзләгән авыл эшчәннәре килгән иде. Аларны тирә-як авылларга урнаштырдылар. Разия анда да өлгерде, авыл кибетләренең ничек сату итүен, клубларның кайчан ачылуын тикшереп йөрде, эшчеләр белән сөйләшеп, төзелеш җитәкчеләренең чыгышын оештырды.

Дөрес, бу эшләрне Разия үзе генә башкармый, аңа берәүнең генә көче дә җитмәс иде, ул аларны уйлап таба, кешеләрне кызыксындыра, оештыра белә.

* * *

Кайчак кеше урман эчендә агачны, халык арасында кешене күрми. Йөзләрчә, меңнәрчә кешеләр турында кайгыртканда, аерым берәүләрнең язмышына битараф булып калмыймы соң Разия?

Менә аның янына яшь кенә хатын килеп керә. Хатынның йөзе сагышлы, күзләре дымлы.

— Ирем белән аерылыштык,— ди ул.— Әйберләрне бүлешергә ярдәм итсәгез иде.

Разия сак кына, әкренләп барысын да сораша. Аннары хатынның өенә бара. Бер генә түгел, берничә тапкыр бара. Ни сөйләшкәннәрдер, нинди киңәш биргәндер Разия ир белән хатынга — анысы өчесе арасында сер булып калды. Тик әйбер-кара бүленмәде, гаилә таркалмады. Берничә айдан әлеге хатын Разия янына тагын килде, бу юлы аның йөзе бәхеттән балкый иде, ул мең рәхмәтләр укып китте.

Улыннан зарланып ана килә.

— Сүземне тыңламый, эшкә керми, укырга йөрми,— ди.

Тагын китә Разия. Малайны эшкә урнаштыра, кичке мәктәпкә кертә, соңыннан айлар буе ничек эшләгәнен, ничек укыганын тикшереп тора.

Разия Хөсәенова — Чаллы шәһәр Советы депутаты. Киңәш-табыш итәргә, аһ-зарын сөйләргә аның янына үз сайлаучылары гына түгел, шәһәрнең төрле урыннарында яшәүчеләр килә. Чөнки беләләр: Разия аларның хәлен аңлар, ярдәм итәргә көчен дә, вакытын да кызганмас.

— Аның тирәсендә кеше артыннан юк-бар сүз сөйләп йөрү, гайбәт ише нәрсә юк,— диләр Разия турында.— Күңелендәген ачыктан-ачык, курыкмыйча сөйләп була.

— Кычкырмый, ачуланмый, ә сүзен тыңлата белә. Ул кушканны эшләми калып булмый.

— Ничек барысына да җитешә ул? Каян көч таба?

Андый тынгысыз кешенең борчулары, эше күплеге йөзенә, бөтен кыяфәтенә чыккан булырга тиеш иде кебек. Әмма Разияның сөйлә-

шуеннән, елмаюыннан, иркенләп-җәйләп утыруыннан ук җан тынычлыгы, күңел көрлеге бөркелеп тора. Бәхетле икәне йөзенә чыккан аның. Аның бәхете көнләштерми, сокландыра, борчулы кешеләрне дә юата, тынычландыра.

Татар хатыннарына хас бу гүзәл сыйфатлар — мөлаемлык, сабырлык, яшәү ямен тою — Разияга мул итеп бирелгән. Абакан—Тайшет тимер юлын төзегәндә туган улы Алмаз инде буй җиткән егет булып килә, ул әти-әнисенә куанычлар китерә: яхшы укый, спортның күп төрләрен ярата. Дөньяга карашы киң Алмазның, әле менә классташлары белән Минск шәһәрендә булып кайтты, Кавказ егетләре белән хат алыша.

Сарман районы, Азалак авылы кызы Разия, культура-агарту училищесын тәмамлагач, берәр клубта мөдир булып эшләсә, аның клубы гөрләп торыр, ә үзе сөйкемле хатын буларак макталыр иде. Анда ул бер авыл яшьләренә файдалы эш башкарыр иде.

Ләкин Сәгыйть белән алар икесе дә үзләрен зуррак мәйданда сынап карарга теләделәр, Абакан—Тайшет тимер юлын төзергә киттеләр. Разия анда үзен яхшы, актив комсомолка итеп танытты.

Яңа тимер юлдан поездлар йөри башлагач, аларның күңеле тагын да зуррак мәйданга ашкынды. Ангара буена, Братск гидроэлектростанциясе төзелешенә башта Сәгыйть китте, берәр айдан гаиләсен чакырды: «Карурман уртасында палаткада яшим, мине аю тотып ашамасын дисәгез, тизрәк килеп җитегез».

Сигез ел да сигез көн эшләде Разия Братскида. Күп милләт балаларын тәрбияләде, әмма үзенең татар кызы икәнен беркайчан да онытмады. Анда алган мактау кәгазьләре — тулы бер папка, алар арасында аеруча кадерле берсе бар: аны Разияга, калфак һәм татар кызы күлмәге киеп, Муса Җәлил шигырьләрен саф ана телендә сәхнәдән укыган өчен биргәннәр иде. Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча оештырылган укучылар конференцияләре дә гөрләп тора иде.

Братскида Разия үзенең талантлы тәрбияче икәнен исбат итте.

Чаллыда Разия Хөсәеновaның бөтен мөмкинлекләре, оештыру сәләте тулысынча ачылды.

* * *

Төзелештә тулы бер гомер үткән кебек. Разия беренче килгән чакта актарылган җир булган урыннарда ап-ак кала һәм завод корпуслары үсеп чыкты.

Ә кешеләр язмышында күпме үзгәрешләр булды?

6/12 нче тулай торакның бер бүлмәсендә өч егет яшиләр иде: Рузалин Фәтхуллов, Рамил Сәйфуллов, Шәфигулла Наскаев. Рамил белән Рузалин инде гаилә төзеделәр, янәшә бүлмәләрдә уллар үстерәләр. Рузалин институтка керергә әзерләнә, Рамил техникумда укый. Шәфигулла армиядә, дуслары белән хат алышып тора.

Үзгәрешләр күп, бик күп. Ә бит Разияның Чаллыга килгәненә күпме генә гомер үтте әле — нибары ике ел ярым.

Менә тагын яз җитте. Каеннар яфрак яра, урман аланнары чәчәккә күмелә.

Разия Ангара буе урманнарында күз явын алып торган утлы чәчәк — жаркины, көньяк далаларының кып-кызыл тюльпаннарын исенә төшерә.

Хатирәләргә, вакыйгаларга, чәчәкләргә бай аның тормышы.

**Сәлам Алишев,**
тарих фәннәре кандидаты

# КНЯЗЬ ЙОСЫФ ЕНГАЛЫЧЕВ ҺӘМ БАШКАЛАР

*Бөгелмә ягы крестьяннарының Пугачев восстаниесендә катнашулары турында*

Казан ханлыгы чорында, бигрәк тә 1552 елда Казан дәүләте бетерелгәч, байтак татар князьләре һәм морзалар рус феодал хөкүмәте хезмәтенә килә. Аларның шактый өлеше христиан диненә күчә һәм дворяннарга әверелә. XVI—XVII йөзләрдә хөкүмәт рус булмаган князь һәм морзаларга да, хезмәтләре өчен җир, акчалата түләү һәм башка льготалар биргән. Хөсәенов, Тенишев, Мансуров, Шейдяков кебек князьләр, Хуҗашев, Яушев, Сөендеков, Дәүләткилдеев кебек морзалар ул вакытта шактый булган. Алар кул астында күп кенә крепостной крестьяннар эшләгән. Ләкин рус дворяннары беренче вакытларда христиан динендә булмаган алпавытларга бераз ирек бирсәләр дә, соңрак аларны үзләренең союзнигы, тиңдәше итеп карарга теләмәгәннәр. Христиан диненә күчәргә мәҗбүр итү, ә чукынмаганнарын кысрыклап чыгару политикасы алып барылган. XVIII гасыр башында, Петр I патшалык иткән вакытта, рус булмаган крепостникларны бетерү аеруча көчәйгән. Татар феодалларының җирләрен чиновниклар, алпавыт һәм монастырьлар үзләренә тартып алганнар. Ә элеккеге князьләр һәм морзалар экономик яктан вак крестьян хуҗалыгыннан әллә ни аермасы булмаган хуҗалык алып бара башлаганнар. Шул вакытта инде татарлар арасына «чабаталы морза» дигән атама кергән. Әмма князьләр һәм морзалар утарларын югалтсалар да, үзләренең нәсел-нәсәпләрен онытмаганнар, рус алпавытларына бирелгән льготалар һәм хокуклар белән файдалануны таләп иткәннәр, хөкүмәткә каршы оппозициядә торганнар. Менә шуның өчен алар сыйнфый көрәшнең кискенләшкән моментларында, крестьян массасыннан аерылмыйча, хөкүмәткә каршы күтәрелешләрдә катнашалар. Бу хәлне без Степан Разин, Емельян Пугачев җитәкчелегендә күтәрелгән крестьян сугышы елларында да күрәбез. Пугачев восстаниесе вакытында баш күтәргән крестьяннар үзләренең башлыклары итеп абруйлы кешеләрне сайлап куя торган булалар. Йосыф Енгалычевны да Бөгелмә өязе Абдулла авылында 1773 елның декабрь аенда баш күтәргән крестьяннар сотник итеп сайлап куялар.

Йосыф Енгалычев Зөя өязендәге авылларның берсендә гвардия подпоручигы князь Енгалычев семьясында туып үсә. Бала вакытында ук әти-әнисез кала. Ятим малайны әтисенең абыйсы үзенә алып тәрбияли. Ул зирәк һәм укымышлы малай булып үсә. Князь нәселеннән булса да кәпрәйми. Хәер, кәпрәерлек мөмкинлеге дә булмый аның: әтисеннән калган җирләр, мал-туар күрше алпавытлар кулына күчә. Төрле рәнҗетүләргә каршы тавыш күтәрә башлагач, аны төрмәгә утырталар, чукынырга мәҗбүр итәләр. Төрмәдән чыккач, туган җирләрен ташлап, Бөгелмә ягына килеп урнашырга мәҗбүр була.

Тарихи документлар 1773—1775 елларда-

гы Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы Бөгелмә өязендә 1773 елның октябрь аенда ук башлануын сөйлиләр[1]. Йосыф Енгалычевның үзенең әйтүенчә, сентябрь азагында Бөгелмә ведомствосы Бутерьма авылы урамында сәүдәгәр татарлар Җаек елгасы буенда патша Петр Федоровичның пәйда булуы турында сөйләгәннәр. 17 сентябрьдә Җаекта башланган Пугачев восстаниесе турында хәбәр Идел—Урал якларында бик тиз тарала.

Октябрь аенда Бөгелмә тирәсендәге авыллар Оренбург янында хәрәкәт иткән Пугачевка үзләренең вәкилләрен җибәрәләр. Алар арасында Абдулла авылы крестьяны Тимербулат Уразмәтов, крепостной Степан Синебрюхов, Муса Мостафин һ. б. лар була. Тимербулат октябрь аенда Берда (Оренбург янында Пугачев урнашкан урын) бистәсенә барып, анда бер-ике атна торган, дәүләт хәрби коллегиясендә булган. Ноябрь аенда авылына кайтып, крестьяннарга ул болай дип сөйләгән: «Оренбург янында чыннан да патша император Петр Федорович хәзрәтләре торыр, мин аның каршында булдым, ул миңа кафтанлык сукно бүләк итте. «Өеңә кайт һәм миңа хезмәт итәргә теләүче кешеләрне үз яныңа җый», дип әмер итте».

Пугачевның мондый әмерләрен крестьяннар бик тиз үтиләр. Аит Уразмәтов та, энесе Тимербулат белән, кыска вакыт эчендә Абдулла һәм башка авылларның ясаклы татар крестьяннарыннан 200 кешелек отряд оештыра.

Икенче бер крестьян Степан Синебрюхов үзенең малае белән Пугачев янына барып кайткач, ноябрь аенда «команда җыя» һәм алпавыт икмәген Пугачевка җибәрергә әзерләнә. Әмма алпавыт утарын сакларга чакыртылган солдатлар аның отрядын тараталар. Бу отряд соңыннан депутат Давыдовка барып кушыла. Ә Давыдов Енгалычевның дусты, көрәштәше була һәм аның белән «татар авылына бик күп татар һәм башкорт крестьяннары тупланган җиргә бара». Бөгелмә ведомствосы Спасск авылы крепостной крестьяны Гаврила Иванов әйтүенә караганда, анда хәлләр түбәндәгечә булган: «Рождестводан шактый элегрәк безнең авылга татар Муса Мостафин җитәкчелегендә җиде йөздән артык бик күп татар һәм башкортлар килде. Алар бездән: «Кемгә ышанасыз?» — дип сорадылар һәм аннан соң крестьяннарга сөңгеләр өләштеләр. Хәрби командаларны авылга кертмичә каршы алып сугышырга куштылар. Соңыннан алпавыт утарын туздырдылар».

Муса Мостафин отряды хәзерге Баулы районы территориясендә — Кандыз, Сайтангул, Дмитриевка, Спасск авыллары тирәсендә — хәрәкәт иткән. 1773 елның декабренда Мостафин Пугачев янына барган. Пугачевның дәүләт хәрби коллегиясе аңа шундый указ биргән: «Үзенең Бөгелмә янында урнашкан командасына кайтырга һәм граф Чернышев килгәнчегә кадәр анда торырга; ул анда корпусы белән килеп җиткәч, Чернышев карамагында булырга... Бөгелмәдә торучы дошманнарга каршы сугышу өчен күпме кеше кирәк булса, һич карышусыз, коралны кешеләр белән ярдәм итәргә». Муса Мостафин шундый указ алгач, Бөгелмә тирәсендә баш күтәргән крестьяннар белән гомуми җитәкчелекне үз кулына алырга тырышкан. Екатерина II нең 1767 елны җыйган комиссия депутаты пугачевчы Давыдов белән урындагы властьны бүлешкән; татар һәм башкортларны үз отрядында калдырып, русларны Давыдовка җибәрә торган булган.

Шул ук вакытта бу якларда баш күтәргән крестьяннарның Чернеев, Попов җитәкчелегендәге отрядлары да хәрәкәт иткән. Гомумән, 1773 елның көзендә Бөгелмә ягында баш күтәргән крестьяннарның 15 мең кешедән торган уннан артык отрядлары, утызлап туплары булган.

Билгеле булганча, крестьяннар армиясенең төп көчләре хөкүмәт тарафыннан җибәрелгән генерал Кар армиясен 8—9 ноябрьда Бөгелмә белән Оренбург арасындагы Мостафа һәм Юзәй авыллары янында тар-мар итәләр. Генерал Кар җиңелгән гаскәрен ташлап качып киткәч, хөкүмәткә турылыклы булып калган гаскәрләр белән генерал Фрейман Бөгелмәгә кереп урнаша. Фрейман Бөгелмәдә бөтен властьны үз кулына ала. Йосыф Енгалычев тикшерүчегә биргән күрсәтмәләрендә үзенең Бөгелмә воеводасы Иван Кирьянов янына баруы һәм аңардан Пугачевның чын императормы, түгелме икәнлеге турында сорағанлыгын сөйли. Ә бәлки ул аны восстаниечеләр ягына чыгарга өндәгәндер, чөнки аңа воевода: «Төкер син ул самозванецка», — дип җавап бирә. Кирьянов турында

[1] Мәкаләдә Борынгы актлар үзәк Дәүләт архивы (БАҮДА) материаллары файдаланылды.

безгә башка нәрсә билгеле түгел. Ләкин бу факт Енгалычевның Бөгелмәдә генерал Фрейманга, ә бәлки әле генерал Карга кадәр үк булуы турында (ягъни октябрьда үк) сөйли. Бөгелмә ул вакытта 500 йортлы, 2 чиркәүле шәһәрчек булган. Ныгытып корылган контора һәм воевода йортлары аерылып торганнар. Бөгелмәдән Бутерьмага кайткач, өендә аңа хатыны: «Сине күрше авыллардан эзләп килгәннәр иде. Үзләренең сотниклары итеп сайлап куярга телиләр», — дип әйткән. Йосыфның әйтүе буенча, аны восстаниечеләргә кушылырга Абдулла авылы мулласы Багдай да димләгән. Мулла Багдай: «Император хәзрәтләре аңа Бозаулык крепосте хорунжие Иван Чернеевка да 10 йорттан бер кешене патша хезмәтенә җыярга кушкан, син дә аңа хезмәткә бар, чөнки ул чын патша хәзрәтләре; гади кара халыкны күп җәберләүче алпавыт-түрәләрне һәм попларны асарга указ биргән», — дип сөйләде, ди ул. Бу шулай булырга мөмкин, чөнки XVIII гасырда күп муллалар авыл крестьяннары арасыннан укымышлылыкларына карап сайланып куела торган булганнар, хөкүмәткә төрле налогларны крестьяннар белән бер тигез түләгәннәр. Христиан диненең кысрыклавы нәтиҗәсендә авыл муллаларының хөкүмәткә булган оппозициясе тагын да көчәйгән. Ләкин, әлбәттә, югарырак күтәрелгән ахун, ишаннар, зур муллалар крестьяннарның бу чыгышларына каршы булганнар, аңа каршы көрәш алып барганнар.

Кыскасы, Енгалычевның восстаниегә кушылып китүе Бөгелмә крестьяннары арасында әнә шундый сыйнфый күтәрелеш башланган чорда булган.

Отряд командиры булып сайлангач ук, башка командирларның киңәше һәм ризалыгы белән, Йосыф Енгалычев күрше авылларны восстаниегә күтәрү өчен чыгып китә. Ул хәзерге Татарстан АССРның көньяк районнарындагы күп кенә авылларында булып, Пугачевның ирекә чакырып язган, җир һәм башка байлыклар вәгъдә иткән манифестларын укый. Бөгелмә ведомствосыннан чыгып, ул Ставрополь өязе авылларында да була. Аның күрсәтүләре буенча, мәсәлән, ул отставкадагы капитан Мальковскийның крестьяннарны бик нык рәнҗетүләрен ишетә һәм 3 крестьян җибәреп аны үз янына китерттерә, бик каты кисәтә. Дәүләзәр авылына килгәч, чуваш крестьяннарын җыеп, государь Петр Федоровичның ихтыярын халыкка җиткерә. Крестьяннарның сораулары нигезендә попның җирләрен һәм бөтен байлыгын халыкка бүлеп тарата.

Енгалычев Дәүләзәрдән юл күрсәтүчеләрне генә алып, үз отряды белән көнбатышка юнәлә. Ул юлдагы авылларда крестьяннарны баш күтәрергә, урындагы эксплуататорларны юк итәргә өнди. Аның 200 кешелек атлы отряды зур урманнар, киң кырлар аша үтә.

...Башка авыллардагы кебек үк, Биләр күл авылында да мәйдан тулы халык җыела. Шау-гөр киләләр, хәл-әхвәл сорашалар, бер-берсе белән танышалар. Йосыф Енгалычев, арба өстенә басып, халыкны татарча да, русча да Пугачев манифесты белән таныштыра. Аннары нинди үтенечләре, теләкләре барлыгы турында сораша. Авыл кешеләре монда да үзләренә җибәрелгән поптан зарланалар. «Безнең поп Иван Степанов халыкны талый, тормыш итәргә бирми», дип, ачулы тавышлар белән кычкыралар. Авыл халкының бердәм таләп итүе буенча, Енгалычев попны мәйданга чакырта. Петр Федоровичны патша итеп танымагач, халыкка, «сез караклар», дип кычкыргач, ул Иван Степановны чиркәү ишегалдындагы агач ботагына асарга боерык бирә. Крестьяннар бу әмерне берничә минуттан җиренә җиткерәләр.

Енгалычев отряды Бөгелмәдән хәзерге Татарстан АССРның Әлки районына кадәр килеп җитә. Ул узган җирләрдә халык изүчеләргә каршы күтәрелә, җирле отрядлар алпавыт утарларын туздыра, власть вәкилләрен кулга ала. Мәсәлән, 1773 елның декабрендә Кәкре күл авылы алпавыты Матюнинның крепостной крестьяны Герасим Владимиров 3 иптәше белән баш күтәрүчеләргә кушыла һәм тиздән алар 200 кешелек отряд булып оешалар. Кәкре күлдән ике чакрым ераклыкта булган Матюнин һәм Змейкиннарның утарлары тар-мар ителә.

Енгалычев әнә шундый зур территориядә баш күтәрергә өндәп йөргәндә Бөгелмәнең үз тирәсендә хәлләр түбәндәгечә була. Хөкүмәткә турылыклы гаскәрләрнең төп өлеше Бөгелмәнең үзендә ныгып урнаша. Генерал Фрейманга буйсынган капитан Шишкин Рәҗәп авылында, секунд-майор Тәвкилев Нагайбәк — Акбаш тирәсендә, ә отставкадагы солдатларны җыеп, Казан губернасының көньяк чикләрен саклаучы генерал Миллер Чирмешән крепостенда була. Ә баш күтәргән крестьян-

нар: депутат Гаврила Давыдов житәкчелегендәгеләре — Суровцево авылына, Муса Мостафин отряды Кандыз, Сайтангул авылларына, Аит Уразмәтов командасы Маклауш авылына урнашалар.

Капитан Шишкин Рәҗәптән һәм тирә-яктагы башка авыллардан хөкүмәт гаскәрләре өчен азык-төлек, фураж җыя. Кырык олаудан торган обоз төзеп, ул аларны конвой белән Бөгелмәгә җибәрә. Ләкин крестьяннар разведкасы яхшы эшли — бу турыда үз вакытында Аит Уразмәтовка җиткерәләр. Уразмәтов тиз генә обозга һөҗүм итә. Бәрелеш вакытында өч ат, бер кеше үтерелә, конвой башлыгы офицер кулга алына. Бу офицер атаман Уразмәтов әмере буенча Маклауш авылында асып үтерелә. Талап җыелган азык-төлекне халыкка таратталар. Баш күтәрүчеләрнең шундый уңышларын ишетеп Уразмәтов янына депутат Давыдов та килә. Бу вакытта алар кул астында өч мең кешелек гаскәр, ике туп була. Алар, җыен җыеп, Рәҗәп авылында торган Шишкин командасына каршы һөҗүм итәргә дигән карарга киләләр. Икенче көнне хөкүмәт гаскәрләре белән крестьян отрядлары арасында сугыш була. Ләкин ул бер якка да җиңү китерми. Сугыш эшен белмәгән, дисциплинага өйрәнмәгән крестьяннар хөкүмәт гаскәрләреннән өстен чыга алмыйлар. Давыдовның күрсәтүләренә караганда, ул сугыш кырына соңгарып килгән һәм шуның өчен Уразмәтов аны әләкләп Пугачевка хат язган. «Караңгы төшкәч, без сугышны туктаттык. Үлүчеләр күп булмады», дип сөйләгән ул. Аит Уразмәтов исә: «Икенче көнне... кешеләрне өйләренә җибәрдек, ә депутат үзенекеләр белән Сок-Карамалы авылында урнашты»,— дигән. Монда «кешеләрне өйләренә җибәрдек» дигәннән крестьяннар тирә-як авыллардан булганлыгын, аларның өйләреннән еракка аерылмаганлыгын, көндез сугышып, кич өйләренә кайтуларын аңларга кирәк. Шулай да отрядларның төп көчләре таралмаган, алар, командага оешып, һәр вакыт җитәкчеләре белән бергә булганнар. Соңыннан допрос вакытында Давыдов: «Без барыбыз да бер фикердә идек, әгәр кайда да булса хөкүмәт гаскәрләренең һөҗүме турында ишетсәк, бер-беребезгә ярдәм итешә идек»; Уразмәтов: «Ташлы авылында минем һәм Чернеев командасында татарлар, чувашлар, мордвалар, һәм руслардан җыелган 900 дән артык кеше бар иде. Аларга азык, ә атларга фуражны тирә-як авыллардан ала идек, чөнки кешеләр барысы да безнең белән бер фикердә иде»,— дип күрсәткән.

Ташлыдан Уразмәтов һәм Чернеев Оренбург янына Шишкин белән булган сугыш турында Пугачевка реляция белән безгә таныш Тимербулат Уразмәтовны һәм Аитның улын җибәрә. Аит үзе 56 яшендә булгач, аның улы да өлгереп җиткән кеше, крестьяннар армиясенең лаеклы сугышчысы булгандыр. Пугачевчылар Бердада һәм Каргалыда вәкилләрне яхшы каршы алалар, баш күтәрүчеләрнең үзәк штабында — дәүләт хәрби коллегиясендә алар белән әңгәмә үткәрәләр, урындагы хәлләр турында сорашалар, Пугачев үзе дә алар белән сөйләшә. Бөгелмә тирәсендәге крестьяннарга ярдәм итәргә вәгъдә бирәләр. Аит Уразмәтовны Пугачев старшина дәрәҗәсенә күтәрә.

Татарстанның көньягы 1773 елның ахырына кадәр тулысынча диярлек восстаниечеләр кулында булган. Генерал Кардан калган хөкүмәт гаскәрләре восстаниечеләр белән берни эшли алмаганнар, алар үзләре крепостьларга бикләнеп крестьяннардан сакланырга мәҗбүр булганнар. Бөгелмәдә генерал Фрейман баш күтәрүчеләр тарафыннан камалып алынган. Аның ярдәмчесе Тәвкилев Бөгелмәдән ерак түгел Кырым-Сарай авылы янында пугачевчы крестьяннар тарафыннан үтерелгән. Гәүдәсен Бәйрәкә авылы татар байлары үзләренә алып кайтып күмгәннәр. Шишкин Рәҗәп авылыннан китеп Бөгелмәгә качарга мәҗбүр булган. Генерал Миллер, отставкадагы солдатлар командасы белән, шулай ук берни эшли алмыйча, Чиремшән крепостена һәм Кичуй ныгытмасына бикләнеп яткан. Болар барысы Пугачевның Оренбург янындагы төп армиясенә зур ярдәм була, хөкүмәт гаскәрләре җирле баш күтәрүчеләр тарафыннан тоткарлана, хәлсезләнә, хөкүмәтнең крестьяннар восстаниесенә каршы эшчәнлеге зәгыйфьләнә.

Хөкүмәт гаскәрләренең шундый хәлдә торулары Енгалычевка да походтан тулы обоз белән исән-сау өйләнеп кайтырга мөмкинлек биргән. Барганда да, кайтканда да аңа хөкүмәт гаскәрләренә каршы сугышырга туры килмәгән.

Йосыф Енгалычев тиздән Чиремшән крепостеннан 25 чакрым ераклыкта Аит Уразмәтов һәм Чернеев отрядлары белән кушыла. Бу вакытта аның кул астында поход-

та йөреп чыныккан, тәртипкә өйрәнгән отряд (кешеләр саны һәм кораллары билгесез), 10 олаудан торган обоз булган. Обозын ул башка командирларга да бүлеп бирә. Аит Уразмәтов кул астында бу вакыт 900 кеше, 5 туп була. Йосыф Енгалычев кайткач, көчләр арта, инде хөкүмәтнең зуррак көчләренә, регуляр гаскәрләргә каршы да ачык сугышка чыгарга мөмкин булып тоела.

Командирлар киңәшмәсендә мондый карарга киләләр: Чиремшән крепостенда торучы генерал Миллерга хат язып, сугышсыз бирелүен таләп итәргә һәм Чиремшән крепостен восстаниечеләрнең үзәк урнашу пунктына әйләндерергә; Пугачев янына яңадан Тимербулат Уразмәтовны җибәреп, крестьян армиясе төп көчләреннән мөмкин булган ярдәмне: туплар, ядрәләр, дары һ. б. сугыш кирәк-яраклары сорарга, шулай ук инструкция һәм киңәшләр алырга; вәкил кайтканчы сугыш хәрәкәтләрен башламый торырга. Тимербулат тиз генә Оренбург янына үзәк штабка барып кайта. Ул алып кайткан указда хөкүмәт гаскәрләренә нык каршы торып, аларны Оренбург ягына җибәрмәскә кушыла, аларның «Патша Петр Федорович» кайгыртуыннан һәм ярдәменнән бер вакытта да игътибарсыз калдырылмаячаклары турында язылган була. Шул указ белән рухланып, Йосыф Енгалычев, Иван Чернеев, Аит Уразмәтов һәм Попов отрядлары берләшеп, генерал Миллер гаскәрләренә каршы походка чыгалар. Бөгелмәдән ерак түгел тоньяк-көнбатыштарак урнашкан Подлесная авылын алар үзләренең төп базалары итәләр һәм крепостька һөҗүм оештыра башлыйлар. Ләкин бу вакытта инде хөкүмәт Пугачев восстаниесен бастыру буенча зур хәрби чаралар күрә. Армиянең башкомандующие итеп тәҗрибәле генерал-аншаф, Екатерина II нең якын сановнигы А. И. Бибиков куела. Ул бер ай буена Петербургта һәм Мәскәүдә торып, төрле җирләрдән Идел—Урал краена хөкүмәткә турылыклы гаскәр, корал, башка кирәк-яраклар җибәрә, восстаниечеләргә каршы төп һөҗүмне әзерли. 26 декабрьда ул Казанга килеп җитә һәм монда да дворяннарны крестьяннарга каршы туплый: алардан ополчение төзи, халык арасында үгет-нәсихәт эшләре алып бара. Нәтиҗәдә, 1774 елның январь аенда Бибиков кул астында яхшы коралландырылган 40 кыр батареясы, 16 мең кешелек армия туплана. Казан дворяннар ополчениесе төзелеп, аның командир вазифасы генерал-майор Ларионовка йөкләнә. Екатерина II үзен «Казан алпавыты» дип игълан итә. Башкомандующий генерал-аншаф Бибиковның планы буенча, хөкүмәт гаскәрләре көнчыгышка таба трактлар буйлап киң фронт белән һөҗүмгә барырга тиеш булалар.

...Январь аеның салкын аяз көне. Подлесная авылыннан атларга атланган, чаналарга төялгән сугышчы крестьяннар тоньякта караңгыланып күренгән урманга таба юл тоталар. Җәяүлеләр дә бар, алар күбрәк туплар, ядрәләр салынган чаналар артыннан баралар. «Чиремшәннән килгән кешеләрнең, крепостьта гаскәрләр аз, карт һәм инвалид солдатлар гына, дигән сүзләре дөресме, крепость тирәсендә кар бик тирән түгелме икән?» кебек сораулар борчый аларны. Яшьрәкләр үзләренең сугышта күрсәтәчәк батырлыклары, генералның үзен кулга төшерү турында хыялланалар. Менә алар — урманда. Урман эче тын... Озакламый отряд, урманнан чыгып, кечкенә генә бер авылга килеп керә.

Менә шунда инде крестьяннар чолганып алына: як-якка да, алга да дозорлар куймаган отрядның хәрәкәтен Бөгелмәгә юнәлүче регуляр гаскәр командиры берничә сәгать инде күзәткән һәм үзенең чараларын күргән була.

Авыл уртасына туп ядрәсе төшеп шартлагач, крестьяннар өйләреннән атылып чыгалар, як-якка чабышалар. Шул вакыт Йосыф Енгалычев урам читендәге куаклыктан йөгереп килгән солдатларны күреп, үз кешеләрен шуларга каршы куя, бер төркем сугышчылар белән тупларны чанадан төшереп атар өчен уңайлы позициягә урнаштырырга тели. Ләкин отрядның язмышы инде хәл ителгән була. Кичкә таба баш күтәрүчеләр тулысынча тар-мар ителә. Аларның күбесе хөкүмәт гаскәрләре кулына әсир төшә, байтагы үтерелә, тик кайберләре генә атларга атланып урманга кереп качалар. Әсирләр арасында Енгалычев, Аит Уразмәтов, Попов та була.

Крестьяннарның Чиремшән крепостена булган походында Давыдов, Муса Мостафин һәм башка шундый пугачевчы командирлар катнашмыйлар. Аларның күбесе соңрак, хөкүмәт хәрби көчләренең Бөгелмәдән Оренбургка һөҗүм итеп баруы вакытында, я үтерелә, я әсир төшә. Енгалычевлар январь ахырында әсирлеккә төшсәләр, Давыдов апрель башында хыянәтче

старшиналәр тарафыннан тотып алына һәм Бөгелмә коменданты Кожинга китереп тапшырыла.

Февраль-март-апрель айлары, гомумән, восстаниечеләр өчен фаҗига чоры, бер-бер артлы җиңелүләр вакыты, крестьяннар сугышының беренче этабы. Хөкүмәт аларга каршы бик зур армия, Екатерина II сүзләре белән әйтсәк, күрше дәүләтләр өчен дә куркыныч тудырырлык гаскәр җибәрә. Башкомандующий генерал А. И. Бибиков бөтен көчләрен ике төп юнәлешкә: Оренбург ягына һәм Уфа тирәсендә хәрәкәт итүче Чика Зарубинга каршы һөҗүм оештыру куркынычы булган Бөгелмәгә җибәрә. 4 февральдә генерал-майор Голицын үз хәрби көчләре белән генерал-майор Фрейманга килеп кушыла. Февраль уртасында монда полковник Ю. Бибиков, аннан соң Казан дворяннар ополчениесе белән генерал-майор Ларионов килеп җитә.

1774 елның башыннан Татарстан территориясе — Казаннан Бөгелмәгә, Минзәләгә кадәр — хөкүмәт гаскәрләре кулында була: монда туктаусыз хәрби көчләр, җәза отрядлары хакимлек итә. Бу вакытта инде баш күтәргән крестьяннарга каршы үзләренә тапшырылган хәрби көчләр белән 8 генерал, дистәләп полковник һәм башка төрле махсус җәза отрядлары сугыша. Шундый вакытта Енгалычевларның да, Давыдовларның да уңышсызлыкка очраулары, таркау крестьян отрядларының җиңелүләре бер дә гаҗәп түгел.

Инде әсир төшкән крестьяннарның һәм аларның җитәкчеләре язмышларына күз салыйк.

Восстаниегә катнашкан крестьяннарны парлап-парлап арканлаганнар һәм төркеме-төркеме белән (кайбер төркемнәрдә егерме-утыз кеше, кайберләрендә алар йөздән дә артып киткән) җәза бирү өчен крепостьларга, шәһәрләргә озатканнар. Аларның күбесе юлда ук, төрле җәза-михнәтләргә түзә алмый, үлеп кала. Татарстанда Минзәлә, Зәй, Чиремшән, Бөгелмә, Биләр һ. б. шәһәрләр һәм крепостьлар җәзалау пункты булып хезмәт иткән. Казанның үзендә исә бөтен Идел — Урал краe өчен Яшерен комиссия эшләгән. Аеруча күренекле пугачевчыларны монда китереп, Казан төрмәсенә япканнар. Ә гади крестьяннарны, тикшерү башланганчы, Бишбалта бистәсендә ясалган лагерьда тотканнар. Монда алар ач-ялангач байтак вакыт хөкем көткәннәр, чөнки Яшерен комиссиянең эше күп булып, аларга чират тиз генә җитмәгән. Кайберләре шунда үлгән, кайберләрен төрле җәзаларга тартканнар, күбесе Пугачев Казанга килеп җиткәч (бу инде 1774 елның 12 июлендә булган), азат ителгән. Енгалычев кул астындагы крестьяннарның Казанга китерелүе турында белешмәләр юк. Бәлки аларны Чиремшән яки Бөгелмә крепостьларында җәзалаганнардыр, әмма аларның җитәкчеләре Йосыф Енгалычев, Аит Уразмәтов, Поповларның 2 февральдә Казан Яшерен комиссиясенә көчле конвой астында җибәрелүләре турында документлар бар. Аларны беренче допрос вакытында, аннан соң юлда каты кыйныйлар. Казан төрмәсендә газаплаулар, җәзалап сорау алулар башлана. Аит Уразмәтов, Яшерен комиссиянең карары чыгарылганчы ук, җәзалауларга чыдый алмыйча, 7 февральдә төрмәдә үлә. Бу турыда допрос протоколында: «Грамоталы булса да кул куя алмады, үлде», диелгән. Енгалычев һәм Попов турында Яшерен комиссия: «Икесен дә асарга, шуның өчен сак астында генерал Миллер карамагына җибәрергә»,— дип карар чыгара. Күренә ки: Енгалычевларның эше комиссия тарафыннан бик тиз каралган, 2 февральдә Казанга җибәрелгән крестьян командирларының берсе 7 сендә инде үлгән, ә икенчеләре 10 февральдә Миллер палачлыгына җибәрелгән. Моның сәбәбе Енгалычев кебек пугачевчыларның халык арасында бик зур абруйлы булулярында булса кирәк. Йосыф Енгалычевны Татарстанның бөтен көньяк өлеше белгән, хөрмәт иткән. Ә властьлар өчен бу, әлбәттә, куркыныч булган, алардан тизрәк котылу ягын караганнар.

13 февральдә Биләрдә әсир төшкән крестьяннарны конвой белән чолгап алып, чиркәү мәйданына китергәннәр. Генерал Миллер — әллә аларны Бөгелмәгә кадәр алып барырга шүрләгәнме, әллә Поповның элек Биләр отставной солдатлар полкында булганлыгын искә алыпмы, (гадәттә хөкем ителгәннәрне үзләре баш күтәргән урында җәзалаганнар) — 13 февральдә Биләрдә үк асарга әмер биргән. Дар агачы инде ясалган... Барабаннар кагалар... Палач хөкем ителгәннәрнең муеннарына элмәк кидерә... крестьяннар да, отставкадагы солдатлар да башларын түбән игәннәр, йодрыкларын каты йомарлаганнар... Халык әнә шулай үзенең батыр улларын соңгы юлга озаткан, алар өчен сыйнфый

дошманнан үч алуга өметләнгән. Шундый өметләрнең гамәлгә ашуын без алда телгә алган Давыдов эшчәнлегендә күрәбез. Енгалычевларның җиңелеп, әсир төшкәнлеген ишеткәч, ул тагын да киңрәк колач белән эшкә керешә, халыкны дошманга каршы оештыра. Үз кул астындагы кешеләрне коралландыруны кайгырта, отрядтагы кешеләр санын арттыра, аларның сугышчан сыйфатларын күтәрү буенча эшли. Хөкүмәт гаскәрләренең зур көчләре һөҗүм итеп килүе турында хәбәр итәргә, ярдәм һәм киңәшләр сорарга дип Пугачев янына бара. Аның үз иптәшләре өчен үч аласы килә, гади халыкның тормыш хәлен яхшыртасы килә. Моның өчен дворяннар сыйныфын яклаучы хөкүмәт гаскәрләренә каршы көчле көрәш алып барырга кирәклеген яхшы аңлый ул. Давыдов үзе Зөя өязе ясаклы татар крестьяны, көчләп чукындырылган кеше була. Кысрыклауларга түзә алмыйча, Енгалычевлар кебек, Давыдов та бу тирәләрдән буш җирләре күп дип даны таралган Бөгелмә ведомствосына юнәлә. Шунда семьясы белән урнашып, хуҗалык корып җибәрә, грамоталы, зиһенле булуы һәм байлык артыннан куучыларга ачы нәфрәте белән халык арасында хөрмәт казана. Аны, Екатерина II 1767 елда законнар тикшерү өчен комиссия оештыргач, ясаклы крестьяннар вәкиле итеп Бөгелмә ведомствосыннан депутатлыкка сайлыйлар. Ул анда барып, комиссиянең берни дә эшләмәгәнлеген, бары тик халык күзен буяу өчен генә чакырылганлыгын яхшы аңлый. Нәтиҗәдә, Екатерина II хөкүмәтенә каршы крестьяннар сугышка күтәрелгәч, бер дә икеләнмичә аңа кушылып китә, чын халык вәкиле булып, баш күтәрүчеләрнең атаманы булып өверелә. Енгалычевның якташы буларак та, бер үк вакытларда яңа җирләргә килеп урнашкан, уртак язмышлы кеше буларак та Давыдов Йосыфны, әлбәттә, якыннан белгәндер. Көрәш елларында кулга-кул тотынып сугышулары моны ачык раслый... Енгалычевтан сигез яшькә яшьрәк Давыдовның апрель башында кулга эләгүе турында инде әйткән идек. Давыдовны һәм аның иптәшләрен хыянәтче старшиналар 13 апрельдә Бөгелмә коменданты Кожинга китерәләр. 17 апрельдә Давыдовтан сорау алу була. 18 апрельдә генерал Щербатов көчле сак белән аны Казанга Яшерен комиссиягә озатуы һәм тотып китерүче старшиналарны бүләкләве турында хәбәр итә. Шуны да әйтеп китәргә кирәк: Давыдов белән бер үк вакытта Пугачевның якын хезмәттәше, Мәскәүдә аның белән бергә җәзалап үтерелгән Вәлит Торнов та властьлар кулына төшә. Алар бер партиядә Бөгелмәдән Казанга җибәреләләр. Торнов Казаннан Мәскәүгә җибәрелә, ә Давыдов, Пугачев Казанны алганчыга кадәр, Казан төрмәсендә җәфа чигә. 1767 елгы комиссия депутатлары юридик яктан шәхси иминлек хокукы белән файдаланганнар, шуның өчен Яшерен комиссия аның турында җәза карары чыгармый торган. Казан губернаторы Фон Брандт Екатерина II гә Давыдов турында махсус хат язып: «Аның җинаятьләре законның бөтен пунктлары буенча үлем җәзасына хөкем итәргә туры килә, депутат буларак аңа карата Сезнең нинди күрсәтүләрегез булыр?» — дип сораган. Бу хәл 1774 елның 5 июлендә булган. Ә 8 июльдә Казанга Яшерен комиссиянең председателе итеп билгеләнгән генерал-майор Павел Потемкин (Екатерина II нең фавориты Григорий Потемкинның туганнан туганы) килә. Шул ук көнне Екатерина II гә язган хатында ул: «Казан төрмәсендә 415 тоткын, алар арасында депутат Давыдов та бар. Сезнең ихтыярыгыз ничек булыр?» — дип сорый. Ике сановникның да сорауларына җавап итеп Екатерина II шул ук елның 28 июлендә үз кулы белән указ язып җибәргән: «Генерал-майор Павел Потемкинга. Әгәр инде бер мәртәбә тантаналы рәвештә депутатларга тормыш вәгъдә иткәнбез икән, Давыдовны дар агачы астында богаулап приговор укырга: Ригага каторгага җибәреп, аны гомере буена Двина елгасында иң авыр эшләрдә файдаланырга.

28 июль 1774 ел.»

Шулай итеп, укымышлы патша дип саналган әби патша Давыдовка үлемнән дә авыр җәза бирә. Ләкин... Ләкин Екатеринаның «мәрхәмәтле» хөкеме соңга кала: Павел Потемкин, Пугачев Казанга штурм ясау алдыннан, төрмә каравылы начальнигына атаклы пугачевчыларны үтереп бетерергә боерык биргән була. 12 июльдә иртә белән каравыл офицеры бу боерыкны гамәлгә ашыра. Давыдов һәм башка пугачевчылар төрмәдә суеп үтереләләр.

Шулай итеп, патша хөкүмәте халык бәхете өчен көрәшүчеләрдән канлы үч ала. Әмма алар киләчәк буын көрәшчеләренә якты эз, революцион рух калдыралар.

**Газиз Иделле**

# БЕРЕНЧЕ ЗУР СӘЯХӘТ

## 21. Кырым кояшы

Без инде бу Кырымга, Ялтага һәм аның тирә-якларына тәмам изләшеп җиттек бугай. Кырымның үзәк шәһәре Симферопольдә дә булдык, кешеләре белән очраштык, шәһәрнең матурлыгына, яшеллегенә соклардык, Пушкин тарафыннан җырланган тарихи Бакчасарайда булдык, борынгы хан сарайларын карап йөрдек, мәшһүр фонтаннан агып торган суын татып, Пушкин поэмасындагы вакыйгаларны күз алдыбыздан кичереп үттек. Чефет-кала («үлек шәһәр») дип аталган бик борынгыдан калган, тау тишекләренә урнашкан таш шәһәр мәгарәләренә («квартираларына») кереп йөрдек. Инде бу тирәләрдә без күрмәгән-булмаган урын да калмады кебек.

— Юк,— диде өлкән агайларыбыздан берсе,— Ай-Петридә булмадык әле, шуннан торып, кояш чыкканны күрмәдек,— диде.

Ай-Петри — диңгез ярларындагы тауларның берсе. Кырым җәйләве дип йөртелә торган тигезлектән күтәрелеп тора. Биеклеге 1233 метр.

Кояш чыгуны кайсыбыз гына күрмәде икән. Әмма аны Ай-Петри тавыннан күру үзе бер гаҗәеп манзара ул, диделәр. Кырымда булган кеше анда менмичә һәм бу манзараны күрмичә калмый икән. Ә кояшка гашыйк Горький бу тауга бернича тапкыр менгән дип сөйләделәр.

Без Ай-Петригә юл тоттык. Кояшны каршы алырга. Кичтән үк. Куна барып. Махсус юл күрсәтүчебез дә бар безнең. Бу тирәдәге юлларны-сукмакларны күп таптаган бер абзый.

Гаспрадан Ай-Петригә борылып-борылып менә торган бик уңай юл да бар икән. Ләкин теге агай безне анда алып китмәде. Кырым татарларыннан булган бу абзый кеше безгә бик ярарга тырышты бугай, туры юлдан дип текә тауга мендерә башлады. Карышып тору юк, аңа ияреп атлый бирәбез. Башта берни сизмәдек, җиңел генә менә бирдек. Ул сүзчән абзый безне үзенең туктауны белмәс теле белән дә сыйлап тора. Мактанчыграк та булып чыкты ул: барлык зур язучылар аңа яхшы таныш икән. Толстой да, Горький да, Чехов та аңа әшнә! Барысына да хезмәт күрсәтә килгән, янәсе.

Тауга менгән саен юлның текәрәк була баруы өстенә, куе булып үскән куаклык-

---

Ахыры. Башы 3, 5, 6, 7 саннарда.

лар комачаулый,. каты ботаклары аякларны тырнап-тырнап алалар, биек булып үскәннәре сиздермәстән биткә дә китереп бәргәлиләр. Озын сыйраклы Рубинштейн. Нигъмәти кебекләр берничә карамый кызу атлыйлар, хәрәкәтчән Кутуй, Гомәр, Закирлар алардан калышмый баралар, без дә сер бирмәскә тырышабыз, авыр сулап, ахылдый-ухылдый башлаган Кави, Кәрим агаларга карап, үзебезнең яшьлекне күрсәтергә тырышабыз. Мирсәй белән ярыша-ярыша атлыйбыз, югары үрмәлибез, әле мин, әле ул алга чыга...

Караңгы төшкәч кенә тауга менеп җиттек. Тирләп чыккан булсак та, бик тиз суындык тагы, чөнки Кырым монда үзенең икенче ягын безгә нык кына сиздереп алды: салкын иде бит ул. Ярыйсы гына җил дә исеп тора иде.

Юл күрсәтүче абзыебызның җаваплы миссиясе шунда тәгәлләнде. Аны тиешенчә ризалатып, рәхмәтләр әйтеп калдык. Ул да бездән бик канәгать булып, безгә уңышлар теләп, кире кайтып китте.

Монда килүчеләр без генә түгел. Якын-тирәдәге курортлардан, ял йортларыннан да кешеләр байтак иде.

Бик үк уңай һәм пөхтә булмаса да, туктар урыннары да бар икән. Бер катлы озын сарайга охшаган бина. Туристик база икән ул. Шунда кундык. Арыган да идек, бик иртә торырга да кирәк булгач, йокы тиз алды.

Таң атканын сизмәдек тә. Берәүләр үзләре уянды, икенчеләрен уятып йөрделәр. Кояш чыкканчы ук барыбыз да аяк өстендә идек инде.

Тау кырыена җыйналдык. Төнлә тыныбрак калган диңгез өсте шадралана башлаган иде инде. Күзләр еракка, диңгез белән күк тоташкан офыкка текәлгән. Ниндирәк була икән монда кояш чыгуы? Түземсезлек белән көтәбез. Офыктагы һәрбер үзгәрешне хәтергә ала барырга тырышабыз.

Менә офык яктыра-кызара башлады. Без күреп күнеккән гади бер офык кызаруы түгел иде бу. Еракта, очсыз-кырыйсыз киңлектә чайкалып торган диңгез суының төссиредер: анда төрле төсләр бер-берен гел алмаштырып тордылар дисәм бик арттырып әйтү булмас. Кызыл, ал, зәңгәр төсләрнең әле куера, әле сыегая барып чагылыпаралашып китүе, шуларның бөтенесенең һаман киңәя, өскә һәм тирә-якка җәелә баруы гаҗәеп бер манзара иде.

Инде кояшның үзенең килеп чыгуын ничек тасвирларга?

Төрле урында төрлечә була инде ул. Шәһәр шартларында, мәсәлән, кояш чыгуын күреп тә булмый әле. Аны инде биек йортлар өстеннән күтәрелгәч югарыда гына күрә аласың. Ә авылда, кырда, яланда күрү истә кала. Урынына карап, төрлечә итеп әйтәләр: урман артыннан килеп чыкты... басу кырыннан күренде... тау артыннан күтәрелде.

Юк, монда болай дип әйтүләрнең берсе дә ярамый. Диңгез артыннан килеп чыкты, дип әйтеп булмый. Ә ничек дип әйтергә? Ничек дип аңлатырга?

Менә аның күзне чагылдырырлык җете алсу кырые күренде һәм ул әкрен генә, мәһабәт кенә булып, үзенең зурлыгы, яктылыгы, көч-куәте белән безне таң калдырып күтәрелә, үсә, зурая башлады. Кайдан килеп чыкты ул? Юк, диңгез артыннан түгел, ә диңгезнең үзеннән. Чөнки күк белән диңгез бергә тоташкан офык әллә кайда бик еракта, ә кояш безгә якыннан гына, диңгез уртасыннан гына калкып килә. Әнә аның алдында да, артында да диңгез җәелеп ята. Кояш үзе дә суга манчылган кебек тәэсир калдыра, күтәрелә, күтәрелә ул һәм, ниһаять, түгәрәк, утлы шар хәленә керә, әмма итәге судан аерыла алмый әле... Әллә ул суны үзенә иартеп мендерә, әллә диңгез, җибәрмәс өчен, аңа ябышып ята. Хәтта утлы кояштан шыбырдап су да коелып тора сыман.

Ниһаять, аерылыштылар алар. Диңгез, ах, ычкындырдым, дигәндәй, бер уфтанып ала, кояшка сырышкан куллары кире төшеп китә. Шунда диңгез бер чайкалып алды да дулкыннарын кызурак йөгертә башлады.

Ул минутларда без, тын да алмыйча, сокланып карап тордык. Үзара сөйләшүләр дә, ах итүләр дә булмады, һәркем үзалдына сихерләнгән кебек тып-тын булып, табигатьнең бу гаҗәеп гүзәл күренеше алдында таң калып басып торды. Әйе, кояш чыгуын Ай-Петридән торып күрми-күзәтми китү, чыннан да, бик тә үкенечле буласы икән. Һаман да, искә төшкән саен мине сокландырып, гаҗәпләндереп, күз алдымда шулай гел кабатланып тора бу гаҗәеп манзара.

# 22. Украина җирендә

Кырым җире белән, Ялта белән саубуллашу көннәре дә килеп җитте. Маршрутыбыз буенча без моннан Харьковка юл тотарга тиешбез. Тик шуңа кадәр составыбызда бер үзгәреш турында берничә сүз.

Телеграмма килеп төште. Татар театрыннан. Сезон башлануга кызу хәзерлек бара икән. Салих Сәйдәшевнең, Кәрим Тинчуринның, Шакир Шамильскийның кайтып эшкә керешүләрен үтенәләр. Алар театрның төп көчләреннән саналалар бит. Үкенечле-кеенечле булса да, бу мөхтәрәм өч иптәшебез өчен сәяхәт шушы Кырым белән тәгәлләнде дигән сүз. Алар кайтып киттеләр. Штаттагы кешеләр булгач, аларның да тәртипкә буйсынулары, җитәкчеләребезнең дә бу очракта берни эшли алмавы ачык иде. Тик «Кәрим бай»ны кем алмаштыру турында гына сөйләшү булган булса кирәк. Аның урынына казначей итеп мине билгеләргә булганнар. Ни өчен мине, ә бүтән берәвебезне түгел — монысын мин аңламадым һәм аны миңа аңлатып та тормадылар. Куштылар — берсүзсез буйсындым. Кәрим ага Тинчурин «кассасын» минем алга актарып салды. Исәп-хисапны бик тиз ясап алдык: күпме акча өләшенгән, тотылган, күпме калган... Суммаларын тәгаен хәтерли алмыйм инде, һәрхәлдә, бөтенесе идеаль тәртиптә иде. Расход документларын, калган акчаны санап, кул куеп алдым. Шул калган акча Казанга әйләнеп кайтканга чаклы җитәргә дә тиеш, тотылып бетәргә дә тиеш иде. Бу бурычны төгәл башкарып чыктым бугай, андый-мондый сүз ишетмәдем. Шулай да өч иптәшебездән аерылу күңелле булмады. Аларның да ничектер моңаебрак кайтып киткәннәрен һәм монда калучыларның да ямансулап калуларын хәтерлим.

...Без яңадан юлда. Поездда. Украинага барабыз. Харьков шәһәренә. Ул елларда бу шәһәр Украинаның башкаласы иде.

Кавказның, Кырымның мәһабәт тау-ташлары, зәңгәр сулы диңгезләре артта калды инде. Тирә-ягыбызда — безнең күзләр яшьтән үк күреп күнеккән бик таныш пейзаж: күз явын алырлык куе яшеллеккә күмелгән тип-тигез кырлар-болыннар буйлап чаба-оча безнең поезд. Бөтен дөнья күзгә муллыкка, төрле хуш-исләргә күмелеп калган сыман. Юл буйларында тезелеп утырган зифа буйлы төрле агачлар, гөрләп үсеп торган игеннәр, мул булып өлгереп килә торган җимешләрен күтәрә алмыйча сыгылып төшкән алма, чия, груша агачлары, төрле җиләк-җимеш бакчалары күз алдыбызда бер-бер артлы йөгерешеп үтәләр. Күңелгә рәхәт...

Бу язмаларым өстендә эшләгән арада, төртелеп-тукталып калган сәгатьләрдә төрле китапларны актаргалый идем мин. Өстәлемдә Муса томнары да ята. Нәкъ шушы юлларны язып утырган мәлдә аның бер шигыре искә килеп төште. Ул елларны, бездән бер ел элек (1928), нәкъ шушы сентябрь аенда, нәкъ шушы юл буйлап, Мәскәүдән Украина аша Кырымга барган ул һәм шуны «Мәскәү — Кырым юлы язмаларыннан» дип үз поэзиясендә мәңгеләштереп тә калдырган:

Яшел кигән ялан уң якта,
Чуар бәдрә таллар сул якта;
Без барабыз яшен поездында.
Әйтерсең лә ярып киң яланны,
Омтылабыз күккә-еракка!
Якынлаштык инде кояшның да
Түбәгә үк менгән җиренә,
Сизәм — хәзер чәчем дулкынлана,
Украина,
Синең җиреңдә!!

Без дә шулай, дулкынланган чәчләребез һәм күңелләребез белән нәкъ шундый хисләр кичергәнбездер Украина җирләре буйлап барганда,— хатирәләргә бирелеп, шулай уйлап алдым, кабат шундый хисләр белән алды мине.

Украина! Үзенең халкы, территориясе, экономикасы ягыннан Советлар Союзында РСФСРдан кала иң зур, иң бай, иң данлыклы республика!

Чал тарихлы ил бу. Монда үз башыннан бик тә катлаулы язмыш кичергән батыр йөрәкле халык яши. Шулай, тарихка күз салсаң, әй-яй, никадәр күпне күргән икән бу Украина җирләре, Украина халкы дип куясың.

Үз теле, территориясе, экономикасы, культурасы белән 14—15 гасырларда ук үзен мөстәкыйль халык буларак таныта ул.

Бик ерак тарихка кереп тирән чуммыйк без, бу очракта аз гына, өстән-өстән генә йөгереп үтү дә җитәр кебек.

Феодализм, аллавыт-крепостнойлык чорлары... Хезмәт халкы икеләтә-өчләтә изү астында яши. Чит ил баскыннары да хакимлек итә Украина җирләрендә: паннар Польшасы, Австрия, Төркия һ. б. илбасарлары... Шундый һәртөрле изүләргә каршы халык хәрәкәте башлану... Рус князьлегенә кушылу өчен прогрессив көрәш.

Богдан Хмельницкий исеме укучыларга бик таныш булса кирәк. Шундый драма әсәре бар (авторы — бүгенге Украинаның атаклы драматургы Александр Корнейчук), опера бар, кинофильм бар. Әнә шул батыр патриот җитәкчелегендә 1648—54 елларда киң колач алган азатлык сугышы башлана һәм бу — чит ил интервентларын зур җиңү белән, Украинаның Россиягә кушылуы белән тәгәлләнә.

Әмма хезмәт халкы өчен тынычлык, бәхет һаман да килми әле. Бер яктан урыннардагы гетман властьлары феодаль-крепостнойлык тәртипләрен ныгыту политикасын алып бара. Әле төрекләр, әле поляклар һөҗүме... әле Швеция, әле Австрия оккупантларының кысрыклавы. Тормыш дәвам итә. Промышленность туу, үсү. Крепостнойлык кризисы. Крестьяннар кузгалышы... Патша хөкүмәтенең колониаль политикасы... Украинаның дәүләт буларак бетерелүе — идарә итүнең патша наместниклары кулына күчүе...

Мәшһүр Украина шагыйре Тарас Шевченконы бездә кем генә белми икән! Аның «Гайдамаклар» исемле поэмасы бар. Анда 18 гасыр урталарында Украинада киң таралган крестьяннар хәрәкәте хакында сөйләнә.

Еллар үтә. Промышленность буржуазиясе формалаша. Пролетариат сафлары бәрлыкка килә башлый. Хезмәт халыклары арасында дуслык җепләре ныгый бара. 1812 елгы Ватан сугышында бу бик ачык күренә. Француз оккупантларына каршы сугышларда украинлылар руслар белән бер сафта булалар, бердәм, уртак Ватан азатлыгы өчен каннарын да, җаннарын да кызганмыйлар, хәрби частьларда да, Денис Давыдовның партизан отрядларында да алар Наполеон армияләренә каршы көрәшеп, зур батырлыклар күрсәтәләр.

Шуннан бирегә таба булган еллар аеруча данлыклы. 1905 ел революциясе, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы елларында инде Украинада чын революцион хәрәкәт, большевистик интернационализм югары баскычка күтәрелгән була. Ворошилов, Щорс, Буденный, Орджоникидзе, Котовский, Фрунзе, Пархоменко — рус, украин, грузин халыкларының батыр уллары — украин җирләрендә дан казандылар. Бу легендар полководецлар хезмәт халкын хәрби частьларга оештырып, алар белән оста командалык иттеләр, явыз дошманнарга каршы җиңүле сугышларга алып бардылар. Чит ил интервентларын, Антанта ерткычларын, эчке контрреволюцион көчләрне, Деникин, Врангель, Юденич, Каледин гаскәрләрен, Австрия, Германия оккупантларын, Петлюра, Махно бандаларын, буржуаз милләтчеләрнең мәкерле явыз фетнәләрен тар-мар итүдә, яшь совет Ватаныбызның Украина халкының азатлыгын, бәйсезлеген саклап калуда Ленин байрагы астына тупланган халыкларның какшамас бердәмлеге, дуслыгы бөтен дөньяга ачык күренде.

Без нәкъ менә шундый каты, канлы сугышлар булган җирләрдән барабыз. Менә Перекоп, Сиваш тирәләре, Фрунзе армиясе дан казанган урыннар. Бу юлларны язганда хәзер менә Гомәр ага Бәшировның «Сиваш» повестен яңадан бер тапкыр күздән кичерәм. Нинди тарихи көрәш эпопеяларыннан берсе безнең татар совет әдәбиятында мәңгеләштерелгән бит. Тукта, повестьның төп герое Шәмси солдат — Гомәр үзе түгелме соң! Әйе, үзе ул. Дошманны кыйный барып, Сивашны кичүдә катнашу — Гомәр ага биографиясендә дә иң күренекле урынны алып тора. Украина җирләрен азат итеп, Сиваш, Перекоп аркылы чыгып, явыз дошманнарны Кырым ярларыннан Кара диңгез упкыннарына ыргытуда, рус, украин һ. б. миллә егетләре белән бер сафта, безнең татар егетләре дә аз булмаган. «Сиваш» повесте — моңа ачык шаһит. Уңае килгәндә әйтеп үтик: Гомәр ага Бәшировның 70 яшь тулу каненда

Октябрь революциясе ордены белән бүләкләнүе безнең барыбызны да бик куандырды, чөнки бу орден талантлы әдибебезнең иҗади эшчәнлеген дә, Октябрь революциясе казанышларын корал белән саклап калуда актив катнашуын да искә алып олылау билгесе бит ул.

Днепропетровск өлкәсенә килеп кердек, шул исемдәге зур шәһәр аша үттек һәм нәкъ шунда без, бөтен Украина буйлап, Гоголь тарафыннан һәм аннан соң да күп кенә язучылар, шагыйрьләр, рәссамнар иҗатында сурәтләнгән мәшһүр Днепр елгасын кичтек. «Чуден Днепр при тихой погоде...»ны шунда байтагыбыз эчтән генә булса да кабатламый калмагандыр дип уйлыйм. Әйе, чыннан да гаҗәеп матур да, зур да, куәтле дә ул Днепр. Украина аның белән хаклы рәвештә горурлана, аның халкы күңеленә ул шулай үлмәс җыр булып кереп урнашкан...

Менә Харьковка да килеп җиттек.

Монда да, һәркайдагыча, каршы алулар тантаналы булды. Речьләрдә, газета битләрендә ялкынлы сәламнәр, тәбрикләр...

Харьков. Аңа XVII гасыр урталарында нигез салынган, диләр тарихчылар. Зур промышленность, фән, культура үзәге. һәм украинлылар өчен бик тарихи шәһәр дә икән үзе. Чыннан да, бер карасаң, Харьков шәһәре үзенең кайбер мөһим тарихи яклары белән Петроградны — Ленинградны да хәтерләтә икән. Октябрь революциясенең бишеге булган элекке башкалабыз Петроград илебез тарихында нинди урын тоткан булса, Харьков шәһәре дә Украина тарихында шундыйрак урын тота диярлек. Мәсәлән, узган гасырда ук Харьков революцион хәрәкәт үзәкләреннән берсе була. Политик түгәрәкләр оештырылып эшләвен, полициягә, шәһәр администрациясенә каршы баш күтәрүләрне, демонстрацияләрне, зур забастовкаларны хәтерендә нык саклый бу шәһәр. 1905 елда Артём (Ф. Сергеев) җитәкчелегендә большевистик оешма да шушы шәһәрдә төзелә. 1917 елның март аенда нәкъ менә шушы Харьковта эшче һәм солдат депутатлары Советы оештырыла. 1917 елның декабрендә I бөтен Украина Советлары съезды үткәрелә һәм Украина шунда Совет Республикасы дип игълан ителә. Шулай итеп, Харьков шәһәре Украинаның беренче башкаласы була[1]. 1919 елның март аенда Харьковта үткәрелгән 3 нче бөтен Украина Советлар съездында Украина Совет Социалистик Республикасының беренче Конституциясе кабул ителә.

Эчтәлекле, файдалы очрашулар булды Харьков шәһәрендә: язучылар оешмаларында, партиянең Украина Үзәк Комитетында, Мәгариф комиссариатында... Аннары шәһәр белән танышу, завод-фабрикаларда булу.

Украин язучыларының иң истә калганнары Кулик белән Микитенко булды. һәр икесе ул елларда иң күренекле әдипләр һәм язучылар оешмасы җитәкчеләре иде. Безне каршы алуда да, Украина әдәбияты, сәнгате, промышленносте, культурасы һ. б. белән таныштыруда да алар башлап йөрүче булдылар, бу эшне бик теләп башкардылар.

Кулик — уртача буйлы, мөлаем йөзле, ияк очында гына эленеп торган сыман кыска кара сакаллы, акыллы күз карашлы, ашыкмыйча, акрын тавыш белән сөйли торган сабыр табигатьле, Микитенко исә житез, кызурак табигатьле, үзенең буе-сыны белән безнең Мөхәммәт Галигә охшаганрак кеше иде.

Алар яшьтәшләр дә булып чыктылар: 32 яшьтә. Ир егет булып та, әдәбиятта киң колач ала барып та иң танылган чаклары... Шулай да тормыш юллары, характерлары, иҗат эшчәнлекләре белән һәркайсы үзенә аерым урын алып тора. Соңыннан, кызыксынып, аларның биографияләре белән дә танышырга туры килде.

Драматург, публицист Иван Кондратьевич Микитенконың без анда булган елны (1929) «Диктатура» исемле пьесасы зур уңыш белән бара иде. Аның авылларда колхозлар оештыруны, кулакларга каршы көрәшүне үткен, оста итеп гәүдәләндергән ул пьесасы соңыннан да күп еллар буена уңышлы барды.

Иван Юлианович Кулик (1897—1941) укытучы семьясында туган. 1914 елдан компартия члены. Одесса художество училищесында укыган. 1914 елда АКШка китә ул һәм анда гади кара эшче була, социал-демократлар партиясе эшендә катнаша. 1917

---

[1] Киевкә башкала 1934 елда күчте.— Г. И.

елда үз иленә кайта, Украинада башланып киткән Октябрь революциясе өчен көрәшләрдә, гражданнар сугышында катнаша. Украинаның беренче Совет хөкүмәте составына керә. 1924—26 елларда Канадада совет консулы була. Бернича чит телне бик яхшы белә. Аның әсәрләре газета-журнал битләрендә 1918 елда ук күренә башлый. Украинада гражданнар сугышына багышланган беренче шигырьләр җыентыгы 1921 елда басыла. Шуннан соң — «Савыгу» (1923), «Яшел йөрәк» (1923), «Чолганьшта» (1927), «Олыгаю» (1935) һ. б. җыентыклар авторы ул. Украина совет поэзиясенә беренчеләрдән булып индустриализация, интернационализм, фәнни эзләнү темаларын кертә, коммунистлар, эшче хатын-кызлар образларын тудыра. Без анда булган елны басылып чыккан «Кара эпопея» исемле поэмасы АКШтагы негрлар тормышын тасвирлый. Тәрҗемә белән дә күп шөгыльләнә. Н. Тихонов, Э. Багрицкий, Б. Ясенский, Н. Бараташвили, А. Акопян шигырьләрен украин теленә тәрҗемә итә. «Америка поэзиясе антологиясе»н төзүче һәм тәрҗемә итеп бастырып чыгаручы да ул.

Гомумән, Украина язучылары белән үткәрелгән очрашу-сөйләшүләрдә дә тәрҗемә мәсьәләсе гел телгә алынып торганлыгын әйтми булмый. Безнең делегациянең әһәмиятен бер-беребезнең иҗатлары аша танышу белән бергә бәйләп сөйләделәр алар һәм бу безнең дә уртак фикер булды.

— Барыбыз да бергә үсик, бер-беребезнең уңышларын уртак итик, эшлекле бәйләнеш тотыйк,— һәр ике як шундый нәтиҗәгә килде.

...Бүгенгесе белән дә, кичәге тарихы белән дә бай әдәбият ул Украина әдәбияты. Шулай да барлык күргәннәребездән-ишеткәннәребездән (һәм укыганнарыбыздан дип тә өстик) Украина бездә — язучыларда — башлыча Тарас Шевченко иле булып истә калган. Бүген шушы язмаларым өстендә эшләп утырганда һәм моның өчен тагын күп кенә чыганаклардан да файдаланганга, шундый нәтиҗә ясарга хаклы булам бугай мин. Чөнки Украинаны, аның әдәбиятын, культурасын (үткәнен дә, бүгенгесен дә) Шевченко исеменнән башка күз алдына китерү мөмкин түгел... Бөек шагыйрь, рәссам, революцион-демократ, патша строена, крепостнойлыкка каршы ялкынлы көрәшче... Аның иҗатында Украина крестьяннарының һәм барлык украин хезмәт халкының авыр тормыш шартлары, революцион көрәше чагылган. Изүчеләргә каршы тирән нәфрәт тулы әсәрләре (шигырьләре, поэмалары, рәсемнәре) белән ул украин халкының милли һәм социаль үзаңын үстерүдә гаять зур роль уйнаган. Украина сәнгатендә критик реализмга нигез салучы Шевченко үз иҗатында украин һәм рус халкы культураларының туганлык-дуслыгы өчен дә күп көч куйган. Үзеннән соңгы барлык буын украин әдипләренә һәм сәнгать эшлеклеләренә үрнәк булып, юл күрсәтеп торган якты йолдыз булып балкый Шевченко исеме! Очрашуларда, әдәбият-сәнгать турында сүз барганда беренче итеп аның исеме телгә алынуы да бик табигый иде, әлбәттә.

Без гел украин язучылары белән булдык. Алар сөйләделәр, без сөйләдек. Культура оешмаларына, шәһәр предприятиеләренә бергә йөрдек. Шулай әдипләрнең үзләре белән дә, гомумән украин әдәбияты-сәнгате белән дә, шәһәр белән дә танышa бардык. Әдәбият турында сөйләгәндә һәр ике яктан телгә алынган исемнәр күп булды. Уртак исемнәрдән, әлбәттә, Максим Горький аларга да, безгә дә бик якын иде. Горький бит Украинаны яхшы белгән, әле Алексей Пешков чагында ук аның бик күп сукмакларын җәяүләп үткән, соңра исә, Максим Горький булып үскәч, 1897 елны Украинада яшәгән (Полтава әлкәсенең Мануйловка авылында халык театры оештырганын да бер әйтеп үткән идем инде). Гомумән, язучы Горький украин әдәбиятысәнгате белән һәр вакыт бик кызыксынып яши. Украина язучылары исә аның бай иҗатын тырышып өйрәнәләр. Яңа украин әдәбияты үсешенә, бигрәк тә бүгенгесенә Горькийның яхшы йогынтысын ихтирам белән телгә алалар монда, аның белән еш кына очрашалар, киңәшләренә игътибар белән колак салалар, аны үзләренең якын дусты, остазы итеп таныйлар. Ике арадагы мондый якынлык, дуслык элек-электән килә икән. Мәсәлән, Горькийны Коцюбинский белән янәшә телгә алулары да бик табигый.

Украина әдәбиятының классикларыннан берсе Михаил Михайлович Коцюбинский (1864—1913) Горькийның шундый якын дусларыннан берсе булган. Алар Италиядә

Каприда очрашып дуслашканнар. Анда байтак вакыт бергә булганнар. Соңыннан да гел хатлар алышып торганнар. Бер-беренә ихтирамнары, яратулары көчле булган аларның. Коцюбинский турында Горькийның бик җылы язылган истәлекләре бар һәм — шундый сүзләр белән аңа бүләк итеп биргән фоторәсеме: «Михайлу Михайловичу Коцюбинскому с крепким чувством любви и уважения — М. Горький».

Уңае килгәндә Коцюбинский турында кайбер кыскача гына мәгълүматлар китереп үтү дә артык булмас.

Бик бай һәм катлаулы тормыш мәктәбе үтә ул. Әллә ни күп укый да алмый: 1880 елны духовный училищены тәмамлый да, шуннан соң аңа бары тик үзлегеннән уку мөмкинлеге генә кала. «Народная воля» группасы кешеләре белән аралаша. Яшьләр арасында, эшчеләр арасында пропаганда эшләре алып бара. Яшерен полиция күзәтүе астына алына. Төрмәгә дә ябып тоталар... Төрле елларда төрле шәһәрләрдә була ул: Каменец-Подольск, Винница, Одесса, Чернигов... Бессарабиягә, Кырымга да барып чыга, авылга да күчеп китә, анда укытучы булып эшли, крестьяннар арасында аң-белем тарату белән актив шөгыльләнә. Чернигов шәһәрендә земский статистик хезмәтләрен дә үти. Әдәби һәм иҗтимагый-политик хәрәкәттә актив катнаша.

Сәламәтлеге бик какшагач, берничә тапкыр чит илләргә барып дәвалана. Австриядә, Германиядә, Швейцариядә, Грециядә, Төркиядә була, озак вакыт Италиядә яши, шунда 1909 елны Максим Горький белән очрашып, дуслашып китәләр. 1910 елны Каприда В. И. Ленин белән таныша. Эшчеләр хәрәкәте белән якынлашу, яшерен таратыла торган революцион әдәбиятны уку, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әсәрләре белән танышу аның карашларының марксизмга күчә баруын көчәйтеп җибәрә.

Коцюбинский бай әдәби мирас калдыра. Аның аерым китап булып чыккан шундый кыйммәтле әсәрләре утыздан артык. Ул Чехов, Горький, Короленко иҗатларына бик югары бәя бирен, яшьләрне алардан өйрәнергә чакыра. Аның 1903—12 елларда иҗат иткән соңгы әсәрләрендә инде Беренче рус революциясенең киң панорамасы гәүдәләнә. Шулай итеп, Коцюбинский әдәбият тарихына революция художнигы булып, Октябрь алды украин әдәбиятында социалистик реализмны башлап җибәрүче булып кереп калды. Бу ягы белән дә аның Горький белән якынлыгы бик зур.

Харьков завод-фабрикаларга бай шәһәр. Берничәсендә без дә булдык. Истә калганнардан — «Урак-чүкеч» заводы.

Мондый зур заводны күбебезнең шунда беренче тапкыр күрүе булгандыр. Бу заводта бик күп төрле авыл хуҗалыгы кораллары эшләнә. Эш процессы бик әйбәт механикалаштырылган. Һәрбер аерым цех машина-коралның фәкать бер детален генә эшләү белән мәшгуль. Ул барлык цехлардан иң ахыргы җыю цехына китереләләр дә, монда конвейер системасы белән бергә җыйналып, бер бөтен әзер коралга әвереләләр.

Бу «Урак-чүкеч» заводында авыл хуҗалыгы өчен кирәкле булган барлык кораллар, машиналар да эшләнә диярлек. Завод эченә бер кереп китсәң — югаласың. Шундый зур ул. Төрле-төрле цехлар. Аларны һәммәсен дә карап, ныклап өйрәнү өчен безнең бер сәгать кенә түгел, көннәр дә, атналар да аз булыр иде...

Без тагын — дәүләт электро-механика заводында да булдык. Күп кенә гаҗәеп нәрсәләргә без шул хәтле күнеккәнбез, бер дә гаҗәпләнми башлаганбыз. Шуларның берсе — электр яктысы, электр көче: шырпысыз, утынсыз-керосинсыз ял-якты ут яндыру, бик күп зур машиналарны, завод-фабрикаларны хәрәкәткә китерү... Башта могҗиза булып саналган бу хәлләр хәзер гади бер күренешкә әвереләләр, ә инде менә шул могҗиза яктылыгын, могҗиза көчен тудыра торган машиналарның үзләрен ясау заводы ул чакта хәтта бездә дә зур кызыксыну тудырды, шуңа күрә без ул заводны бик күңел биреп карап йөрдек.

Завод үзе беренче империалистик сугыш елларында Ригадан Харьковка күчереп китерелгән булган икән. Ләкин соңгы вакытта ул бик нык киңәйтелгән, яхшыртылган, камилләштерелгән. Андагы төгәллек, эштә пөхтәлек, чисталык — бөтен Советлар Союзында үрнәк урынны алып тора иде ул елларда. «Правда» газетасы тарафыннан үт-

керелгән производство киңәшмәләре смотрында бу завод беренче урынга чыккан, беренче премияне алган иде.

Электр дөньясында нинди машина бар, нинди корал бар — бу заводта боларның һәммәсе эшләп чыгарыла. Цехлар бик күп һәм төрле. Менә без меңәр пот авырлыгындагы маховой тәгәрмәчләр эшләү цехында йөрибез. Бу тәгәрмәчне эшләү кораллары да кеше кулында түгел, ә зур куәтле машина кулында. Менә икенче бер цех. Монда электр машиналарына кирәк булган бик бәләкәй, юка әйберләр, кечкенә детальләр эшләнә. Монда эш кораллары — шат, көләч, чибәр комсомолкаларның нәфис кулларында. Гомумән, бу заводның күпчелек цехларында хатын-кызлар күп эшли. Кайбер цехлар бөтенләе белән хатын-кызлар монополиясендә диярлек. Завод барлык планнарны, заданиеләрне үз вакытында югары сыйфатлы итеп төгәл үтәп бара икән. Һәркайда эленеп торган күрсәткеч такталары күңелләрдә бик яхшы, шатлыклы тәэсир калдыралар. Гигант заводның гигант эш нәтиҗәләре һәркемнең күз алдында...

Гигантлар төрле булалар. Менә без икенче бер төрле гигант алдында. Бу — Харьковтагы дәүләт промышленносте йорты. Алдына бассаң күз колачы җитми. Биек. Киң. Зур. Мәһабәт. 1 100 бүлмә. Советлар Союзында беренче дәрәҗәле бина. Бөтен җир шарында (үзенең оригиналь архитектурасы, төзелеше белән) өченче дәрәҗәле бина иде бу ул елларда. Без шуның эчендә йөрибез. Эшләп торган 14 лифтнең берсенә утырып өскә күтәрелдек. Күп кенә бүлмәләрен, залларын карап чыктык. Түбәсенә мендек. Түбәнгә карадык. Тирә-якны күзәттек. Бөтен Харьковны, аның бөтен тирә-ягын учыбыздагыдай берьюлы күрә алдык. Бу бинада Украинаның барлык промтрестлары, хуҗалык, финанс органнары һәм кайбер наркоматлары урнашкан иде.

Йөрер, күрер җир, сөйләшер сүз күп, әмма вакыт аз — безне алда Мәскәү көтә, башкала белән, андагы зур язучылар белән, Максим Горький белән очрашу көтә...

Дусларча ачык чырай, киң күңел белән каршы алган һәм барлык уй-фикерләре белән, үз республикаларының промышленность, культура, әдәбият-сәнгать байлыклары турындагы төрле истәлекле мәгълүматлары белән юмарт уртаклашкан украин дусларыбыз-каләмдәшләребез безне тагын да яңарып, ныгып, тамыр җәеп киткән дуслык хисләре белән, олылап, шундый очрашуларның алда да кабатлануын теләп, озатып калдылар.

## 23. Мәскәүдә

Озын-озак юлыбызда бер генә шәһәргә дә шул кадәр дулкынлану белән килеп кермәгәнбездер. Бу — без булган бүтән зур, матур, атаклы шәһәрләрне кимсетеп әйтүем түгел, әлбәттә. Башта язып үткән идем инде, аларның да һәркайсы үзенә хас күркәм сыйфатлары, кабатланмас күренешләре, бик яхшы җанлы, кунакчыл кешеләре һәм күп кенә башка яклары белән безне сокландырды, дулкынландырды, күңелләребездә озак онытылмаслык җылы, якты истәлекләр калдырды. Әмма алар берсе дә Мәскәү хәтле үк булмады, чөнки Мәскәү бөтен бер бөек һәм уртак Ватаныбызның башкаласы бит ул, аның йөрәге, акылы. Һәм безнең генә дә түгел, бәлки бөтен дөнья хезмәт ияләренең өмет, мәхәббәт тулы күз карашлары шушы шәһәргә, мәшһүр Кызыл мәйданга, тарихи Кремльгә төбәлгән... Монда бөек даһи Владимир Ильич Ленин үзе эшләгән, илебезне, халкыбызны сугышлар һәм бәлгенлекләр, фәкыйрьлек һәм ачлыклар, кимсетелү һәм изелүләр упкыныннан тартып алып, якызлыкка, золматкә каршы изге көрәшкә күтәргән, бөек җиңүләр яулап алуда көч-куәт биргән һәм олы, якты юлга алып чыккан...

Мәскәү безне бик җылы каршылады. Көтелгәннән дә артык дияр идем. Күңелләр тулып ташты безнең. Язучылар, партия, совет җәмәгатьчелеге, матбугат безнең килүгә зур әһәмият бирде. «Литературная газета», «Известия» кебек үзәк газеталарда котлау-сәлам сүзләре һәм махсус мәкаләләр басылып чыкты. Безнең Мәскәүгә килүебез турында үзәк радио бөтен Советлар Союзына хәбәр итте.

Һәм иң әһәмиятлесе — беренче көннән үк кызу, киеренке практик эш башланып китте. Мәскәү темпы белән!

Дәүләт нәшриятында, Мәскәү язучылары оешмаларында очрашулар, сөйләшүләр, фикер алышулар...

Шәһәр белән, завод-фабрикалар белән танышып йөрү, эшчеләр, укучылар белән очрашулар. Даны бөтен дөньяга таралган театрларда, музейларда булу һ. б., һ. б.

Башта ук әйтеп китим: ул елларда Мәскәүдә яшәгән Шамил Усманов, Афзал Шамов кебек өлкән язучыларыбыз, үткәрелгән барлык чараларда диярлек, безнең белән бергә актив катнашып йөрделәр.

Башта — язучылар оешмаларында үткәрелгән очрашулар турында. Менә ул елларда Мәскәү язучыларының «Герцен йорты» дип йөртелә торган үзәк йорты. Иң беренче булып монда РАПП белән ТАПП активлары киңәшмәсе булды. Икенче каттагы кечерәк кенә бер бүлмә. Безнең экскурсиянең ничек оештырылуы, аның максаты, кайларда булуыбыз, кемнәр белән очрашуыбыз, нәрсәләр күрүебез, алган тәэссоратларыбыз турында Гомәр Гали, Кави Нәҗми чыгыш ясадылар. Фикер алышуларда үзара якынлык, туганлык атмосферасы бик тиз урнашты монда. Әйтерсең лә без Мәскәүдә түгел, ә үзебезнең Казандагы Мәдәният йорты бүлмәсендә шулай берниндн тартынусыз, җәелеп үзара сөйләшеп утырабыз. Мәскәүлеләр безнең һәм шулай ук без булган республикалардагы иҗатлар турындагы, интернациональ бердәмлек нигезендә үсүгә таба дөрес юл белән бару турындагы сүзләргә куандылар, җитешсезлекләребез, кимчелекләребез, кыенлыкларыбызга кагылганда дусларча, туганнарча борчылып, аларны төзәтү, эшне яхшырту чаралары турында эшлекле конкрет киңәшләр бирделәр.

Бу утырыш көндезге сәгатьләрдә булды. Кич белән без тагын шул Герцен йортына килдек. Монысы инде зур җыелыш. Герцен йортының зур залында. Монда Мәскәүнең барлык язучылар оешмаларыннан, культура учреждениеләреннән күп кенә күренекле иптәшләр җыйналган. Атаклы рус язучыларын күреп сокланабыз... Әнә Фадеев... Әнә Гладков::. Әнә Сельвинский... Әнә Леонов... Әнә Олеша...

Бу зур җыелышта безнең экскурсиябезнең әһәмияте, хәзерге рус совет әдәбиятының торышы, алдагы уртак бурычлар һ. б. турында ул еллардагы язучылар федерациясе председателе Сутырин доклад ясады. Илебездәге күп милләтле совет әдәбиятының сәламәт нигездә үсә баруына тукталып үткәннән соң, аларның үзара дуслык, .туганлыклары турында күбрәк уйланырга, моның өчен аларның әйбәт үрнәкләрен рус телендә югары сыйфатлы тәрҗемәләрдә бастырып чыгару, кайчан, кайда, күпме чыгару турында инде конкрет сөйләргә кирәклегенә басым ясады. Бүгенге зур очрашуыбыз да бу мөһим эшкә яхшы этәргечләрнең берсе булсын, диде. Безнең экскурсиянең әһәмиятенә тукталып, ахырда шулай дип тә өстәде: — Кадерле кунакларыбыз — татар язучыларының үзләренең елына бер генә ай була торган ял вакытларын менә шундый политик, практик яктан зур әһәмияте булган үзара культура элемтәләрен ныгытуга багышлаулары мактауга лаеклы, яңа хәрәкәт, яхшы характердагы чара.

Докладтан соң фикер алышулар башланып китте. Хуҗалар да, безнекеләр дә үз чыгышларында халыклар дуслыгы, әдәбиятлар дуслыгы турында, төрле милләт язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп бастырып чыгару турында, бу өлкәдәге кайбер уңышлар һәм кимчелекләр, алда торган практик эшләр турында сөйләделәр.

Кичәнең ахырында зур концерт булды. Анда безнең атаклы җырчыбыз Асия Измайлова да уңышлы чыгышлар ясады. Такташ, Кутуй үзләренең шигырьләрен бик дулкынланып, тәэсирле итеп укыдылар. Кичәнең рәсми өлеше кебек үк, концертның да тыңлаучыларга йогынтысы зур булды.

Кунакчыл Мәскәү язучылары оешмалары тарафыннан безнең хөрмәткә оештырылган махсус банкет-мәҗлесләр турында, андагы үзара әйтелгән җылы сүзләр, яхшы теләкләр турында шулай ук әйтми үтеп булмый.

РСФСР Дәүләт нәшриятында үткәрелгән очрашуда Артем Багратович Халатов белән без инде иске танышлар булып күрештек.

Рәсми утырыш башланганга чаклы Артем Багратович безнең сәяхәтебез ничек үткәнлеге турында әледән-әле сораштыргалап торды. Бик канәгать булуыбыз турында әйттек һәм аңа игътибары — ярдәме өчен рәхмәтебезне белдердек. Шул арада бу очрашуда катнашуга чакырылган Мәскәү язучылары да килеп җиттеләр.

Барыбыз да җыелып-урнашып беткәч, кунакчыл хуҗабыз мәҗлесне ачып, сөйләшүләрне үзе башлап җибәрде.

— Сезнең шулай зур төркем булып оешкан рәвештә Мәскәүгә килүегез,— диде ул,— культура-политик яктан да, иҗтимагый яктан да бик әһәмиятле. Илебезнең төрле почмакларындагы хезмәт ияләре тормышы, культурасы белән якыннан танышу һәм, ниһаять, менә хәзер үзәктәге оешмалар белән тыгыз бәйләнешкә керү юлында сез икенче урынны алдыгыз,— дип безне котлады.

Беренче тапкыр Мәскәүгә шулай Украина язучыларының оешкан бер төркеме килгән булган икән.

Эш, әлбәттә, котлау сүзләре белән генә калмады. Нәшрият тарафыннан татар язучыларының әсәрләрен русча тәрҗемә итеп бастырып чыгару турында кайбер конкрет чаралар да билгеләнде. Моның өчен махсус комиссияләр дә төзелергә тиеш булды. Бу — иң мөһиме иде.

Шулай ук очрашулар, утырышлар центриздатта да үткәрелде.

Безнең Мәскәүдә үткәргән дүрт-биш көн олы башкала өчен бик аз вакыт булса да, күпне күрергә, күпне белергә, күп урында булырга тырыштык. Сирәк туры килә торган буш сәгатьләребездә шәһәр белән танышып йөрдек. Минем үзем өчен, мәсәлән, бу да бик әһәмиятле, истәлекле булды... План буенча, оешкан рәвештә «Урак-чүкеч» металлургия заводына бардык. Цехларны карап йөрдек, эшчеләр белән әз-мәз сөйләшеп алдык (кызу эш вакытында әллә ни күп сөйләшерлек түгел!). Мондагы авыр да, мактаулы да хезмәтләрен күреп сокландык, горурландык. Ул заводта 25 тән артык цех бар икән. Вакыт тар булу сәбәпле без биш цехны гына карап өлгерә алдык.

Мәскәүдәге күп санлы татар эшчеләре белән очрашуда булдык. Моныcы Әсәдуллаев мәктәбе дип йөртелгән бинада үткәрелде. Төрле завод-фабрикалардан бирегә җыелган татар эшчеләре алдында без үзебезнең бу сәяхәтебез турында, эшебез, иҗатыбыз, планнарыбыз турында тулы хисап бирдек диярлек. Чыгышлар күп булды, шигырьләр укылды, клуб каршындагы үзешчәннәр үз осталыкларын күрсәттеләр.

Башкала музейларыннан мәшһүр Третьяков галлереясында булу аеруча истә калган. Рус классик рәссамнарының, борынгы Европа классикларының шедеврларын таң калып, сокланып, илһамланып карап йөрдек.

Театрларда берничә спектакль карадык. Иң истә калганы — атаклы МХАТ сәхнәсендә Всеволод Иванов әсәре буенча куелган «Бронепоезд 14-69» исемле спектакль булды. Гражданнар сугышы чорының үткән бер өлешен оста һәм реаль күренешләрдә, зур характерларда чагылдырган совет драматургиясенең үлмәс әсәре бу. Бик зур тәэсир калдырды. Рольләрне башкаручылары да — совет сәхнәсенең тиңдәшсез классиклары иде бит. Шунда без Вершинин ролендә Качаловны, Пеклеванов ролендә Хмелевны, Васька-Окорок ролендә Баталовны, Надежда Львовна ролендә—Книппер-Чеховны, Маша ролендә Тарасованы һ. б. күрү бәхетенә ирештек, аларның зур талантлары алдында баш идек. Пьесаны сәхнәгә куючы җитәкчесе дә мәшһүр Станиславский иде бит!

Әнә шундый онытылмас хатирәләр, очрашулар...

## 24. Горький белән очрашу

Мин боларның барысы турында тәртип белән язып баруны мәҗбүри дип тапмадым. Мәскәүдә булуыбызның иң кульминацион вакыйгасы бар бит әле. Бу — Максим Горький белән очрашу, сөйләшү — безгә иң көчле тәэсир иткәне, гомергә онытылмаслык булып калганы. Шуңа күрә дә мин, хронологияне бозып, үзебезнең Мәскәүдә булуыбызны шул очрашу белән тәмамлау бик урынлы, бик зарури булыр, дигән карарга килдем һәм үз вакытында игълан ителгән кайбер материаллардан да файдаланып, тулырак тасвирлауга керешмәкче булам.

Унбишенче сентябрь. Кәндезге сәгатьләр.

Галимнәрнең тормыш-көнкүрешен яхшырту үзәк комиссиясе (ЦЕКУБУ) йорты. Мәскәү язучылары белән бергә, шундагы бүлмәләрнең берсенә килеп тулдык. Кунаклар буларак, озынча өстәл тирәсенә безне утырттылар. Бүлмә әллә ни зур түгел. Хәтерлим, Мәскәү язучыларының кайберләренә урын да калмады, алар басып тордылар.

Билгеләнгән вакыттан без әлегрәк килдекме, әллә Алексей Максимович соңгардымы — моңысы истә калмаган инде. Күпмедер вакыт шулай без үзара тегене-моны сөйләштергәләп, кайбер ара тып-тын калып утырдык.

Менә безгә таныш булмаган яшь кенә, чибәр генә, мөлаем генә бер егет (шулай хәтеремдә калган) килеп керде. Мәскәүле дуслар аны ничектер олылап та, бик үз итеп тә каршы алдылар. Ул — Алексей Максимовичның секретаре Крючков икән. Бөтен бүлмәдәгеләргә баш иеп исәнләште дә, Алексей Максимовичның тиздән килеп җитәчәген белдереп, безне тынычландырды. Ә бездә бу бүлмәгә килеп кергәннән бирле, тынычлану дигән нәрсә юк инде ул, бик тә дулкынланып аны көтәбез без. Менә, менә тиздән без Горькийның үзе белән очрашачакбыз!..

Башта ук әйтеп куйыйм: мин үз хисләремне, үз кичерешләремне язам. Шәриф Камал, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали кебек олы әдипләребез өчен, Горький белән моңа кадәр дә очрашу-сөйләшү бәхетенә ирешкән Кави Нәҗми, Гадел Кутуй, Сәрвәр Әдһәмовалар өчен бу очрашу, ихтимал, ул кадәрле дулкынлануы-кичерешле булмас та. Ә минем өчен!... Мин бит аны бүген, менә хәзер бик тиздән, үз күзләрем белән беренче тапкыр күрәчәкмен, шундый тарихи очрашуда беренче тапкыр катнашачакмын...

Горький һәм мин... Өнме, төшме бу? Юк, юк! Үземне Горький белән янәшә кую, янәшә күрү ничектер мөмкин булмаган нәрсә, хәтта ниндидер гөнаһ эш сыман булып тоела димме...

Мин, ул чакта гади бер татар малае, яңа гына кулына каләм алып, хикәяләр, очерклар язып, газета-журнал битләрендә генә бастыра башлаган, әле, ичмасам, бер генә аерым китабы да басылып чыкмаган әдәбият чебеше. Ә ул әнә нинди бөек шәхес, бөтен дөньяны шаулаткан зур әдип, Ленинның якын дусты һәм көрәштәше, кыскасы — даһи кеше. Әйе, даһи! «Горькийның бөтен тормышы үзе аны даһи дип әйтергә безгә хокук бирде»,— дип яза Константин Федин... Кеше генәме соң әле ул... Аның бөтен тормыш-көрәш юлын, иҗат колачын бер юлы күз алдына китереп бастыр әле син! Аның турында төрле легендалар да сөйлиләр бит... Ул давыл хәбәрчесе, лачын, бөркет, Данко...

Күптән түгел Казандагы Горький музеенда укучылар белән очрашу булган иде. Анда Мирсәй Әмир, Сәрвәр ханым Әдһәмова, Габдрахман Минский һәм мин катнаштык. Шунда Габдрахманның чыгышыннан бер чагыштыру хәтеремдә: кеше дә үзе, кеше түгел дә кебек, шундый гаҗәеп бөек зат... 1928 елда Казанда Горький белән беренче очрашуындагы хисләрен шул мәгънәдәрәк биргән иде ул.

Шундый уйлар, шундый чагыштырулар, шундый күзаллаулар... Хәзер менә аның үзе белән очрашу... Йөрәк үз урынында түгел, күңелгә әллә нинди сәер уйлар да килеп китә. Ә кинәт... булырмы мондый очрашу, мондый бәхетле минутлар?.. Кем белә бит... Бүтән берәр ашыгыч эш чыгып, безнең белән очрашудан күп тапкыр мөһимрәк эш белән тоткарланып калса... Булыр да — Горький бит ул! Бер генә бит ул! Нинди генә җаваплы эшләр башкармый ул... Я булмаса аны берәр җитәкче оешмага ашыгыч чакырып алсалар? Булыр да — Горький бит ул! Бер генә бит ул! Аның фикере, киңәше дәүләт җитәкчеләре өчен дә бик кыйммәт ләбаса... Я булмаса нәкъ шушы минутларда бик якын, бик кадерле бер дусты аңа килеп кергән булса... Булыр да — Горький бит ул! Бер генә бит ул! Үз илебезнең төрле почмакларында дисеңме, төрле чит илләрдә дисеңме, аның бик якын, кадерле дуслары азмыни!.. Бик зур эшлеклеләр дә, бик гади кешеләр дә. Үз гомерендә бик күп сәяхәтләрендә танышкан һәркайсы аңа якын, үз...

Ниһаять, менә — ул үзе килеп керде!..

Хәзер, шушы юлларны язып утырганда, күземне йомам да, ул минутларның, секундларның һәрберен хәтерләргә, күз алдымда кабат җанландырырга тырышам.

...Алгарак иелгән (бөкрәйгән димәс идем) озын гәүдәсен чак кына сизелерлек

чайкап, салмак адымнар белән атлап килеп керде ул... Ничектер авыр атлый сыман хәтеремдә калган минем. Алтмыш еллык гаҗәеп бай һәм катлаулы гомер йөге авырлыгы белән димме, күп дистәләрчә томнарга да сыеп бетми торган бихисап иҗат җимешләрен бөтенесен бер юлы күтәреп атлый димме... Һәрхәлдә, олылык, мәһабәтлек, салмаклык хәрәкәтләре хас иде бугай аңа — аны беренче күрүдә алган тәэсирем шулайрак булды минем.

...Без барыбыз да аягүрә басып, дәррәү кул чабып каршы алдык аны. Ул исә үзенең тонык калын тавышы белән: «Кирәкмәс, кирәкмәс, кул чабуга караганда язу яхшырак» диде. Һәркайсыбыз белән кул биреп күрешеп дә, үзенә билгеләнгән урынга, түрдәге урындыкка барып утырды...

Менә хәзер шуны искә төшереп язып утырам, ә никадәр еллар үтеп китүгә дә карамастан, аның кул җылысын, һаман тоям сыман. Горький кулы җылысы, Горький кулы ныклыгы! Онытыла, җуела, суына торган түгел бу!

Горький белән бер бүлмәдә, бер өстәл тирәсендә булу, аның тавышын ишетеп, сүзләрен тыңлап утыру... Горький хәтле Горький белән бит!.. Шулай аңа, бер могҗизага караган кебек, сокланып та, шаккатып та карап утырам мин...

Ул үзенең җылы күз карашларын барыбыз өстеннән бер йөртеп ала да урындыгын үзенә тартыбрак, җайлап утыра. Аның белән янәшәдә — Һади Такташ, Шәриф Камал... Мәскәү язучылары да аралашыбрак утырганнар: Галимҗан Нигъмәти, Кави Нәҗми, Фадеев, Кутуй, Санников, Гомәр Гали, Городецкий...

Әлбәттә, Артем Багратович Халатов та шунда.

Сөйләшүләр ничектер башланып китә алмый торуын хәтерлим. Ә соңыннан... Үзара бик тиз якынаеп-үзләшеп киттек...

Шундагы хисләрне-кичерешләрне соңыннан Такташ шигъри телдә бик дөрес һәм төгәл аңлатып биргән иде:

Бер чакны без шулай Горький белән
Бер мәҗлестә бергә утырдык.
Әллә ничек аның сул ягына
Туры килде минем урындык...
Горький безнең чорның зур әдибе,
Аның даны
Бөтен планетага таралган,
Ә мин үземне бер бик кечкенә
Кеше итеп сиздем аңардан...
Башта аның белән сөйләр өчен
Зур гакыллы сүзләр эзләдем,
Тирләп беттем...
Ә соңыннан инде түзмәдем,
Башта булган гади уйлар белән
Башлап алып киттем сүземне,
Ә бераздан яхшы ук акыллы бер
Кеше итеп сиздем үземне!

Әйе, нәкъ Такташ әйткәнчә, Горький янында без барыбыз да бик кечкенә кеше булып, башта ничектер каушабрак калдык. Бу бик табигый дә, аңлашыла да торган нәрсә. Бөек кеше, дәһи кеше алдында шулай булмый хәле юк. Такташ хисләрен барыбыз да бердәй кичердек, дисәм, дөреслеккә хыянәт итү булмастыр... Ләкин чын бөеклекнең сокландыргыч үз сыйфатлары да бар икән. Горький белән очрашуда без шуны да бик тирән аңладык. Горький бер үк вакытта бөек тә, гади дә кеше. Моны күрү-аңлау өчен күп вакыт та кирәк булмады.

Сүз, хәтерем алдамаса, сорау-җаваплардан башланып киткән иде бугай. Алексей Максимович безгә, үз якташларына, күзләрен азрак кыса төшеп карап, аска таба сузылган, бөтен иреннәрен, хәтта авызын да диярлек каплап торган куе җирән мыеклары аша чак кына сизелерлек, әмма бик җылы елмаеп, зур сәяхәтебезнең ничек үтүе турында сорашты. Кыска-кыска җаваплар аны канәгатьләндерде... Я, шуннан соң тагын нәрсә? Аның аңа сорауларын көтеп торыргамы? Юк, әгәр, миңа тагын

тынып калдыгыз, дигән сыманрак бер ишарә ясап алды да, башлап үзе алдындагы чәйгә сузылды. Бер йотым эчте. Без дә шулай... һәм шуннан соң әңгәмә ничектер үзеннән-үзе җанланып киткәндәй булды. Тартынып тору бетте, ике арадагы зур аерма юкка чыкты — Горький баштагы аң-хыялыбыз җитмәстәй әллә нинди бөек заттан безнең кебек үк гади кешегә әверелде, үзара бик тиз якынлашып, Такташ әйткәнчә, үзебез дә инде аның белән рәхәтләнеп сөйләшә алырлык дәрәҗәдә үсеп киткәндәй булдык. Үзенең бөеклеге һәм гадилеге, даһилеге һәм садәлеге белән Горький үзе безне шулай үстереп җибәрде дип әйтү дөресрәк булыр һәм шул кыска очрашуның үзендә үк, Такташ әйткәнчә, бераздан үзебезне кыю да, яхшы үк акыллы да итеп сизә башладык...

Горький безнең алдыбызда речь тотмады, әлбәттә. Җанлы әңгәмә тәсендә, бүленә-бүленә, сорау-җаваплар белән аралаша-аралаша барды безнең сөйләшүләр. Шулардан нык истә калганнарын гына бергә тезеп әйтеп бирергә тырышып карыйк.

Горький татар әдәбияты белән бик үк таныш түгеллеген әйтеп, хәтта гафу үтенгән сыман да булды. Бу — аның бүгенге, ягъни революциядән соң туган безнең әдәбиятка карата әйтелгән сүзләр иде. Моңа ул түгел, ә без үзебез гаепле, әлбәттә. Чөнки тәрҗемәләр юк дәрәҗәсендә! Әмма элекке әдәбиятыбыздан яхшы ук хәбәрдар булуын белдереп, Габдулла Тукай исемен башлап телгә алды һәм бездә аның кебек зур талантлар барлыгын белә икәнен шунда ук аңлап алырга мөмкин иде. Җитәкчеләребез сүзгә кушылып китеп, бүгенге татар әдәбияты турында кыскача гына мәгълүматлар биреп өлгерделәр.

Ул исә, әйтелгәннәргә йомгак ясагандай итеп, гомумән илебездәге пролетариат әдәбиятының, совет әдәбияты-сәнгатенең, совет культурасының бер сызыктан, интернационализм юлы белән үсүе өчен шартлар тудырылган булуын әйтте, тик моны тормышка дөрес итеп ашыру өчен көчне аямаска кирәклекне дә кисәтте. Безнең классик һәм хәзерге язучыларыбызның иң яхшы әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп, аерым бер җыентык чыгару кирәклеге турындагы фикерен дә өстәп әйтте. Шунда ук иптәш Халатсвка, «Страна Советов» журналына Дәүләт нәшрияты тарафыннан СССР халыклары иҗаты өчен бирелгән мең табак урын турында, бу журналның шул күп милләтле иҗатны, димәк, татар әдипләре иҗатын да, тиешенчә чагылдыру эшенә игътибар бирүе кирәклеген исенә төшерде.

Безгә мөрәҗәгать итеп, үз халкыгызның яхшы традицияләрен һәм культура байлыкларын совет культурасының гомуми байлыгы итегез, диде. Үз халкыбызның тормышы, көрәше, уй-фикере, кайгысы-шатлыгы, үзләре белән бергә яшәүче бүтән милләт халыклары белән татулык һәм дуслыкта яңа тормыш төзү эшендә ничек катнашулары турында күбрәк язарга киңәш бирде, яхшы, оста язылган шундый әсәрләр белән рус теле аша киң дөньяга чыгарга өндәде. Кыскасы, татар әдәбиятының — поэзиясенең һәм прозасының балкып чәчәк атуын ихлас күңелдән бик теләвен дә, әмма моңа ирешүнең әдәбият алдына куела торган зур бурычларга фәкать җитди, таләпчән мөнәсәбәт нәтиҗәсендә генә мөмкин икәнлеген кисәтә торуын да без һәрбер сүзе — хәрәкәте саен тулысынча аңлап утырдык.

...Безнең мәңге онытылмас бу очрашуыбыз күпмегә сузылгандыр, хәзер инде аның сәгатьләрен, минутларын һич тә хәтерләмим һәм моның кирәге дә, әһәмияте дә юк дип саныйм. Бик кыска булды, сизелмичә үтеп тә китте кебек ул. Һәм шул ук вакытта ул минем күз алдымда һаман җанлы булып та тора һәм туктаусыз дәвам итә сыман да... Бөек кешеләр белән очрашу чыннан да шулай була икән ул.

Мин тик шуны хәтерлим: Горький әллә ни күп сөйләмәде кебек, күбрәк сорашты, ә сорауларга бик теләп, бик тулы җаваплар бирде. Гомумән, аның күп сөйләргә яратмавы, сүзгә һәвәс булмавы киң мәгълүм. Петроград советы утырышындагы бер чыгышында (1920 ел, 20 апрель) үзе үк «Минем ораторлыгымның рәте юк, мин сүз белән түгел, йөрәгем белән сөйлим» дигән иде. Нәкъ менә аның шулай йөрәге белән сөйләгәннәре безгә күбрәк тәэсир итте, күбрәк истә калды.

Ул бит рухи яктан бездә, Казанда туган, безнең халык турында бик җылы итеп, мәхәббәт белән язган. Аның татар халкы турында аерата хөрмәт итеп, яратып әйткән сүзләре безнең колакта яңгырый. Татар халкын бала чагыннан ук якыннан белүен, аларның аек акыллы, хезмәт сөючән, пөхтә, яхшы, җылы, йомшак күңелле һәм максатка ирешүдә нык характерлы булуларын әйткәне дә безгә билгеле. Ә бу очрашуда

ул йөрәге белән безгә тагын бик күп нәрсә сөйләде һәм күп нәрсәгә өйрәтте. Зур йөрәкле, олы җанлы бу әдипнең, даһи кешенең бөтен тормышы, көрәше, киң колачлы сугышчан иҗаты — аның безгә сөйләгәннәре шулар. Аның шундый тирән, юмарт, йөрәктән чыккан ялкынлы, тылсымлы иҗат җәүһәрләре безне тормыш юлын ничек үтәргә дә, искелеккә каршы яңалык өчен ничек аяусыз көрәшергә дә, үз иҗатың белән халыкка, Ватанга ничек турылыклы хезмәт итәргә дә, социалистик реализм принципларына нигезләнгән бу иҗатның югары баскычларына ничек күтәрелергә дә — тагын бик күпкә, бик күпкә өйрәтте һәм өзлексез һаман өйрәтә килә. СССР язучыларының беренче съездында ук әле татар әдәбияты турында махсус доклад ясауны оештыручы да Горький булды бит.

...Мин тагын үзебезнең Казандагы Горький музеена барам. Андагы «Горький һәм татар әдәбияты» бүлеген ничәнче тапкыр инде карыйм, элекке һәм бүгенге олы һәм урта буын язучыларының рәсемнәрен, иҗат иткән китапларын күрәм. Гафур Колахметов һәм Гомәр Бәширов, Галимҗан Ибраһимов һәм Афзал Шамов, Һади Такташ һәм Сибгат Хәким, Шәриф Камал һәм Мирсәй Әмир, Кави Нәҗми һәм Габдрахман Әпсәләмов, Галимҗан Нигъмәти һәм Ибраһим Гази, Галиәсгар Камал һәм Хәсән Туфан, Гомәр Гали һәм Мөхәммәт Гайнуллин, Кәрим Тинчурин һәм Риза Ишморат, Гадел Кутуй һәм Габдрахман Минский, Таҗи Гыйззәт һәм Сәрвәр Әдһәмова... күп алар, зур бер залны тутырып-баетып торалар. Һәркайсының Горький турындагы җылы сүзләре, үз иҗатларына аның игелекле йогынтысы, аны үзләренең якын дусы һәм зур остазы итеп танулары, аңардан өйрәнүләре кыска итеп, конкрет фактлар китереп язылган. Бу бинада мин, хәзер инде бүгенге барлык каләмдәшләрем белән дә бергә, Горький белән әлеге тарихи очрашуыбызның дәвамын күрәм. Бу очрашуның бүген дә, иртәгә дә, алдагы буын язучыларыбыз белән дә шулай туктаусыз гел дәвам итәчәгенә тулысынча ышанган хәлдә, язмаларымны шушында тәгәлләргә дә мөмкин икән дип, эчке бер канәгатьләнү белән ахыргы ноктаны куям.

1968—1972.

# ГАЛИМ, ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Үзләренең хезмәтләре белән халкыбызның мәдәният һәм әдәбият тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәрне без хөрмәт белән искә алабыз. Шундый кешеләр арасыннан иң беренче итеп бөек әдип, галим һәм күренекле җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовны, талантлы тәнкыйтьчеләребездән Галимҗан Нигъмәти белән Гомәр Галиләрне, татар әдәбияты тарихын өйрәнү буенча зур эш башкарган Габдрахман Сәгъдиләрне искә алырга кирәк. Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң татар әдәбият белемен үстерүдә тарихи әһәмиятле эш башкарган бу беренче буын галим һәм тәнкыйтьчеләр кулыннан эстафетаны Мөхәммәт Мамин, Гази Кашшаф, Гали Халит, Хәсән Хәйри, Якуб Агишев, Габделхәй Хисмәтуллин кебек әдәбиятчылар кабул итеп алдылар. Ибраһимов һәм Нигъмәтиләр буыны эстафетасын бик хаклы рәвештә үз кулларына алган, аны тагын да алга алып киткән бу икенче буын әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре арасында яшь әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин да бар иде...

Мөхәммәт Гайнуллин 1903 елның 18 августында Казан губернасының Тәтеш өязе, Коллар авылы (хәзерге Татарстан АССРның Апас районы, Кызылтау авылы) крестьян семьясында туа. Авыл мәктәбен уңышлы тәмамлаганнан соң, аны укытучылар хәзерләү курсларына җибәрәләр. 1920 елда 17 яшьлек егет авыл мәктәпләрендә укытучы булып эшли башлый. Күпмедер вакыттан соң ТатЦИК каршында оештырылган кыска сроклы курсларда була, шунда беренче тапкыр әдәбият галимнәрен һәм язучыларны күрә. 1931 елда ул Казан Көнчыгыш педагогия институтын тәмамлый, бер елдан үзе дә институтта татар әдәбияты һәм әдәбият теориясе буенча студентларга лекцияләр укытуга керешә. Шушы ук институтта аспирантура тәмамлый. Соңрак республика газеталарында аның беренче мәкаләләре басыла башлый. Шулай итеп Мөхәммәт Гайнуллин фән дөньясына килә.

Бөек Ватан сугышы елларында партиянең Татарстан өлкә комитеты аны китап нәшриятына эшкә җибәрә, ә 1944 елда ул Татарстан тел, әдәбият һәм тарих гыйльми-тикшерену институтының директоры итеп билгеләнә. 1945 елның ахырында, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы оештырылгач, бу институт филиал составына кертелә һәм М. Гайнуллин 1945—1953 һәм 1959—1961 елларда шушы институтның директоры булып эшли.

...Авыр һәм дәһшәтле Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соңгы беренче тыныч көз иде. Без — яңа гына урта белем алган унҗиде яшьлек егетләр — шул елда студент дигән зур дәрәҗәгә лаек булдык. Сугыш елларында алган белем чамалы... Нишлисең бит... Яңа чор — тыныч төзелеш чоры башлана. Хәзер югары уку йортлары тулы булырга тиеш! Билгеле, шуларның барысын исәпкә алып булса кирәк (әле фронтовиклар да кайтып җитмәгәні), безне — авызларыннан ана сөте дә кибеп җитмәгән «сары томшыкларны» — югары уку йортларына бик теләп кабул итәләр иде... Укытучыларыбыз арасында гаҗәеп җитез хәрәкәтле, энергияле, үз фәнен эсте аңлата торган ачык йөзле Мөхәммәт абый да бар иде. Беренче семестр сизелми генә



үтте кебек. Һәм менә без — Казан педагогия институтының дүрт студенты — 1946 елның январь кичендә үзебезнең Мөхәммәт абый янына килдек. Исәп — имтиханны срогыннан алда тапшыру һәм берничә көн генә булса да иртәрәк авылга, әти-әниләр янына, җылыга һәм, иң әһәмиятлесе, карточкасыз тамак туйдырырга мөмкин булган җиргә кайту иде...

Ул вакытлардан соң ничә еллар узды инде. Ләкин әлегә кадәр без керган бинаның (хәзер Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты) өченче каты коридорындагы стена газетасы иселе астындагы «ТНИИЯЛИ»[1] дигән сүзне тегеләй дә, болай да боргалап, тулы мәгънәсен озак вакытлар ачыклый алмый торганыбыз истән китми.

Хәзер мин Мөхәммәт аганы көн саен диярлек күрәм һәм күргән саен аның нәә шул еракта калган еллардагы кебек үк энергияле, җитез, хәрәкәтчән, ачык күр тавышлы һәм киң күңелле булуын күреп сокланам. Ул бит нәкъ шул елларда үзенең иң актив һәм нәтиҗәле гыйльми эшчәнлеген башлап җибәрде һәм бүгенгә кадәр шулай дәвам итә!

1946 елда Мөхәммәт ага «XIX йөзнең ахыры һәм XX йөзнең башындагы татар әдәбияты буенча эзләнүләр» дигән темага диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1947 елда ул, Җ. Вәзиева белән бергәләп, югары уку йортлары өчен «XX йөз башы татар әдәбияты» дип аталган зур күләмле дәреслек-хрестоматия бастырып чыгара.

Мөхәммәт ага Гайнуллин әдәбият фәне өлкәсендәге беренче адымнарыннан алып хәзерге көнгә кадәр татар әдәбиятының байлыгын туплау һәм өйрәнү өлкәсендә гаять зур эш алып бара. Әдәбиятыбызның Каюм Насыйри, Закир Һади, Заһир Бигиев, Миргазиз Укмасый, Шакир Мөхәммәдев, Дәрдмәнд, Сәгыйть Рәмиев кебек күренекле вәкилләренең тормыш һәм иҗат юллары турындагы бик күп яңа материалларны ул беренче буларак фәнни әйләнешкә кертә, аларның биографияләрен ачыклый, бу язучыларның әсәрләрен туплап чыгара. Шулар белән бергә, тәрҗемә өлкәсендә Октябрьга кадәр зур эш алып барган Габделмәннан һәм Солтан Рахманкуловлар, театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрәм, татар шагыйрәләре З. Сәгыйдә, М. Мозаффария, З. Бурнашева, М. Акчуриналар М. Гайнуллинның тырыш хезмәте белән әдәбиятыбыз тарихында үзләренең урыннарын таптылар. Ул татар һәм рус телләрендә басылып чыккан «Татар поэзиясе антологиясе»н хәзерләүдә дә зур эш күрсәтте.

Мөхәммәт ага Гайнуллинның бөтен иҗат юлы буенча кызыл җеп булып сызылып килгән бер тема бар. Ул — халыклар дуслыгы идеяләренең әдәбиятта чагылышы, тугандаш әдәбиятларның үзара йогынтылары һәм бер-берләренә тәэсир итеп баюлары. Шуның беренче ачык мисалы итеп Мөхәммәт ага тарафыннан бөек пролетариат язучы Алексей Максимович Горький һәм татар әдәбияты дигән зур теманың шактый тулы итеп ачылуын күрсәтергә кирәк. Китапны басып чыгару өчен тәкъдим иткән рецензиясендә Кави Нәҗми бу хезмәтнең бик актуаль һәм кирәкле булуына аерата басым ясаган иде. Китап басылып чыккач, күренекле совет әдәбият галиме, СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Н. Пиксанов аның авторына 1944 елның 29 августында махсус хат яза. «Сездән үрнәк алып, башка тугандаш республика әдәбиятчылары да шушындый китаплар чыгарсалар, бик яхшы булыр иде»,— ди ул үзе-

[1] ТНИИЯЛИ — татарский научно-исследовательский институт языка, литературы и истории.— Ред.

нең хатында. М. Гайнуллинның «В. Г. Белинский һәм татар әдәбияты тәнкыйте», «Гоголь һәм татар әдәбияты», «Лев Толстой һәм татар әдәбияты», «Н. Г. Чернышевскийның татар телендәге кульъязмалары», «Пушкин һәм татар әдәбияты», «Татар совет әдәбиятында халыклар дуслыгы», «Чынлык көче», «СССР халыкларының әдәбиятлары арасындагы элемтә һәм бәйләнешләр турында» һ. б. хезмәтләре дә аның иҗади-фәнни эшчәнлегендә зур урын алган әлеге проблемага багышланганнар иде.

М. Гайнуллинның «Беренче рус революциясе чорындагы татар әдәбияты һәм публицистикасы» дигән зур күләмле, тирән эчтәлекле хезмәте татар совет әдәбият белемендә гаять күренекле өлеш булып керде. Шушы хезмәтен ул 1958 елда СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында докторлык диссертациясе итеп яклады, шул нигездә 1966 елда рус телендә аның зур күләмле китабы басылып чыкты. Мәскәү һәм Казан вакытлы матбугатында М. Гайнуллинның бу китабы югары бәя алды.

СССР Язучылар союзы члены, Татарстан АССРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Хәйрулла улы Гайнуллинның гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлеге бик күп төрле. Ул Азия һәм Африка халыклары белән дуслык җәмгыятенең Совет комитеты члены буларак та танылган кеше. Ул хәзергә кадәр СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми сотруднигы буларак зур фәнни эш алып бара, фәнгә яшь кадрлар тәрбияләүдә актив катнаша. Шул ук вакытта тагын никадәр кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклау вакытында официаль оппонент буларак чыгышлар ясый...

Күрәсез: никадәр хезмәт! Берничә галимнең бөтен гомеренә җитәрлек темалар, проблемалар, әһәмиятле мәсьәләләр! Менә шуларның барысына да Мөхәммәт аганың кулы җитешкән. Аның һич иренмичә һәм бер урында таптанып тормыйча, фәндә һаман якты перспектива белән янып яшәвенә, дәртле иҗат итүенә сокланмый калып булмый.

Менә берничә айдан аның күп милләтле тугандаш совет әдәбиятларының үзара аралашып баюлары, татар әдәбиятының СССР халыклары әдәбиятлары белән дуслыгы һәм татар совет әдәбиятының традицияләре һәм новаторлыгы мәсьәләләрен яктырткан «Дуслыкта — көч» исемле яңа китабы басылып чыгачак.

Мөхәммәт ага Гайнуллинның киләчәккә планнары зур. Ул тырышып эшли. Аның яшьләрчә дәртлелеге һәм җитезлегенең, өлгер булуының да төп сәбәбе — ару белмәс иҗади эшчәнлегендә, ахрысы...

**Нур ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.**

**Мөхәммәт Гайнуллин,**
филология фәннәре докторы

# ДӨНЬЯВИ ӘСӘРЛӘР ЭЗЕННӘН

Билгеле булганча, татар әдәбиятында дөньяви мотивлар XIX йөзнең урталарыннан аеруча көчәеп китә. Киң күпчелеккә аңлаешлы телдә язылган реалистик әсәрләр нәкъ шул чорда күбәя башлый. Ләкин заманының әһәмиятле мәсьәләләрен күтәргән реалистик әсәрлар элегрәк тә булган икән. Шундыйларның берсе төсендә 1879 елда Казан университеты типографиясендә басылган, ләкин халыкка таратылмыйча калган «Мәкәрҗә бәете» исемле әсәрне күрсәтергә мөмкин.

Шунысы кызыклы, университет нәшриятында аерым китап булып чыкканчы ук бу әсәр рус җәмәгатьчелегенә дә билгеле булган. Әле 1860 елда ук, ягъни китап булып басылудан 19 ел элек, Н. А. Некрасов редакциясендәге «Современник» журналында бу хакта киң генә мәгълүмат бирелә. Бәетнең русчага тәрҗемәсеннән аерым өзекләр китергәннән соң, мәкалә авторы П. И. Пашино түбәндәге аңлатманы китерә:

«...Есть муллы смиренники, говорящие всегда в полголоса, глаза опуская долу. Жизнь их однообразна и тиха. Народ любит таких мулл и питает к ним большое уважение. Не думайте, что это были ханжи, это поэты, это люди, вполне чувствующие свое положение и постоянно готовы на горячую и откровенную беседу.

Раз свела судьба меня с подобным человеком... он... показал мне свои труды. Это были стихи на различные эпохи жизни деревенской: на рекрутчину, на подати, сатиры на различных мулл, на писаря и т. д.... Он написал в стихах все тягости, которые народ терпит от ближайших властей, начиная со станового и ниже. Поэма или как хотите назовите ее, начинается тем, что он просит снисхождение у читателей к себе, потом сравнивает нашу жизнь с нижегородской ярмаркой и доказывает старую истину: что посеешь, то и пожнешь или как у него выражено: посеявши ячмень, не соберешь пшеницы» [1].

Чынлап та, әсәрнең беренче өлеше Мәкәрҗә ярминкәсендәге төрле хәлләрне сурәтләү белән башлана. Шуңа охшатып, шагыйрь үз заманы кешеләренең дөньядагы хәле хакында сөйләүгә күчә.

Авторның төп игътибары гади кешеләр тормышына юнәлтелгән, ул кешеләрдә яхшы сыйфатлар тәрбияләргә омтыла. Шагыйрь кешеләрне бер-берләренә яманлык кылмаска, тырыш булырга, һәр яхшыдан үрнәк алырга өнди:

**Золымлык кыйлмагыл һәргиз [2] кешегә,**
**Гадаләт әйләгел һәрбер кешегә,**
**Төн, көн иҗтиһад кыйл яхшылыкка,**
**Яманлык кыйлмагыл һичбер халыкка.**
**Халыкның изгесен күреп нәргел,**
**Яманнарны күреп гыйбрәт алгыл...**

---

[1] П. И. Пашино. Волжские татары. «Современник» журналы. 1860 ел. 81 том, 255 бит.

[2] һәргиз — бервакытта да.

Поэманың төп өлеше үз заманының тискәре күренешләрен реалистик чагылдыруы һәм патша чиновникларын ачы тәнкыйть итүе белән әһәмиятле. Без монда, татар язма әдәбиятында беренче буларак, социаль теманың күтәрелүен, патша Россиясендә халык кичергән газаплы тормышның поэзиябездә ча¨ыла башлавын күрәбез. Язучы гади һәм үткен чагыштырулар белән халык җилкәсендә яшәүче патша түрәләренең чын йөзен укучыларның күз алдына китереп бастыра:

Бу өязне кыйлыблар өчкә кыйсмәт [1],
Аны кыйсмәттә бар әлбәттә хикмәт...
Куеплар анлар үзә бер әмирне,
Иза кыйлыр сагыйрь вә һәм кәбирне [2],
Куеплар хаким идеп аны, и яр,
Гаҗәп залыйм ирер мәккярь, гаяр.
Атаплар аның адыны пристав,
Төн, кон кыйла халык андан тәэссеф.
Белә алмаймын аларның исмене һич,
Мәгәр бере Фулкин Алексей Федорич.
Золымлыкта барыннан әкмәледер [3],
Җинаятьтә барыннан әгъләмедер...[4]
Аны куюдан морат халыкка әмандыр [5],
Вә ләкин бонларның фигыле ямандыр.
Кайчан яз көне ирешсә халыкка,
Җыядыр иманадин йомырка.
Дәхи җәй җитсә җыядыр — тәкәләр,
Тәкә булмаса, сарыкларны илтәләр.
Аның өчен дәхи акчаны җыялар,
Илтеп ул акчаны анда куялар.
Аның бу эше имәс елда якъбар [6],
Кыйла бәлкем аны тәкрар, тәкрар.
Аның бүләк дип алганларыны
Имәс мөмкин бәян итмәк барыны...
Әгәр хаҗәт булып җыйса ул стан,
Гүя галәм аның кашында ристан.
Кыйла угрыйларә шәфкать, химая
Ата-анасидән бәлкем зиядә...
Гарыз кыйлсаң [7], сүзең ятып каладыр,
Залыймгә һич хөкем булмай каладыр.
Хакимләр үзләре кыйлса яманлык,
Рәгыятьтә [8] кайчан булгай әманлык.
Аның хезмәтендә бардыр хадимнәр,
Һәммәсе бер беридән артык залыймнәр.
Өязгә чыкмага боера аларга,
Халык арасыйдан фетнә табарга,
Чыкып йөри алар эт кеби искәп,
Халаекъ арасыйдан фетнә эстәп.
Әгәр бүләк бирә алмаса бер инсан,
Кыйлалар бәс аңа кизәб вә бөһтан [9],

---

[1] Кыйсмәт — бүлеп.
[2] Сәгыйрь вә һәм кәбирне — кечеләрне дә, олыларны да.
[3] Әкмәледер — иң зурысы, көчлеседер.
[4] Әгъләмедер — остарагыдыр.
[5] Әмандыр — тынычлык, иминлек урнаштырудыр.
[6] Якъбар — бер мәртәбә генә.
[7] Гарыз кыйлсаң — үтенеч белән керсәң.
[8] Рәгыятьтә — җәмәгатьчелектә.
[9] Кизәб вә бөһтан — ялган һәм яла.

Бәс ул кешене чакыртып аладыр,
Аның башына фетнәне саладыр.
Боның дик эшләрнең хисабы юкдыр,
Барып әйтергә һис имканы [1] юкдыр.
Боның лә фәһем итәр бәс фәһме камил,
Шуның лә хәлне аңлар гаклы камил...
Хәраҗ [2] вакты кайчан җитсә түләргә,
Гавам халкы җитәләр бәс үләргә.
Җыелып киләләр һич берсе калмай,
Һич эшне кыйлмайлар акчаны алмай.
Алып акчаны үз янына салалар,
Бәс андин соң имананы алалар.
Бөтен казны салалар тиз пешәргә,
Арыш маен алалар һәм эчәргә...
Бирә алмасак теләгән нигъмәтне,
Таба алмасак сораган ришвәтне,
Орып-сугып тәмами рәнҗетәдер,
Зәгыйфь улып яки үлеп китәдер.

Бу строфаларда патша түрәләренең, аерым алганда, приставның характерлы сыйфатлары шактый тулы күрсәтелә. Әсәрнең икенче урынында шул чорның судьялары хакында да ачы тәнкыйть сүзләре бар. Язучы аларның эш белмәүләреннән, писарьлар нәрсә язса, шуңа кул куеп утыруларыннан көлә. Ахырдан мондый нәтиҗә чыгара:

Бу эшләр халыклара олуг бәладер,
Боның лә күп халыклар мөбтәладер.
Әгәр кыйлсак болар хәлен хикаять,
Мәлал кәлер [3], озын булыр шикаять.
Фәһемле кемсә сүзне камил аңлар,
Гакыллы кемсә аздин күпне аңлар.

Шулай итеп, автор әле барын әйтеп бетермәвен дә искәртә. Шуның белән бергә, ул түрәләрнең җинаятьләрен югарыда белмиләрдер дип уйлый, патшага һәм аның сенатына ышанып карый. Китабын түбәндәге строфалар белән тәмамлый.

Әгәр белсә иде моны олуглар,
Гакыл, фәһем, фирасәтлә [4] тулуглар,
Риза булмаслар иде бәс бу эшкә,
Сапырларды (иде) залыймнәрне бер эшкә.
Әгәр белсә иде моны министр,
Ясар иде бу эшкә бер реестр.
Рәгыятькә [5] кыйлырды мәрхәмәтне,
Кыйлырды бәс бу эшкә мәслихәтне.
Әгәр белсә иде моны сенатлар,
Падишаһ хәзрәтендә кул, канатлар,
Кайчан разый булырлар ды бу эшкә,
Гаҗәп хәйран калырлар ды бу эшкә.
Әгәр белсә иде моны үзе шаһ,
Кәмал шәфкатендән дир иде аһ,
Кыйлыр иде залимнәргә сәясәт,
Белер иде бу эшне бик кабахәт.

---

[1] Имканы — мөмкинлек.
[2] Хәраҗ — имана, налог.
[3] Мәлал кәлер — күңелсез булыр.
[4] Фирасәтлә — тапкырлык, зирәклек белән.
[5] Рәгыятькә — халыкка.

Шундый строфалары булуга карамастан, төп өлешендә патша түрәләренең халыкны талауларын ачыктан-ачык күрсәтеп язган бу китап беренче нәүбәттә Казан губернаторына ошамый. Ул аны зарарлы дип таба, басылып чыккач, таратудан туктата.

Ленинградта Үзәк тарих архивында сакланган материаллар арасында бу китапның һәм кульязмасы, һәм басылган бер данәсе бар. Шунда әсәрне басарга рөхсәт биргән Казан цензоры Ф. Саррурның матбугат комитеты исеменә язган аңлатма язуы да саклана. Ул да җавапка тартылган була. Саррур үзенең 1879 ел 30 август датасы куелган аңлатмасында поэманың нәкъ соңгы строфаларына таянып, ни өчен басарга рөхсәт бирүе турында түбәндәге җөмләләр белән аклана:

«Имею честь объяснить Цензурному комитету, что в задержанной г. Казанским губернатором татарской брошюры, изданной в текущем году под заглавием «Макарижe бейте»... я не мог усмотреть таких оснований, по которым можно было бы запретить издание этой брошюрки, так как она не содержит в себе ничего ни против христианства, ни против высочайших особ или правительства...

Нельзя при том не обратить внимания и на то, что, указав на злоупотребление и противозаконные действия каких-то нижних чинов — писарей и одного пристава брошюрка очень ясно и пространно разъясняет ту законную, благонамеренную и добросовестную цель, служить которой эти люди были назначены местным начальством»[1].

Цензор акланса да, китапка барыбер рөхсәт бирелми. Бу поэма үз чиратында татар әдәбиятында XIX йөзнең урталарында ук социаль эчтәлекле әсәрләрнең туа башлавын ачык күрсәтә.

* * *

Шул рәвешчә, XIX йөз татар әдәбиятында дөньяви эчтәлекле китаплар шактый күп була. Шунысы характерлы, бу китаплар үзләренең исемнәре белән турыдан-туры дини-дидактик темаларга карый, баш бүлекләре аларның дини-этик мәдхияләрдән тора. Ләкин соңга таба дөньяви мәсьәләләргә һәм хәтта социаль күренешләргә багышланган аерым бүлекләр башлана. Мисал өчен 1899 елда Казанда басылган бер китапны алыйк. Шигъри формада традицион стильдә язылган бу китап «Мәрхәбә шәһри рамазан һәм тәравих тәсбихләре» дип атала.

Китапның алдагы бүлекләре гадәттәгечә дини эчтәлекле, ә «Вә гайре гыйбрәтләр чуктыр игътибар әһленә» дип аталган соңгы бүлекләрне автор аеруча мәхәббәт белән язган. Ул бу бүлекләрне укучылар үзенә бер дикъкать белән укырлар дип ышана. Чыннан да, бу әсәрдә үз вакытындагы мораль-этик мәсьәләләрне һәм төрле социаль төркем кешеләренең үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган урыннар бик кызыклы. Анда «Бер мәнзум дилкәша вә бер газәл гыйбрәтнамәдер»[2] дип аталган бүлек бигрәк тә характерлы. Бу бүлек дөньяга һәм, бигрәк тә Байлыкка, үз мәнфәгатьләреңнән чыгып кына карауның зарары турындагы хикәяләр белән башлана. Авторның фикере буенча, барлык тискәре сыйфатлар (караклык, дошманлык, бер-береңне хурлау, канәгатьсезлек, хыянәт һ. б.) бу дөньяга үз мәнфәгатьләреңнән генә чыгып караудан һәм байлык артыннан куу аркасында килеп чыга.

Язучы, барлык сыйныф кешеләренә гомуми бәя биргәннән соң, үзенең фикерләрен ныгыту өчен һәр социаль группага аерым бүлек багышлый. Эшсезлектән җәфа чигеп хәерчелеккә бирелергә һәм базарларда, урамнарда төркем-төркем йөрергә мәҗбүр булган фәкыйрьләр турында автор болай яза:

**Фәкыйрьләр би хәя булган, оят капчыгы ертылган,**
**Теләнчилә җиһан тулган, имәс мәстүр[3] ки аңлардан**
**Йөрерләр күчә бәкүчә[4] ки көндезләрдә вә кичә,**

---

[1] ЦГИА СССР. 777 фонд. 3 тасвирлама. 4 бит.
[2] Бер мәнзум дилкәша — иситкеч сокландыргыч бер шигырь.
[3] Имәс мәстүр — котыла алмый.
[4] Күчә бәкүчә — урамнан урамга.

Калыр булсаң ки күрмичә, угырлар мәтаглардан [1],
Күрер күзгә зәгыйфь улыр, кыяфәте нәхиф [2] улыр,
Вәла көчле зариф улыр вә дәкләү пәһлуаннардан.
Әгәр очраса аулакка ки ягъни кеше юк чакка,
Биреп җибәрсә яңакка, екылырсың аяклардан.

Шуннан соң автор авыл халкының — крестьяннарның хәле һәм аларның эшләре турында язуга күчә. Беренче строфаларда ул крестьян хезмәтенең файда китермәвен әйтә, аннан соң крестьяннарның хәтта намаз укырга да вакытлары юклыгы турында сөйли һәм шунда ук аларның җавапларын китерә:

Язием диһканнардан бер хәбәр:
Аңлар арасыда нәдер шур вә шәр [3].
Бәрәкәт юктыр аларның эшидә,
Кыйлми намаз иртә, кичтә, төшидә.
Кер диерсәң, кыйл намазың, и фәлан,
Сиңа дөшнам әйләер ул бәд гөман [4].
Диер: беземдәй эшләсәң сән бу эши,
Сән дә булмассың намаз укыр кеше.
Кайда намаз мондый каты эш ара,
Бу сүзи чирканмый да йөзе кара...
Һәр дәм эш эшли, тамагы туймыйдыр,
Мәнһи булган [5] эшләрне һич куймыйдыр.
Гошереңне бир дисә имам анларә,
Дөшерер имамны бәд намләрә [6].

Диалог формасында язылган бу строфаларда крестьяннарның шул чордагы тормышы-көнкүреше һәм аларның руханиларга мөнәсәбәте сурәтләнә. Беренчедән, автор крестьян хезмәтенең авырлыгы турында әйтә һәм, көне-төне эшләүләренә карамастан, алар ач яшиләр, ди. Икенчедән, ул крестьяннарны дини йолаларны үтәмәүдә һәм муллага дип кушкан гошерне бирмәүдә гаепли төсле. Ләкин шунда ук аларда дини йолаларга һәм паразитик тормыш алып баручы руханиларга нәфрәт көчәюе турында искәртә. Крестьяннарның әлеге күренешләргә булган нәфрәтен күрсәтеп, ул болай яза:

Диер: безем мулла ни каты сүзледер,
Эшләмичә баймакны күзлидер.
Җиремез гошри түгел диер безләрнең,
Тик ятып алмакка ачма күзләрең.

Бу юллар һичшиксез авыл хезмәт халкының нәфрәте булып яңгырый.

Автор галимнәрнең гади халыкка үрнәк булырлык гүзәл сыйфат ияләре булуларын күрергә тели. Аның фикеренчә:

Галимнәр чөнки дөньяның хасыдыр [7],
Алар азмаса, җиһан азмастыр.
Алардыр моктәда биһ [8] һәр рәвештә,
Торышта, утлырышта һәм йөрештә.

---

[1] Мәтаглардан — әйберләрне, чемоданнарны.
[2] Нәхиф — ябык.
[3] Шур вә шәр — яхшылык һәм яманлык.
[4] Дөшнам әйләер ул бәд гөман — сүгенеп ташланыр ул — ышанычсыз.
[5] Мәнһи булган — тыелган.
[6] Бәд намләрә — хурлыларга, дансызларга.
[7] Хасыдыр — сайланганнардыр.
[8] Моктәда биһ — алдынгылар.

**Алар булмаса иде хәссад вә тәммаг[1],**
**Булырды җир йөзендә нур лиммаг[2].**

Монда автор тормыштагы тискәре күренешләрне бетерүдә, үзенең мәгърифәтчелек карашларыннан чыгып, тәрбия эшенә зур әһәмият бирә, тәрбиячеләр үзләре дә тәрбияле булырга тиешлеге турындагы гуманистик карашны яклый. Ләкин автор тәрбиячеләр киеменә төренгән һәм үзләрен галим дип саный торган мулла-мonтагайлар арасында андый кешеләрне тапмый.

Китапта без хосусый милекчеләрнең, байларның комсызлыгын, икейөзлелеген тәнкыйть итә торган түбәндәге юлларны укыйбыз:

**Кәлде сүзем әйтмәгә бәс әгънәя утагына[3],**
**Ниләрем кара төшәдер аңларның агына...**
**Шөкер итәмез һәм канәгать кыйламыз бу дәүләтә**
**Дәюбән әйтмәкләре үз-үзләрен алдау гына.**
**Шөкер улдыр — малны хак кушкан җиргә сарыф әйләмәк,**
**Бонлара мал масрафы ат, тун, хатын, пулат кына.**
**Мәсҗед, мәдрәсәләр бина кыйлыр шөһрәт өчен,**
**Ни дисеннәр ошбуларны ул фәлән салган гына,**
**Шуныңчын күп бина кыйлырлар олуг юллара,**
**Чөнки күрә ул эшине һәр узып барган гына.**

Китапның ахырында автор үзе турында да кайбер мәгълүматларны бирә һәм башкаларга карата әйтелгән тәнкыйть фикерләре, беренче чиратта, үзенә карый ди:

**Мулькай Юмачиков минем атым,**
**Үләң менән[4] перват язган хатым...**
**һәр каю таифәдә улган гамәл**
**Мәндәдер, хакымда бел һәза әзал(л)[5]**
**Чүк пернишанлык илә язан буны**
**Бер фәкыйрь, хәкыйрь адәмләр азгыны.**
**Рәхмәтеңдән күз тотып һәр сабах вә шам[6].**
**Кыйлдым әтмам, барчага дидем сәлам.**

Шигъри формада «Исерек хәлләре бәянында гыйбрәтнамә, ягъни исерткеч эчкән кешегә үгет, насыйхәт вә гыйбрәт» исеме белән язылган һәм 1896 елда Казан университеты типографиясендә басылган тагын бер китап бар. Китапның авторы күрсәтелмәгән. Фәкать сүз башында: «Бу бәетләрне моннан егерме биш ел элек исерткеч эчемлекләрне ташлаган бер бәхетсез язды» дигән сүзләр генә бар. Ләкин моны бу бәхетсез автор үзе икән дип аңларга ярамый. Бу авторның укучыларга тәэсирне көчәйтү өчен генә язган сүзләре. Аның бу алымы яңа да, шул чордагы татар әдәбияты өчен уңышлы да.

**Эчкәнгә исерткеч агу,**
**Эчмәгәнләргә дару:**
**Бераз аның кыйссасыны**
**Сезгә сөйләргә могу,—**

дигән строфалар белән башланган бу китапта «Эчкечелекнең башы», «Яңа эчә башлаганда», «Эчемлектән авыру тиюе», «Эчеп эштән чыгу» исемле бүлекләр бар. Бу

---

[1] Хәссад вә тәммаг — көнчелек һәм комсызлык.
[2] Нур лиммаг — яктылык чәчә торган нур.
[3] Әгънәя утагына — байлар тормышына (карата).
[4] Үләң менән — шигырь (җыр) белән.
[5] һәза әзал(л) — шулай ук ялгышулардан азат түгелмен.
[6] Сабах вә шам — иртә һәм кич.

бүлекләрдә спиртлы эчемлекләр мораль бозылуның сәбәбе, кешелекне югалтуның сәбәбе икәнлеге күп мисаллар белән исбат ителә.

Шул рәвешчә, 1860 елда ук Некрасов җитәкчелегендә чыккан «Современник» журналы игътибар итеп үз битләрендә аннан өзекләр китергән «Мәкәрҗә бәете» поэмасы ул чор татар әдәбияты тарихы өчен яңа бер күренеш булган. Ул кеше, бу поэмасыннан тыш, «Современник» журналында күрсәтелгәнчә, тагын бик күп темаларга (мәхәббәт, рекрутчылык, налоглар һәм муллаларга карата сатиралар) шигъри әсәрләр язган. Бу әсәр чиновникларның башбаштаклыгын күрсәтүе белән Гогольнең шуннан элек иҗат ителгән «Ревизор»ын хәтерләтә. Гогольнең «Ревизор»ы да «югарыдан килә», ә безнең поэманың авторы да бу җинаятьләрне патшаның уң канаты булган сенаты белмидер, белсәләр, чик куярлар иде дип ышана. Мондый ышанулар ул заман язучылары өчен, әлбәттә, котылгысыз иде. Андый әсәрләрнең әһәмияте реаль чынбарлыкны, андагы тискәре күренешләрне халык интересларыннан чыгып сурәтләвендә булды. Әнә шул халык интересын яклаганы, халык зарарына эшләүче түрәләрне фаш иткәне өчен Гогольнең «Ревизор»ына реакцион көчләр ташланган булсалар, безнең авторның «Мәкәрҗә бәете» поэмасын Казан губернаторы басылып чыккач ук таратудан туктата.

Мәкаләбезнең соңгы бүлегендә күрсәтелгәнчә, башта дини темага багышлап язылып та, төп өлешендә көнкүреш мәсьәләләрен кинрәк гәүдәләндергән, үз вакытының төрле социаль группаларның характерлы сыйфатларын күрсәткән шигъри әсәрләрнең туа башлаулары да очраклы хәл булмаган. Болар, бер яктан, язучыларның иске стильдә, иске традицион формаларда яңаны, яңа эчтәлекне, үзләрен дулкынландырган, борчыган мәсьәләләрне халыкка әйтеп бирүгә омтылуларын күрсәтсә, икенчедән, цензурадан үткәзү өчен дә кирәк булган. Чөнки алар үзләренең исемнәре һәм язылу формалары белән гадәттәге дини-этик эчтәлекле китаплардан бик аерылып тормаганнар. Бу үз чиратында һәм укучыларны җәлеп итү һәм цензура киртәсен узу өчен дә кирәк булган.

Мондый иске формаларда яңа эчтәлек салып язу әле Тукайлар чорында да, хәтта Октябрь социалистик революциясеннән соң Галиәсгар Камал иҗатында да киң урын алып тора. Аның «Вәгаз нәсихәтләр», «Тәкый гаҗәп», «Бакырган китабы», «Бәдәвам китабы» һ. б. дип исемләнгән сатирик шигырьләре шундый алымнан файдалануын бик ачык күрсәтә. Димәк, бу алым белән яза башлау XIX йөз язучыларында ук булган икән.

Югарыда тикшерелгән әсәрләрнең стиль һәм телләрендә дә яңалык күренә. Аларда элегрәк басылган китапларда күп урын алган гарәп, фарсы сүзләре урынына киң массага аңлаешлы рус сүзләре дә күренә башлый.

Нил Юзиев

# «ХӘРӘКӘТТӘГЕ ЭСТЕТИКА» — ХӘРӘКӘТТӘ

Башта ук мәкаләнең вакыт ягыннан чикләрен ачыклап куйыйк әле. Биредә сүз 1972 елгы әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме турында барачак.

Узган елгы әдәби тәнкыйть башка еллардан нинди хасиятләре белән аерыла соң, дигән сорауга кыска гына итеп: «Җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булуы белән», дип җавап бирергә мөмкин булыр иде. Әлбәттә, башка елларда да тәнкыйть турында сүз булмыйча калмый иде, әмма сөйләшүләр күбесенчә тәнкыйтьчеләрне тиргәү яисә тәнкыйтьнең артталыгын, пассивлыгын билгеләп үтү рухындарак уза иде. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары тәнкыйть хакындагы сөйләшүләрне бөтенләй яңа югарылыкка күтәрергә сәбәпче булды. Бу карар әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең иҗтимагый тормышта зур роль уйнавына һәм аны үстерү киң җәмәгатьчелек эше икәнлегенә ныграк һәм тирәнрәк төшенергә ярдәм итте. Әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең торышы, ихтыяҗы һәм бурычлары турында иҗат оешмаларында, югары уку йортларының филология факультетларында, фән учреждениеләрендә җитди сөйләшүләр булып узды һәм ул җыелышларда тәнкыйтьне үстерүгә кагылышлы күп төрле тәкъдимнәр әйтелде, практик чаралар билгеләнде.

Хәзер инде тәнкыйтьнең торышы һәм үсеше турында, бирелгән вәгъдәләрнең үтәлеше турында кайбер нәтиҗәләр ясарга да мөмкинлек бар шикелле. Иң беренче нәтиҗә шул: Үзәк Комитет карары татар әдәби тәнкыйтенең үсешенә дә көчле һәм шифалы йогынты ясады. Без, әлбәттә, тәнкыйтькә багышлап җыелышлар үткәрү белән генә бу өлкәдәге кимчелекләр кинәт һәм берьюлы юкка чыктылар дип әйтергә җыенмыйбыз. Үзәк Комитет карары — әдәбият-сәнгать тәнкыйтенең үсеш юлларын озак елларга билгеләгән программ документ, һәм анда күтәрелгән барлык мәсьәләләрне хәл итәр өчен күп еллар кирәк булачак. Әмма Үзәк Комитет карарының уңай тәэсирен үткән бер ел эчендәге әдәби тормышта да күрергә мөмкин. Бу бигрәк тә әдәбият-сәнгать тәнкыйтенә мөнәсәбәтнең яхшыруында, тәнкыйтьне үстерү өчен уңайлы атмосфера туууында ачык сизелә. Моны, мәсәлән, Татарстан китап нәшриятының тематик планнарына күз салуда да күрергә мөмкин. 1972 елда әдәбият белеме һәм тәнкыйтькә караган 2 китап дөнья күргән. Аларның гомуми күләме — 21 басма табак. 1973 ел планында әдәбият белеменә бирелгән күләм өч тапкыр арткан: 73 табак күләмендә биш китап басылып чыгачак. Әмма әле бу күләм дә хәзерге тәнкыйть һәм әдәбият белеме ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый. Нәшриятның портфелендә, мәсәлән, хәзерге вакытта басылуны һәм планга кертүне көтеп ята торган уннан артык кульязма бар. Күрәсең, нәшриятта әдәбият-сәнгать тәнкыйтенә караш яхшыра төшсә дә, әдәбият белеме һәм тәнкыйть әсәрләрен укучыга мөмкин кадәр үз вакытында җиткерү мәсьәләсе һаман да җитдилеген югалтмый икән әле.

1972 елда республикабыздагы газета-журналлар да әдәбият-сәнгать тәнкыйтенә игътибарны көчәйтә төштеләр. Яңа басы-

ълып чыккан китапларга рецензияләрнең һәм аннотацияләрнең, шулай ук тәнкыйть мәкаләләренең саны, үткән еллар белән чагыштырганда, беркадәр артуы күзгә ташлана. Бу аеруча «Социалистик Татарстан» газетасында һәм «Казан утлары» журналында күренә. Мәсәлән, «Казан утлары» журналында 1971 елда «Китап күзәтү» бүлегендә 13 рецензия урнаштырылса, 1972 елда рецензияләнгән китаплар саны 17 гә җиткән. Тик ни өчендер бәләкәй рецензияләр кимүгә йөз тоткан. Журналның «Әдәби тәнкыйть» бүлегендә 1970 һәм 1971 елларда 7 шәр мәкалә басылса, 1972 елны ул сан 14 кә җиткән. Әлбәттә, журналда тәнкыйть мәкаләләренең ике тапкыр күбрәк урнаштырылуына карап тәнкыйтьнең ике тапкыр үсүе турында нәтиҗә ясарга ярамый. Әмма шул ук вакытта сан күрсәткечләрен дә искә алмаска хакыбыз юк. Саннар исә тәнкыйть тормышының җанлана төшүе турында сөйлиләр. Моны тагын бер дәлил белән ныгытырга мөмкин булыр иде: бу — газета-журналларда әдәби тәнкыйтьнең торышына һәм үсү мөмкинлекләренә караган мәкаләләргә урын бирү, шундый чыгышлар аша җәмәгатьчелекнең фикерен тәнкыйтькә юнәлтү. Бу яктан «Социалистик Татарстан» газетасының уңышлы бер башлангычын билгеләп үтәсе килә. Газета редакциясе, татар әдәби тәнкыйтенең мөһим мәсьәләләре турында күмәкләп фикер алышу өчен, бер төркем әдәбият галимнәрен, тәнкыйтьчеләрне һәм язучыларны «түгәрәк өстәл» янына чакырды. Анда, мәсәлән, Х. Туфан, Г. Әпсәләмов, З. Нури, А. Расих, Н. Дәүли шикелле язучылар белән бергә, Х. Госман, М. Гайнуллин, Б. Гыйзәт, Х. Хәйри, Р. Мостафин, И. Нуруллин шикелле әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр катнашты. Сөйләшүдә әдәби тәнкыйтьне үстерүнең байтак мөһим мәсьәләләре күтәрелде. Газета редакциясе шушы сөйләшүләрнең эчтәлеген «Көн тәртибендә — әдәби тәнкыйть» исеме астында тулы бер бит итеп басып чыгарды (26 февраль, 1972 ел). Мондый алымны куллануның никадәр отышлы икәнен әйтеп торуның, ихтимал, кирәге дә юктыр. Әмма әлеге сөйләшүнең чын мәгънәсендә диалог булып чыгуы һәм газета битендә тулы итеп, хәтта катнашучыларның фоторәсемнәре белән үк бирелүе «түгәрәк өстәл янында сөйләшү» формасын башка газета-журнал битләрендә дә файдалану, шундый сөйләшүләрдә әдәбият үсешенең әһәмиятле яңа мәсьәләләрен карау теләген уята. Шушы сөйләшү-диалогны газетаның үзендә быел дәвам итеп, беренче сөйләшү вакытында күтәрелгән мәсьәләләрнең үтәлеше һәм нәтиҗәләлегe турында сүз алып барганда да әйбәт булыр иде. Әйтик, сөйләшүдә тәнкыйтьче кадрларны хәзерләү юлларын төрләндерү, аларны хәзерләүнең сыйфатын яхшырту турында күп сүз булган иде. Философия кафедраларында эстетика һәм әдәби тәнкыйть буенча белгечләр хәзерләү мөмкинлеге, сәнгать белгечләрен пединститут, консерватория, төзелеш институты, культура институтларында да хәзерләүне яхшырту һәм яшь тәнкыйтьчеләрне хәзерләүдә билгеле бер система булдыру турында фикерләр әйтелгән иде. Шушы тәкъдимнәр ни дәрәҗәдә тормышка ашкан, тәнкыйть үз адресатына ни дәрәҗәдә барып җиткән, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать тәнкыйте кадрлары хәзерләү өлкәсендә тиешле оешмалар нинди кайгыртучанлык күрсәткәннәр — менә шушы мәсьәләләр буенча газетаның тагын бер махсус сәхифәсен кору бик тә отышлы булыр иде, чөнки әлегә бу мәсьәләләрдә яңалык күренми кебек. Тәнкыйтьнең резервы турында кайгырту — ул тәнкыйтьнең киләчәге турында кайгырту дигән сүз. Ә бу өлкәдә хәл ителәсе мәсьәләләр белән бергә, эчне пошырырлык күренешләр дә тулып ята. Соңгы елларда әдәбиятчы-аспирантлар арасыннан диссертация яклаучылар күбәйсә дә, агымдагы әдәби тәнкыйтькә килүчеләр бөтенләй азайды. Т. Галиуллин, Ф. Урманчеевлардан соң кемнәрне атап булa? Юк бит! Әдәбиятчы-белгечләрнең хәзерге әдәби процесска тартылмаулары нәрсәгә бәйле? Уйлашасы иде, тиешле чаралар күрәсе иде. Янсә сөйләшүдә күзгә тылган мөһим мәсьәләләрнең тагын берсе — әдәби тәнкыйтьне үстерүгә катнашы булган оешмаларның һәм учреждениеләрнең эшен координацияләү, аларның элементләрен ныгыту мәсьәләсе булды. Үзәк Комитет карарында әйтелгәнчә, фәнни-тикшеренү эшендәге кимчелекләр, фәнни һәм иҗат кадрларының ведомство ягыннан таркаулыгы, фәнни учреждениеләр эшчәнлегендә тиешле координациянең булмавы тәнкыйтьне үстерүгә кире йогынты ясый. Хәзер үзеннән-үзе сорау туа: шушы сөйләшүдән соң үткән бер елда татар әдәбиятчыларының һәм тәнкыйтьчеләренең эшен координацияләү буенча нинди чаралар күрелгән, әйтелгән кимчелекләрнең кайсылары төзәтелгән, татар әдәбияты тарихының проспектын тикшерүгә җәмәгатьчелек

ничек катнашкан — шуның кебек мәсьәләләр белән бер ел үткәч кызыксыну файдалы булыр иде.

Мин биредә «түгәрәк өстәл янында» сөйләшүдә күтәрелгән тик берничә мәсьәләгә генә игътибарны юнәлттем һәм шулар мисалында газета битендә башланган тәнкыйть турындагы сүзне дәвам иттерүнең кирәклеген, күтәрелгән мәсьәләләргә кабат әйләнеп кайтуның зарурилыгын әйтергә телəдем.

Тәнкыйтьнең үзе турында сөйләшүгә караган тагын берничә җитди тәнкыйть материалын күрсәтеп үтәргә кирәк. Болардан берсе — Н. Фәттахның «Тәнкыйтькә — тәнкыйть» исемле мәкаләсе («Социалистик Татарстан» газетасы, 11 март). Бу мәкаләдә сүз 1971 елгы әдәби тәнкыйть турында, тагын да конкретрак әйткәндә, «Казан утлары» журналындагы әдәби тәнкыйть материаллары турында бара. Р. Мостафинның «Тәнкыйтькә тәнкыйть уты» («Казан утлары» журналы, 4 сан) һәм «Поговорим о рецензиях» («Вопросы литературы» журналы, 3 сан) исемле мәкаләләрендә безнең тәнкыйть хуҗалыгына, бигрәк тә аның оператив тармагына — хәзерге әдәбиятны тикшерүгә караган тәнкыйть мәкаләләренә һәм рецензияләренә төпле анализ ясала, бу өлкәдәге шактый күп кимчелекләр ачыла, тәнкыйтьчеләр хәл итәсе мәсьәләләр күтәрелә, нәшрият җитәкчеләрен уйландыра торган сораулар куела, рецензияләрнең һәм аннотацияләрнең жанр үзенчәлекләрен ачыклаган фикерләр әйтелә.

Әдәби тәнкыйть турында башланган шушы рухтагы файдалы сөйләшүне тәнкыйтьнең методологиясен ачыклау, аның тактикасын һәм стратегиясен фәнни эшләү юнәлешендә киләчәктә дә дәвам итәргә кирәк. Әдәбият-сәнгать тәнкыйтен әдәбиятсәнгатьнең әһәмиятле һәм мөстәкыйль бер тармагы дип саныйбыз икән, аның фәнни нигезләрен ачыклау, критерийларын фәнни билгеләү турында да җитди уйланырга тиешбез. Бу, үз чиратында, татар әдәби тәнкыйтенең тарихын язуны, үсеш тенденцияләрен, закончалыкларын ачуны, әдәбият белеме методологиясен камилләштерү мәсьәләсен дә көн тәртибенә куя. Билгеле бер стильдәге, әйтик, реалистик юнәлештәге язучыны күтәреп тә, аның янәшәсендә романтик стильдә иҗат итүче әдипнең уңышларын һәм казанышларын танып бетерә алмау, бәяләүдә берничә факторны гына исәпкә алып (күбесенчә тематик-стилистик якны яки уңай һәм кире геройлар нисбәтен) һәм шуларга гына таянып, әсәрнең бөтенлеген һәм эстетик көчен тудыруда катнашкан башка факторларны (мәсәлән, конфликт элеклелеге һәм дәвамлылыгы, вакыйгаларны сурәтләү ритмы, характерлар ачылуда вакыт роле) искә алмау — болар барысы да безнең әдәби тәнкыйть практикасында очрый торган гадәти күренешләр. Болар барысы да безнең әдәбият тикшерү методологиясенең эшләнмәве турында сөйли.

Агымдагы әдәби тәнкыйтьнең әдәбиятка тәэсир көче, һичшиксез, әдәбият теориясенең җитлеккәнлегенә, аның фәнни тирәнлегенә бәйле, шул ук вакытта татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең торышы белән дә аерылгысыз.

Д. Лихачев, Л. Тимофеев, М. Храпченко, Х. Госман, Г. Халит кебек галимнәрнең иҗаты шуны раслый: үткән тәҗрибә бүгенгене ныграк аңлатырга, аерым әдәби тенденцияләрнең үсешен ачыграк билгеләргә ярдәм итә. Шуңа да без хәзерге тәнкыйтьнең торышын аның үткәненнән, әдәби тәнкыйтьне аның теориясеннән һәм әдәбият тарихыннан аерып карый алмыйбыз. Әдәбият тарихы—тәнкыйтьнең тылы. Ә тыл ныклы булмаса, фронтта сугышуы авыр икәнлеге мәгълүм хакыйкать. Ә безнең әдәби тәнкыйтьнең тылында йомшак урыннар шактый күп әле.

Нурихан Фәттах «Тәнкыйтькә — тәнкыйть» исемле мәкаләсендә «татар әдәбиятының тигез өйрәнелмәве, галимнәрнең ничәмә еллардан бирле әдәбият тарихының 25—30 елын эченә алган бер төбәгендә, ягъни 1905 елдан 1930 елларга кадәрге төбәгендә җыйнаулашып ятулары» турында сүз кузгаткан иде. Беркадәр арттырыбрак һәм үткенәйтебрәк әйтелсә дә, нигездә бу фикер хакыйкатьтән әллә ни читкә алып китми. Безнең әдәбият тарихы тигез өйрәнелми, аның борынгы һәм урта гасырлар, XIX гасыр тарихында чишелмәгән әллә никадәр мәсьәләләр ята.

Шул ук вакытта бу өлкәдә соңгы елларда күңелне шатландырырлык кайбер эшләр эшләнүенә дә күз йомып үтеп китеп булмый.

Шул яктан мин, мәсәлән, М. Усмановның «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» исемле монографиясен (КДУ нәшрияты, 1972), Әнвәр Шәриповның 1972 елда дөнья күргән «Мөһиммат эззаман» кем әсәре?» дигән тикшеренүен («Казан утлары», 4 сан), Хатип Миңнегуловның «Сәйф Сараиның яңа әсәрләре»

исеме астында «Казан утлары»нда (6 сан) басылган публикациясен һәм аның Казан университеты нәшриятында офсет ысулы белән чыккан «Сәйф Сараиның тормышы һәм иҗаты» дигән хезмәтен, Ф. Урманчиевның «Легендалар эзеннән» («Казан утлары», 8 сан) мәкаләсен, шулай ук соңгы елларда «Советская тюркология» журналында басылган аерым мәкаләләрне уңай күренеш буларак бәяләп үтәр идем.

Бездә борынгы һәм урта гасыр әдәбияты әсәрләренең фәнни текстологиясен эшләү шактый артка калды һәм озакка сузылды. Бу өлкәдә дөнья стандартларыннан артка калуыбыз, мәсәлән, Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» әсәренең Будапештта венгр галиме Бодроглигети тарафыннан хәзерләнгән басмасын (1969) күргәч, бигрәк тә нык күзгә ташлана.

XX йөз башы татар әдәбияты безнең әдәбият тарихында иң нык тикшерелгән чор булып санала. Әмма бу чорда да әле ак тапларның күп булуы 1972 елда тагын берничә хезмәт белән расланды. Беренче чиратта, мин Абдулла Сайгановның «Фатих Әмирхан эстетикасы һәм XIX йөз ахырындагы, XX йөз башындагы реалистик татар әдәбиятындагы эстетик идеяләр» исеме белән аталган һәм филология фәннәре докторы фәнни дәрәҗәсе алу өчен тәкъдим ителгән диссертациясенең авторефератын (Баку, 1972), шулай ук аның Казан педагогия институтының 1971—72 елгы гыйльми язмаларында басылып чыккан «Ф. Әмирхан эстетикасы», «Реалистик татар әдәбиятында типиклык мәсьәләсе», «Ф. Әмирхан иҗатын татар тәнкыйтендә өйрәнү турында» исемле хезмәтләрен күздә тотам. А. Сайганов Ф. Әмирханның татар эстетикасы тарихындагы зур ролен дәлилле күрсәтүгә ирешкән. Гомумән, соңгы елларда А. Сайганов, Й. Нигъмәтуллина кебек әдәбиятчыларыбызның эстетиканың катлаулы теоретик мәсьәләләрен чишәргә алынулары һәм XX йөз эстетикасын тулыландырган җитди хезмәтләр иҗат итүләре куандыра һәм әдәбият теориясенең киләчәктә шундый ук җитди хезмәтләр белән баюына якты өметләр уята. Й. Нигъмәтуллинаның «Эстетик идеалның милли үзенчәлеге» исемле хезмәтенең (ул КДУ нәшриятында 1970 елны басылган иде) бөтен союз матбугатында уңай бәя алуы да шушы ышанычны ныгыта. Бу өлкәдә әдәбиятчыларның һәм философларның бергәләп эшләүләре гаять нәтиҗәле булыр иде. Философ Яхья Абдуллинның «Татар мәгърифәтчеләре философиясенең кайбер мәсьәләләре» исемле мәкаләсе («Казан утлары», 12 сан) әнә шул яктан игътибарны үзенә тарта. Анда XIX йөз һәм XX йөз башында яшәгән татар философларының эшчәнлекләренә һәм дөньяга карашларындагы үзенчәлекләренә караган байтак яңа, кызыклы күзәтүләр бар һәм алар шул чор татар язучыларының эстетик фикерләрен аңларга да ярдәм итәләр. Әдәбиятчы Энгель Нигъмәтуллинның «Жан-Жак Руссо һәм XX йөз башы татар әдәбияты» дигән мәкаләсе дә («Казан утлары», 11 сан) XX йөз башы татар эстетик фәлсәфиәдәби фикеренең яңа бер сәхифәсен ачуы ягыннан кызыклы һәм әһәмиятле. Г. Нигъмәтигә хас фәнни тирәнлек һәм киң эрудициялек традициясен аның варислары: кызы Йолдыз Нигъмәтуллина, улы Энгель Нигъмәтуллинның дәвам иттерүләре безне шатландыра. Без аларның, әтиләре шикелле, хәзерге әдәби процесска якын килеп, хезмәтләрендә хәзерге әдәбиятның аерым мәсьәләләрен күзәтүләрен дә теләп калабыз.

Эстетика һәм әдәбият теориясе галимнәренең эшчәнлекләрен хәзерге әдәбият-сәнгать процесының закончалыкларын гомумиләштерү буенча да активлаштырасы һәм бу мәйданда да әдәбият-сәнгатьне комплекслы өйрәнүне чын мәгънәсендә юлга саласы бар. Казан университетында татар әдәбияты һәм татар теленең закончалыкларын тарихи-эксперименталь өйрәнү буенча проблемалы төркем оештырылуы (җитәкчесе Х. Госман) һәм анда бер төркем тарихчыларның, әдәбиятчыларның, телчеләрнең эшли башлаулары әлеге өлкәдә дә якын елларда уңай якка үзгәрешләр туачагына өмет уята. Ә хәзергә, гадәттәгечә, эстетика һәм әдәбият теориясе бүгенге әдәбият-сәнгать процессын өйрәнүдә аерылыбрак яши, аларның әдәби процесска йогынтысы йомшак. Эстетика мәсьәләләре буенча хезмәтләр һәм мәкаләләр гаять сирәк басыла. Мәсәлән, «Казан утлары»нда 1972 елда бары тик бер мәкалә — Казбек Гыйззәтовның «Ленинның чагылыш теориясе һәм художникның активлыгы» (11 сан) исемле мәкаләсе дөнья күргән. «Татарстан коммунисты» журналында эстетика буенча басылган мәкаләләр гадәттә сугышчан рухлары белән көчле булсалар да, хәзерге әдәби процесска бәйле конкрет анализның җитәрлек булмавы ягыннан аксыйлар (мәсәлән, В. Дмитриевның «Со-

циалистик реализм: теория һәм тәҗрибә» дигән мәкаләсе, 6 сан).

Әдәбият теориясенең, әдәби тәнкыйтьнең философик дәрәҗәсен югары күтәрү бурычын әдәбиятчыларның философлар белән аерылгысыз дуслыгына, хезмәттәшлегенә ирешкән очракта гына үтәп чыгарга мөмкин.

Икенче яктан, хәзерге әдәбият-сәнгать закончалыкларын гомумиләштерү эшенә шул өлкәнең үз әһелләрен: язучыларны, режиссерларны, художникларны ныграк, кыюрак тартырга кирәк. Бу өлкәдә язучыларның матур традициясе бар. Аларның байтагы әдәбиятны үстерүгә үз әсәрләре белән генә түгел, тәнкыйть мәкаләләре һәм фәнни хезмәтләре белән дә актив катнашып киләләр. Н. Исәнбәтнең фәнни хезмәтләре аны хаклы рәвештә тюркологиянең күренекле галимнәре рәтенә күтәрде. 1970 елда С. Хәкимнең, 1971 елда М. Әмирнең, 1973 елда Ә. Фәйзинең тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары басылып чыкты. Якын киләчәктә К. Нәҗми һәм Ф. Хөсниләрнең шундый ук китаплары укучы кулына керәчәк. Болар — иҗат практикасын баетуга да, әдәби тәнкыйтьне һәм әдәбият белемен үстерүгә дә тирән эз сала торган хезмәтләр. Мондый хезмәтләр язучыларның үзләренә генә түгел, хәтта галимнәрнең һәм әдәбият белеменең үсешенә дә көчле йогынты ясый. Шушындый хезмәтләрне сәнгать әһелләреннән дә көтәргә хакыбыз бар. С. Эйзенштейн, К. Станиславский, В. Немирович-Данченко, Е. Вахтангов — болар режиссерлар да, теоретиклар да. Бездә дә бит талантлы режиссерлар бар һәм аларның иҗат концепцияләре белән спектакльләр аша танышып торабыз. Ш. Сарымсаков, М. Сәлимҗанов, П. Исәнбәт кебек режиссерлар, Б. Урманче кебек рәссамнар, Н. Җиһанов, Р. Яхин кебек композиторлар үзләренең иҗат тәҗрибәләрен гомумиләштерү аша да татар сәнгате теориясен үстерүгә өлеш кертә алырлар иде. Бу фикер күренекле артистларыбызга да, оркестр һәм ансамбль җитәкчеләренә дә, архитекторларга да карый. Миңа, мәсәлән, композитор Җәүдәт Фәйзинең шундый изге эшкә тотынуы — үз тормышы һәм иҗат лабораториясе турында әдәби этюдлар яза башлавы һәм бер өлешен тәмамлавы да мәгълүм. Мондый эшкә тартуда, күрәсең, социаль заказ алымын куллану, Н. Исәнбәт кебек галимнәрнең язылган хезмәтләрен бастырып чыгаруда ниндидер оештыру чараларын күрү дә кирәктер. Чөнки сәнгать теориясен һәм мәдәният тарихын эшләү бездә арткарак калып баруы һәм талантлы кешегә дә гомернең бер генә бирелүе кемгә дә сер түгел.

Татар әдәбият белеменең совет чоры әдәбиятын өйрәнү буенча туплаган ярыйсы гына тәҗрибәсе бар. Билгеле бер уңышларын да, аерым үрләрне зур тырышлык белән яулап алуларын да күрмичә мөмкин түгел. Шул ук вакытта әдәбият белеменең җитди кимчелекләре дә мәгълүм. 1972 елда әдәбият белеме һәм тәнкыйтьнең торышы турындагы мәкаләләрдә табигый рәвештә акцент бу өлкәдәге җитешсезлекләргә һәм кимчелекләргә юнәлтелде. Хәтта Н. Фәттахның күзәтүендә 1971 елда басылып чыккан зур монографияләрнең исемнәре дә аталмады. Монысы инде үзе икенче бер кырыйга ташлану. Безгә исә бу өлкәдәге хуҗалыкка игътибарлырак булырга, әдәбият белеменең кимчелекләрен генә түгел, уңышларын да күрә белергә, бу өлкәдә нинди тенденцияләрнең яшәвен ачыграк һәм тулырак күзалларга кирәк.

Хәзерге әдәбият белемендәге тенденцияләрнең берсе — татар совет әдәбиятының үсеш баскычларын ачыкларга омтылу, татар совет әдәбиятының гомуми панорамасын тудыру. 1956 елда басылган «Татар совет әдәбияты тарихы» белән чагыштырганда, әдәбият белеме хәзер бу мәсьәләдә шактый үсте. Тематик анализ, ягъни әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү, авторларның исемнәрен санау белән мавыгудан игътибарны әдәбият баскычларының аерым дәверләрендә яшәгән әдәби-эстетик тенденцияләрне ачыклауга юнәлтүдә һәм аерым тенденцияләрне күрсәтә алуда үсеш аерата ачык күренә. Мин, әлеге фикергә дәлил эзләгәндә, беренче чиратта, әдәбият галимнәребезнең союз күләмендәге академик басмада — М. Горький исемендәге Дөнья институты коллективы җитәкчелегендә бөтен Союз әдәбиятчылары көче белән хәзерләнгән «Күп милләтле совет әдәбияты тарихы» томнарында катнашуларын күздә тотам.

Аның һәр томында татар әдәбиятына да урын бирелә. Академик басмада татар совет әдәбиятының ни рәвешле яктыртылуы турында, бәлки, киләчәктә әдәбиятчылар һәм язучылар катнашында махсус сөйләшү үткәрелер, ә хәзергә детальле анализга күчеп тормастан, татар әдәбиятчыларының Г. Халит җитәкчелегендә башкар-

ган әлеге коллектив эшен татар әдәбият белеменең җитди казанышы дип бәяләр идем. Әлеге томнарда татар әдәбиятының байлыгы укучы күңелендә горурлык хисе уята икән, моңа, беренче чиратта, әдәбият үзе сәбәпче булса, икенчедән, шул байлыкны күрсәтә алган авторлар да сәбәпче. Л. Тимофеев, Г. Ломидзе, З. Кедрина шикелле күренекле галимнәр җитәкчелек иткән коллективта катнашу татар әдәбиятчылары өчен күп җәһәттән файдалы булды. Бу иҗади аралашу, фәнни анализ культурасын күтәрергә, академик стильне ныграк үзләштерергә булышу белән бергә, әдәбият өлкәсендә күп милләтле зур коллективлар белән эш итү традициясенә дә нигез салды. Ул хәзерге заманда әдәбият мәсьәләләрен эшләүдә коллективларның роле гаять зур икәнлеген тагын бер тапкыр раслады. Татар әдәбиятының биш томлык тарихын язганда әлеге тәҗрибәне өйрәнү һәм файдалану зарури.

Әдәби мирасны барлау һәм укучыга җиткерү буенча да әдәбиятчылар тарафыннан шактый гына эшләр эшләнүен инкарь итеп булмый. Бу өлкәдә М. Гайнуллинның «Краткая литературная энциклопедия» томнарында татар әдәбияты һәм язучыларын яктырту буенча җаваплы вәкил буларак зур оештыру эше башкаруын билгеләп үтәргә кирәк. Мәгълүм булганча, әдәби энциклопедия 10 томнан торачак. Ул 1962 елдан басыла башлады һәм хәзер 7 томы дөнья күрде. 1929—39 елларда басылган «Литературная энциклопедия» томна[illegible]ында татар әдәбияты турында белешмәләр гаять аз бирелгән иде. Хәзерге энциклопедиядә татар әдәбияты шактый киң урын алган. Бу шулай ук татар әдәбият белеменең үсүен күрсәткән бер факт. Мәсәлән, 5 томда гына да 65 татар язучысы турында белешмә бирелгән. Моннан тыш, анда татар әдәбияты һәм журналистикасы турында да, «Казан утлары» журналы турында да, җәдитчелек турында да (М. Гайнуллин һәм И. Брагинский), Идегәй эпосы турында да (Ш. Мөхәммәдьяров) төпле белешмәләр бар. Сез энциклопедиядә Акмулла һәм Муса Акъегет, Думави һәм Дәрдмәнд турында да, З. Бәшири һәм Г. Кандалый, Ф. Кәрими һәм Ә. Курмаши, М. Колый һәм Мөхәммәдъяр кебек төрле чор язучылары турында да, классикларыбыз һәм хәзерге исән язучыларыбыз турында да белешмәләр таба аласыз. Шул ук вакытта энциклопедиядә татар әдәбиятының яктыртылуына бәйле кайбер кимчелекләрне дә күрсәтеп үтик.

Кайбер урыннарда фактик төгәлсезлекләр очрый. Мәсәлән, С. Батталга караган белешмәдә (Х. Хисмәтуллин язган) шагыйрь ике повесть — «Газзә» һәм «Олы юл буйлап» исемендәге ике әсәр язган булып аңлашыла (1 том). Чынында алар бер әсәр, тик ике басмада ике исем белән генә басыла.

«Литературоведение в СССР» дигән белешмәдә татар әдәбият белеменә нибары ике юл бирелгән һәм анда да хаталар бар: «В Татарии работают литературоведы М. Х. Гайнуллин, М. Галеев, Г. Галеев, Г. Губайдуллин и др.». Кем ул М. Галеев? Гали Халитмы? Һич очына чыгарлык түгел. Г. Галеев — бәлки Гомәр Галидер, Г. Губайдуллин — бәлки Газиз Гобәйдуллиндыр? Алай дисәң, сүз исән әдәбият галимнәре турында бара...

Язучыларны урнаштыруда бер система төгәл сакланмый: гадәттә, язучыны фамилиясенә карап эзлисең. Латыйпов Галимҗан икән, ул «Л» хәрефендә. Ә менә, мәсәлән, Зариф Бәширине «Б» хәрефеннән табып булмый, аны «З» дан эзләргә кирәк. Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Галәү, Нәби Дәүли белән дә шул ук хәл: аларны исемнәре буенча гына табып була. Кайбер язучыларны (мәсәлән, Н. Арсланов, К. Әмири, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, Х. Вахит) ни өчендер фамилияләре буенча да, исемнәре буенча да очратып булмый. Ә безнеңчә, алар энциклопедиядә урын алырга лаеклы әдипләр. Шулай ук Г. Афзал, Ш. Галиев, Х. Камалов, Р. Мостафин, Ю. Әминов, Ә. Маликов, А. Гыйләҗевләр буыны да бөтенләй читтә калган. Яшьрәк буын әдипләргә белешмә юклыкка энциклопедияне чыгаруның озак елларга сузылуы да комачаулавы ихтимал. Чыга башлавына да бит 10 ел. Әмма алай дисәң, башка милли әдәбиятлардан кырык яшьлекләр буыны да урын алган. Гомумән, энциклопедик һәм био-библиографик белешмәләрдә язучыларны, аларның иҗатын ни рәвешле яктырту турында бездә дә махсус сөйләшү үткәрү кирәк түгелме икән? Мәскәүдә РСФСР язучылар союзының тәнкыйть буенча оештырылган советы, мәсәлән, үзенең бер утырышында нәкъ шушы мәсьәләне тикшерде, фикер алышу үткәрде.

Әдәби мирасны барлау һәм укучыга җиткерү эше энциклопедик һәм библиографик белешмәләр белән генә чикләнми. Бу эшкә Татарстан дәүләт нәшрияты да, Татарстан китап палатасы да, архивлар да, «Казан утлары» журналы да катнаша. Мө-

сәләт, нәшрият соңгы елларда исән язучыларыбызның сайланма әсәрләрен чыгару буенча мактауга лаек зур эш башкарды. Ләкин бу эштә фәнни-методик системалылыкның җитмәве дә күзгә ачык ташланды. Томнар нинди принцип белән төзелә — хронологиямы, жанрмы — аңлавы кыен, чөнки ул төрле язучыда төрлечә. Бер язучыга кереш сүз бирелә, икенчесенә юк, берсендә комментарийлар һәм библиография дә бар, ә башкасында тегесе дә, бусы да юк.

«Казан утлары» журналы 1972 елны «Әдәби мирас» исеме астында яңа бер бүлек ачты һәм анда Ибраһим Гази, Гали Хуҗи, Шәрәф Мөдәррисләрнең әдәби архивларыннан бик тә кызыклы һәм әһәмиятле материаллар басып чыгарды. Бу бүлекне киләчәктә дә даими рәвештә алып барырга һәм укучыларны мәрхүм әдипләребезнең басылмый калган әсәрләре белән таныштырып торырга иде. Язучыларның шәхси архивларында, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, университет, музей архивларында моның өчен материал озак елларга җитәрлек. Материал гаять бай, әмма аны фәнни эшкәртү канәгатьләндерерлек тормый. Татарстан Дәүләт музеенең архивындагы байтак әдәби фондларга, мәсәлән, Такташ фондына, әлегә кадәр кереп булмый. Язучының мирасына караган җыентыкларны әлегә кадәр бер архив та хәзерләп бастырганы юк. Ә бит музей һәм архив хезмәткәрләре бу өлкәдә зур эш башкара алалар.

Иҗат мирасы комиссияләренең эше белән кызыксыну һәм аларга булган таләпне дә көчәйтәсе иде, аларның хисапларын идарә утырышларында, җыелышларда тыңлыйсы иде. Әгәр тыңласак, Г. Ибраһимовның иҗат мирасы председателе А. Шамов, М. Җәлил иҗат мирасы комиссиясе председателе Г. Кашшафларның уңай эш тәҗрибәләре бик күп комиссияләр өчен үрнәк булуын күрер идек һәм бу өлкәдә ялпан килгән кимчелекләр тагы да тулырак ачылыр иде. Мин Шабай, Г. Насрый, С. Урайский, И. Рәми, Ә. Давыдов, С. Рафиков кебек әдипләрнең иҗат мирасы кайда, ничек саклана? Бу исемлекне тагын да сузарга мөмкин. Бу турыда, мөгаен, махсус сөйләшү кирәктер.

Язучыларның иҗат мирасын тулырак туплап укучыларга җиткерү буенча әдәбиятчыларның да, Язучылар союзының да, нәшриятның да күп эшлисе бар әле. Алыйк Такташ мирасын гына. Тууына 70 ел, үлүенә 40 ел тулып узды. Әлегә кадәр аның тулы җыелмасы, хәтта ике томлыгы да чыкканы юк. Җыентыклары басылмый түгел, басыла, әмма һаман да бер үк әсәрләре генә кабаттан дөнья күрә. Г. Кутуй әсәрләре белән дә шул ук хәл. М. Гафуриның дүрт томлыгы чыга башлаган иде, соңгы томы беренче булып басылды да шуның белән эш бетте, беренче-өченче томнарының әлегә кадәр дөнья күргәне юк. Ә башкорт дусларыбыз алты томлыгын чыгарып куйдылар. Исән язучыларыбызның томлыклары чыгуын хупларга кирәк, әмма шул ук вакытта Такташ, Кутуй, Гафури кебек классикларыбызны һәм әдәбият үсешенә билгеле бер өлеш керткән Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди кебек мәрхүм әдипләребезне дә онытырга ярамый. Классикаларыбызны рус укучысына җиткерү буенча да кирәгеннән артык пассив, өкрен эш итәбез. Әдәби тәнкыйть бу өлкәдәге хуҗасызлык турында ныграк борчылырга, катырак чаң кагарга тиештер. Үз байлыгыбызны күрсәтә дә белергә кирәк. Бу өлкәдә күршеләрдән, тугандаш халыклардан да үрнәк алу, өйрәнү зыян итмәс.

Соңгы елларда әдәбият фәненең хәзерге әдәби процесска якыная төшүен, вульгар социологизм кысаларыннан арына баруын һәм әдәби осталык мәсьәләләренә игътибарларын көчәйтә төшүләрен уңай бер тенденция буларак билгеләп үтәргә кирәк. 1972 елда нәшриятта басылып чыккан ике китап та шушы тенденцияләрне ачык чагылдыра.

Берсе аның — Тәлгат Галиуллинның «Яңа үрләр яулаганда» исемле китабы. «Яңа үрләр яулаганда» китабына соңгы еллар тәнкыйтендә нәтиҗәле эшләгән һәм хәзерге поэзия турындагы мәкаләләре, рецензияләре белән матбугатта еш күренә торган, поэзияне тирән аңлый торган сәләтле тәнкыйтьченең хәзерге әдәби процесска, аның да поэзия төренә турыдан-туры караган мәкаләләре тупланган. Тәнкыйтьчене бигрәк тә татар поэзиясенең хәзерге торышы һәм үсеш тенденцияләре кызыксындыра. Поэзиядәге аерым жанрларның (мәсәлән, поэма, баллада) үсеш юллары, шигъри сурәтлелекнең аерым тенденцияләре (мәсәлән, поэзиядә лирик жанрлар һәм сатира үсеше, Х. Туфан иҗатында табигать сурәтенең эволюциясе) турында кызыклы күзәтүләре, табышлары күп авторның. Тәнкыйтьче шагыйрьләрнең осталык мәсьәләләренә киң урын бирә, уңыш-

лы һәм кимчелекле якларын ышандырырлык анализлый.

Икенче китап «Герой, стиль, осталык» дип атала. Бу китапка Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәренең нигездә татар совет әдәбиятының әдәби осталык мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре тупланган. Җыентык Гали Халитның укучыларга журнал варианты буенча таныш «Яңа герой ничек туды» исемле мәкаләсе белән ачыла.

Башка мәкаләләрдә нигездә сүз хәзерге әдәбиятның аерым төрләренең үсеш тенденцияләре, аерым язучыларның әдәби осталыклары, стиль үзенчәлекләре турында бара. Җыентыкта, тәҗрибәле әдәбиятчылар белән бергә, әле генә аспирантура үткән яшь әдәбиятчыларның да хезмәтләре урын алган. Һәм, әйтергә кирәк, тәҗрибәле галимнәрнең дә, яшь әдәбиятчыларның да мәкаләләрендә әдәбият фәненең хәзерге үсеш дәрәҗәсен күрсәткән, әдәби процессның аерым тенденцияләренә төпле анализ ясый алуны раслаган, яки язучының үзенчәлеген нечкә әдәби сизем белән дөрес тотып алуны күрсәткән күзәтүләр байтак (мәсәлән, Г. Халит, Х. Хәйри, А. Әхмәдуллин, Р. Сверигин, Н. Гыйззәтуллин, Х. Курбатов). Шул ук вакытта әлеге ике китапта әдәбият фәненең хәзерге әдәби процесс закончалыкларын, әдипнең осталыгын тикшерүдәге авырлыклары, йомшаклыклары да ачык чагыла.

Шундый йомшаклыкларның берсе — фәнни стильнең эшләнмәве. Фәнни стиль ул — гыйльмилекнең тирән булуы, фәнни бәяләүнең төгәллеге, дәлилле чишелүе белән аерылып тора. Хәзерге әдәбиятны тикшерүгә караган мәкаләләрдә нәкъ менә фәнни тирәнлекнең, фәнни бәяләүнең төгәллеге җитмәве, аргумент-дәлилләрнең йомшаклыгы үзен нык сиздерә. Әдәбиятчылар төрле сәбәпләр аркасында (бигрәк тә журналда, газетада басылу өчен) популяр, фәнни-публицистик стильгә юнәлеш тоталар, шул сәбәпле мәкаләне вакыт-вакыт үтә билгеле нәрсәләрне сөйләгән урыннар басып китә, үзенә кадәр галимнәр тарафыннан әйтелгән фикергә дә мөрәҗәгать итеп тору артык эш итеп санала. Нәтиҗәдә авторның үз ачышын, үз фикерен аерып алу кыенлаша. Популяр стильгә юнәлеш тоту сәбәпле әйтелгән фикерне тиешенчә дәлилләп торуга, аргументлар белән ныгытуга да ихласлык нык кимеде. Мондый кимчелекләр һәр ике китапта да урын алган. Һәм аеруча яшь әдәбиятчыларда нык күзгә ташлана.

Әдәбият фәне методологиясенең әдәби процессны тикшерүгә караган башка авырлыклары, йомшаклыклары турында да әйтү урынсыз булмас. Берсе аның — традицияләр мәсьәләсе. Т. Галиуллинның бер отышлы ягы — аның хәзерге әдәби сурәтләлектәге үзенчәлекләрнең җирлеген ачарга омтылуы. Автор беренче планга халык иҗаты традицияләрен чыгара һәм шул юнәлештә кызыклы гына күзәтүләр ясый. Әмма Г. Афзал, Ш. Галиев сатирасындагы, яки Х. Туфан шигъри фикерләвендәге яңалыкларны халык иҗатына гына бәйләргә омтылу хәзерге поэтик үсешнең катлаулылыгын, иҗат практикасында яшәп килгән традицияләр синтезын ачарга комачаулый да. Гомумән, хәзерге шагыйрь-әдип тапкан һәр яңалыкны фольклорга бәйләп кенә аңлатырга, карарга омтылу әдәбият белемендә шактый көчле тамыр җибәрде. Ә бу исә язучының иҗат процессын бөтен катлаулыгында, әдәбият һәм сәнгать төрләренең үзара тыгыз бәйләнешләреннән чыгып карарга мөмкинлек бирми. Хәзерге әдипләр — күп аллалы. Алар фольклорга һәм әдәбиятка гына түгел, театрга да, музыкага да, рәсем сәнгатенә дә, киногә да табыналар, бер диндәге-телдәге аллаларны гына түгел, төрле телдәге, төрле гасырдагы алла-пәйгамбәрләрне үз итеп кабул итәләр, алардан да өйрәнәләр, традицияләрен үзләштерәләр.

Кайчакта язучыларның әдәби процесстагы урыннарын билгеләгәндә яки язучының теге яки бу әсәренә бәя биргәндә критерийләрнең чуарлыгы һәм төгәлсезлеге күзгә ташлана. Әйтик, Т. Галиуллин шагыйрь дәрәҗәсен шигырь язган һәм бастырган һәркемгә өләшергә ярата. Яшьләр иҗаты турында сүз алып барганда, әлбәттә, аларны искә алырга кирәктер, әмма һәрберсенә яшь шагыйрь яки шагыйрь титулы бирү, хәзерге поэзиянең төп йөзе һәм тенденцияләре турында сүз барган мәкаләләрдә аларга кирәгеннән артык урын бирү урынсыздыр. Шагыйрь — ул талант дигән сүз, яңа, үзенчәлекле рухи дөнья дигән сүз. Р. Байтимеров, Ә. Габидиләрнең «күңелдә урын дауларлык шигырьләренең бик аз булуын» тәнкыйтьче исә «аларның иҗади ярыштан куркып, электән таныш поэтик кануннарны кабатлау юлына басулары» белән аңлатырга тырыша. Шагыйрь белән шигырь чыгаручы арасындагы аерма-чикләрне безгә ачыграк үткәрергә кирәктер.

Аерым хезмәтләрдә тарихилык прин-

цибын гадиләштереп, аны тарихи тема рәвешендәрок кенә аңлату да күренгәли. З. Рәмиев, мәсәлән, болай дип яза: «С. Хәкимнең поэтик фикерләвендә тарих, үткән тормыш зур урын били. Күрәсең, аның әсәрләрендә тарихилык принцибының әледән-әле калкып чыгуы шагыйрьнең кешегә тарихи киселештә, аның үткәнен «сүтеп» каравыннан килә торгандыр» (145 бит). Дөрес, шагыйрьдә тарихи тема әледән-әле калкып чыга, әмма С. Хәкимнең бервакытта да тарихилыктан читләшкәне юк. Тарихилык аның иҗатының төп агышын хасил итә, бервакытта да, хәтта хәзерге көн турында язганда да өзелгәне яки арткы планга күчкәне юк. Тарихи караштан башка бүгенге көнне ничек кабул итәргә мөмкин булсын ди!

Әдәбият белеменең әдәби процесска йогынтысын көчәйтү аның теоретик дәрәҗәсен күтәрү белән аерылгысыз. Хәзерге әдәбиятның күп теоретик мәсьәләләре әдәбиятчылар тарафыннан кузгатылуын һәм эшләнүен көтеп яталар. Аеруча социалистик реализм методының хәзерге замандагы үсеш тенденцияләрен ачкан, гомумән совет әдәбияты үсешендәге закончалыкларны гомумиләштергән фундаменталь хезмәтләрнең булмавы үзен нык сиздертә. Әдәби әсәрне тикшерү методологиясен камилләштерү, тикшерү ысулларын баету һәм төрләндерү агымдагы әдәби тәнкыйтьне үстерүгә дә нык ярдәм итәчәк.

Хәзер сүзне агымдагы тәнкыйтькә күчерик. 1972 елгы хәрәкәттәге тәнкыйтьтә аеруча актив һәм нәтиҗәле эшләүче Р. Мостафин булды. Ул, республика матбугатында актив катнашу белән бергә, «Литературная Россия», «Литературная газета»да, «Вопросы литературы» журналында да мәкалә-рецензияләр бастырды. Ф. Мусин, И. Ахунҗанов, Ф. Әгъзәмов имзалары да башка еллар белән чагыштырганда ешрак күренде. Нечкә эстетик тоемлы Илдус Ахунҗановның озак авырудан соң кабат тәнкыйтьчеләр сафына кайтуын шатланып каршы алдык. Ул, мәсәлән, 1972 елда «Казан утлары» журналында өч, «Волга» журналында ике әйбәт сыйфатлы мәкалә-рецензия бастырды. Студент М. Вәлиевнең рецензияләре тәнкыйтькә яңа бер исемне өстәде. Тәнкыйтьчеләрдән Г. Кашшаф, А. Әхмәдуллин, И. Илялова, Д. Гыймранова, Т. Галиуллин, М. Мәһдиев, Б. Гыйззәт, Ф. Урманчиев, язучылардан Ф. Хәсни, Р. Фәйзуллин, З. Нури, Х. Сарьян, С. Хәким, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Роберт Әхмәтҗанов, Б. Камалов, Т. Миңнуллин, М. Рафиков һ. б. 1972 елгы тәнкыйть үсешендә билгеле бер эз калдырдылар. Гомумән, 1972 елда язучылар әдәби тәнкыйть эшенә ныграк тартыла төштеләр, аларда әдәбиятның бүгенгесе белән кызыксыну, борчылу көчәйде.

СССР төзелүгә 50 ел тулу бәйрәме, бөтен әдәби процесска тирән эз салган шикелле, әдәби тәнкыйтькә дә билгеле бер йогынты ясады. Бу олы бәйрәм игътибарны табигый рәвештә халыкларның интернациональ дуслыкларын, культура-әдәби бәйләнешләрен яктыртуга, төрле милләтләрнең үзара аралашуларында туган үсеш тенденцияләрен ачыклауга юнәлтте. Ф. Әгъзәмовның «Әдәбиятлар дуслыгы — халыклар дуслыгы» мәкаләсендә («Казан утлары», 12 сан), Г. Бәшировның «Вопросы литературы», Р. Мостафинның «Дружба народов» журналлары редакцияләренең анкеталарына биргән җавапларында шушы уңайдан игътибарга лаек фикерләр әйтелә.

М. Гайнуллин, З. Нури, Б. Камалов, Г. Минский, А. Гыйниятуллиналарның публицистик мәкаләләрендә культура-әдәбият бәйләнешләренең аерым яклары, фактлары яктыртыла. Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәренең Украинада, Ворошиловград өлкәсендә үткәрелүе, ә украин язучыларының Татарстанда кунак булулары татар һәм украин әдәби культура бәйләнешләре турында сүз кузгатуга сәбәпче булды. Кыргыз әдәбияты һәм сәнгате декадасының Татарстанда үткән көннәре чын мәгънәсендә дуслык-туганлык көннәренә әйләнде. Хәзерге хикәя турындагы сөйләшү кыргыз һәм татар язучыларының диалогы рәвешен алды. Әмма, шунысы кызганыч, газеталар да, «Казан утлары» журналы редакциясе дә шундый сөйләшүләрнең төп эчтәлеген укучыларга җиткерә алмадылар, тулы итеп тарихка беркетеп кала алмадылар. Чыңгыз Айтматов, Тендик Әскәров, Александр Жирков һәм татар әдәбиятчылары катнашуында үткән мондый югары дәрәҗәдәге сөйләшүләр атна саен да, ай саен да, хәтта ел саен да булып тормый бит! Фатих Хөснинең «Социалистик Татарстан газетасында (13 сентябрь) шушы сөйләшүгә оеткы салу рәвешендәрәк басылган «Хикәя турында уйлану» исемле мәкаләсе сөйләшүнең шактый кызыклы, җанлы үтәргә тиешлегенә шик уятмый. Авторның хикәягә характерларны үткенәйтеп күрсәтә алырдай тетрәткеч вакыйга сайлау, сюжетның тыгызлыгы, тирәнлеге, әдипнең

кирәклеме артыктан аера белү осталыгы турындагы фикерләре һәр ике әдәбият вәкилләрен уйландыра. Шул ук вакытта мәкаләдә бәхәсләшерлек урыннар да бар һәм, мөгаен, сөйләшүдә авторның кайбер фикерләре, мәсәлән, кайчандыр, әйтик, сугышка кадәрге елларда «күп кенә әдәбиятчылар әдәби әсәрләргә якын килгәндә, бары тик ике генә үлчәүне — озынлык һәм киңлек үлчәвен генә беләләр иде» (ягъни тирәнлек үлчәвен белмиләр иде), яки «хикәя үтә гадәти вакыйгага корыла алмый» дигән фикерләре бәхәс уяткандыр. Әмма, кызганычка каршы, без бәхәснең барышын белми калдык. Ә сөйләшүне тулы итеп бирү хәзерге әдәбият практикасы өчен дә, әдәбият тарихчылары өчен дә кирәк иде.

РСФСР язучылар союзы секретариатының Идел буе әдәбиятларында заман темасына багышлап Казанда үткәрелгән утырышы да тәнкыйтьтәге әлеге матур башлангычны — милли әдәбиятларда аерым тенденцияләрнең үсешен чагыштырма планда анализлауны көчәйтүгә сәбәпче булды. Роберт Бикмөхәммәтовның «Постигая трепет времени» мәкаләсендә («Литературная Россия» газетасы, 14 июль) Идел буе әдәбиятлары прозасы — татар, башкорт, мари, удмурт, мордва прозасы — нәкъ менә шушы планда карала.

Күрәбез, әдәби тәнкыйтьтә әдәбиятларның аралашуына һәм үзара тәэсир-йогынтыларына кагылышлы мәсьәләләр дә күтәрелә икән, бу эштә публицистик уйланулары белән язучылар да катнаша икән. Хәзер безнең алда, КПСС Үзәк Комитеты карарына таянып, шушы юнәлештәге эзләнүләрне тирәнәйтү, шушы юнәлештәге эшчәнлекне тагы да җанландыру, киңәйтү бурычы тора. Бүгенге әдәби процесста булып торган күп төрле аралашуларның кызыклы фактларын һәр төрле юллар белән (мәсәлән, фотога, киногә төшерү, чыгышларын магнитофонга язып алу) җыйнап калу турында да чынлап уйлаганыбыз һәм чаралар күргәнебез юк бит. Бу мәсьәлә буенча җаваплылыкны, бәлки, Татарстан Дәүләт музееның әдәбият филиалына йөкләтергә кирәктер, җаваплылык белән генә чикләнмичә, бәлки, мөмкинлекләр тудыру, бу мәсьәлә белән махсус шөгыльләнүче штат булдыруга кадәр карешергә кирәктер.

Агымдагы тәнкыйтьнең үсеше һәм характеры күп төрле факторларга бәйле. Республикабызның Г. Тукай исемендәге премиясенә һәм комсомолның М. Җәлил исемендәге премиясенә кандидатлар тикшерү уңаеннан басылган мәкаләләрдә, табигый рәвештә, теге яки бу язучының, сәнгатькәрнең уңай сыйфатларын ачу беренче планда тора, һәм нигездә тәнкыйть шул уңай сыйфатларны күрсәтү белән чикләнә дә.

«Казан утлары» журналының 50 еллык юбилее журналның үткәне һәм бүгенгесе турында да язган эчтәлекле мәкаләләрнең күренүенә (мәсәлән, Г. Кашшаф, Г. Ахунов мәкаләләре), Г. Бәширов, Г. Иделлеләрнең кызыклы истәлекләре язылуына сәбәпче булды. Н. Арслановның иҗат бәйрәме шагыйрьнең әдәбияттагы урынын билгеләгән мәкаләнең язылуына (С. Хәким), иҗатына тәпле анализ ясаган мәкаләнең басылуына ярдәм итте (Р. Фәйзуллин мәкаләсе, 9 сан).

1972 елда бәйрәмнәрнең күплеге әдәби тәнкыйтьтә бәйрәм рухлы мәкаләләрнең чагыштырма авырлыгы күп булуын аңлатучы бер сәбәп. Әмма мондый материалларның күплеген бәйрәмнәр белән генә аңлату тулы булмас иде. Гомумән, ул әдәбият-сәнгать тәнкыйтендә шактый ук тамыр җәйгән тенденциягә дә бәйле. Тәнкыйтьнең комплиментар рухы шушы тармагы аеруча музыка, рәсем сәнгате кебек өлкәләрдә ныклы җирлек тапкан. Театр сәнгате бу яктан аерыла, әмма анда да артистларның биографияләрен сөйләү белән мавыгуның, портрет жанрының өстенлек итүен танымыйча булмый. «Казан утлары»ның «Сәнгать» бүлеге нигездә шундый портретлардан тора (Л. Ихсанова, З. Шәһиморатов, Х. Кумысников, Д. Гыймранова, Ә. Гобәйдуллина мәкаләләре). Әлбәттә, андый портретлар артист өчен дә, укучы өчен дә кирәк һәм алар язылышлары белән матур тәэсир дә калдыралар. Әмма сәнгать тәнкыйтенең башка жанрларын һәм башка тармакларын үстерү турында да җитди уйланырга кирәк. Хәзерге театрның торышын яктырткан, андагы актуаль мәсьәләләрне күтәргән тәнкыйть мәкаләләре, сирәк булса да, күренә. Мин, беренче чиратта, Илтани Иляскованың «Казан утлары»нда басылган «Кеше — җирнең бизәге» исемле мәкаләсен күздә тотам. Мәкаләдә Татар дәүләт академия театрының дүрт спектаклена («Әни килде», «Ир егетләр», «Намус хөкеме», «Эңгер-меңгер») һәм бу спектакльләр турында әйтелгән төрле фикерләргә тәпле анализ ясала, шушы спектакльләргә бәйле рәвештә драматург һәм режиссерның осталыгы, театр һәм драматургиянең үсеш тенденцияләре кебек мәсьәләләр дә кузгатыла. Шушын-

дый тәпле фикерле, ышандырырлык һәм таләпчән тәнкыйть мәкаләләрен сәнгать тәнкыйтендә күбрәк күрәсе килә. «Социалистик Татарстан» газетасында театр сезоны ачылу уңае белән театрга багышлап бер тулы бит бирелүен дә хупларга кирәк. Мондый сөйләшүләрне редакция сезон ачылуга гына бәйләмичә, театрның аерым мәсьәләләренә карата һәр даим үткәрә торса һәм сөйләшүнең эчтәлеген тулы итеп укучыга җиткерә барса, ул сәнгать тәнкыйтен үстерергә җитди этәргеч булыр иде. Ә андый кузгатырлык мәсьәләләрнең байтак булуы М. Харисовның «Театр һәм драматург» исемле мәкалә-репортажында да, Х. Кумысников, И. Илялова мәкаләләрендә дә ачык күренеп кала.

Үзәк Комитетның әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы карарын тормышка ашыру юнәлешендә газета-журналларда басылган мәкалә-рецензияләрдә әдәби сыйфат дәрәҗәсенә ныграк игътибар бирелә башлавын әйтергә кирәк. Идея-эстетик таләпчәнлекнең артуына, бәяләү критерийларының югарылыгына һәм анализның профессиональ югарылыкта торуына И. Иляловаың «Үсү авырлыклары», Т. Миңнуллинның «Без театр уйныйбызмы?» («Казан утлары», 5 сан), Р. Фәйзуллинның «Үр артында яңа үрләр бар» («Казан утлары», 6 сан), Р. Мостафинның «Җаваплылык хисе» (шунда ук, 1 сан), «Тема, идея, әдәби осталык» (шунда ук, 9 сан) исемле мәкаләләре мисал була ала. Боларга тагын В. Воздвиженскийның «Зур таләпләр югарылыгыннан» исемле мәкаләсен (шунда ук, 8 сан), Мирсәй Әмирнең Диләрә Зөбәерова прозасы, Х. Сарьянның яшь прозаиклар турындагы («Социалистик Татарстан») рецензияләрен өстәргә була.

Таләпчәнлекнең көчәюен без һичшиксез хуплыйбыз һәм бу тенденциянең мәкаләләрдә дә, басылып чыккан китапларга, куелган спектакльләргә бирелгән рецензияләрдә дә киңрәк урын алуын телибез. Әмма шул ук вакытта эстетик таләпчәнлек һәм хәзерге заманга хас югары эстетик критерийлар лозунгысы астында хәзерге сәнгать-әдәбиятның аерым уңышларын күреп бетермәү дә дөрес булмас иде. Миңа калса, Х. Кумысниковның театр сезоны йомгакларына багышланган «Җаваплылыкны киметмәскә» исемле җитешсезлекләрне шактый дөрес тотып алган мәкаләсендә дә («Социалистик Татарстан») күләгәле яклар белән артык мавыгу сәбәпле, театрның уңышлары күләгәдә калган.

Хәтта Р. Мостафинның аерым мәкаләләрендә дә бәяләүдәге әнә шундый катылык, ясисә билгеләрне бишле-дүртледән өчлегә төшерү очрый шикелле. Ул безнең әдәбиятның алтын фондын тәшкил иткән әсәрләргә Такташ, Җәлил, Туфан, Ә. Фәйзи, Ф. Кәрим, С. Хәким шигырьләрен, Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ын, М. Әмирнең «Агыйдел»ен, Бәшировның «Намус»ын, Ф. Хөснинең «Җәяүле кеше сукмагы»н кертә дә, мондый фикер әйтә: «Кызганычка каршы, соңгы елларда шушы исемлекне тулыландырырлык, һич югы, шулар югарылыгында торырлык әсәрләр язылмады диярлек» (9 сан, 156 бит). Мин үзем әлеге фикер белән килешеп бетмим һәм соңгы елларда да әлеге исемлекне тулыландырырлык әсәрләр язылды дип карыйм.

Р. Мостафинның мондый рухтагы фикерләре, бәлки, мәкаләнең хәзерге проза турындагы сөйләшүгә оетка салу максатында язылуы белән дә бәйледер. Һәрхәлдә, таләпчәнлек әдәби хуҗалыгыбыздагы әсәрләрнең чын эстетик кыйммәтен дөрес бәяләргә ярдәм итәргә тиеш.

Журналыбызның хәзерге татар прозасы турында сөйләшү башлавы да уңай күренеш. Дөрес, дискуссия оештырудагы тәҗрибәнең азлыгы 1972 елдагы мәкаләләрдә дә ачык күзгә ташлана. Р. Сверигин, Ф. Мусин, Ф. Ибраһимоваларның мәкаләләре һәрберсе аерым алганда кызыклы булса да, дискуссия күзлегеннән караганда, сөйләшүнең салкынлыгы, пассивлыгы, бер ноктага юнәлмәгәнлеге нык сизелә. Әмма әле бу дискуссиянең башы гына, бәлки мәҗлес кызып китәр, дип ышанасы килә. Сөйләшүдәге таркаулыкның сәбәбе, күрәсең, сөйләшү темасын артык киң һәм абстракт итеп алу белән дә бәйледер.

Без әдәбият һәм сәнгатьнең тормыш белән бәйләнеше тыгыз булырга тиешлеге турында күп сөйлибез, бу турыда күп язабыз. Әмма конкрет әсәрне, язучы күтәргән проблемаларны тормышның үзе белән чагыштырып тикшерүгә килгәндә үзебез ук бу мәсьәләдән читләшәбез, «проблемасы актуаль», «образлары тормышчан» дигән артык гомуми сүзләр әйтү белән чикләнәбез һәм тикшерүне нигездә әдәбиятның тормыш белән чагыштырылмыйча каралган «саф» кануннары буенча гына алып барабыз. Әлбәттә, тәнкыйтьнең әдәби-эстетик анализга игътибары көчәюе һәм бу өлкәдә билгеле уңышларга ирешүе тәнкыйтьнең гомуми үсеше яктылыгында күзәткән-

дә үзе уңай бер тенденция. Бу тенденция үзе 30—40 еллардагы әдәби тәнкыйтьтә әдәбият һәм чынбарлык мөнәсәбәтләрен үтә гадиләштереп аңлаткан вульгар социологизм карашларына кире реакция буларак туды. Әмма хәзер шушы үсешнең, ягъни әдәби осталык мәсьәләләрен караунын берьяклырак юнәлеш алуын, гомумән социологиядән читләшергә тырышуы, камбала балыгы шикелле бер күзлегә әверелә баруын да күрмичә мөмкин түгел. Камбалага тормыш итәр өчен бер күз дә җитә торгандыр, әмма тәнкыйтькә «бер күзлелек» һич тә килешми. Әдәби осталыкны әдәбиятның саф кануннары белән генә чикләү, тормыш белән бәйләнештә карамау үзе, ахыр чиктә, чикләнгәнлеккә илтә. Шушы чикләнгәнлектән, берьяклылыктан котылу юнәлешендә дә 1972 ел әдәби тәнкыйтендә билгеле бер талпынулар булуын әйтергә кирәк. Тәнкыйтьче Р. Свеpигинның «Заман һәм тормыш таләбе» исемле («Казан утлары», 11 сан), язучы М. Зариповның «Каты токымнар»ны үткәндә» исемле («Социалистик Татарстан») мәкаләләре шушы яктан игътибарны үзләренә җәлеп итәләр.

Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы турында М. Зарипов язган мәкалә әдәби әсәргә һәрьяклап бәя бирү өчен тәнкыйтьченең тормышны да яхшы белергә кирәклеге турындагы билгеле хакыйкатьне тагын бер кат искә төшерә. М. Зариповның нефтьчеләр тормышын һәм Татарстан экономикасын нечкәләп белүе аңа язучының аерым кимчелекләрен күрсәтергә, хәтта нефть тормышы яхшы ук таныш редакторның күзе күреп җиткерә алмаган җитешсезлекләрне күреп алырга һәм аларны хәзерге тормышның аерым тенденцияләре белән бәйләп гомумиләштерүләр ясарга ярдәм иткән. Әлеге мәкалә тәнкыйтьне үстерү мөмкинлекләренә бәйле шундый фикер дә уята: әдәби тәнкыйтьнең резервларын журналистлар арасыннан да эзләргә кирәк икән. Бу фикерне Ф. Әгъзәмовның 1972 елгы әдәби тәнкыйтьтә уңышлы чыгыш ясавы да ныгыта. Әдәби әсәрнең тормыш белән бәйләнеш мәсьәләләрен яктырту, әсәрдә күтәрелгән проблемаларның ни дәрәҗәдә әһәмиятле һәм мөһим икәнлекләрен билгеләү буенча филологик белемгә ия булган журналистлар әдәби тәнкыйтьне үстерүгә зур өлеш кертә алалар.

1972 елгы әдәби тәнкыйтьтә нәшриятта басылган китапларга рецензияләр бирү арта төшүен билгеләү белән бергә, бу өлкәдә Р. Мостафин һәм Н. Фәттах мәкаләләрендә әйтелгән кимчелекләрнең һаман да кабатлана килүенә дә күз йомып булмый. Байтак рецензияләргә анализ тирәнлеге җитми, эчтәлек сөйләү белән мавыгу көчле. Мактауга гына корылган, әсәрнең аерым кимчелекләренә күз йомган рецензияләр дә һаман күренә торалар. Т. Галиуллин һәм Ф. Урманчиевларның «Фронтовиклар» романы турында «Кызыл таң» һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында басылган рецензияләрендә дә, мәсәлән, анализны тик бер дулкынга — мактау дулкынына кору нык сизелә.

Сайлап алып тәкъдим итү принцибы эзлекле тормышка ашырылмый. Күбрәк нинди китаплар рецензияләнә: юкарак китаплар, башлап һәм яшь язучыларның җыентыклары. Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, Ф. Хәсни, И. Гази, Ә. Еники, Р. Ишморат, М. Әмир һ. б. әдипләребезнең томлыкларына тәнкыйть игътибар итмәде. Бу томнарда әдипләрнең байтак әсәрләре беренче тапкыр дөнья күрде. Ә. Фәйзинең, мәсәлән, III томындагы барлык драма әсәрләре беренче тапкыр басылдылар. Тәнкыйть бу турыда үз сүзен әйтергә тиеш иде. Нәшрият шагыйрь китапханәсе сериясеннән дистәгә якын китап чыгарды. Болар шулай ук тәнкыйть сүзе ишетмәделәр. Саный китсәң, мондый китаплар гаять күп. Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги» исемле китабы бөтен союз матбугатында югары бәя алды. Аның турында «Вопросы литературы», «Советская тюркология», «В мире книг» кебек журналлар язып чыктылар. Ә менә республика матбугаты бу яктан саранлык күрсәтте. «Казан утлары» журналы, мәсәлән, бу китап турында 1971 елда да, 1972 елда да рецензия бастырмады. Кыскасы, библиография хуҗалыгында да тәртипне чын-чынлап урнаштырасы бар әле.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы тарихи карарын республика җәмәгатьчелеге, язучылар һәм тәнкыйтьчеләр зур җитдилек, җаваплылык белән хуплап каршы алдылар һәм нәтиҗәле эш белән җавап бирделәр. Үзәк Комитет карарының шифалы йогынтысын бер еллык тәнкыйтьне күзәтүдә дә күрмичә мөмкин түгел. Әдәби тәнкыйтьне үстерү өчен шактый уңайлы һәм эшлекле атмосфера туып килә. Әмма без әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләнгән эшләрнең шушы юнәлештә беренче адымнар гына икәнлегенә яхшы төшенәбез.

## Фарваз Миңнуллин

# ХИКӘЯГӘ БЕР КАРАШ

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

Менә бер ел инде «Казан утлары» журналы битләрендә бүгенге татар прозасының үсеш юллары турында сөйләшү бара. Бәхәс барышында күп кенә мәсьәләләр ачыкланды, проза әдәбиятының гомуми хәленә караган кызыклы фикерләр әйтелде. Фикер алышуда катнашучылар игътибарыннан хикәя жанры гына нигәдер һаман читтә кала килә.

Хәлбуки, болай булмаска тиеш иде кебек. Хикәя жанры, бу жанрның үсеш юллары һәм язмышы безнең җәмәгатьчелекне күптәннән борчып килде, бүген дә нык борчып тора. Моннан 4—5 еллар элек «Казан утлары» журналында М. Әмир белән Ф. Хөснинең хикәя жанры, аның киләчәге өчен борчылып язган мәкаләләрен укыган идек. Аннан соң да, язучыларның гомуми җыелышларында булсын, проза секциясе утырышларында булсын, хикәя мәсьәләсе гел кузгатыла торды. Узган җәй, Казанга кыргыз язучылары килгәч, тагын җыелышып сөйләштек. Соңгы сөйләшү вакытында күп мәсьәләләр кузгатылды, кызыклы гына фикерләр әйтелде. Тагын шул нәрсә ачыкланды: хикәя жанрының торышы, үсеш үзенчәлекләре төрле әдәбиятларда төрлечәрәк икән. Кыргыз язучылары, мәсәлән, үз әдәбиятларында хикәя жанрының активлашып китүен 50 еллар азагында илебез тормышында булып узган үзгәрешләр белән бәйләп аңлаттылар.

Партиябезнең XX съездыннан соң урнашкан иҗади атмосфера татар әдәбиятының үсешенә дә зур йогынты ясады. Моны әдәбиятның һәр өлкәсендә күрергә була. Бездә зур мәсьәләләргә багышланган, зур иҗтимагый конфликтларга корылган кызыклы романнар барлыкка килде. Чорның актуаль мәсьәләләрен күтәргән повестьлар активлашып алды. Татар поэзиясенең бөтен яңгырашы, пафосы яңарды. Шигырь мәйданына сәләтле яшь шагыйрьләрнең бөтен бер плеядасы килде. Шул елларда алган темпны, шул елларда башланган сыйфат яңарышын поэзия бүген дә саклап килә шикелле. Драматургия булып драматургия җанлана төште. Бүгенге драматургиянең төп көчләре нигездә шул елларда формалашты.

Заман җилләре, нигәдер, тик бер жанрны — хикәя жанрын гына читләтеп уздылар. Бер хикәячеләребез генә заман, чор адымына иярә алмадылар. Дөрес, әйбәт хикәяләр ул елларда да чыккалап торды. Мисал төсендә М. Шабай һәм Р. Төхфәтуллин хикәяләрен китереп булыр иде. И. Гази, Ф. Хөсни, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Г. Минский, Г. Галиев кебек хикәячеләребез дә тик утырмады. Урта буын дип йөрткән прозаикларның да матур-матур хикәяләре күренгәләп торды. Әмма хикәя өлкәсендә, башка жанрлардагы кебек, кискен яңарыш, сыйфат сикереше сизелмәде. Хикәя бер урындарак таптанды, бер югарылыктарак кала бирде. Заман рухы, чор сулышы хикәяләргә караганда повестьларда тулырак чагылды. Шул ук хәл бүген дә дәвам итә.

Без татар прозасы йөз белән заман темасына борылды, дибез. Бүгенге әдәбият-

ның иң көчле сыйфаты — әнә шул, дибез. Хикәя бу җөмләгә керми, хикәя һаман арттә кала килә. Хикәячеләребез бүген дә чорның актуаль проблемаларыннан, көннең үзәк мәсьәләләреннән читтәрәк торалар. Мисалга әдәбиятыбызның барлык тармакларында ныклы урын ала барган КамАЗ темасын гына күздән кичерик. КамАЗга багышланган очерклар хакында сөйләп тә тормыйбыз. Алар бик күп. Һәм бу кадәресе аңлашылсын да ди. Шигырьләр нихәтле, поэма хәтле поэмабыз бар. Повестьлар, пьесалар, романнар язылды. Ә хикәя чыкканын хәтерләмим, юк хикәя...

Билгеле, бер КамАЗ темасына карап кына хикәя турында соңгы нәтиҗә ясау дөрес булмас иде. Гаделлек өчен әйтергә кирәк: чор, заман сулышы күпмедер дәрәҗәдә бүгенге хикәяләрдә дә чагыла, әлбәттә. Бу яктан мәрхүм Г. Мөхәммәтшин хикәяләрен мактап телгә алырга булыр иде. Ф. Хөсни һәм кайбер башка прозаикларыбыз да заманча хикәяләр язып торалар. Шулай да бу мәсьәләдә иң нык аерылып торган кеше Марсель Зарипов дияр идем мин. Аның «Вакытсыз туй», «Җәйге командировкада», «Су буенда» кебек хикәяләрен искә төшерегез. Заман сулышын чагылдыру ягыннан бигрәк тә «Җәйге командировкада» дип исемләнгәне игътибарга лаек.

...Авыл хуҗалыгы министрлыгының өлкән агрономы Әгъзәмов менә тагын «Кызыл шәрык» совхозына бара. Бу хуҗалык республиканың иң читенә урнашкан. Барыр юл ерак, сикәлтәле. Шулай да Әгъзәмовның күңелендә әйтеп бетергесез күтәренкелек. Ниһаять, ул теге кире беткән Доргуновага кемнең хаклы булганын, кемнең ялгышканын исбат итәчәк.

Доргунова дигәннәре ул бара торган совхозның баш агрономы була. Ә бит алар кайчандыр дуслар иде. Моннан бер ел элек сүзгә килештеләр.

Барлык пар җирләре урынына борчак чәчәргә кирәк, министрлыктан шулай кушалар, диде Әгъзәмов. Доргунова каршы килде. Моңа бик ачуы килгән Әгъзәмов шул ук көнне «Кызыл шәрык»ка үзе килеп җитте. Син шуны аңларга тиеш,— дип җикеренде ул совхоз агрономына,— боерык бирелгән икән, аны үтәргә кирәк! Хәзер югарыдан төшерелгән боерыкларны уйламый-нитми үтәп торучылар юк, сездән зуррак авторитетларның сүзен дә тота-каба гына үтәмиләр, диде Доргунова.

Ул чагында «Кызыл шәрык»тән Әгъзәмовның кәефе нык кырылып кайткан иде. Кайту белән бик тә ачулы итеп, тозлы-борычлы приказ чыгартты. Анда «Кызыл шәрык» совхозының баш агрономы Доргуновага соңгы кисәтү белән каты шелтә бирергә, диелгән иде. Менә шул хәлләрдән соң бер ел үтеп тә китте. Һәм хәзер Әгъзәмов былтыргы командировкасының нәтиҗәсен күрергә дип бара.

Сап-сары арыш келтәсен тезенә салып утырган килеш, ул Доргунова белән ике арада буяган бәхәсне сүзгә-сүз искә төшерде. Ә күңелендә аның торган саен шатлык, тантана хисе тулып ташыды: менә бит, ул хаклы булып чыкты!

Шундый уйлар белән ул Доргуновалар яшәгән таныш йорт каршына килеп туктады. Яшьләрчә җитез генә машинадан чыкты һәм капканы этеп ачты да... туктапып калды. Болдырда аңа һич таныш булмаган тәбәнәк буйлы, какча гәүдәле бер карчык басып тора, аның киң күлмәк итәгенә чатан аяклы, таза гына штансыз малай ябышкан иде...

— Ул икенче фатирга күчеп китте. Әнә теге очта фатиры, тегермән артында, беләсеңдер бит тегермәнне? — дип, карчык поселокның аргы башына таба күрсәтте.— Үзеннән өстен булган бер зур начальник белән бәхәскә кергән имеш тә, тегесе «аны җиргә якын җибәрмәскә!» дип әмер чыгарган икән, диделәр. Шуннан соң ул тотты да кооперативка күчте.

Бер мәлгә Әгъзәмов югалып калгандай булды: Доргунова хәзер агроном түгел... Кооперативта эшли... Нәрсә булган аңа? Туры сүзле, үҗәт холыклы хатынны директор урыныннан алган икән. Янәсе, министрлык кешеләре белән тынышып эшли алмый. Имештер, һәркем үзе теләгән якка тарта башласа, эш алга бармаячак... Әгъзәмов хәзер инде кычкыруның да, өстәл сугуның да файдасыз икәнен, берни бирмәячәген аңлады. Ярый, Доргунованы эшкә кире кайтарып та булсын ди, ләкин булган хәлне кеше хәтереннән сызып ташларга мөмкинме соң?

Ул директор белән саубуллашып та тормыйча, машинасына ашыкты. Әнә ул, арткы урындыкта тирбәлеп утырган хәлдә, әле моннан ике сәгать элек кенә үзе карап узган арыш басуларыннан күзен ала алмыйча уйланып бара. Ләкин теге вакытта аның күңелен биләгән тантаналы шатлыкның хәзер әсәре дә калмаган иде. Кем өстеннән тантана итәргә тиеш соң ул? Доргунова өстеннәнме? Ә нигә ул, ягъни

Әгъзәмов, тантана итәргә тиеш? Эш урыны югарырак булган өчен генәме? Минем әйтүем булды — аларның минемчә эшләүләре булды, дипме? Ләкин тантана итәрлек сәбәп бар микән соң әле монда? Менә бу авыр башаклар, басуда игеннәрнең күкрәп утыруы бәлки елның уңай килүеннән генәдер, яңгырлы булуыннандыр? Ә аның, Әгъзәмовның, моңа бәлки бернинди дә катнашы юктыр? Җирдә, иген басуында бер ел әле бернәрсә дә хәл итми, киләсе кәздә, аның соңгысында ни буласын белгән юк бит әле... Ә Доргунова акыллы хатын, кооперативта эшләп булса да, үз совхозында калган, киләсе елны көтәсе, экспериментның ни белән бетәсен үз күзе белән күрәсе килгән аның. Ә киләсе көзнең ниндирәк булачагын кем әйтә алыр икән? Әгъзәмовмы?..

Хикәянең кыскача эчтәлеге әнә шундый. Һәм мин ышанам: шушы кыскача конспекты буенча гына да укучы аның никадәр заманча хикәя булуын сизми калмагандыр. Әйе, бу хикәядә бүгенге көнгә генә хас мәсьәләләр кузгатыла, безнең заманга гына хас конфликтлар күтәрелә. Монда без заманча уйлый белә торган кыю кешеләр белән очрашабыз. Мин соңгы елларда заман, чор сулышын бирү ягыннан «Җәйге командировкада» белән янәшә куярлык тагын бер хикәя чыкканын хәтерләмим. Безнең әдәбият өчен бу гына бик аз. Безне заман темасына караган бер-ике хикәя генә канәгатьләндерә алмый. Хикәячеләребез күбрәк үткән заманнар турында язарга яраталар. Соңгы 3—4 ел эчендә газета-журналларда басылган һәм аерым җыентык булып чыккан хикәяләр исемлегенә күз салсагыз, күрерсез: иң зур күпчелекне үткән заманнарга караган хикәяләр тәшкил итә. Коры сүз булып калмасын өчен кайберләрен санап узам: Р. Зыятдинов. Бер телем икмәк; С. Сабиров. Хәтәр сәфәр; И. Нуруллин. Хәсрәт бакчасы; Ә. Шәмин. Алтын медальон; Р. Төхфәтуллин. Җиләкле аланнар; Җ. Мостафин. Күк толпар; М. Хәсәнов. Дулкыннар ярга тәгәри; В. Нуруллин. Ул яшәргә тиеш иде; Т. Миңнуллин. Кульъяулык; И. Гази. Беренче сыналу; М. Юныс. Энҗе эзләүчеләр; М. Рафиков. Йомышчы Әбүбәкер; Х. Сарьян. Финал; К. Латыйпов. Көзге көннәрдә; һәм башкалар, һәм башкалар... Нинди илләр, кайсы заманнар турында гына сөйләнми бу хикәяләрдә!.. Мин аларның һәммәсе дә начар хикәяләр диярgә җыенмыйм. Һич юк. Арада бик матурлары, бик кирәкле һәм файдалылары бар. В. Нуруллинның «Ул яшәргә тиеш иде» һәм М. Юныcның «Энҗе эзләүчеләр» дигән хикәяләрен үз вакытында һәркем мактап телгә алды. Җ. Мостафинның «Күк толпар»ы да зур эмоциональ тәэсир көченә ия булган бик сочный һәм романтик рухлы хикәя. Мин боларга каршы түгел. Мондыйлары була бирсен. Мине башка нәрсә борчый. Әгәр 50 елларда туган егетләр гражданнар сугышы вакыйгалары турында яза башласалар, Татарстаннан ары дөньяның бер генә почмагын да күрмәгән кешеләр чит илләр турында язарга тотынсалар — бүгенге көн, бүгенге тормыш турында кем язар икән?!. Менә өр-яңа бер мисал: «Казан утлары» журналының узган елгы 10 санында Ә. Гафаров дигән егетнең ике хикәясе басылды. «Әҗәт» дигәнен укыгач: «Кара моны!» дип сокланып та куйган идем. Шуннан соң ук «Соңгы сүз» дигән тагын бер хикәясе килә. Бусы Бөек Ватан сугышы елларындагы әсирләр тормышыннан алып язылган. Хикәянең үзеннән чыгып фикер йөрткәндә, автор әсирләр тормышын ишетмеш буенча гына белгәнгә охшый. Ә шулай да алынган. Ни хикмәттер, без үзебез кичермәгәнне язарга яратабыз. Күбрәк шундый темаларга алынабыз. Шуңа хикәяләребез ышандырмый, шуңа күрә язганнарыбыз укучыны битараф калдыра...

Кайчан, кем башлап әйткәндер: хикәяне әдәбиятның иң сугышчан, иң оператив жанры дип йөртәләр. Ләкин соңгы еллар татар әдәбияты мисалында хикәя үзенең иң оператив, иң сугышчан жанр булуын раслый алмады. Киресенчә, мин аны иң артта калып килгән, катып калган жанр, дияр идем. Тематикасы буенча гына түгел, әдәби сурәтләү чаралары, сюжет-композиция төзелеше ягыннан чыгып караганда да. М. Әмирнең «Балыкчы ялганнары»нда үтә искечә киенеп йөри торган бер карт бар. Менә ул: «...площадкада, тыз-быз үтеп йөрүчеләргә игътибар итмичә, күзгә бәрелерлек дәрәҗәдә кызык киенгән өлкән бер кеше басып тора. Башында киң кырыйлы соры эшләпә, киң җилкәле, кулбашлары туры почмаклы итеп тегелгән соры макентошы аяк йөзеннән, арт яктан җиргә тиеп торган киң чалбар балагы астыннан сары шиблетының тупыйк борыны гына күренә...» Кай вакытларда хикәя миңа әнә шундыйрак — заман, тормыш агышына исе китми торган сәер картны хәтерләтә...

Нигә алай, хикмәт нәрсәдә? Бәлки, чын-

нән дә, хикәягә әдәбиятның иң сугышчан, иң оператив жанры дип карау хата фикердер?.. Алай дисәң, кайбер тугандаш әдәбиятлар мисалында ул үзенең иң оператив жанр булуын раслый алды һәм бүген дә раслап тора. Хәер, нигә ерак китеп йөрергә! Үзебезнең татар совет әдәбияты тарихын — егерменче, утызынчы елларны алыйк. К. Нәҗми һәм Ш. Усманов, Г. Толымбай һәм Г. Гали, А. Шамов һәм М. Әмир хикәяләрен искә төшерик. Ул заманның кайнар сулышын әле бүген дә алар язган хикәяләр буенча тоябыз бит. Тик шуннан соң гына хикәя бездә, ничектер, сүрелебрәк, йомылыбрак һәм сыегаебрак калды.

Хикәя жанрының артта калуын төрле кеше төрлечә аңлата. Берәүләр моны прозага яшь авторларның аз килүе белән аңлатырга телиләр. Икенче кешеләр хикәя жанрына игътибар җитми, дип зарланалар. Хикмәт боларда гына түгел шикелле. Прозага яшьләр килеп тора һәм шактый күп килә. Соңгы елларда әдәбият мәйданына килеп, кимендә берәр җыентык чыгарган яшь хикәячеләрнең генә саны да 30—40 кешегә җитә. (Менә алар: М. Рафиков, М. Зарипов, М. Мәһдиев, В. Нуруллин, А. Ганиев, Җ. Мостафин, Л. Хәмидуллин, Д. Зөбәерова, М. Маликова, Р. Батуллин, Ф. Шәфигуллин, М. Юныс, Ф. Яруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Г. Шәрәфетдинов, Ф. Мансуров, Р. Кәрамиев, И. Низамов, Р. Фәизов, Ә. Фазылҗанов, М. Харисов, К. Тимбикова, Х. Гарданов, А. Хәсәнов, Р. Исаев, Л. Шәфикова, В. Монасыйпов, Мәгъсүм Хәбибуллин, Г. Фәрхетдинов, Җ. Рәхимов... 30 кеше санадым. Исемлекне суза төшәргә дә мөмкин.) Күрәсез: хикәячеләр аз килә дип зарланырга урын юк.

Хикәяләр аз языла дип зарлану да дөрес булмас. Ныклап тикшереп карасаң, сан ягы да җитәрлек кебек. Бер «Казан утлары» журналында гына да елына уртача 15—20 хикәя чыгып бара. Шуңа башка журналларда һәм газеталарда басылган хикәяләрне, нәшриятта аерым җыентык булып чыккан хикәяләрне китереп кушыгыз. Елына 80—100 хикәя җыелыр. Бу инде аз түгел. Хикәяләр аз түгел, әйбәт хикәяләр аз. Безнең хикәяләрнең сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, сыйфат ягы түбән. Иң зур бәла — әнә шунда.

Миңа безнең прозаикларның соңгы елларда язылган 200—250 ләп хикәясе белән танышып чыгарга туры килде. Хәзер менә уйлап карыйм, шуларның бик азы гына истә калган. И. Газиның «Табылдык китап» һәм «Сарбай — сары эт» дигән хикәяләре, Ф. Хөснинең «Өзелгән җыр»ы, Ә. Еникинең «Картлар»ы, Г. Мөхәммәтшинның «Ике әби бәрәңге ала» исемле хикәясе, М. Маликованың «Кар сулары», В. Нуруллинның «Ул яшәргә тиеш иде» дигән хикәясе, һәм тагын 3—4 хикәя... Шулар янына 1972 елда дөнья күргән 5—6 хикәяне китереп кушарга була. Узган ел Татарстан китап нәшрияты Ф. Шәфигуллинның «Каен яктысы» исемле яңа китабын чыгарды. Җыентыкка яшь авторның 20 исемдәге хикәясе кергән. Арада төрлесе бар. Уртачалары шактый, ясалмалары, хикәя булып оешып җитмәгәннәре очрый. Шул 20 әсәр арасыннан мин өч шәп хикәя таптым: «Тальян гармун», «Ана», «Кәтелмәгән шатлык». Төрлесе төрле характердагы өч җыйнак хикәя, берсеннән-берсе матуррак өч алтын бөртеге. Х. Сарьянның «Туган як хикәяләре» җыентыгында да матур гына хикәяләр очрый. Шулай да чын сәнгать югарылыгында эшләнгән хикәяләрнең бик аз, бармак белән генә санарлык булуларын тагын бер кат басым ясап әйтми булмый.

Бүгенге татар хикәяләренә хас характерлы кимчелекләр турында бик күп сөйләргә мөмкин. Әйе, Фатих Хөсни дөрес әйтә: бездә кызыклы, гадәттән тыш вакыйгаларга корылган хикәяләр аз. Күбесенчә бик гадәти хәлләр, көн дә кабатлана торган вакыйгалар турында сөйләнә. Шуңа алар үз артларыннан ияртә алмыйлар. Шул ук вакытта без хикмәт монда гына түгел икәнен дә беләбез. Чын художник тормышның беренче карашка бик гадәти якларыннан поэзия табарга, бик гадәти вакыйгаларга нигезләнеп сәнгать әсәре тудырырга, беренче карашка күзгә бәрелеп тормый торган кешеләрнең матурлыгын, олылыгын ачып бирергә тиеш.

Әйе, безнең күп кенә хикәячеләребез коры вакыйга сөйләү, вакыйганың тышкы ягын сөйләү белән мавыгалар. Иң кирәклесе эшләнми кала: вакыйгаларның тозы чыгарылмый кала, эчке мәгънәсе ачылмый кала. Үзе сайлаган вакыйга аша автор нәрсә әйтергә тели? Нинди яңа идея уздырырга тели? Шуны чамалау кыен.

Менә Р. Исаевның «Күрәзәче» исемле хикәясе. Бер ир урамда бөтенләй таныш булмаган хатынны туктата. Сөйләшеп китәләр. Баксаң, бу кеше әлеге хатынның исемен дә, аның ничә яшьтә булуын да, алай гына да түгел, бөтен гөнаһларын, кыекмыек эшләрен дә белә икән... Тәмам ап-

тырый бичара хатын. Мине каян беләсез, әллә сез күрәзәчеме, ди. Юк икән, һич алай түгел икән.

— Без унбиш кенә минут элек бер трамвайда утырып килдек,— ди ир аптыраган хатынга.— Сез саргылт чәчле бер ханым белән дөньягызны онытып сөйләшә идегез. Мин сезнең арттагы утыргычта утырып тыңлап бардым. Менә шул. Әле хәтердә калганнарын гына әйттем.

Үзенең бу хикәясе белән автор нәрсә әйтергә тели? Ни өчен, нинди максат белән язылган ул? Трамвайда барганда эч серләрегезне кычкырып сөйләшмәгез дипме?.. Шуның өчен генә хикәя хәтле хикәя язып торырга кирәк идеме икән?!.

Безнең хикәяләребездә бик әйбәт геройлар күп. Алар матур-матур эшләр башкаралар. Ләкин аларның характерлары ачылмый кала, эш-хәрәкәтләре, кылган гамәлләре мотивлаштырылмый кала. Узган ел китап нәшрияты К. Латыйповның «Мизгел» дигән хикәяләр җыентыгын чыгарды. Ниндиләре генә юк, нинди тормыштан гына алып язылганнары юк алар арасында!.. Ләкин күбесенә мотивлаштыру, дәлилләү җитми. Сәер, бик сәер хикәяләр. Хәзергә мин ул хикәяләр турында шуннан башка бер фикер дә әйтә алмыйм...

Безнең күп кенә хикәяләрдә автор үзе юк. Аның тормышка, кешеләргә, үзе яза торган хәлләргә мөнәсәбәте күренми. Бусы бигрәк тә балалар өчен язылган хикәяләргә хас күренеш.

Бүгенге хикәяләргә хас кимчелекләрне тагын да санап булыр иде. Үз фикерләремне дәлилләү өчен, мин бик күп мисаллар китерә алыр, бик күп хикәяләргә анализ ясап күрсәтә алыр идем. Бусы — әллә ни кыен эш түгел. Иң кыены шунда: ул кимчелекләр кайчан башланган? Аларның үсеш тенденциясе нинди? Кимүгә, бетүгә йөз тоталармы алар? Әллә, киресенчә, торган саен күбәя, арта гына баралармы?.. Татар хикәясенең үсеш юлы нинди? Яхшыруга таба барамы ул? Әллә начарланганнан-начарлана гына торамы? Иң кыены — әнә шул сорауларга җавап табу...

Моңа кадәр без хикәя жанрына бер яклырак карап килдек. Гомуми шаукымга ияреп, ул — әдәбиятның иң оператив, иң сугышчан жанры, дип килдек. Кулына каләм алган һәр яшь автор иҗат эшен, әлбәттә, хикәя язудан башларга тиеш, дип уйладык. Инде килеп, безгә тагын бер хакыйкатьне аңларга вакыт: хикәя — әдәбиятның иң кыен, иң авыр жанры. Хикәя жанрына әдәбиятыбызның иң талантлы көчләре алынырга тиеш. Шунсыз әйбәт хикәяләр артмаячак, шунсыз хикәя жанры алга китмәячәк!

♦♦♦♦♦♦♦♦♦♦♦♦

# ТАРИХЫБЫЗНЫҢ МӨҺИМ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Соңгы елларда республикабыз тарихчылары безне кызыклы яңа хезмәтләр белән шатландырдылар. Мин, беренче чиратта, С. Алишевның татар-башкортларның, шулай ук Идел һәм Урал буенда яшәгән башка халыкларның Е. И. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар кузгалышында катнашуларын өйрәнүгә багышланган монографиясен, Н. Мәҗитованың Казан университетының шәрык бүлеге һәм шәрык халыкларының тарихын өйрәнүдә А. М. Казембекның роле турындагы һәм С. Михайлованың XIX йөзнең беренче яртысында татарлар арасындагы мәгърифәтчелек хәрәкәте турындагы тикшеренүләрен күздә тотам. Шулар янына, үзе тарихчы булмаса да, Ә. Кәримуллинның бездәге китап тарихы буенча монографиясен өстәргә мөмкин. Бу хезмәтләргә күп кенә уртак сыйфатлар хас. Аларның һәркайсы мөстәкыйль фикерле, иҗади планда язылган булуы белән игътибарны җәлеп итә. Барысында да татар халкының тарихына, шулай ук Россиядәге азатлык хәрәкәте тарихына караган мөһим мәсьәләләр күтәрелә. Кыскасы, һәр монография авторы узган тарихны өйрәнүгә җитди һәм лаеклы фәнни өлеш кертә.

Һәм менә безнең алда шундый ук тагын бер хезмәт — Миркасыйм Госмановның «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары»[1] дигән китабы. Бу темага караган фәнни хезмәтләрнең бездә күптән, бик күптән күренгәне юк иде. (Дөрес, Г. Рәхимнең егерменче еллар азагында төгәлләгән кечерәк бер хезмәте бар. Ләкин ул да басылмаган килеш, кулъязма хәлендә генә калган.) Теманың кыенлыгы тагын шунда, гарәп шрифтында язылган, өстәвенә фарсы һәм гарәп сүзләре белән кирәгеннән артык чуарланган иске татар әдәби телендә иҗат ителгән кулъязма әсәрләрне бүгенге укучыларның күбесе укый алмый. Бу кыенлыкны да җиңәргә булыр иде — ахыр чиктә, иске алфавитны мөстәкыйль рәвештә дә өйрәнергә мөмкин. Ләкин шунда ук башка характердагы өстәмә кыенлыклар алга килеп баса. Мәсәлән, тарихи чыганакларның үзләрен каян табарга?.. Кайчандыр билгеле булган, төрле җирләрдә, төрле кешеләрдә сакланып килгән кулъязма чыганакларның күбесе хәзер төге яки бу сәбәпләр аркасында бөтенләй юкка чыккан... Аларның бик аз өлеше генә анда-монда «яшеренеп» ята.

М. Госманов, илебез архивларында сакланып калган кулъязмаларны барлау белән бергә, И. Хәлфин, Н. И. Березин, В. В. Бартольд, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, Г. Рәхим, С. Вахиди кебек галимнәрнең хезмәтләрендә азмы-күпме каралган барлык чыганакларга тәфсилле анализ ясаган; шулар өстенә үз темасы буенча язылган бөтен хезмәтләрне өйрәнеп чыккан. Шуның белән чикләнеп калса да сүз әйтеп булмас иде. Бу кадәресе дә зур эш. Аерым мәсьәләләрне бәяләүдә капма-каршы фикерләр яшәп килә. Чыганакларга анализ ясауда бәхәсле моментлар тулып ята. Шуларга карата үз мөнәсәбәтеңне әйт, үз бәяңне бир, тиешле нәтиҗәләр ясә да канәгатьлән. Һәм бездә шактый еш язылa торган тагын бер гадәти хезмәт барлыкка килгән булыр иде.

Бәхеткә каршы, М. Госманов мондый җиңел юлдан китмәгән. Хәер, китә дә алмас иде. Чөнки ул — чын мәгънәсендәге фән кешесе, галим, тарихчы. Миркасыйм ел саен борынгы кулъязма китаплар җыю

[1] М. А. Усманов. Татарские исторические источники XVII—XVIII вв. Рус телендә. Казан университеты нәшрияты. 1972 ел. Редакторы проф. А. Х. Халиков.

буенча экспедицияләр оештыра. Ул да түгел, аны Мәскәү һәм Ленинград архивларында очратасың. Аның бөтен вакыты фәнни эзләнүләр өстендә уза: ул билгеле булган, табылган чыганакларны анализлый, яңаларын эзләүне һәм табуны оештыра. Әлеге хезмәтен язар өчен, галим XVII—XIX гасырларга караган 200 ләп тарихи кулъязманы өйрәнеп чыккан.

Үз тәҗрибәмнән чыгып әйтә алам: татар халкының тарихын яктыртырга алынган кеше туктаусыз эзләнергә, көн-төн казынырга тиеш. Хәтта XIX йөзнең ахырына XX йөзнең башына караган материал һәм документларның да күбесе югалган, фактлар онытылган. Шуңа күрә өстә яткан, күптән билгеле мәгълүматлар белән һич кенә дә чикләнергә ярамый. Архив киштәләрен актарырга, үз вакытында хаким сыйныф интересларын яклаган рәсми властьлар тарафыннан эзәрлекләнгән, фәнни әйләнешкә кертә алмаган кулъязмаларны табарга, аларның авторларын ачыкларга кирәк. Бу — әле XIX—XX йөзләрне өйрәнүче тарихчыга карый. Димәк, XVII һәм XVIII йөзләрне өйрәнүчеләр турында сөйләп тә торасы юк.

М. Госманов үз китабында Идел һәм Урал буе халыкларының иҗтимагый фикер тарихына караган фәнни мәсьәләләрнең барысы да эшләнмәгән, тарихи чыганакларның җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуын дөрес билгели. Элекке тарихи әсәрләрне эченә алган кулъязмаларның ничек юкка чыгуларын аңлатуда да ул ышандырырлык дәлилләр китерә.

Марксистик-ленинчыл методологиягә таянып, автор феодализм эпохасының безнең җирлектәге кайбер конкрет үзенчәлекләрен, иске татар җәмгыятенең социаль-экономик структурасындагы хосусиятларны аңлата, аларга характеристика бирә. Царизмның билгеле бер максат белән уздырган политикасы аркасында, XVII—XVIII йөзләрдә местәкыйльлеген югалткан татарларда беръяклы социаль үзгәрешләр башлана: татар дворяннары экономик һәм политик яктан нык көчсезләнәләр, шәһәр культурасы яшәүдән туктый. Шуларның нәтиҗәсе буларак, табигате белән хаким сыйныф язмышына бәйләнгән феодаль тарих фәне дә бетүгә йөз тота. һәм бу нәрсә бер феодализм дәверенә генә дә карамый. М. Госманов үзе өйрәнә торган чорга әнә шундый карашлардан чыгып якын килә. Бу — аның хезмәтенең тиешле югарылыкта эшләнүен тәэмин иткән, күп кенә мәсьәләләргә дөрес җавап табарга булышкан. Моның шулай икәнен конкрет мисалларда күрәбез.

Мәсәлән, XIX йөздә, соңрак та, хәтта безнең көннәрдә дә күп кенә тикшеренүчеләр Мөслими дигән берәүнең «Тәварихы Болгария» исемле язмасын XVI йөздә иҗат ителгән әсәргә исәпләп, анда бәян ителгән хәлләрнең дөреслеген дәгъва итеп йөрделәр. Дөрес, китапта гадел күрсәтелгәнчә, Мөслими хезмәтенә шикләнеп караучы галимнәр, хәтта аны кискен төстә тәнкыйтьләп чыгучылар элек тә булган. Әмма М. Госманов хезмәтенең кыйммәте шунда, ул «Тәварихы Болгария»ның XVIII гасыр ахырыннан да иртәрәк языла алмавын эзлекле һәм нигезле дәлилләр белән исбатлап бирә. Хезмәтнең бу өлеше аеруча кызыклы һәм мавыктыргыч итеп язылган, тарих фәненнән ерак кеше дә китапны кызыксынып укыячак. Шул кадәресе дә ачыклана, Мөслими гадәти ялгыш ясаучы гына түгел, тарихны аңлы рәвештә бозу һәм мистификацияләү эше белән шөгыльләнүче булган икән. Моннан ары татар халкының тарихын юри фальсификацияләүне күздә тоткан кешенең генә Мөслимигә тарихи чыганак буларак мөрәҗәгать итүе мөмкин. Ә инде Мөслими ялганнарына таянып, Идел буе халыкларының тарихы буенча мәгълүм нәтиҗәләр ясап өлгергән кешеләргә исә ул карашларыннан баш тартырга һәм чын мәгънәсендә чыганак булырга лаек әсәрләрне өйрәнү белән шөгыльләнә башларга туры киләчәк. Бүгенге көннән башлап, без тагын бер әсәргә — Таҗетдин Ялчыголның «Тәварихы Болгария»сына да шундый ук мөнәсәбәт булдырырга тиеш булабыз.

М. Госманов хезмәтенең тагын бер мөһим ягы шунда, юл уңаеннан ул кайчандыр «Тәварихы дәваир», «Фәрһәнг-намә» кебек кулъязмалар булган дигән карашларның нигезсез икәнен исбатлый. Автор әлеге «әсәрләр» турындагы ялган хәбәрләрнең ничек барлыкка килүен һәм таралуын дәлилләп аңлата, аларны уйлап чыгарган кешеләрнең берсе шул ук Таҗетдин Ялчыгол булуын ачыклый. Мондый уйдырмаларны кире кагу, фактларны тәнкыйть күзлегеннән карап өйрәнү белән бергә, тарихчыларга табылуы ихтимал булган язма чыганакларны эзләүне көчәйтә төшәргә, эзләнүләрнең географиясен дә киңәйтергә кирәк булачак.

Кадыйр Гали бәкнең «Җәмигъ-ет тәварих» исемле хезмәте тарих фәнендә күп-

тән билгеле иде. Шуңа да карамастан, М. Госманов аны яңача укырга, яңача аңларга алынган. Дөрес, бу эшкә аны кайбер бүгенге галимнәрнең әлеге чыганакның әһәмиятен һәм авторын бозып күрсәтергә омтылулары этәргән. Мәсәлән, А. Х. Маргулан, бигрәк тә Э. А. Масанов әлеге хезмәтнең авторын дәлилсез-нисез мактау, олылау юлына басканнар, К. Җөнесбаев исә чыганакның текстын бозуга кадәр үк барып җиткән. Ул, мәсәлән, «Җәмигъ-ет тәварих»ның текстындагы «төрки теленә... тәрҗемә иттем» дигән гыйбарәне «казакъ теленә... тәрҗемә иттем» дип «төзәткән» һәм, шуннан чыгып, әсәрнең әһәмиятен билгеләүдә нигезсез дәгъва юлына, XVII гасыр авторын идеаллаштыру, димәк, тарихны бозу юлына баскан. Җитмәсә, ул М. Әуезов, Г. Рәхим кебек объектив фикер йөрткән шәхесләрне гаепли. Рецензияләнә торган китапта мондый тенденциозлыклар сүтеп ташлана. Әмма М. Госманов ялгышларны тәнкыйтьләп кенә калмый, ул шулай ук Кадыйр Гали бәкнең кайсы халык вәкиле булуы хакында да бәхәс куертуны бурыч итеп куймый. Аны зуррак, җитдирәк мәсьәләләр кызыксындыра. Мәсәлән, әлеге чыганакны ныклап өйрәнү, узгандагы политик тарихны ачыклауда фактлар бирү белән бергә, себер татарларының килеп чыгышында казакъ компонентының катнашын һәм ролен билгеләүгә һәм бу процессның башлангыч дәверенә караган мәсьәләләрне көн тәртибенә куярга мөмкинлек бирә икән. Автор шулай ук Кадыйр Гали бәк Касим шәһәренә Казаннан китерелгән борынгы тарихи әсәрләрдән файдаланган булырга тиеш дигән игътибарга лаек нәтиҗәгә килә.

Беркемгә дә сер түгел, урта гасырларга караган кульязмалар хакында сүз барганда, аларның тел үзенчәлекләрен билгеләгәндә, бүгенге галимнәребез арасында бер уртак фикер юк. М. Госманов бу мәсьәләдә Әмир Нәҗип фикерен куәтли: XIII—XV йөзләрдә туган язма истәлекләрнең телен «Алтын Урда — Хорәзм төрки теле» дип билгеләү дөресрәк булыр иде һәм бу чор истәлекләр безнең илдәге төрки телле халыкларның күпчелеге өчен уртак мирас дигән караштә тора. (Әлбәттә, XV—XVII йөзләрдә, ягъни татар халкының милли нигезе — народность барлыкка килгәч, мәсьәлә нык үзгәрә.)

Кадыйр Гали бәк әсәрендәге оригиналь бүлекләрнең тарихи-документаль әһәмиятен билгеләү белән бергә, М. Госманов шул ук вакытта аның сыйнфый характердагы әсәр, татарның эре феодалларын рус патшасы белән бердәм, тату яшәргә өндәгән, патшага мәдхия җырлаган тенденциоз әсәр булуын да ача. 1913 елда буржуаз татар милләтчеләре һәм алар арасында Совет властеның булачак явыз дошманы З. Вәлиди Романовлар династиясен бер дә юкка гына күкләргә күтәреп мактамадылар, алар күрә торып тарихи чынлыкны боздылар, имештер, патша сайлаганда татарлар рус феодаллары белән тигез хокукта булдылар дип ялганладылар. Якынлашып килгән пролетариат революциясеннән котлары очкан буржуазия идеологлары татар милләтен царизм белән бердәмлеккә чакырдылар, үзләренең бу явыз ниятләренә халыкның узганын идеаллаштыру юлы белән ирешергә маташтылар.

Узган йөз ахырында фән дөньясына И. Хәлфин ачкан «Дәфтәре Чыңгыз-намә» исемле аноним җыентык турында да М. Госманов кызыклы итеп, мавыгып укырлык итеп яза. Үз вакытында бу әсәрне Х. М. Френ, Н. И. Березин, С. Күкләшев һәм башка бик күп галимнәр өйрәнгән булган. Әлеге «Дәфтәр» М. Госмановның игътибарын кай ягы белән үзенә тарта һәм ул бу әсәр хакында нинди яңа сүз әйтә? Галим чыганакның күп кенә кульязма һәм басма нөсхәләрен җентекләп өйрәнә, төрле басмаларда киткән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны ачыклый, фән дөньясында бу әсәр турында яшәп килгән ялгыш карашларны тәнкыйтьли, аерым нөсхәләрдә тарихка караган кызыклы мәгълүматлар булуын ачыклый. Бу мәсьәләдә аңа Г. Рәхим хезмәте зур ярдәм күрсәтә. Шушылар өчен генә М. Госманов хезмәтен тәкъдир итәргә була. Болардан тыш, ул «Дәфтәре Чыңгыз-намә»нең аерым бүлекләрендә рус елъязмалары белән авазлаш урыннар булуын ача. Күрәсез, «Дәфтәр» авторы безгә килеп җитмәгән ниндидер борынгы хезмәтләр белән таныш булган.

Әсәрдә кыпчакларны монголларга каршы көрәшкә күтәргән Бачманның исеме, шулай ук 1615 елгы күзгалышның башлыгы Җан Гали, 1681—1683 еллардагы күтәрелешнең җитәкчесе Сәет Җәгъфәр телгә алына. Димәк, XVI—XVII йөзләрдәге татар әдәбияты Бачман кебек шәхесне белгән. Ләкин аның шуннан соңгы чорларда исеме нигә онытылган? Бу бик кызыклы хәл. Тарихта хезмәт иясен чит ил басып алучыларына һәм изүче сыйныфларга каршы көрәшкә күтәргән Бачманнар бер генә бул-

маган. Идел һәм Урал буендагы башка халыкларның да үз Бачманнары булмый калмагандыр. Тарихның бу ягы белән революциягә кадәрге галимнәр шөгыльләнмәгәннәр; нидер язганнар икән, анда да өстән-өстән генә һәм рәсми позицияләрдән генә чыгып язганнар. Элгәрге тарих китапларының нәкъ шундый сыйфатларын игътибарга алып, Ф. Энгельс, тарих яңабаштан язылырга тиеш, дигән таләпне куя. Кызганычка каршы, рус булмаган халыкларның абсолютизмга каршы социаль көрәшләре, чит ил басып алучыларына каршы сугышларда катнашулары фәндә тиешенчә яктыртылмаган. Шул рәвешчә, М. Госманов үзенең урта гасырлар тарихына караган тикшеренүендә бүгенге көн өчен дә актуаль мәсьәләләрне бермә-бер арттыра.

Хезмәтнең 3 бүлегендә Болгар шәһәренең язмышы, Болгар дәүләтенең руслар белән мөнәсәбәте, Казан шәһәренең салынуы турында кызыклы мәгълүматлар китерелә; борынгы рус елъязмаларында бозып язылган, шуннан аерым галимнәрнең хезмәтләренә кереп киткән ялгызлык исемнәрнең дөрес язылышын ачыклый. Кадыйр Гали бәк белән чагыштырганда, «Дәфтәре Чыңгыз-нәмә»не язган кешенең чагыштырмача алдынгырак карашлы булуын әйтә, шул ук вакытта аның пессимизмын, идеалларының утопик характерда, үткәнгә төбәлгән булуын да күрсәтә. Башка тарихчылар башлаган сүзне дәвам итеп, М. Госманов Мәскәү патшаларының мөселманнарга карата ике яклы политика алып баруларын өйрәнүнең зарурилыгын, татар феодаллары арасында һәм Мәскәү тарафдарлары һәм оппозициядә торган кешеләр булуын әйтә.

Минем яшьтәге кешеләрнең күбесе «шәҗәрә» сүзенең мәгънәсен сүзлекләргә карап кына белә булыр. Китапның соңгы бишенче бүлеге татар шәҗәрәләренең төрләрен һәм үзенчәлекләрен, аларның эчтәлеген өйрәнүгә багышланган. Моңа кадәр аларның тарихи чыганак буларак махсус өйрәнелгәне юк иде. Хезмәттә үз вакытында Р. Фәхретдинов тарафыннан һәм соңгы елларда авторның үзе тарафыннан җыелган 100 дән артык шәҗәрә тикшерелә.

Шәҗәрә — «нәсел агачы», нәсел-ыру тарихын яктырткан әсәр, кайбер очракларда теге яки бу авылның тарихы турындагы язма. Аларны язуда һәм яшәтүдә киң халык массалары катнашкан. Ул — тарихи чыганакларның ныклап өйрәнүне, фактларны тикшереп-сайлап алуны сорый торган үзенчәлекле, катлаулы төре. «Нәсел агачы»н ныклап өйрәнү тарихның мөһим мәсьәләләрен хәл итәргә булыша. Мәсәлән, Нократ татарларының бер шәҗәрәсен тикшерү аша М. Госманов моны бик матур итеп дәлилли. Шәҗәрәне өйрәнү ярдәмендә галим Нократ ягы татарларның кайчан, ничек килеп урнашуы турында кызыклы фикерләр әйтә, Казанны яулап алганда шул яктагы татарлардан патша хөкүмәтенең ничек файдалануын күрсәтә. Автор теге яки бу халыкның тарихын язганда, аерым төбәкләрнең, этник группа һәм нәселләрнең дә тарихын күздә тотарга кирәк, бу эшне башкарганда исә иң элек шәҗәрәләрдән актив файдалану матур нәтиҗәләргә китерер, ди. Галимнең бу фикерләрен хупламый булмый, билгеле.

Бу хезмәт белән танышу безнең XVII—XVIII йөзләрдәге тарихи чыганаклар хакындагы белемебезне бик нык киңәйтә. Ләкин хезмәтнең әһәмияте моның белән генә чикләнми, анда башка чорларга караган истәлекләр турында да кызыклы күзәтүләр шактый. Китапта тикшерелгән әсәрләрнең барысы да татар язма әдәбияты истәлекләре. Димәк, бу тикшеренү әдәбият тарихчылары өчен дә кулланма ролен үти ала икән. Галимнең социаль атамалар өлкәсендәге эзләнүләре дә (мәсәлән, «чура», «кол» сүзләре) ифрат кызыклы.

Хезмәт татар халкының узганы турындагы тарихи әдәбиятның чагыштырмача бай булырга тиешлеген әйтә, тарихи истәлекләрне ныграк сакларга, борынгы кульъязмаларны эзләү эшенә укучыларны да катнашырга чакыра. Кызганыч, хезмәтнең тиражы гына артык кечкенә.

Мондый китапларның методологик-практик әһәмияте дә бик зур, чөнки алар үткән заманнар турында ничек язарга кирәклекне өйрәтәләр, тарих белән шөгыльләнүче кеше үз эшенә ничек карарга тиешлек турында сөйлиләр.

Китапның соңгы битләренә килеп җиткәч, миңа, дөресен әйткәндә, аңардан аерылуы бик кыен булды, чөнки кызыклы, мавыктыргыч итеп язылган ул.

Җыеп әйткәндә, җитди һәм югары хәзерлекле тарихчы безне якын араларда үзенең тагын шундый яңа хезмәтләре белән шатландырыр дип ышаныч белдереп, сүзне йомгаклыйсы килә.

**Рәфыйк НӘФИКОВ,**
**тарих фәннәре докторы,**
**профессор.**

# ҖӘЙЛӘР ҖИТСӘ

Кулымда Клара Булатованың әр-яңа шигырьләр җыентыгы[1]. Каен яфрагы хәтле генә, җыйнак кына китапчык ул. Тышында — бер кыз рәсеме. Йомшак чәчләр, моңсу күзләр. Кырыслык та бар аңарда. Һәм кемгәдер наз катыш чак кына үпкә дә...

Аяз күкләренең зәңгәрлеге
Күзләремә тулган.
Басу кырларының иркенлеге
Күңелемә сыйган.
Теләгем бер: синдә үтеп гомер,
Бабаларым җире,
Үзең биргән орлык җимеш булып
Үзеңә кайтсын кире.

Китап тышындагы кыз рәсеменә яңа штрихлар өстәлә. Ниләр җырлар ул кыз? Күңелнең төрле чаклары була. Җыентыкның исеме — «Җәйләр җитсә».

Китапның алдагы битләренә үтәм. Менә «Бәхет» дип исемләнгән шигырь:

Әле генә шушы җиргә килеп,
Өн салуга көнгә нәниләр:
— Бәхетле бул!
        Тәүфыйклы бул! — диеп,
Ак биләүгә били әниләр.

Бәхет... Кешеләрнең бәхетле буласы килә. Әкият илендә батыр егетләр бәхетне ай йөзле кыз янсә алтын кош сурәтендә күреп кайталар. Нәрсә соң ул бәхет? Бу хакта Клара Булатованың лирик герое менә нәрсә ди:

Күз алдыма Илне,
        Тыныч көнне,
        Киң Иделне,
Иген үскән җирне
Китерәм мин бәхет дигәндә.

Әйе, моннан да зур бәхетнең булуы мөмкин түгел. Кешеләрнең, бөтен терек-лек ияләренең язмышлары шуңарга бәйләнгән — тынычлык!

Китап битләрен актарган саен, лирик герой якыная, аның рухи дөньясы ныграк ачыла бара.

Клара Булатованың шигырьләре җырлап тора. Хәтта аларга музыка язу да кыендыр. Композитор тудырган көй шагыйрәнең үз тавышы аша биргән мәгънәне бозуы бар. Артыктыр аларга икенче көй...

Шушы яктан, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап,
Өянкеләр елап озата.

Шушы яктан, шушы туфрактан без,
Читтә йөрсәк, шуңа күрәдер,
Чишмә чыңлап, өянкеләр елап,
Таллар җырлап төшкә керәдер.

(«Шушы яктан, шушы туфрактан без».)

Кызлар халкы, Клара Булатова шигырьләрен очраткан саен, газетаданмы-журналданмы, кисеп алып, көндәлек битләренә ябыштырып куярга ярата, бер-берсеннән күчереп ала.

Ябырылып җиргә кар яумагач
Яңа елга кергән көнеңдә,
Әллә карлар, әллә ярлар җитми,
Әллә нәрсә җитми күңелгә...

Кай чакта, шагыйрьнең иҗатына (бигрәк тә яшьләрнең) күзәтү ясаганда: «Мәхәббәтне оста язасың. Ә менә фәлән-фәлән темаларга шигырең юк»,— дигән сүзләр әйтелә. Минемчә, һәр фикернең үз вакыты (хәтта үз кешесе!) бар. Каләм иясенең, өлгереп тә җитмәгән уйларын җыештыргалап, «кирәк» булган өчен генә шундый-шундый темаларга язарга тырышуы — шигырь ясау гына булыр иде.

Кешене мәхәббәт шагыйрь итә, ди. Кем белә, бәлки шулайдыр да. Лакин шагыйрьнең көчен мәхәббәт лирикасында сынарга була! Бу яктан Клара Булатова безгә күптәннән үз кеше. Хатын-кызның яшерен һәм тирән мәхәббәтен, зарларын, йомшак күңелен, романтик ашкынуларын поэтик төгәллек, кыскалык белән әйтеп биргән күп шигырьләренә сокланмый мөмкин түгел.

Чык та кара
        үлән күмгән
Сукмакларының таралганын.
Чынга кара,
        ә мин инде
Күз яшенә саранландым.

(«...Бу кырлар, бу болыннардан».)

[1] К. Булатова, Җәйләр җитсә. Казан, 1972 ел.

Лирик герой сөйгән кешесе белән аралары ерагаюны турыдан-туры әйтми. Үләнгә күмелә барган сукмаклар шул турыда сөйли. «Ә мин инде күз яшенә саранландым» дип сабыр тавыш белән эндәшә ул сөйгәненә. Ләкин: «Чыкка кара»,— дип куя. Җәйләрен исә чык бөртекләренең һәр таңны төшүе мөмкин бит...

Автор табигатьнең һәр күренешендә кеше җаны белән уртаклык таба. Тормыш агышы, гомер узуы уйландыра аны. Җыентыкның соңгы битләренә көзге яфраклар моңсулыгы иңгән.

«Петрау үтте, җәйләр бетте», диләр.
Безнең якта халык сүзендә.
Петраудан соң чәчәк атмый гөлләр.
Сары йөгерә кырлар йөзенә.

Петраудан соң яфрак бәйләмиләр.
Мәтрүшкәләр җыеп кайтмыйлар...
Үләннәрдә хуш ис бетә, диләр...
«Бу тормышның петраулары җитте.
Кыл урталай бүлеп гомерне» —

дип бетерә ул шигырен. Нигә, гаепмени?

Ялгызлыкны ялгыз каенга охшатып җырлау күптәннән килә. Шагыйрә көзге каенның «кул тимәгән» бизәкләрен таба белгән:

Хәсрәтле серен берүзе
Тәлгешкә сөйнәгән ул.

(«...Күгелҗем-соргылт».)

Нечкә җанлы, йомшак күңелле шәхес тормыш ваклыкларын, четреклекләрен авыррак кичерүчән. Клара Булатованың кайбер шигырьләрендә дә үтә тирән кичерешләр сизелә; моң-зарлар вакыт-вакыт артып киткән шикелле тоелып, ялыктыргыч бертөрлелек тудыралар. Җыентыкның кыйммәтен төшерәләр алар... Арада озынгарак сузылган тезмәләр, яшь шагыйрьләрнең өйрәнчек шигырьләре хәтерләткән тәэсирсез юллар да очраштыра:

Җитте инде кырлар, урманнарның
Җәйге ямьгә төренер көннәре.
Иң беренче шомырт яфрак ярды.
Аннан каен, усак, өрәңге.

(«...Җитте инде».)

Хезмәт булган җиргә якты нур тула.
Хезмәт булган җирдә яңа җыр туа.
Хезмәт булган җирдә саф җилләр исә.
Хезмәт булган җирдә саф гөлләр үсә.

(«Ул булган җирдә».)

Клара Булатова каләменә ят булырга тиеш санап китүләр болар. Шундый шигырьләр шагыйрәнең бу өченче җыентыгына әллә ни яңалык өстәмиләр.

Шигырьләр авторы укытучы профессиясенә ия. Үтә катлаулы педагогик тормыш — кеше җаны белән идарә итү турында уйланулар булмаса да, шигырьләргә юмор аша класс һавасы: шаян малайлар, яшьрәк чакта әдәбият белән җенләнеп, юанайгач тарих укытырга тотынган кырыс завучлар, мең төрле сораулары белән «юлларга гөлләр түгеп» беренчеләрнең килеп керүләре — куанычлы күренеш. Шагыйрә хезмәт кешесенә оран салып дан җырламый, заман кешеләренең гади, тыйнак хәрәкәтләренә соклану, ихтирам сизелә аның шигырьләрендә. Бу сыйфатларны үстерәсе иде! — диясе килә китапның соңгы битләрен япканда.

Шигырьләр, җырлар, моңнар... Кайберләрен, яңадан актарып, кат-кат укыйм. Салмак көй, ягымлы тавыш, үзләреннән-үзләре күңелдә кала торган әчкерсез авазлар...

Шигырь китаплары күп бездә. Кеше әйбәт шигырьләр укырга сусый. Кеше, сердәшен эзләп, шагыйрьләрдән шагыйрьләргә бара...

Равия АБДУЛЛИНА,
Казан университеты студенты.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Апрель — жир-анабызның ак юрганын яшелгә алыштыра торган, бөтен тереклек иясәренә көч, яңарыш, үсеш алып килә торган ае.

Апрель — кешелек дөньясына бөек Ленинны бүләк иткән ай. Шуңа күрә дә бу айны илебез халыклары һәм бөтен прогрессив кешелек җәмгыяте күтәп ала.

Ә безнең халкыбызга апрель ае тагын бер яктан бик кадерле: бу айда халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай туган. Инде күп еллардан бирле Татарстан язучылар союзы шагыйрь туган көннәрдә шигырь бәйрәме үткәреп килә. Башка елларда бу бәйрәм нигездә Казан шәһәрендә генә (Тукай һәйкәле янында һәм язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында) үткәрелә торган булса, быел аның географиясе киңәйде, масштабы зурая төште. Иң элек, шагыйрьнең туган көненә багышлап, Казан шәһәрендә «Казан язы» дип аталган әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелде. Казанның иң зур культура сарайларында уздырылган ул кичәләрдә күренекле шагыйрьләребез, драматургларыбыз, прозаикларыбыз һәм республикабызның атаклы җырчылары, сүз осталары әдәбият һәм җыр сөючеләргә бүгенге татар әдәбияты турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, яңа җырларын җырладылар. Барлыгы 12 кичә үткәрелде. Аннары, егерме бишенче апрельдә, үзебезнең әдипләребез һәм Тукай көннәренә кунак булып килгән Мәскәү, Уфа, Пермь, Ворошиловград шагыйрьләре Тукайның туган җиренә — Арча районындагы Тукай-Кырлай авылына — шагыйрьнең музеена, аның якташлары белән очрашырга бардылар. Шул ук көнне Арча педагогия училищесында укучылар белән дә очрашу булды. Егерме алтынчы апрельдә Казанның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры каршына куелган Габдулла Тукай һәйкәле янында зур шигъри митинг үткәрелде. Язучылар союзының партоешма секретаре Габдрахман Минский ачып җибәргән ул митингта Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Ренат Харисов 1973 елгы Тукай премиясе лауреатларын — язучы Гариф Ахунов һәм композитор Әнвәр Бакиров иптәшләрне котлаганнан соң шагыйрьләребез һәм кунаклар үзләренең Тукайга, туган җиребезгә, халыклар дуслыгына багышланган шигырьләрен укыдылар. Аннары шигырь бәйрәме шәһәрнең культура сарайларына, клубларга күчте: шагыйрьләр, группаларга бүленеп, Казан хезмәт ияләренә әдәбиятыбыз турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Шушындый ук шигырь бәйрәмнәре шул ук көннәрдә республикабызның Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама шәһәрләрендә дә уздырылды.

## ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

Татар әдәбиятының офыклары көннән-көн киңәя — әдипләребезнең әсәрләре илебез халыклары телләренә һаман саен күбрәк тәрҗемә ителә бара. Әле соңгы ике-өч ай эчендә генә дә тәрҗемәләребез киштәсенә тагын берничә әсәр өстәлде. Кыргыз теленә тәрҗемә ителеп, Муса Җәлилнең атаклы «Алтынчәч» поэмасы басылып чыкты. Шунысын да искәртеп үтик: герой шагыйребезнең бу поэмасы моннан алда да кыргыз теленә тәрҗемә ителгән һәм басылып чыккан иде инде. Ул чакта әсәр кыргыз шагыйре Т. Шамшиев тәрҗемәсендә басылды. Ә бу юлы ул А. Медетбеков һәм А. Стамовлар тәрҗемәсендә чыкты.

* * *

СССР төзелүгә илле ел тулуга багышлап, Кыргызстан китап нәшрияты «Достук гүл тестеси» («Дуслык букеты») исемле шигъри җыентык бастырып чыгарды. Б. Сарногоев тарафыннан төзелгән бу китапка



РСФСР дагы барлык автономияле республикалар шагыйрьләреннән берничәшәр шагыйрьнең әсәрләре тупланган. Татар шагыйрьләреннән Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Зәки Нури, Нәби Дәүли һәм Ренат Харисов әсәрләре урнаштырылган.

* * *

Балалар язучысы Ләбибә Ихсанованың «Сары Алан малайлары» исемле повесте рус һәм украин телләрендә күп тираж белән басылып чыгып, рус һәм украин укучыларының күңеленә хуш килгән иде инде. Бу




әсәр әле шушы көннәрдә генә Таллин шәһәрендәге «Ээсти раамат» нәшриятында да бастырып чыгарылды. Повестьны эстончага Нелви Кукк тәрҗемә иткән, иллюстрацияләрен рәссам Кэрнумээс Марет эшләгән.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Татарстан язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында әдипләребездән Г. Әпсәләмов, Л. Ихсанова, Р. Харисов, Р. Ишморат, Н. Дәүли һәм яшь шагыйрь Госман Садә республикабыз районнарындагы балалар китапханәләре мөдирләре белән очрашып, аларга бүгенге әдәбиятыбыздагы яңалыклар хакында, үзләренең иҗатлары турында сөйләделәр. Яңа әсәрләрен укыдылар, китапханәчеләрнең күп санлы сорауларына җаваплар бирделәр.

* * *

Язучыларыбыздан Фаил Шәфигуллин, Вакыйф Нуруллин, Татарстанның атказанган артисты Сөләйман Йосыпов, композитор Зиннур Гибадуллин, нәфис сүз остасы Мансур Шигапов һәм яшь җырчы Клара Хәйретдиновалар язгы чәчү көннәрендә Чистай районы авылларында әдәби-музыкаль кичәләр үткәреп кайттылар. Алар культура сарайларында, терлекчеләр йортларында чыгышлар ясап, үзләренең әсәрләрен укыдылар, яраткан җырларын башкардылар. Чистай районы хезмәт иияләре язучыларны һәм артистларны җылы кабул итте.

* * *

Шагыйрьләрдән Мостафа Ногман, Зәет Мәҗитов һәм Татарстан язучылар союзы каршындагы пропаганда бюросы хезмәткәре Мансур Шигапов Казанның «Татсельстрой» эшчеләре торак йортында әдәбият сөючеләр белән очрашып, үзләренең әсәрләрен укыдылар, әдәбиятыбыздагы яңалыклар турында сөйләделәр.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Тәнкыйтьчеләр секциясенең 27 апрельдә үткәрелгән чираттагы утырышында Абрар Кәримуллин һәм Фарваз Миңнуллиннарның иҗаты тикшерелде. А. Кәримуллин иҗаты турындагы докладны филология фәннәре кандидаты Нил Юзиев, Ф. Миңнуллин иҗаты турындагы докладны Рафаэль Мостафин ясады. Болардан тыш, фикер алышуларда язучылардан һәм әдәбият галимнәреннән Азат Әхмәдуллин, Баян Гыйззәт, Ибраһим Нуруллин, Миркасыйм Госманов, Фәрит Хатипов, Кыям Миңлебаев, Зәет Мәҗитов, Риза Ишморат, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиевләр катнашты. Бу иптәшләр барысы да Ф. Миңнуллин һәм А. Кәримуллиннар иҗатына нигездә уңай бәя бирделәр.

* * *

Шул ук секциянең 21 майда уздырылган утырышы филология фәннәре кандидаты Азат Әхмәдуллин иҗатын тикшерүгә багышланды. Тәнкыйтьченең иҗат эшчәнлеге турындагы докладны Баян Гыйззәт ясады. Аннары А. Әхмәдуллин иҗаты турында М. Бакиров, Ф. Хатипов, М. Мәһдиев, Н. Юзиев, Ф. Мусин сөйләделәр һәм барысы да А. Әхмәдуллин иҗатын уңай бәяләделәр.

* * *

Драматурглар секциясенең май аенда үткәрелгән утырышында драматург Туфан Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» исемле яңа пьесасы укып тикшерелде. Ул пьеса буенча фикер алышуларда драматурглар Ш. Зәйни, Х. Вахит, А. Гыйләҗев катнаштылар һәм әсәрне нигездә әйбәт дип таптылар, аны тагын да яхшырта төшү өчен үзләренең киңәшләрен, тәкъдимнәрен әйттеләр.

Т. Миңнуллинның шул ук пьесасы күчмә театрда да укылып, сәхнәгә куярга лаек дип табылды һәм театрның репертуарына кабул ителде.

• • •

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының художество советы утырышларында Диас Вәлиевнең «Бишбалта диванасы», Нурихан Фәттахның «Колгали» исемле яңа пьесалары укып тикшерелде. Аны тикшерүдә драматургларыбыздан А. Гыйләҗев, Т. Миннуллин да катнаштылар.

Һәр ике авторның да әлеге пьесалары художество советы тарафыннан уңай бәя алды һәм сәхнәгә куюы өчен театр репертуарына кабул ителде.

### Г. ГАЛИЕВКӘ 70 ЯШЬ

Шушы елның май аенда өлкән язучыбыз Гариф Галиевкә 70 яшь тулды. Шул уңай белән Татарстан язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы әдипкә түбәндәге котлау сүзләре язылган адрес тапшырдылар:

### ХӨРМӘТЛЕ КАЛӘМДӘШЕБЕЗ ГАРИФ ГАЛИЕВ!

*Синең турыда уйлаганда башы юлдан кайтып кермәгән җаяуле юлчыны күз алдына китерәбез. Үткән юлың озын, бик озын синең. Барыр юлың кебек. Бу юлларда карлы, бураннны көннәрне дә кичергәнсеңдер. Кояшлы аланнарны, сандугачлы урманнарны да үткәнсеңдер. Авылдан авылга, кеше күңеленнән кеше күңеленә шулай юл салтың син.*

*Гомер буе халык арасында — авылдашларың янында булдың син, Гариф дус. Алар иген иккәндә шул хезмәтне мактап хикәяләр, очерклар, пьесалар яздың. Ватан сугышы башлангач, алар белән бергә фронтка киттең. Совет солдатының батырлыгы турында аларның үз яннарында булып яздың.*

*Илебезнең алтын баганалары — ил агаларының балаларын да онытмадың. Аталары хезмәтенең тәмен, ямен сөйләгән матур хикәяләреңне язып куандырдың.*

*Әйе, күп еллар, күп юллар үтелгән. Барган саен иҗат хәзинәң баеган, тулыланган. Син халкыңнан акыл, хикмәт, гыйбрәт өйрәндең. Шуның бәрабәренә аларга үзеңнең матур-матур китапларыңны бирдең.*

*Син әле юлдан арып, бераз ял итеп утырган юлчы хәлендә. Туган җирнең саф һавасы, тәмле суы, дусларыңның җылы күңеле үзеңә яңадан көч-куәт бирер. Син тагын да юлга чыгарсың. Гомереңбуе җыйган хәзинәңне туган халкыңа кайтарып бирү җаен табарсың. Без сиңа шуны телибез, Гариф дус!*

*Житмеш яшь тулган көнең һәм озак еллык иҗат бәйрәмең белән чын күңелдән тәбрик итәбез.*

*Татарстан язучылар союзы, „Казан утлары" журналы редакциясе*

• • •

Совет әдәбияты өлкәсендә күрсәткән хезмәтләре өчен һәм җитмеш яше тулу уңае белән, СССР Верховный Советы Президиумының 22 майда игълан ителгән Указы белән язучы Гариф Закир улы Галиев «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде.

### ҚАЗАГЫСТАНДА — ТАТАР МОҢНАРЫ

Казагыстанда Татарстан сәнгать осталарының һәм яшь артистларның СССР төзелүгә 50 ел тулуга багышланган чыгышлары булды. Алма-Ата шәһәренең В. И. Ленин исемендәге культура сараенда үткән концертларны шәһәрнең 30 меңгә якын хезмәт иясе тыңлады. Шулай ук әч концерт республиканың Караганда өлкәсендә үтте һәм ул бер үк вакытта радио һәм телевидение аша бөтен өлкәгә тапшырылды.

Концертта катнашучы РСФСРның халык артистлары Ф. Насретдинов, В. Шәрипова, ТАССРның халык артисты И. Шакиров, ТАССРның атказанган артистлары А. Арсланов, Э. Җәләлетдинов, халык җырларын башкаручыларның бөтен Россия лауреаты Г. Ильясов, яшьләрдән эстрада артистларының бөтен Союз дипломанты З. Нурмөхәммәтов, Р. Сибгатуллина, Э. Зарипова һәм башка артистлар татар халык җырларын, композиторларыбызның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләрен башкардылар.

### КОНКУРС-СМОТР ЙОМГАГЫ

Х. Ямашев исемендәге мех берләшмәсе белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры арасында социалистик договор бар иде. Мех берләшмәсе жюрие академия театрының иң яхшы спектакльләренә смотр-конкурска йомгак ясады. Замандашларыбыз — хезмәт кешеләре турындагы иң яхшы спектакль конкурсында беренче урынны алган «Чит кеше» (И. Дворецкий әсәре) спектакле Почет грамотасы белән бүләкләнде. Бу спектакльне режиссер М. Сәлимҗанов сәхнәләштергән. Х. Вахитның «Мәхәббәтең чын булса...» спектаклендә хатын-кыз ролен иң яхшы башкарган өчен ТАССРның атказанган артисткасы, Тукай премиясе лауреаты Н. Гараева, «Чит кеше» спектаклендә ирләр ролен иң яхшы башкарганы өчен ТАССРның атказанган артисты, Тукай премиясе лауреаты Р. Таҗетдинов Почет грамотасы һәм кыйммәтле бүләкләр белән бүләкләнделәр.

### ЯҢА СПЕКТАКЛЬ

Арча районы, «8 март» колхозының Түбән Аты авылы культура йортында Республика дәүләт күчмә театры артистлары Аяз Гыйләҗевнең «Сии дөньяда берәү генә!» дигән өч пәрдәлек драмасын күрсәттеләр.

Авыл халкы бу яңа спектакльне яратып карады.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Азнакайда Әлмәт бүлеге язучыларының күчмә утырышы булды. Азнакай әдәбият берләшмәсе члennары катнашында үткәрелгән бу җыелышта яшь язучы Хәрәви Басыйровның «Чоңгыл» исемле повесте тикшерелде. Нефтьчеләр тормышын сурәтләүгә багышланган бу әсәргә язучылардан Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Г. Афзал, Ю. Әминов, М. Хәсәнов һәрьяклап анализ ясадылар, авторга файдалы киңәшләрен әйттеләр.

* * *

Драматург С. Кальметов һәм рус шагыйре И. Винокуров Бөгелмә әдәбият-иҗат түгәрәге утырышында катнаштылар. Алар яшь авторлардан Михаил Киреев, Анатолий Блинов шигырьләрен, Фатыйма Бикчәнтәева, Валерий Хромов хикәяләрен тикшереп, яшь авторларның уңышлы һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр.

* * *

Шушы елның 26 апрелендә Әлмәтнең «Татарстан» кинотеатры каршындагы Тукай һәйкәле янында шәһәр хезмәт ияләре, укучылар, укытучылар һәм Әлмәт бүлеге язучылары катнашында шигырь бәйрәменә багышланган митинг булды. Тукай һәйкәленә чәчәкләр куелды. Шул ук көнне кич М. Горький исемендәге клубта зур әдәбимузыкаль кичә үткәрелде. Татар поэзиясендә Тукай традицияләре турында Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов сөйләде. Шагыйрьләрдән Г. Афзал, С. Сөләйманова, Э. Мөэминова, К. Булатова һәм яшь шагыйрь И. Әхсәнов үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

## ДЕПУТАТ ИТЕП САЙЛАНДЫЛАР

Шушы елның 17 июнендә җирле Советларга үткәрелгән сайлауларда әдипләребездән Татарстанның атказанган культура работнигы Ләбибә Ихсанова Казан шәһәр Советына, шагыйрь Әдип Маликов Әлмәт шәһәр Советына, РСФСРның атказанган культура работнигы Гариф Ахунов Бауман районы Советына депутат итеп сайландылар.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

1973 ел узып бара. Редколлегия һәм редакция хезмәткәрләре алдагы ел саннары турында уйлана башладылар. Яңа ел саннарында да язучыларның әле генә нокта куелган роман һәм повестьлары, хикәя, поэма, шигырь һәм пьесалары биреп барылачак. Болардан тыш сезгә таныш булган рубрикаларда очерклар, истәлекләр һәм очрашулар, әдәби тәнкыйть, сәнгать, язучының көндәлек дәфтәреннән, культурабыз тарихыннан, китап күзәтү һ. б. күп кенә кызыклы материаллар урнаштырылачак.

1974 елда республикабызның революцион тарихына, бүгенге көн уңышларына — нефтьчеләргә, химикларга, Кама автомобиль заводын салучыларга күп урын бирелер.

Ел башыннан әдәби тел мәсьәләләренә багышланган зур сөйләшү башланып китәчәк.

Язучылар, тәнкыйтьчеләр, галимнәр, журналистлар 1974 елда басып чыгару өчен редакциягә кульязмаларын китерә дә башладылар инде. Килгән әсәрләрдән Әхсән Баяновның «Тау ягы повесте» сугыш елларында ятим үскән бер егетнең туган җирләрен сагынып кайтуы, әнкәсенең фаҗигале язмышын сорашып белүе турында сөйли. Кешеләрнең туган җиргә, авылдашларына мөнәсәбәте турындагы фәлсәфи әсәр. Бу көнгә кадәр гел шигырьләр язып килгән Хисам Камалов үзенең беренче прозаик әсәрен китерде. Ватан сугышының фаҗигале дә, героик та көннәрен сурәтләгән бу әсәр «Кеше гомере» дип атала һәм аның бөеклегенә дан җырлый.

Газета, журнал битләрендә юридик темага очерклар белән күренеп килгән Мәгъсүм Насыйбуллин «Телсез шаһитлар» дигән повесть язды. Бу — суд органнарында эшләүчеләрнең кеше тормышы, аның куркынычсызлыгы өчен көрәшүләре турындагы әсәр. Вакыйф Нуруллин сугыштан соңгы колхоз тормышыннан «Әгәр син булмасаң» дигән яңа әсәрен тәмамлады. Миргазиян Юныс «Һаваларда торна тавышы» дигән повестен китерде.

Гомәр Бәширов «Җидегән чишмә» дигән зур романын төгәлләү алдында тора. Табигатьне саклау мотивларына корылган бу әсәрне дә без алдагы ел саннарында укучыларга тәкъдим итәрбез дип өметләнәбез. Фатих Хөсни дә «Алтын эзләүчеләр» дигән сатирик повестен төгәлләп, редакция өстәленә китереп куйды.

Роман-повестьлардан тыш редакция Габдрахман Әпсәләмовның үзенең иҗат тәҗрибәсен уртаклашкан «Кояш тотылганда табылган хәзинә» исемле язмаларын, Саҗидә Сөләймановaның «Әссәләми, Суфият!» исемле сәяхәт язмаларын, Әхмәт Фәйзи, Әнвәр Давыдовларның әдәби мирасларын бастыруны планлаштыра.

Театр сәнгатен сөючеләргә Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» һәм Диас Вәлиевнең «Намус хөкеме» дигән сәхнә әсәрләрен тәкъдим итәчәкбез.

Хөрмәтле укучылар! Сез инде журналга язылу тәртипләрен беләсез. «Казан утлары» журналына Советлар Союзының барлык почта бүлекләрендә язылып була. Эшне җиңеләйтү өчен язылган вакытта журналның 73210 номерлы индексын әйтергә онытмагыз.

**Журналга язылу бәясе бер елга 6 сум, 6 айга 3 сум була.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал